ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

8.2006





*Петербургта Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды.*
*Июнь, 2006 ел.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

# 8

(1006)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
: **Факс**—(843) 541-38-77.
: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рашат НИЗАМИ. Шәҗәрәмнең кан тамырын эзләп... *Шигырьләр.* ... 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. *Роман.* ... 10
Харрас ӘЮП. Төрле еллар дәфтәреннән. *Шигырьләр.* ... 56
Илсөяр ИКСАНОВА. Офыкларда – без белмәгән хаклык. *Шигырьләр.* ... 61
Рәфкать КӘРАМИ. Олы юл да сикәлтәле. *Роман.* ... 65
Әдип МАЛИКОВ. Гомер хатларыннан. *Шигырьләр.* ... 104
Әнәс ХӘСӘНОВ. Ефәк пәрәвез. *Хикәя.* ... 107
Сирень ЯКУПОВА. Алма исле август йолдызлары. *Шигырьләр.* ... 112
Рифә РАХМАН. Сөннәтче әби. *Хикәя.* ... 116

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Эльвира ҺАДИЕВА. Яшь хыял сурәте. *Шигырьләр.* ... 115

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. ... 127
Рәфикъ ЮНЫС. Милек һәм ирек. *(Әхмәт Галиев белән әңгәмә).* ... 134

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит ХАТИПОВ. Нахактан аралау юнәлешендә. ... 141
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Тамырлары үзебездә. ... 144

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Ләйсән КӘШФИЕВА. Сагыш һәм моң тулы. ... 149
Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Тормыштан алынганмы, язучы хыялында туганмы? ... 153

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ... 157
Ирек ҺАДИЕВ, Раиф МӘРДАНОВ. Саба төбәгенең эпиграфик истәлекләре. ... 162
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 171
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Тел сагында тора солдат. ... 174

**СӘНГАТЬ**

Рашат НИЗАМИ. Ерактагы йолдыз яктысы. ... 179

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ... 182
Бер сорауга – бер җавап. ... 184
Берлекнең яңа әгъзалары. ... 185
«Казан утлары» архивыннан. ... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Ф. САДРИЕВА «Счастье несчастных» (начало), Р. КАРАМИ «Тернистый путь» (начало); рассказы А. ХАСАНОВА «Шелковая паутина», Р. РАХМАН «На последнем дыхании»; стихи Р. НИЗАМИ, Х. АЮПОВА, И. ИКСАНОВОЙ, А. МАЛИКОВА, С. ЯКУПОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Э. ХАДИЕВОЙ.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (продолжение); интервью Рафика ЮНУСА с Ахмедом ГАЛИЕВЫМ.
«Литературная критика»: Ф. ХАТИПОВ. «Во время сказать верное слово»; С. ХАФИЗОВ. «Имея глубокие корни».
«Книжное обозрение»: рецензии Л. КАШФИЕВА на книгу Н. Гамбарова «Открытое окно...», А. АХМАДУЛЛИНА—на книгу Т. Галиуллина «Саид Сакманов».
«Наука»: статьи И. ХАДИЕВА, Р. МАРДАНОВА «Эпиграфические памятники Сабинского района», Р. ФАЙЗУЛЛИНА «На страже родного языка», Ф. ГАРИПОВОЙ «История наших деревень» (продолжение), А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации».
«Искусство»: статья Р. НИЗАМИ к 100-летию композитора Л. Хамиди.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: панорама Кремля; писатель Н. ГАРИФ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by F. SADRIEV «Happiness of unfortunates» (beginning); R. KARAMI «Thorny path» (beginning); stories by A. HASANOV «Silk Web», R. RAHMAN «With last breath»; verses by R. NIZAMI, H. AYUPOV, I. IKSANOVA, A. MALIKOV, S. YAKUPOVA.
«Creativity of youth»: verses by E. HADIEVA.
«Publicism»: R. HAKIM. «Metamorphoses of spirit» (continuation); interview of Rafick YUNUS with Ahmed GALIEV.
«Literary criticism»: F. HATIPOV. «Tell in time a right word»; S. HAFIZOV. «Having deep roots».
«Book review»: reviews by L. KASHFIEVA on book by N. Gambarov «Open window ...», A. AHMADULLIN one book by T. Galiullin «Said Sakmanov».
«Science»: articles: I. HADIEV, R. MARDANOV «Epigraphic memoirs about Sabinsky area», R. FAIZULLIN «On guard of native language», F. GARIPOVA «History of our villages» (continuation), A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation».
«Art»: article by R. NIZAMI to 100th anniversary of composer L. Hamidi.
Pages from «Tatar encyclopedia».
New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: panorama of Kremlin; writer N. GARIF.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.07.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3-585. Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Рашат
Низами

# ШӘҖӘРӘМНЕҢ КАН ТАМЫРЫН ЭЗЛӘП...

## Азатлыкның төсе

*Тотса Мәскәүләр якаң...*
Габдулла Тукай

*Көрәшчеләр кирәк!..*
Равил Фәйзуллин

I

**Татар рухы, төрки карендәшлек**
**Ишетелә ерак Лозаннан.[1]**
**Гаяз Исхакыйның алкышлары**
**Кошлар булып оча Казаннан!**

**Хәтерләп кал, Вакыт, бу мизгелне:**
**Трибунада—Йосыф Акчура.**
**Төрки халыкларның байрагын ул**
**Азаматлар кулына тапшыра.**

**«Инкыйраз...» дип, Гаяз әфәнденең**
**Борчулары илдә чаң кага.**
**Ул перчатка ташлый—каргыш белән,**
**Зольмәт белән тулы дөньяга!**

**Сөртәсе бар «яман татар» дигән**
**Тамгаларын урыс абзаның.**
**Вакыт безгә шушы нәҗесләрдән**
**Чистартырга тарих абзарын.**

**Бәддогасы, матбагасы белән**
**Шаулый татар, даулый үз хакын.**
**Иҗатына «тышау» салган саен**
**Сәясәткә чума Исхакый.**

[1] Йосыф Акчура 1916 елда Лозанн (Швецария) конгрессында төрки-татар милли үзәге исеменнән чыгыш ясый.

Рашат НИЗАМИ (1950)—*шагыйрь, прозаик, публицист; «Кызыл җәй», «Тормыш трамвае», Фәрит Яруллин турындагы роман-хроника һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## II

Кан-кызылдан кояш баеп бара,
Россиядә төннәр кап-кара.
Ә Исхакый, археолог сыман,
Тарих катламнарын актара:[1]

*Ислам белән яктыртылган*
*Синең барыр юлларың.*
*Кодрәтле-әһкатьле булып*
*Дан тоткансың, Болгарым.*

*Сау-сәламәт яшәгәнбез*
*Чәчәк аткан чорда без.*
*Алгарышта алдын булган*
*Безнең Алтын Урдабыз.*

*Офыкларда ни җилферди,*
*Кемнең канлы яулыгы?*
*Утка кергән, авып төшкән*
*Ялгыз Казан ханлыгы...*

Асу-кисү, курку-куркытулар—
Урыс коралының бер төре.
Ак бүредән килә нәсел-нәсәп,
Без һаман да исән, без—тере!

## III

Таралганны җыяр вакыт безгә:
Идел-Урал! Яши хыялда...
Ватанымның байраклары бүген
Өч зөбәрҗәт төскә буялган.

Сандал белән чүкеч арасында
Татарстан һаман кыйнала.
«Берләшегез, татарларым!»—диеп
Кыйтгаларга әнә өн сала.

Шаңдау булып кайтавазлар килә
Дау-көрәшле кайнар көннәрдән.
«Көрәшчеләр кирәк!..»—диеп, шагыйрь
Чакыру ташлый шигъри мөнбәрдән.

Сөлге таза, билен яза татар,
Кайгыларны чөя башаркан.
Көрәшчеләр туып торган чакта
Исән калыр нәсел, яшәр кан.

Хөр буласың килсә, бүтәннәргә
Чын Азатлык бир син иң элек.
Баррикадалардан килә торган
Азатлыкның төсе—мәңгелек!

[1] Г. Исхакыйның «Идел-Урал» дигән хезмәте күздә тотыла (автор искәрмәсе).

## Ватаным

Зеңләп тора...
Чыңлый, актарыла—
Офыклардан түгелә кай өннәр?
«Татарстан, минем Ватаным»—дип
Шаулый сыман үрдә каеннар.

Идел киңлекләре дулкын-дулкын ,
Айкап-чайкап ала бәгырьне.
Урман җыры, киек кошлар хоры,
Һәр түмгәге—якын, кадерле.

Ак бүресе гайрәт чәчеп тора,
Кош рухымы—ул бит канатлы!
«Туган җирем шушы» ,—дия-дия
Ил догасын күкләр кабатлый.

Авырттырып, кысып ала хәтер:
Сибелгән шул татар, сибелгән...
Мәхәббәтен ләкин үзе белән
Алып киткән туган җиреннән.

Читтә яшәп яткан татарымның
Күз яшьләре—сагыш яңгыры.
Җир-сулары , җирсүләре җанда
Бер кайтаваз булып яңгырый.

Шәҗәрәмнең кан тамырын эзләп,
Йөгерешә көмеш кылганнар.
«Болгарстан, минем Ватаным»—дип
Бабаларым сәҗдә кылганнар.

Буразнада орлык шытмый икән—
Бәрәкәте, даны юк аның.
Яраланган иреннәрем белән
Үбәм туган җирнең туфрагын.

## Җәй уртасы

Галәмара мизгел!
Тып-тын гына
Туктап калган кояш зенитта.
Һәрбер үлән, яфрак дога кыла—
Кемдер туды шушы минутта.

Сузылып ята инеш, тере килеш:
Манзарасы җәйнең шушындый,—
Качыш-качыш уйный вак дулкыннар,
Ярга ятып кояш пышылдый.

Җәясеннән атылган ук сыман
Карлыгачлар оча сызгырып.
Тояк тавышлары... Җайдак уза
Олы юлдан тузан туздырып.

Чалгы тавышларын кұмә-кұмә
Күтәрелә астан курпылар.
Жәй—жәй инде! Бөтенләй ят аңа
Икеләнү, сагыш, куркулар.

Әй, талпына бакча карачкысы,
Ак каеннар дәшә—ак җилкән.
Җәй сызылып кала офыкларда,
Нинди әйтер сүзе бар икән?

## Вокзал

Поездлардан тамып кала
Дегет тамчылары.
Офыкларны кисә-турый
Рельс кайчылары.

Сакал баскан ач бомжлар
Чүп савытын сара.
Экзотика! Асфальт буйлап
Жигүле ат бара:

Келтер-келтер калкып чыккан
Гасыр азагыннан,—
Тукайларыбыз кайнашкан
Печән базарыннан...

Көтү залы шыгрым тулган,
Шау-шу катыш йокы.
Исәрләр күп, әйтерсең лә
Бу—юләрләр йорты.

Семафорда өч төс яна:
Күзен кысып-кысып,
Бөтенесен җайга сала
Яшел, сары, кызыл.

Иртәгә бу юлчыларның
Булмас кайсылары.
...Болытларны кисә -турый
Рельс кайчылары.

## Ташландык мендәр

Голицыно. Мәскәү яны.
Ташлап кәгазь-каләмне,
Чыктым шәһәр читенә мин
Язар өчен бәдәнне.

Шаулап яз килә дөньяга—
Яңарышлар дәвере!
Минем дә бит акты-китте
Күңелем гөрләвеге.

Иске карлар шиңеп төшкән,
Кечерәйгән, чулыккан.
Чүп-чарларны агызып китә
Канаудагы сулыклар.

Чү! Канау читендә әнә
Йомарланып, капланып,
Ташландык бер мендәр ята,
Чит-читендә—кар табы.

Уйларым сикереп чыкты
Теге якка яр аша.
Кайчандыр, башкаен куеп,
Кемдер йоклаган ласа?

Нидер таба һәм югалта
Безнең кыска гомерләр.
...Кире кагылган сөюне
Хәтерләтте бу мендәр...

## Көзге учак

Яр читенә куләгәләр елыша,
Ике яфрак, көчек сыман, куыша.

Юк иде бит, каян чыкты бу аваз—
Этләр өрә... Әрәмәдә—кайтаваз.

Салкынчарак һава саркый куенга,
Яшьләр инде төшми кичке уенга.

Алтын канат—Ай кабынды югартын,
Хакимлеккә дәгъва кыла чуар төн.

Учак яна... Без кабызган учаклар.
Теләсәң дә кабатланмас ул чаклар.

Табигатьме, безме әллә үзгәргән—
Саргаябыз калышмыйча көзләрдән.

Ялгыз болыт—гүя, соры ямаулык.
Тәкъдир дәшә: көннәребез санаулы.

Белдек микән соңгы учак якканны,
Хәзер инде кемнәр шакыр капкаңны?

Ак каенның итәкләре шәбәргән.
...Сәлам юллыйм сиңа капрон шәһәрдән.

Чү, күңелкәй, салмак атла, акрын бар,
Арабызда—кул җитмәслек чакрымнар!

## Юану

Шәм сыман эри көннәрем,
Ыжгырып оча гомер!
Учак яккан урыннарда
Көл катыш утлы күмер.

Шәһәремнең уртасында
Җәйрәп ята Казансу.
Кичләргә килеп кергәндә
Дөнья никтер ямансу.

Йөзә, чумадыр уйларым
Иделемнең төбенә:
Ялтыр-йолтыр—яшенме ул,
Әллә чабак тибенә?

Язар шигъри юлларымны
Капылт искә төшерәм.
Сүзләр арты сүзләр үреп,
Мин иҗатта «исерәм».

Алда—яшәр елларым бар,
Юанамын мин шуңа:
Үлемне җиңгән үләннәр
Яз саен калкып чыга!



Фоат
Садриев

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ*

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### 1

Ирек кузгала алмыйча, чит кеше кебек ишек төбендә басып тора бирде. Рашатның көлүе аның бөтен тәнен эсселе-суыклы итте, бала йоннарын кабартты, тезләрен калтыратты. Әйтерсең лә өстенә һавадан көчле өермә килеп төште дә, аны аунaта-аунaта, яфрак кебек каядыр очырып алып китте. Рашат көлүдән туктагач, Ирек бераз аңына килгәндәй булды. Беренче уе «Бу аның өрәге түгелме икән?» дигән сорау булды. Юк, бу өрәк түгел иде. Шул ук вакытта бу элеккеге җиңел холыклы, бер минут эчендә әллә ничә төрле халәткә керә торган дуамал Рашат та түгел иде бугай. Аның күзләрендә, йөзендә ниндидер авырлык сизелә, ул нәрсә кургаш кебек бөтен гәүдәсенә кунган. Рашатның өстендә чем-кара затлы костюм-чалбар, кофе төсендәге күлмәк, муенында куе зәңгәр галстук, аякларында елкылдап торган шундый ук кара төстәге затлы туфлиләр. Диванга салып куйган куе зәңгәр плащы, кара эшләпәсе дә өр-яңа, тузан-мазар кунмаган, бүген генә кибеттән алгандай иде.

—Нәрсә ишек янагына ябышып каттың?—диде Рашат боздай салкын тавыш белән.—Аңлыйм, аңлыйм, син бит инде мине күптән күмгән идең.—Ул тагын хихылдап көлеп куйды.—Әйе, үлгән идем, рәхәт түгел анда. Тоттым да җир астыннан чыктым. Ник әле сез монда йөргәндә мин анда череп ятарга тиеш?!—Рашат костюмының күкрәк кесәсеннән алып өстәлгә коньяк утыртты. Аннары күзләрен алартып, башын Зәнфирәгә таба борды.—Бәлкем өстәлгә берәр нәрсә куярсыз, ханым? Безнең татар хатыннары бит бик кунакчыл була торган иде.

Ирек киемнәрен салып аның каршына килеп утырды. Зәнфирә өстәлгә ипи, киселгән тозлы кыяр куйды, икесенә дә аерым йомырка тәбәсе китерде, бер рюмка бирде.

* «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясенең өченче китабы. Романның журнал варианты тәкъдим ителә.

Фоат САДРИЕВ (1941)—*прозаик; «Таң җиле» романы, «Шаһзаманов эше», «Авыш басу икмәге» кебек повестьлар һәм күпсанлы пьесалар авторы. Мөслимдә яши.*

—Бусы ни була инде?!—Рашат рюмканы эләктерде дә шапылдатып Ирекнең алдына утыртты.

—Мин бит эчмим,—диде Ирек, рюмканы кабат аның алдына куеп.

—Эчмисең?!—Рашат әллә нинди кәҗә тавышлары чыгарып кеткелдәп куйды.

—Әйе, эчмим.

—Ни булды?

—Организмыма ярамый.

—Син хитрить итмә!—диде Рашат, күзләрен ачулы уйнатып.—Минем белән эчәргә җирәнәсеңмени?

Ул җилпенеп сикереп торды да барып шкафтан бер стакан алды, коньякны башта рюмкага салды, аннары калганын стаканның күзеннән итеп тутырды.

—Әйдә, тоттык! Без бит икебез дә теге дөньяга ычкынган идек. Бу дөньяда очрашу хөрмәтенә.

Ирек рюмкасын чәкештерде дә аның эчкәнен көтеп тора башлады. Зәнфирә яшь белән тулган күзләрен мөлдерәтеп ана төбәлде. Ул күзләрдә ни язылганын Ирек бик яхшы аңлады. Рашат башын артка ташлады да, авызын зур ачып, стаканны түнтәрде. Коньякның, зур бүрәнкәгә салган су кебек шарылдап, аның тамагыннан төшеп киткәне ишетелеп торды. Кунак тирән итеп сулады да шытырдатып кыяр чәйнәргә керешге, ипи белән йомырка тәбәсе элеп капты, аннары Ирекнең алдында торган рюмкага ияге белән ымлады:

—Ачуланма, булдыра алмыйм,—диде Ирек.

—Ярар, аңладым мин сине,—диде Рашат кисәтүле тавыш белән.—Вакыт бар, барысына да өлгерербез. Әле бит башы гына. Шулаймы?

Ирек дәшмәде. Рашат сәгатенә карап алды да, күзләрен йомып, нәрсәдер уйлагандай, беркадәр торды, аннары кинәт аягын сузып җибәрде.

—Билем авырта, иелә алмыйм, ботинкаларымны салдыра алмассызмы икән?—дип күзләрен Зәнфирәгә төбәде.

Зәнфирә агарып китте, йөзенә хурлану галәмәтләре чыкты, күзләрендә ачулы очкыннар биеште. Ул, яклау эзләгәндәй, Ирекка карап алды, ләкин Ирек берни дә кылмады, аның башын бер уй томалаган иде: Рашат нинди максат белән килгән, аның уенда нәрсә?

—Ирек дус, хатының сиңа карый бит, сиңа салдырырга куша.—Рашат уң аягын күтәреп Ирекка таба борды.

—Үз өемдә мин үзем хуҗа, монда без боерабыз. Шуңа күрә, Рашат дус, син гафу ит инде. Минем әтинең дә аяк киемен салдырганым юк.

Рашатның йөзе караңгыланып китте. Аннары ул чыраен ачуташ капкандай җыерып, ясалма елмайды.

—Син Мәскәүдә минем квартирада яшәгәндә болай сайрамый идең. Үзгәргәнсең, нык үзгәргәнсең.

—Ә-ә-ә, аңладым тел төбеннең кая барганын,—диде Ирек, күңелендә ачу кузгала башлавын тоеп.—Күпме түләргә кирәк?

—Күпмеме?—шулай диде дә Рашат тагын сәгатенә күз төшереп алды һәм, нәрсәдер тыңлагандай, күзен йомып, башын артка ташлады. Ирек бу очрашуның төш түгеллегенә һаман ышанып бетә алмады. Ничек исән калды икән соң ул? Рашат кинәт күзләрен ачты.—Түләвең шушы инде,—ул аягын сузып селеккәләп алды.

—Без синдә яшәгән өчен аяк киеме салдырырга сөйләшмәдек бит.

—Молодец!—диде Рашат һәм шапылдатып кул чапкандай итеп куйды.—Горурлык ир кешегә бик кирәк нәрсә ул. Әгәр өенә сыя алса. Тик монда бик тар, сыя алмый синең горурлыгың. Кайда саклана соң ул?—Аның тавышында ачыктан-ачык мыскыллау билгеләре сизелде.—Син аны токмач басарга он алып кергән кебек сарайдан көнлекләп алып керәсеңме? Әллә

кесәнә тутырып йөрисенме? Көнбагыш кебек кирәк чакта кешеләрнең йөзенә кабыгын чиертәсең, әйеме?

Ирек, инде ачуын яшерә алмас дәрәҗәгә житсә дә, тешләрен кысты, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып, Рашатка таба иелде һәм болай диде:

—Кайда сакласам да, үземә житә. Һәрхәлдә синнән әҗәткә сорамам.

—Молодец! Ха-ха-ха!

Рашат көлүеннән кинәт туктады, йөзе караңгыланып, тартышып куйды. Ул, күзләрен Иректән алмаган килеш, акрын гына уң кулын костюмының эчке кесәсенә тыкты, анда нидер капшады да хәрәкәтсез калды. Кулын кесәсеннән алмаган килеш, сәер итеп иренен кыйшайтты. Бу елмаю да, мыскыллау да түгел, әллә нинди яшерен бер уйны чагылдыра иде. Аның кысылган күз керфекләре арасыннан елтыраучы күзләрендә ниндидер куркыныч көч шәйләнә, ул менә хәзер дөртләп кабыныр, шартлар кебек тоелды. Рашат кинәт кулын алды да беләге белән өстәлдәге әйберләрне түргә таба сыпырды, аннары терсәген өстәлгә терәп, бармакларын бер йодрыкка төйнәде, бер җәйде.—Әйдә, кул көрәштереп карыйк әле.

Аның шул сүзен көткәндәй, Ирек шундук үзенең учын аның учына салды. Зәнфирә, йөрәге ярылырдай булып, аларга карап тора иде. Ирек тынычлан дигән мәгънәдә ана керфек сирпеп куйды. Менә алар кул көрәштерә башладылар. Беренче тотыну белән Ирек аның үзеннән көчле икәнлеген аңлады. Бу эшләгән, бирчәеп беткән кул түгел, әмма ифрат та саллы, көчле иде. Ирек тешләрен кысып, кулын туры тотарга тырышты, җиңәргә омтылмады, бары тик шулай төз торырга кирәк иде. Аларның икесенең дә маңгайларындагы, муеннарындагы тамырлары бүртеп чыкты, кып-кызыл булдылар, еш-еш сулыш алганнары ишетелде, әмма куллары шул бер урында тора бирде. Ахырда Рашат кулын ычкындырды.

—Минем уң кул имгәнгән иде, төзәлеп житмәгән, әйдә сулы белән,—диде ул, бармаксыз кулын өстәлгә куеп.

Бусында Ирек каршы тора алмады, Рашат аның кулын тоту белән шартлатып өстәлгә китереп салды.

—Мәскәүләр менә шулай тота,—диде ул, кимсетүле караш ташлап.—Буйсынырга өйрәнергә кирәк булыр.

Зәнфирә курку катыш ачулы күзләре белән аның һәр хәрәкәтен күзәтеп тора иде. Бу Рашатка ошамады.

—Кара әле, Ирек дус,—диде ул зарланган булып.—Хатының күзе белән миңа атмасын әле. Өегезгә кергәннән бирле мин аның карашы астында пистолет көпшәсе алдында торган сыман торам. Ату бит ул гаҗәп нәрсә. Берәү мәңгелек йокыга тала, икенчесенә яшәү килә. Берәүгә инде берни кирәкми, икенчесенә байлык, гамьсез күңел ачулар килә. Килешәсеңме? Атарга ниятләгән кеше берни дә уйламаска тиеш. Зинһар атмагыз инде күзегездән. Мин мондый карашка күнекмәгән. Алла сакласын... Минем дә атып куюым бар.—Ул кисәк кенә көлеп жибәрде.—Күз белән диюем.—Рашат сәгатенә карады да кинәт сикереп торды:—Миңа китәргә вакыт.

Ул плащына үрелде, кесәсеннән калын блокнотка охшаган бер әйберне алып Ирекка суздысы.

—Менә син моны укып чык әле. Мәскәүдә самиздатта басылган китап бу. Ошаса, тәржемә итәрсең. Юк, син аны ошамаса да тәржемә итәчәксең. Һичшиксез татарча чыгарырга кирәк.

Аның сүзләрендә боеру, мәжбүр итү яңгыраса да, Ирек нишләптер китапны алды. Рашат плащын, эшләпәсен киде, аннары бер генә мизгелгә хәрәкәтсез торганнан соң, плащ кесәсеннән алып, Ирекка бер төргәк акча сузды. Төргәк банкта ябыштырылган хәлендә, бишлекләрдән генә тора иде.

—Минем бай чак, ничек яшәвегезне күреп торам. Ал инде, ал,—диде ул Ирекка якынлашып.

Ләкин Ирек артка чигенде. Рашат акчаны диванга ташлады.

—Сыегыз өчен рәхмәт булыр бу.

Аннары ул чыраен Ирекнең йөзенә тери язып якын китерде. Карашы әллә нинди, аңлаешсыз, күзләре каядыр качкан, аларның урынында куе-кара сөрем генә кебек күренде. Ирекнең күнелен шомландырып, чыннан да өрәк бугай бу, дигән уй йөгереп узды. Жылы, тәмсез аракы исе бөркелде, укшыта язып борынына керде.

—Әгәр минем монда булганны ялгышып берәр жан иясенә ычкындырсагыз, икегезгә дә бик начар булачак.—Рашат үлем тынлыгы ясап, тукталып калды.

Ул ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Зәнфирә белән Ирек торатащ катып калдылар. Аларның икесен дә әллә нинди шом, табигатьне дәһшәтле давыл алдыннан биләгән халәт баскан иде. Бөтен кош-корт, җәнлек, бөҗәкләр ничек тынып калган булса, аларның да йөрәге тибүдән туктагандай булды, өй эченә үлем тынлыгы җәелде. Ирек коточкыч бер әйбергә төшенде: иң әүвәл тырышып-тырмашып ул аны уеннан куарга тырышты, чөнки ул җимергеч нәрсә. Әмма күпме генә теләсә дә куа алмады һәм аның белән килешергә мәҗбүр булды.

—Акчаларны...—Зәнфирәнең калтыранган куллары диванга таба сузылды.— ... акчаларын зинһар чыгарып бир үзенә,—дип пышылдады ул көч-хәл белән.

Ирек төргәкне эләктерде дә ишек алдына атылды, капкага таба йөгерде. Көчле җил күтәрелгән иде. Капканы ачып, тыкрыкка күз ташлады, ләкин анда беркем дә күренмәде. Күктә ай йөзә, җил уйнаткан агачларның шәүләләре, ычкынып китәргә теләгәндәй, җирдә шуышалар, бәргәләнәләр. Шул арада Рашатның чыгып китүе мөмкин түгел иде. Димәк, ул ихатада. Ирек кабат борылып өй турына килде, як-ягына каранды. Абзар-кура ягына күз ташлап:

—Рашат, син мондамы?—дип кычкырды.

Җавап бирүче булмады, абзар эчендә нәрсәдер дөпелдәгәндәй, аяк тавышы ишетелгәндәй булды. Ирекнең күнеленә әллә нинди ямьсез уй килде. Шомланып, ул ишекне ачты, өйалдындагы балтаны эләктерде. Тавыш чыгармыйча, абзар ягын күзәтә башлады, өйдән Зәнфирә килеп чыкты.

—Бирдеңме акчасын?—диде ул.

—Юкка чыккан ул. Тыкрыкта да күренмәде.

—Кулыңа нишләп балта тоттың?

—Аяк астында калган бит.

—Юкны сөйләмә, мин аны үз кулларым белән кертеп сөядем.

—Рашат!—дип кычкырды тагын Ирек.

Җавап бирүче булмады.

—Мин нишләптер куркам, Ирек. Тизрәк капканы биклик тә өйгә керик.

—Керә тор,—диде Ирек.—Үзем бикләп киләм.

Ул капканы ачып тагын бер мәртәбә тыкрыкка күз салды. Шушы арада Рашатның чыгып китеп өлгерүенә һич тә ышанырлык түгел иде. Ай зур кара болыт астына кереп юк булды, бөтен җиһан караңгылыкка чумды, җил көчәйгәннән-көчәйде. Ирек капканы бикләде дә бераз тыңланып торды, уйланды. Рашатның ул үзенә килгән бәла икәнлеген аңлады. Аның күз карашы рәхимсез, җанга шом сала иде. Аны куып та җибәрү мөмкин түгел, аннардан качып та котылып булмаячак. Аларның тормышында ниндидер хәвефле сызык башлана, язмыш шуны кисәтә, әзер булырга куша иде.

Ирек, көчәйгәннән-көчәя баручы җилдә, пальтосын эләктермәгән килеш бик озак басып торды. Әллә кая поскан айның сизелер-сизелмәс кенә сирпелүче яктылыгында, каядыр шуышучы болытлар шәйләнә, йолдызлар

чагылып ала, гүя бөтен җир шуыша, үзе белән бергә Иректне дә алып китә иде. Аның күңеленең беркайчан да бу дәрәҗәдә ачыргаланганы булмады. Тагын Рашат, дип уйлады ул. Димәк, Ирек аның белән һаман бер дәрәҗәдә. Күпме генә югарыга омтылып та, үзен олы гамь белән яшим дип хисаплап та, Рашатлар, куркыныч Вышкалар дәрәҗәсендә калган булып чыкты. Бу тоткынлыктан, бу түбәнлектән ул мәңге чыга алмаячакмы, бу нинди зур ялгышлык булды? Ирек бит алардан күпкә өстен кебек, ә менә бүген ул җан өшеткеч хакыйкатьне аңлады: һич тә өстен түгел, бер дәрәҗәдә, алай гына да түгел, Рашат хәзер аның өстеннән таптап йөрергә кайткан. Җавап эзләгәндәй, ул тагын күк йөзенә карады, сызгырып искән җилне тыңлады, әмма җавап юк иде. Аны эзләп чыккан Зәнфирәнең эндәшүенә ул сискәнеп китте. Зәнфирәгә ияреп, буш һава шары кебек, үзенең бернинди авырлыгын, җанын-тәнен сизмичә өйгә керде. Зәнфирә ниләрдер сөйләде, Рашат турында сорады, куркам, диде, ләкин аның сүзләре Ирек өчен әһәмиятсез иде. Аны бары бер уй көйдерде: тормышта алар белән бер дәрәҗәдә хурлыклы сөйрәлү. Ул шушының сәбәбен дә тапты кебек. Әгәр гомеренең иң кадерле вакытларын коточкыч кара сөрем белән агуламаса, ул хәзер әллә нинди югары биеклекләрдә булыр иде. Рашатлар аңа якын килү турында уйлый да алмаслар, бәлкем аны танымаслар да иде. Үзең кискән канатлар тиз генә үсмидер. Телисеңме-теләмисеңме, хәзер син алар белән...

## 2

Рашат, Ирекләрнең капкасыннан чыгу белән, эшләпәсен сумкасына салып, күзенә кадәр батырып кара башлык киде һәм ашыга-кабалана юлга таба атлады. Аңа ашыгырга, бик ашыгырга кирәк, ераккарак китәргә, беркемне дә очратмаска кирәк иде. Ахмак, дип тиргәде ул үз-үзен, әле бу араларда аңа Болынкырга аяк басарга бөтенләй ярамый ич. Ирек янына теләсә кайчан кайтып була. Йөрәкләренә шом салуыннан канәгатьлек алды алуын. Ә бит шушы бер адым аны харап итәргә мөмкин. Ул йөгерә-атлый Болынкырның уравыч юлына чыкты. Сул якта караңгылык каплаган ялан, ә унда утларын балкытып Болынкыр утыра. Шул яктан плащ итәкләрен, чалбар балакларын йолкып юеш җил исә. Рашат, юлда фара яктысы күренүгә, койма буйларына йөгереп шуннан атлады, яктылык бетүгә, тагын юлга чыкты. Авыл ягыннан искән җил аны сул якка этте, әмма Рашат нишләптер җилгә каршы Болынкыр эченә таба тартылды. Әйтерсең лә бу юеш җилнең уртасында, аны каршы якка сөйрәүче икенче бер агым бар иде. Шулай карышып бара торгач, ул авыл эченә килеп керде. Урам баганаларындагы лампочкаларның яктылыгыннан качып, өй, агач шәүләләре караңгылаган урыннарга елышты, тыкрыкларга чумды. «Кит, читкә кит, кермә!» дип боерды ул үз-үзенә, әмма гәүдәсен, аякларын буйсындыра алмады, сулышы кысылды, әллә куркудан, әллә кабаланудан йөрәге döп-döп типте. Ул үзенең аракыдан түгел, бүтән аңлаешсыз нәрсәдән ярым исерек хәлендә икәнлегенә төшенде. Ниндидер көч, аның эчке боерыкларына буйсынмыйча, Рашатны һаман Болынкырның уртасына куалады...

Берничә минуттан ул үзләре турында иде инде. Каршыдагы караңгы эченнән ул үзләренең калай түбәле мәһабәт йортына, аның челтәрләп бизәлгән матур кәрнизле тәрәзәләренә карап торды. Тамагы ачкан кеше ашарга әзерләнгәндәй, берничә мәртәбә төкереген йотты, кипшенгән кайнар иреннәрен ялмап куйды. Зал ягы тәрәзәләре, кухня ягы караңгы иде. Күрәсең, гадәттәгечә әнисе үз бүлмәсендәдер. Рашатның өй эченә тәрәзәдән генә булса да күз саласы килде, бу теләкнең төзәтә алмаслык хатага китерү ихтималын уйлап, бер генә мизгел икеләнеп торгач, тәвәккәлләде. Бу вакытта инде капка бикле булганын ул белә, урам яктан койма өстеннән керергә ярамый—

туктаусыз үтеп-сүтеп йөриләр. Рашат, караңгы почмаккарак барып, урамны аркылы чыкты, бәрәңге бакчасына койма өстеннән генә сикерде, иелеп өйләренә таба йөгерде.

... Минзаһит телевизор карап утырган җиреннән тәрәзә турында шәүлә күрде. Үзе дә сизмәстән, сикереп торып артка чигенде. Шул арада шәүлә юк та булды.

—Хәят!—дип кычкырды ул карлыккан тавыш белән.—Хәят, кил әле тизрәк!

Хатыны кухнядан атылып-бәрелеп аның янына керде.

—Ни булды, ник шулкадәр кычкырасын?!

Минзаһит җинелчә генә калтырый иде. Ул кулы белән тәрәзәгә күрсәтеп:

—Анда кемдер бар!—дип пышылдады.

Хәят аптырап иренә карады да тәрәзәгә китте, иелеп тышка күз ташлады.

—Берни дә юк бит.

—Бар дим мин сиңа, бар! Мин урынымнан торгач, юкка чыкты.—Хәят аптырап баш чайкап торды.

—Әйдә, әйләнеп керик алайса.

Алар, барлык утларны гөлт итеп яндырып, ишек алдына чыктылар, сакланып кына агач бакчасына, әле генә Минзаһитның котын алган тәрәзә турына килделәр.

—Менә күрәсеңме,—диде Минзаһит чүгәләп.

Юеш җир өстендә олы ботинка эзләре ярылып ята иде. Эз аларны сарай янына алып килде.

—Әйдә, тизрәк керәбез,—диде Хәят, Минзаһитның кулыннан әләктереп.—Кемдер йөргән шул...—Казанга барып эш турында ныклап сөйләшеп кайтырга кирәк,—диде ул, ишекләрне бикләп өйгә кергәч.—Күпме сузарга була? Безне куркытып куарга теләүләредер бу...

Минзаһит авыр сулап куйды.

-—Әз булса да иректә яшисем килгән иде. Таш дивар эченә кереп утырып кара әле син. Аягың белән әнә шул бакча туфрагына басарга да тилмереп ятачаксың.

—Безгә башка юл юк бит инде, Минзаһит.

• • •

Әтисе урыныннан тору белән, Рашат иелеп агачлар арасына йөгерде. Сарайга үзенең мәктәптә укыгандагы чаңгы таягы сөяп куелган иде, Рашат, ни икәнен дә аңламастан, аны эләктерде дә ярым иелгән хәлдә бакча буйлап йөгерде.

Ун минуттан ул олы юлдан шактый ерак Чабырлы тау буйлап кызу-кызу атлый иде. Тыз-быз узып торучы машиналар тынган арада юлны аркылы чыгып, зиратка юнәлде. Аның нарат-чыршы, каен, усак агачлары белән томаланган аргы ягына барып житте. Шунда ул, аучылар куып арыткан кыргый җәнлектәй, адымнарының хәлсезләнүен, гәүдәсенең камырдай йомшавын тойды. Йөрәгенең кагуына, күңеленең болгануына, ике чигәсенең кысуына түзәрлек түгел иде. Бу хәлдә беркая да китә алмаячагын ул яхшы аңлады. Сирәк кенә коелган койманың ике тактасын шартлатып кубарды да, хәлсез аякларын авырлык белән сөйрәп, эчкә атлады. Әгәр шушында иртәгә кичкә кадәр йокларлык җылы кабер булса, ул ике дә уйламас, хәзер үк шунда кереп авар иде. Өч-дүрт адым атлауга, авыш җирдәге юеш кауданнан аягы таеп, ул сырты белән барып төшкәнен сизми дә калды. Калак сөяге турын нindидер каты нәрсә авырттырып алды. Сикереп торгач, Рашат һаман чатырдатып кысган сумкасын, чаңгы таягын читкә селтәде дә теге әйбергә үрелде. Кулы тию белән тәне чымырдап китте. «Баш сөяге!»—дип уйлады ул куырылып. Жентекләп караганнан соң гына аның кеше башы түгел, ә бәлки череп беткән кабер бурасының сынып төшкән башы икәнлеген абайлады.

Әмма күнелен биләгән шом таралмады. Черегән үләннәрдән, яфраклардан, юеш җирдән килгән кабер исе аны әллә нишләтеп җибәрде. Ул кабаланып зират эченнән чыкты һәм, коймага күкрәге белән сөялеп, бераз күзләрен йомып торды. Күзләрен ачуга, аста үзенең җем-җем иткән утлары белән җәйрәп яткан Болынкыр пәйда булды. Әйтерсең лә галәмнең барлык йолдызлары менъяфрак чәчәгедәй бергә шунда җыелганнар, аларның җылысында күпме кеше бернинди гамьсез гомер кичерә. Бары аңа гына, бары аңа гына моннан читкә, мөмкин кадәр ераккарак китәргә кирәк...

Ул башын югарырак күтәрде. Күктә йолдызлар калмаган диярлек. Туктаусыз җил куалаучы болыт ертыклары арасыннан күренеп алганнары да салкын һәм шомлы, алар корбанын эзәрлекләүче күп санлы бүре өеренең күзләрен хәтерләтәләр. Йолдызлар да, бүре күзләре дә, эзәрлекләүчеләр дә бер үк. Бөтен нәрсә буталды, кайсысы нәрсә икәнен, булдыра алсаң, үзенә аерырга туры килә...

Ул, коймага аркасын терәп, юеш чирәмгә утырды, сумкасын ачып, башланган коньяк шешәсе, колбаса, ипи чыгарды. Коньягын шешә борыныннан гына голт-голт эчте дә, колбаса, ипи кабып чәйнәргә кереште. Күптән түгел генә яңгыр юып киткән үләннәрнең юеше салкын булып тәненә үтте, тик ул моңа игътибар бирмәде, комсызланып умырып алып, колбаса белән ипи чәйнәде, гәүдәсенең җылына баруын тойды. Җил һаман басылмады, зират эчендәге агачлар тагын да шомлырак булып шауларга керештеләр.

Ул чәйнәвеннән туктап калды. Нәкъ аның баш очында «торрыйк-торрыйк» дигән тавышлар ишетелде. «Торналар кайта!»—дип уйлады ул. Торналар кайта... Кошлар туган якларына төнлә очалар—Рашат моны яхшы белә. Ул башын күтәреп һавага карады, әмма торналар күренмәде...

Кошлар туган җирләренә төнлә очалар...

Аның уен сизгәндәй, тагын торна тавышлары көчәйде. Бер төркеме узып китеп, икенчесе килеп җиттеме, әллә шул ук төркемме! Кошлар туган җирләренә юлны йолдызларга карап та билгелиләр, диләр. Әллә алар, үз йолдызларын югалтып, болытлар арасында адашып кычкыралармы?

Кинәт тып-тын булып калды, хәтта җил дә акрынайды бугай. Рашат шешәсен күтәреп тагын эчте, тик бу юлы берни дә капмады. Аңа әллә ни булды, бөтен барлыгын салкын бушлык биләп алды, гәүдәсен кайнар ут көйдерде һәм ул күзләрен йомды. Шулай да аның фикере сизгер иде: юк, сина йокларга ярамый, дип кисәтте ул. Рашатка бүген үлеп-житеп булса да төнлә тимер юл вокзалына барып житәргә кирәк. Бу тирәдән эзне суытырга, ерагаерга, шау-шу, ыгы-зыгылы, буталчык вокзал дөньясына чумарга. Тизрәк теләсә кайсы поездга утырып, ераккарак сызарга! Ул уйный торган хәтәр уенның кануны шундый. Бу канунны бозсаң, барысы да бетте, дигән сүз... Әгәр Вышка аны Ирек белән сугыштырганда, Рәсүл үзләренең төркемен алып килмәгән булса, менә болай йөрергә дә туры килмәс, ул рәхәтләнеп кара җир куенында йоклап ятар иде. Әнә бит күпме кеше йоклый, берсен дә борчучы, куалаучы юк. Больницадан чыгу белән күзне йомып шушында—Болынкырга ычкынасы булган. Ә ул һаман Мәскәү тормышына кызыкты, һаман нидер житмәде.

Квартирасын хуҗаларына тапшырып, урамда калды. Рәсүл төркеменә ияреп, Вышканың күзеннән югалырмын, дип уйлады. Мәскәү зур, җир астында да тулы бер шәһәр, күзләренә чалынмам, дип өметләнде. Әмма бер ай да үтмәде, ничек килеп капканын сизми дә калды. Вышка хәзер аның бар икәнен дә белми, югары даирәләр эчендә кайнаша. Ә Рашат барыбер ул корган пәрәвезгә эләккән килеш. Пәрәвез җепләренең кайларга кадәр, күпме җирләргә сузылганын Вышка үзе генә белә... Рашатка соңгы корбанын юк итәргә бер

ай вакыт бирделәр. Ул аның койрыгына ябышып, күрше районга кадәр кайтып житте. Төрмәдә утырган дустына килүе булган икән. Рашат бер атна сагалады, мунча кергән вакытында эш итте. Сабынланып ята иде, сизми дә калды...

Баш очында, гел якын гына сагышлы итеп тагын торналар кангылдаша башлады. Рашат аларны аңлагандай булды. Торналар да аны куалый, ашыктыра, ә бәлкем без төшәсе жирне билисен, диләрдер. Аларның тавышы үткен хәнжәр белән Рашатның йөрәгенә сызып жибәргәндәй итте һәм ул, гел сизмәстән, беркайчан булмаганча, тыелгысыз үксергә тотынды...

Кошлар туган якларына төнлә очалар... Кошлар туган якларына очалар...

Рашат кул аркасы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә торып басты һәм тешләрен шыкырдата-шыкырдата ыңгырашып жибәрде. Ул чаңгы таягын әләктереп алды да ике куллап тотып һаваны айкарга кереште, гүя анда кангылдашучы торналарны куркытырга, туктатырга теләде. Аннары үзен-үзе белештермәс хәлгә килеп, таяк белән зират коймасына уңлы-суллы сугарга тотынды. Койма башлары кителгәнче, алюмин таяк кәкрәеп-бөгелеп беткәнче такталарны кыйнады. Тәмам ярсып, тирләп чыккач, таякны зират эченә томырып, олы юлга атлады. Әле күрәсе көннәрегез алда, әле сез берни дә белмисез, йолдызларыгыз алай күнелле, шат янмас, дип янады ул, аста жемелдәп яткан Болынкыр утларына карап. Рашат елаудан туктаган иде инде.

Төн аны үз кочагына алды. Торналар йөрәкләрне кабындырырлык кыңгылдаша-кыңгылдаша туган якларына очуларын дәвам иттеләр...

## 3

Нинди көн булды соң бу? Кайбер көннәрне эшкә киләсең дә тәгәрмәчтәге тиен кебек бөтерелә башлыйсың: әле райкомга чакыралар, әле ишек төбенә кешесе жыела, әле Казаннан, әле авыллардан шалтыраталар. Вакытның ничек үткәнен дә сизмисең. Әйтерсең лә бөтен дөньяның кендеге сиңа береккән, әйтерсең барысы да сиңа карап торалар, синең фәрманыңнан башка берни дә эшли алмыйлар. Андый көннәрдә арыйсың, талчыгасың, әмма эш көне бетеп өенә кайтканда, ниндидер канәгатьләнү кичерәсең. Бу—үзенә күрә рәхәт талчыгу, канәгатьләнү халәте була. Ә менә бүген, уч иткәндәй, Сөембикәгә беркем дә шалтыратмый да, туктаусыз булып тора торган киңәшмәләр, жыелышлар да юк, ишек төбендә чират көтүчеләр дә күренми. Ичмасам кем дә булса керсен иде. Сөембикә шулай дип уйлап бетерә алмады, ишек шакыдылар.

—Керегез,—диде ул эчке куану белән.

Ишек акрын гына ачылды һәм анда Кәбировның йөзе күренде.

—Әйдә, кер, Мөнир абый, уз,—диде Сөембикә, аңа каршы барып.

Кәбиров ничектер моңа кадәр булмаганча сак, куркулы карашы белән Сөембикәне, бүлмәне капшап чыкты. Аны каршына утырткач, Сөембикә аптырап китте: туганнан туган абыйсы шактый картаеп, ябыгып киткән, чәчләре коелмаса да көмештәй чаларган, кашлары гына кап-кара килеш иде.

—Ни хәлләрдә ятасыз, абый?

—Казаннан кайтып килешем. РКБ да дәваландым.

—Әйе, ишеткән идем.

Кәбиров башын аска иеп, уйланып торгандай итте, борынын тартып куйды.

—Казандагы минем врачның әтисенең йомышы бар синдә.

—Кем соң ул?—диде Сөембикә сәерсенеп.

—Син аны беләсең. Ул ишек катында басып тора. Әгәр булдыра алсаң, зинһар ярдәм кулыңны суз.

Кәбиров чыгып ишекне ябуга, аны кемдер шакыды һәм, Сөембикәнең тавышын ишетүгә, шакучы үзе дә килеп керде. Алар исәнләштеләр, Сөембикә

бер генә мәлгә хәрәкәтсез калды. Бу кеше аңа бик таныш та, таныш та түгел кебек тоелды. Ниһаять, аның фамилиясе хәтеренә келт итеп килеп төште: Янчурин! Әйе, бу шул үзе, Янчурин иде. Какао төсендәге затлы плащы, шундый ук чалбары, замш туфлиләре, аксыл төрткеләр төшкән көрәнсу галстугы аның үзенең дә затлы кеше икәнлеген күрсәтә кебек. Сөембикә белгәндәге ялтырап торучы алсу битләр шактый эчкә батканнар, аның хәзер йөзе коры, вак җеп белән тартылгандай, нечкә җыерчыклар белән капланган. Озын гәүдәсе элеккедән дә ябыграк. Дулкынланудан Сөембикәнең дә сулышы кысылды. Янчурин аның тормышында иң күңелсез эз калдырган кешеләрнең берсе иде. Бернинди җинаяте булмаса да, Сөембикә артыннан ул нәрсәдер эзләп, аны гаепләү өчен дәлилләр тупларга килгәндер кебек тоелды.

—Тыңлыйм сезне,—диде ул калтыранган тавыш белән.

Янчурин, озын гәүдәсен сузып, Сөембикәгә таба иелде һәм:

—Минем сезнең янга килүдән башка чарам калмады,—диде.

Сөембикә аның авызы тулы алтын теш икәнлеген күрде.

—Сез мине хәтерлисездер дип уйлыйм...

Сөембикә, кулларының калтыранганын күрсәтмәс өчен, аларны өстәл астына яшерде. Әгәр хәленнән килсә, ул бу кешене каргый-каргый бүлмәсеннән куып чыгарыр иде.

—Хәтерләмим,—диде ул, күзеннән зәһәр очкыннар чәчеп. Янчуринның күзләре түгәрәкләнеп китте, йөзенә аптырау билгеләре чыкты.

—Мин бит сезгә Кәбиров артыннан күп мәртәбәләр сәлам юлладым. Ничә еллар буе... Әйтмәдемени?

—Тизрәк йомышыгызны әйтегез!

Әлбәттә, Сөембикә барысын да хәтерли иде. Аның сәламен тапшыргач, Мөнир абыйсына үпкәләп тә йөрде. Яңадан миңа аның турында бер сүз дә әйтмә, исемен ишетәсем килми, диде.

Янчурин ярым пышылдап сүз башлады:

—Әгәр сез ярдәм кулы сузмасагыз, мине утыртачаклар.

—Миннән ярдәм?!—диде Сөембикә, чыннан да гаҗәпләнеп.—Фамилиягезне ишеткәлим, газеталардан да укыштырам. Бик югары хокук органында эшлисез...

—Анысы шулаен шулай...

—Димәк, һаман да гаепсезләрне утырту, гаеплеләрне коткару белән шөгыльләнәсез.

—Беләсезме, Сөембикә Даутовна, бу гөнаһлы җир йөзендә гаепле кешеләр юк. Камил булмаган законнар гына бар.

—Сезнең телегездән кайчандыр «Җинаять кодексының фәләненче статьясы, җинаять кодексының төгәненче статьясы», дигән сүзләрдән башка гыйбарә ишетелми иде.

—Сезнең үтенечегезне мин кире какмадым,—диде Янчурин, Сөембикәнең күзләренә туп-туры карап.—Менә хәзер үзем бик начар ситуациягә эләктем. Сез ярдәм кулы сузмасагыз, мине утыртачаклар. Дөресрәге, сезнең беренче секретарегызның йогынтысы кирәк.

—Юкәдә икән чикләвек!—дип куйды Сөембикә, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

—Минем язмышны хәл итүче кеше сезнең Шәрифуллин белән институтта бергә укыган, тулай торакта бер бүлмәдә торган.—Янчурин ул кешенең фамилиясен әйтте.—Шәрифуллин теләсә аңа йогынты ясый алачак.

Сөембикә кулларының гына түгел, бөтен гәүдәсенең калтырый башлавын тойды. «Күземнән югал!» дип кычкырып җибәрүдән аны ниндидер көч туктатты.

—Мине ришвәт алуда гаепләделәр,—диде Янчурин, башын аска игән хәлдә

авыр сулап.—Бернинди гаебем юк... Дошманнарым оештырды...

Сөембикәнең аны әллә ничекләр итеп мәсхәрәлисе килде, әмма тыелып калды.

—Ярый, сөйләшеп карармын,—диде.

Янчурин ишек тоткасына үрелде.

—Мин сезнең каршыда мәңгегә бурычлы булып калам.

—Бурычлы булмассыз, мин вакыты житкәч, сезне үзем эзләп табармын.

Сөембикә аның адресын, телефоннарын язып алды да, коридорда Янчуринның аяк тавышлары басылуга, тәрәзәне һәм ишекне киереп ачып жибәрде. Өстәлдәге кәгазьләрне жилфердәтеп, үтәли жил йөри башлады. Бүлмәне жилләтеп була, ә менә Янчуринның, үзен күңелдән берничек тә кырып ташлап булмый иде. Һич көтмәгәндә, уйламаганда килеп чыккан шеш кебек, ул ни үсмәде, ни тишелмәде, ничә еллар буе Сөембикәнең күңелен сызлатты да сызлатты... Бүлмә жилләгәч, ул ишекне япты да тәрәзә төбенә барып утырды. Аның уйлары шул ерак елларга юнәлделәр.

Сөембикә Кәшифулланың мәсхәрәләвен онытып бетереп килә иде ул чакта. Беркөнне фермада Фәйзрахман хатыны Кәримә белән әнисе канга батканчы сугышканнар. Ызгыш сыерларга бирәсе фураж аркасында чыккан. Кәримә, имеш тә аның әнисен фураж урлауда гаепләгән. Халык арасында: сәбәп анда түгел, әнисенең Фәйзрахман белән шаяруында, дигән хәбәр дә таралды. Кәримәнең бер кабыргасы сынып, больницага баруы хак иде. Ул әнисен судка бирде. Әнисеннән туктаусыз сорау алдылар, шаһитларны авыл Советына чакырып, эшнең ничек булганлыгын ачыкларга керештеләр. Әнисенә кимендә өч ел төрмә яный иде. Сөембикә белән алар икесе дә мичтә янган кара күмер кебек көйделәр, чөнки язмышлары упкын читенә килеп терәлде. Беркөнне әнисе фермада чакта Мөнир абыйсы Сөембикә янына керде.

—Эш бик житди төс ала. Кул кушырып утырырга ярамый,—диде ул, Сөембикәнең иңбашларыннан кагып.

Аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламакчы булып, Сөембикә Кәбировның күзләренә төбәлде.

—Нишләргә соң?

—Бүген тикшерүче монда. Ул ферма хатыннарын чакырта. Кеше беткәнен сагалап тор да янына кер. Коткаруын сора. Алар бит законны ничек телиләр, шулай боралар.

—Мине тыңлар дип уйлыйсыңмы?—диде Сөембикә аптырап.

—Тыңлатырга кирәк. Башка чара юк.

Кәбиров урыныннан торды, инде чыгарга кузгалгач, Сөембикәгә таба борылып:

—Яхшы киемнәреңне киен, бизәнебрәк бар,—диде. Сөембикә аның бу сүзләреннән аптырашта калды. Яхшырак киенеп, бизәнеп баргач, ни була инде бу? Абыйсының ни әйтергә теләгәнен ул аңлады да аңламады да кебек. Бизәнде, төзәнде, иң яхшы туфлиләрен киде, ләкин аягы тартмады. Урамга чыгып, авыл Советы тирәсенә барды, анда кергән-чыккан кеше күренмәде. Эченнән генә күз яшьләрен йотып, тагын кире борылды. Каршысына Фәһимә очрады, ул Әхнәфнең мотоциклына утырган иде. Алар ике мәртәбә кәлә-кәлә Сөембикәне урап әйләнделәр дә, нәкъ каршына килеп туктадылар. Аларның шул кадәр дә кәефле, шул кадәр шат булуларына Сөембикә көнләшеп карады, көчәнеп булса да елмаерга тырышты. Фәһимә аның хәлләрен сорады, кич килеп утырырга чакырды, мотоцикл белән район үзәгенә танцыга барырбыз, диде. Фәһимә Сөембикәләрнең нинди упкын читендә торуларын башына да китерә алмый, чөнки ул бәхет дингезендә рәхәтләнеп йөзә иде. Сөембикәнең икеләнүе юкка чыкты. Ул башын игән хәлдә жәһәт-жәһәт

атлап, авыл Советына юнәлде, тирән итеп сулыш алды да ишек шакыды. Тикшерүче Янчурин председатель өстәле артында утыра иде. Уң якта авыл Советы секретаре гарип куллы Камалиев нидер яза, ярты өстәлне алып торучы борынгы счет төймәләрен кәкре кулы белән чалт-чолт сала да нәтиҗәсен кәгазьгә язып куя.

—Мин Газизова кызы булам, сезнең белән сөйләшергә кирәк иде.

Янчурин дәшмичә аны баштан аяк карап чыкты да секретарьга таба борылды:

—Иптәш Камалиев, сезгә әбәткә кайтырга вакыт түгел микән?

—Ярый, ярый, хәзер...

Камалиев чыгып киткәннән соң, тикшерүче аңа урын тәкъдим итте. Янчуринның бөтен йөзе каз мае белән майлагандай елтырый иде. Хәтта борын астындагы нечкә генә матур итеп калдырылган мыегы да ялтырый. Иреннәрен теле белән әледән-әле ялаганлыктан алар гел юешләнеп торалар. Аның күз карашы Сөембикәнең йөзеннән дә, матур тез башларыннан да йөгереп-йөгереп узды. Ул ничек итеп сүз башларга белмәде. Тиешле сүзләр таба алмыйча шактый вакыт торганнан соң:

—Әнкәйнең гаебе юк, зинһар коткарыгыз, абый!—диде дә күз яшьләренә буылып еларга тотынды.

—Әниегезнең җинаяте кире каккысыз, аны ничек коткарыйм?

—Ул хатын бит үзе башлаган. Ул гомер буе әнинең күнеленә тоз салды. Иреннән көнләште бит ул.

—Ире Фәйзрахман килә идеме соң сезгә?

—Юк,—диде Сөембикә, кып-кызыл булып.

Фәйзрахманның килгәнен, әнисе белән эчеп тә утырганнарын белә иде ул. Ләкин бу хакта тикшерүчегә әйтәсе килмәде. Алай уйласаң, аларның өендә кереп салып утыручылар азмыни? Ирләре генә түгел, хатын-кызлары да җитәрлек.

—Син алдашасың!—диде Янчурин, аның күзләренә туп-туры төбәлеп.

Шунда Сөембикә аның күзләренең эчкә батканлыгын һәм хәтәр елтыравын абайлады.

—Мин сезгә дөресен әйтәм,—диде ул, үз тавышын үзе чак-чак ишетеп.

Янчурин, булмә буйлап йөри-йөри, аңа сорау арты сорау яудырды. Әнисе кемнәр белән аралаша, аларның өйләренә ир-атлардан һәм хатын-кызлардан кемнәр килә, җитәкчеләрнең булганы бармы, әнисе эчәме, аны кыерсытмыймы һәм башкалар, һәм башкалар. Сөембикәнең башы тәмам тубал булгач, ул сәгатенә карады да:

—Төш вакыты җиткән икән. Әйдә, мотоцикл белән район үзәгендә ашханәдә сыйлап алып киләм,—диде.

Сөембикәнең кашлары жыерылды, күзенә курку билгеләре чыкты.

—Юк, юк!—диде ул, ишек катына йөгереп.

—Кешеләргә ышанмыйсың икән,—диде Янчурин кисәтүле тавыш белән.— Сиңа бик авыр булыр ялгыз яшәве. Хатын-кызның бөтен бәхете ирләр белән уртак тел таба белүендә.

Тикшерүче тагын ниләр сөйләгәндер—Сөембикә ишетмәде. Ул күз яшьләренә буылган хәлдә урамнан өйләренә йөгерде...

Шуннан соң ничә көн үткәндер, анысын ул артык хәтерләми. Кич клубта район үзешчәннәре концерты бара иде. Бер егет үзенең җыры белән бөтен халыкны әсир итте. Моң дөньясына батып, күз яшьләрен сиздермичә генә сөртеп утырган Сөембикәнең иңбашына кемдер кагылды:

—Сине Кәбиров чакыра, чыгып кер әле.

Агыйделнең аръягында
Күлләр дингез түгел ул.

Берәү моңлы, берәү моңсыз—
Дөнья тигез түгел ул...

Җыр өзелеп калды. Клуб ишегеннән чыгу белән Мөнир абыйсы аны читкәрәк алып китте.

—Тикшерүче бүген монда, колхоз кунакханәсендә куна,—диде ул пышылдап.—Сина аның янына барырга кирәк.

Кәбировтан аракы исе килә иде. Сөембикә ачынып:

—Мин бит инде аның белән сөйләштем—файдасыз,—диде.

—Син башкача сөйләшеп кара. Иртәгә йә берсекөнгә Җәүһәрияне кулга алырга мөмкиннәр. Син моның ни икәнен аңлыйсыңмы?

—Ә ничек ул—башкача?

—Белмим, белмим!—диде Кәбиров, нишләптер аңа ачулангандай.—Бигрәк бала-чага буласың. Мин әле генә аның янында утырып чыктым. Кылын тартып караган идем, ул теләсә, барысын да эшли ала. Мина шулайрак тоелды. Җәүһәрияне дә, үзеңне дә коткару синең кулда. Әйдә, киттек.

Мөнир абыйсы кызу-кызу атлап, аны йөгертеп диярлек урам буйлап алып китте. Сөембикә кычкырып елый башлагач, шып туктады да инбашына төртеп куйды.

—Әйдә, елый бир. Менә шулай елап, әниеңне озатып калырсың. Икегез дә юкка чыгачаксыз. Уян, акылыңа кил!—Шулай диде дә Кәбиров китеп барды.

Ул үксеп басып тора бирде. Әллә яшькелт, әллә зәңгәрсу, әллә көмеш төсендә ай үзенең нурларын койды. Сөембикә җиргә төшкән шәүләсенә караган килеш үкседе дә үкседе.

Ул, үзләренең турына җиткәч, агач күләгәсе астында туктап, койма буендагы утыргычка утырды. Күз яшьләре кипкән, башы ничектер ачыграк эшли башлаган иде. Ана хәзер ихтыяр көче, тәвәккәллек кирәк. Сөйләшүнең ничек тәмамланачагын да ул якынча чамалый кебек. Аны менә шул куркыта да. Ниһаять, ул койманың күләгәле ягына чыгып, кешеләр күрмәсен өчен иелеп, кунакханә ягына атлады. Анда килеп җиткәч, тәрәзәдән төшкән яктылыкка карап туктап калды. Юк, бүген булмый. Иртәгә район үзәгенә барып күрергә. Ул шул уй белән тагын кире борылды, әмма каршысына көлешә-көлешә килгән яшьләр төркемен күреп, кире бөкләнде һәм кунакханә артына посты. Алар үтеп киткәч, тәвәккәлләп кунакханә ишеген какты. Янчуринның «Керегез!» дигән тавышын ишетүгә дер-дер калтырап кыюсыз адымнар белән эчкә узды. Ул ап-ак күлмәктән, кара галстуктан, кара трикодан иде. Бүлмә яхшылап җыештырылган, андагы караватларның өстенә ап-ак җәймәләр җәелгән, мендәрләр күпертелгән. Янчурин аны тересәгеннән йомшак кына тоткандай итеп кухняга алып керде, сый-нигъмәттән сыгылып торган өстәл янына утыртты.

—Сезнең эчегезгә салкын төшкән, бөтен тәнегез белән калтырыйсыз,—диде Янчурин, өстәлдәге башланган аракы шешәсен кулына алып.

—Миңа кирәкми, миңа салмагыз,—диде Сөембикә ялварып.

—Ул чакта ширбәт белән генә сыйлыйм,—диде Янчурин ачык елмаеп.

Ул, серванттан кызыл аракы алып, Сөембикә каршындагы бокалны күзеннән тутырып куйды.

Сөембикә торып басты:

—Мин сезгә үтенеч белән генә килгән идем...

—Үтенеч соңыннан. Бүген минем туган көн,—диде Янчурин, аны урынына утыртып.—Шул хөрмәткә шәраб эчеп куюдан баш тартмассың бит инде, Сөембикә?

Сөембикә күзләрен йомып, берничә мәртәбә шәрабне йотып куймакчы

булган иде, Янчурин үзенең кулы белән күтәрә-күтәрә аны эчертеп бетерде.

—Менә рәхмәт,—диде ул шоколад сузып.

Бераздан Сөембикә калтыраудан туктады. Ләкин анын башы коточкыч әйләнергә тотынды. Әйтәсе сүзен тизрәк әйтеп чыгып китмәсә, шушында егылыр кебек тоелды. Анын кызлар белән бергәләп мәҗлесләрдә, туган көннәрдә кызыл аракы капкалаганы бар иде, ләкин болай кинәт баш әйләндерә торганына беркайчан да туры килгәне булмады.

—Мин сезгә...—дип сүз башлады ул, ләкин теленең үзенә буйсынмавын тойды.—Ник килгәнемне беләсез... Мине... ятим итмәгез...

—Әниеңне коткару өчен Кәримә Шамгунованың гаризасын кире алдырырга кирәк. Син аның белән сөйләшә аласыңмы?

Сөембикә анын сүзләрен ниндидер бер битарафлык белән тынлады, әле сүзләр аңа кагылмыйлар, каяндыр читтән үтәләр, күңеленә төшмиләр иде. Ул торган саен авырая барган башын тоту өчен ияген учына куеп, терсәгенә таянды. Әмма кулы ычкынып, шапылдап өстәлгә төште. Ул йомылып барган керфекләре арасыннан Янчуриннын ут сүндерергә дип үрелгәнен күреп калды. Бүлмә кап-караңгы булды. Янчурин Сөембикәне күтәреп алды да зал ягына алып чыгып китте. Кыз нидер кычкырды, янады, ләкин ана каршы торырлык көче калмаган иде инде...

Сөембикә ничәдә кайтканын да хәтерләмәде. Анын келәне калай кисәге белән ачып кереп ятканын әнисе сизмәде дә. Шуннан соң ике-өч көн Сөембикә шомлы томан эчендә йөрде. Әнисенең эштән кайтуын коты алынып көтте. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кораллы милиционерлар килеп керер, дип хафаланды. Түзә алмагач, Мөнир абыйсына барды. «Сабыр ит, без уйлаганча барып чыга бугай»,—диде ул, аны тынычландырып. Көннәр уза торды, ахырда эшне яптылар. Аны беренче булып хәбәр итүче Фәйзрахман булды. Ул төнге уннарда тәрәзә шакып аларга килеп керде.

—Нәрсә булды, нишләп йөрисең?—дип ташланды аңа әнисе.

—Синнән мәгәрич,—дип шаркылдады кызмача Фәйзрахман.—Хатын гаризасын кире алган. Тикшерүче ничектер анын үзен куркыткан, миңа сөйләп бетермәде. Мәгәричеңне куй.

Әнисе мич астыннан алып бер чүлли чыгарды, алар шушы шатлыкны юарга өстәл янына утырдылар... Фәйзрахман үзе чыгарган көйгә үзе генә җырлый торган җырын урам буйлап җырлап кайтып китте:

Агыйделне буйлый-буйлый,
Килә аккош атучы.
Атма аккош, ат сандугач—
Шул безне саргайтучы...

Эшне япканнан сон, Янчурин мотоцикл белән аларга туктап, Сөембикәне район үзәгенә үзенең фатирына кунакка чакырды. Сөембикәнең хәйләсе әзер иде: авырыйм, миндә ниндидер үзгәреш бар, дип анын котын алып җибәрде.

Ничә еллар узды, күпме җилләр исте, тормышта күпме очрашулар, аерылышулар булгандыр, һәммәсе дә вакыт кочагында, еракта калдылар. Янчуринны да шулай дип уйлаган иде Сөембикә, ә менә алай түгел икән. Ул үзенең ялгызлыгынын сәбәбен аңлаган кебек булды. Анын тормыш көймәсенә Янчурин, Шәвәлиев кебек сигезаяклар, сөлекләр, хәшәрәт кабырчыклар ябышкан, алар аны акрын гына тормыш төбенә сөйриләр. Сөембикәгә беркем дә кул сузмый, ул нишләсә дә япа-ялгыз.

Анын елыйсы килде, үзен кемнәндер кызгандырасы килде. Ни аяныч, андый йомшак куллы кеше юк, иркәләргә теләүчеләр күренми. Ичмасам

ике күзенең берсеннән дә сыгылып сынар яшь тамчысы да чыкмый иде. «Әллә мин хатын-кыз булудан туктадыммы, бөтенләй тимергә әйләндемме?»— дип уйлады ул хафаланып. Кешелек калгандыр бит әле анарда. Ничек кенә күңеле теләмәсә дә, ничек кенә карышса да, Янчуринга ярдәм итәргә кирәк. Күрәсең, шушындый халәт, гел шушлай теләмәгәнне эшләү туганда ук аның маңгаена язылган. Инде өлкәнәеп барганда булса да, моның шулай икәнлеген аңлап, язмышка күнәргә, бернинди газаплар кичермичә, шул үзең теләмәгән эшне башкарырга, хәтта мең төрле чаралар, алдау-йолдаулар белән булса да башкарырга кирәк иде.

4

Эштән кайткач та, Сөембикә Янчурин турында уйланды. Мең кат үлчәгәннән соң, анык карарга килде: аны коткарырга! Айгөлгә урта мәктәп бетерергә дә күп калмый. Кая да булса укырга кертим дисәң, югары урында утыручы кодрәт иясе кирәк. Дошманмы ул, хәшәрәтме ул—Сөембикә өчен киләчәктә һичшиксез бер таяныч булачак. Күрәсең, пычракка кермичә яшәп булмыйдыр, тормыш кануны шундыйдыр. Хәер, кем белә, изге гамәлләр генә кылып яшәгән кешеләр бәлкем гомер юлларын да пакь килеш кичә алалардыр, илаһи биеклектә калып, бу дөньядан китеп баралардыр. Сөембикәгә андый язмыш турында хыялланырга да ярамый, бу мөмкин дә түгел иде инде ахрысы. Ирек белән аерылышкач, ул, Болынкырны ташлап, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ерак җиргә—Камчаткага ук китәргә карар кылган иде. Анда әнисе ягыннан туганнары яши, Сөембикә хат язды. Алар үз яннарына чакырдылар, эш тә күп, акчасы да әйбәт дигәннәр иде. Тик аны ин элек Айгөл куркытты. Ул бала татар тормышыннан, әтисеннән аерылып нишләр? Аны гомере буе каһәрләмәсме? Инде ниятләп бетерүгә, Ирекнең баш күтәрми эчә башлавы Сөембикәнең күңелендә әллә нинди давыллар кузгатты. Үз кызының әтисенең шушы хәлгә төшүендә ул гаепле иде бит! Уйлана торгач, Болынкырда калырга, ә элекке Сөембикәне үтерергә карар кылды. Гөнаһлы тәнгә пакь җан, саф рух индерәм, дип яшәде һәм бу карарыннан чигенмәде. Тик... менә бит юллар тагын ул теләмәгән якка сөйри һәм аларга буйсынмыйча булмый, күрәсең. Әхнәфкә кереп, барысын да җентекләп сөйләп бирергә, аның ярдәмен сорарга кирәк. Әхнәф турында уйлагач, ул ничектер күңелендә җинеллек тойды. Хәер, бу тойгыны Сөембикә генә түгел, районның барлык җитәкчеләре дә кичерә иде. Иң беренче эше итеп, ул куркыту дигән нәрсәне ташлады. Нинди генә авыр хәлләрдә дә, әллә нинди киеренке киңәшмәләрдә дә Арсланов кебек, җитәкчеләргә ырлап капмады, кешенең сүзен башына китереп суккандай бүлмәде, һәркемне зур сабырлык белән тынлады, күп кенә мәсьәләләрне уртага салып, үзе читтәрәк калырга тырышып, гомуми фикердән, киңәшләрдән чыгып хәл итәргә тырышты. Ул кадрлар алыштыру белән дә артык мавыкмады. Арсланов кырыннан чыкмыйча ана ялагайланган, гомере буе кемнәрнедер әләкләп, кемнәрнедер сатып көн күргән Өлфәт Җәмилев кебекләргә дә кагылмады, халык арасында Әхнәф Шәрифуллинның, «кадрлар белән уйнарга ярамый, һәркемнең гаиләсе бар, әти-әнисе бар, балалары бар, әгәр кеше ялгышкан икән, аны төзәтергә тырышыйк», дигән сүзләре афоризм кебек йөрделәр. Үзенә икенче секретарь итеп ул Наратбашта эшләп киткән Зәйнуллинны алды. Күпләр башта анардан химик дип көлеп маташсалар да, бу егет кешеләрне тирән аңлый торган, йомшак күңелле, мәдәният, матбугат, медицина, көнкүреш мәсьәләләрендә дә бик тирәнтен белеп фикер йөртә торган җитәкче булып чыкты. Аның да эш стиле, беренче секретарьныкы кебек үк, үзара аңлашуга, киңәшүгә корылган иде. Райкомның оештыру бүлеге мөдире итеп Фәнис Сәлахованы куйгач, җитәкчеләр, Шәрифуллин ТИҮ белән ныклап торып никахлашырга уйлый, ахрысы, дип

сөйләнә башладылар. Бу сүзләрдә шатлану күбрәкме, әллә иронияме—монысын әйтү кыен иде. Май ахырында ук Болынкырның нәкъ урта бер жирендә хуҗасыз ике йорт урынына Әхнәф, сайлаучылар алдында биргән вәгъдәсен үтәп, балалар яслесе салдырта башлады. Бусы инде яшь гаиләләрне һәркөн иртә-кичен Әхнәф Шәрифуллинны рәхмәт хисләре белән искә алырга, әби-бабалары, ата-аналары тарафыннан аның исәнлегенә дога кылырга мәҗбүр итте. Ул бөтенесен тәмам туйдырган, көненә әллә ничәшәр мәртәбә үткәрелүче һәртөрле җыелыш-киңәшмәләрне җыюдан туктады, житәкчеләр рәхәтләнеп, киң сулыш алып эшли башладылар. Фермаларга, игенчелек буенча колхоз-совхозларга вәкилләр куу, аларны бастырып сорау алу дигән нәрсәләр бетте. Аның бүлмәсенә кергәндә калтырап торулар, йөрәк даруы кабулар да онытылды, житәкчеләр беренче секретарь белән үзара рәхәтләнеп киңәшеп, үз фикерләрен курыкмыйча әйтеп сөйләшеп була, дип уртак куанычларын белдерәләр иде.

Сөембикәнең үтенече бик четрекле булса да, Әхнәф янына кыенсыну тойгысы кичермичә, тыныч күңел белән керде. Ул аны өстәл артыннан чыгып каршылады. Житез адымнар белән килде дә җиңелчә генә терсәгенә кагылды һәм, бүлмәнең түренә алып барып, үзенең каршына утыртты.

—Йә, ни хәлләрдә яшәп ятасыз?

Сөембикә серле генә елмайды да:

—Барына канәгать, югына сабыр итәбез,—диде.

—Бу тормыш әллә ниндигә әйләнеп китте бит әле, Сөембикә.—Әхнәф, гаепле кеше кебек, як-ягына каранып алды, уң кулы белән чәчләрен артка сыпырды.—Заманында бик аралашып яши идек. Хәзер килеп тә чыкмыйсын. Фәһимә белән әллә урамда гына очрашасыз инде?

Сөембикә ана ни әйтергә дә белмәде. Әхнәф беренче секретарь булып сайланганнан соң, Фәһимә алыштырган кебек үзгәрде дә куйды. Аның адымнары салмакланды, гәүдәсе турайды, күз карашы, ничектер сиңа кагылмыйча читтән генә үтеп, бик еракка, әллә кая юнәлә торганга әйләнде. Монын шулай икәнлеген элек аралашкан хатын-кызлар үзара хәйран калып сөйләшсәләр дә, Сөембикә үзенә карата Фәһимәнең алай кылануын сизмәде сизүен. Шулай да ул элекке Фәһимә түгел иде. Очраган саен хәл сораша, Ирек белән үзара мөнәсәбәтләрен төпченә. Эштән башка аралашмыйбыз, дигән сүзне ишетсә, Сөембикәне кызганырга тотына, төрлечә юата, хәленә керә. Ә Сөембикәнең һич тә үзен анардан кызгандырасы килми. Шул ук вакытта элеккеге дустының кызгануларына каршы куярлык дәлил дә таба алмый. Нинди дәлил табасын? Ул ирсез, ул ялгыз, ул берүзе кыз үстерә, башкалар белән, бигрәк тә Фәһимә белән чагыштырырлык та түгел. Дустының кызгануларыннан туеп, Сөембикә мөмкин кадәр аның белән очрашмаска тырыша.

Әлбәттә, Әхнәфнең соравы урынлы, бәлки ул бу мәсьәләне Фәһимәнең башкалардан бик кинәт, күзгә күренерлек дәрәҗәдә аерылуын күреп кузгаткандыр. Хатынының башкаларга югарыдан каравы аны бит һич кенә дә бизәми, киресенчә, күпмедер дәрәҗәдә абруена китереп суга.

—Тормыш та үзгәрә, үзебез дә картаябыз бугай,—диде Сөембикә ихлас күңелдән.—Хәзер сер капчыкларын уртага куеп, туйганчы бушатын утырырга әллә вакыт юк, әллә монын кызыгы бетте инде.

—Син Фәһимәне ташларга тырышма,—диде Әхнәф.—Талпынып һавага оча башласа, аягыннан сөйрәп төшер.—Ул сәгатенә карады да:—Йомышыңны әйт,—диде.

Сөембикә ана Янчуриннын махсус килүен, бәлагә таруын һәм аны коткару өчен Әхнәфнең кем белән сөйләшеп ярдәм итә алачагын аңлатты. Аны тыңлап бетергәч, Әхнәф шактый вакыт дәшми утырды, аннары әллә ничек, мыскыллау

чалымнары белән елмайды:

—Заманында ул минем әнине төрмәгә утырудан йолып калды. Мин аның каршында мәңге бурычлы,—диде Сөембикә.

Әхнәф галстугын бушатып куйды, учлары белән йөзен, муенын сыпырып алды.

—Синең өчен җаным-тәнем белән нindидер яхшылык эшлисем килә.—Ул торып өстәл тирәсендә йөргәндәй итте.—Тик беләсеңме, без Янчурин белән ул заманда якага-яка килеп туктадык бит. Әгәр шулай булмаса, ул сиңа түгел, туп-туры минем үземә килгән булыр иде. Янчурин «Сельхозтехника»—да эшли торган бер комсомолыбызны төрмәгә тыкты. Гел юктан җинаять эше әвәләп. Егет ике ел утырып кайтты. Без аның белән очрашкач, Янчуринның әлеге егетнең хатыны артыннан сөйрәлгәнен, аны юлыннан алып ату өчен төрмәгә утыртканын белдем. Син шуны коткарырга кушасың.

—Мин аңладым,—диде Сөембикә, чыгарга әзерләнеп.

—Уйлыйм әле, Сөембикә, үз-үземне җиңсәм дә синең хакка гына җинә алырмын...

Сөйләшү шуның белән тәгәлләнде.

...Ирек райкомның кабул итү бүлмәсенә нәкъ чакырылган вакытка килеп керде. Гадәттәгечә, халык күп иде. Ул таныш-белешләре белән күрешкән, хәл-әхвәл белешкән арада Әхнәф бүлмәсеннән Сөембикә чыкты. Секретарь кыз шундук Ирекккә керергә кушты. Алар кочаклашып күрештеләр.

—Иҗатыннан бүлгән булсам, гафу ит, дустым,—диде Әхнәф, аңа урын күрсәтеп. Үзе түргә үтмәде, Ирекнең янәшәсенә утырды.

—Бу арада иҗат эшләре бакча тирәсендәрәк йөри әле,—диде Ирек, аның сөрмәле зәңгәр күзләренә туп-туры карап.

—Ә син язны ычкындырма, синең ындыр артында табигатьнең чын мәгънәсендә туй иткән чагы. Иҗат кешеләре илһамны шуннан алалар, диләр. Дөресме?

—Минем өчен алай түгел бугай ул. Көн саен эшләгәндә генә илһам килә.

—Дөрес әйтәсең, иҗат кешеләренә дә үзләрен билгеле бер рамкада тотар өчен көн саен эшли торган эш кирәк, дустым,—диде Әхнәф, кулын аның инбашына салып.—Минем читтән редактор китертәсем килми. Алын шул эшкә зинһар өчен.

—Без бит бу хакта сөйләштек инде, Әхнәф.

—Сөйләшүен сөйләштек, аннан соң күп сулар акты, язгы җилләр исте, чәчелмәгән басулар чәчелеп, игеннәр шытып чыкты. Бөтен дөнья үзгәрә, синдә дә нindидер үзгәреш булырга тиеш бит инде.

—Юк, Әхнәф, мәҗбүриләмә,—диде Ирек, аның кулын инбашыннан алып.

—Соң эшсез ята алмыйсың ич инде син. Әрәм тамак, дип, закон нигезендә җавапка тарттырам мин сине.

Әхнәф рәхәтләнеп көлеп җибәрде, Ирекнең инбашына җиңелчә генә төртеп алды.

—Эшләргә кирәк, әлбәттә. Ә редакциягә килгәндә... Беләсеңме, теге вакытта Арсланов районнан куган Мәкъсутов Чаллыда эшли ди бит. Чакырт шуны. Бер дигән редактор ул.

—Ярый, ярый, уйлашырбыз,—диде Әхнәф сак кына.—Алайса мин сиңа бик тыныч эш тәкъдим итәм. Безгә музей директоры кирәк. Бинасы иске, акрынлап ремонт та ясарбыз. Алынасыңмы?

—Менә анысы хакында уйлап карармын,—диде Ирек.

—Әгәр син анда эшләсәң, акрын гына район тарихын да яза башларга кирәк иде. Гомер уза бит.

—Шушы изге ниятең өчен генә дә мөгаен ризалашырга туры килер,—

диде Ирек елмаеп.

Әле өлкә комитетыннан, әле башка җирләрдән телефон шылтыравы аларга озаклап әңгәмә корырга мөмкинлек бирмәде. Ирек чыгып китү белән Әхнәф Гаскәровка шылтыратты.

—Сәет Мөбәрәкович, сез бу Ирек Сабитовка квартира мәсьәләсендә берәр карарга килдегезме?

—Юк әле,—диде Гаскәров.

—Һаман сузыла бит. Ничек тә хәл итәргә кирәк инде. Сөйләшкән вариантларның берсен сайларга вакыттыр.

—Ярый, бу атнадан да калмабыз.

«Ирек Сабитов, Ирек Сабитов»,—дип кабатлады Гаскәров авыз эченнән. Күнелен авырттырып нәрсәдер кыймылдап куйгандай булды. Үзе янына чакыртырга, сөйләшергә кирәк. Бәлкем бүгеннән калдырмаска да кирәктер. Ул Ирекнең башкарма комитет бинасында дежур торган чакларын күз алдына китерде. Сакларга тырышты, барып чыкмады. Ә шулай да Гаскәров аңа хөрмәт белән карый. Эштән киткәннән соң, аның турында әйбәт булмаган сүзләрне дә шактый ишетергә туры килде. Ә нигә чакыртырга соң әле аны? Барырга да кайтырга.

Кич эштән соң үзе генә машинага утырып, ул кайчандыр апасы яшәгән таныш йортның капка төбенә килеп туктады. Аның килеп керүен күргәч, Ирек белән Зәнфирә каушап киттеләр. Өстәл артында язып утырган җиреннән Ирек кабаланып аның каршына чыкты.

—Әйдәгез, рәхим итегез,—диде Зәнфирә түргә чакырып, нишләргә белмичә, ул арада өстәл әзерләргә кереште, Ирек, өстәлдән язуларын җыеп, шкафка куйды.

—Зинһар өчен бер нәрсә җыймагыз, бер нәрсә әзерләмәгез,—диде Гаскәров.—Мин хәл белергә генә кердем.

Шулай да Ирек аның плащын салдырып чөйгә элде. Алар өстәл янына кара-каршы утырдылар.

—Ни хәлләрдә яшәп ятасыз?

—Рәхмәт, Сәет Мөбәрәкович,—диде Ирек. —Зарланыр әйбер юк.

Гаскәров күзе белән өйнең һәр почмагын карап чыкканнан соң:

—Мин үземне сезнең алда гаеплегә санап йөрим,—диде.

Ирек баш чайкап куйды:

—Алай димәгез. Минем өчен мөмкин булмаганны да эшләдегез. Сезгә мин гомерем буе рәхмәтле. Ә упкынга мин үзем төштем. Сез кисәтә килгән упкынга төштем.—Ирек башын иеп тынып калды. Аннары ул, урыныннан торып, Зәнфирәне өстәл янына алып килде.—Ул упкыннан мине менә шушы изге җан тартып чыгарды. Ничек сабырлыгы, көче җиткәндер.

Зәнфирә бурлаттай кызарды:

—Йә инде, Ирек, кирәкми,—диде ул пышылдап.

—Мин аны синең үзенә әйтә аламмыни? Ичмасам Сәет Мөбәрәкович белсен.

Зәнфирә кызык кына итеп кулын селтәп җибәрде дә:

—Үлән чәе белән сыйлыйм әле үзегезне,—дип кече якка атлады.

—Үлән булса, эчәм. Болай, чәйне өнәмим мин. Дөресрәге, врачлар эчмәскә кушалар, йөрәк шаяра.

—Ә менә бу чәй йөрәкне тынычландыра,—диде Зәнфирә, икесенең дә алдына тулы чынаяк куеп.

Шунда ук бал, конфет, вареньелар да пәйда булды.

—Чын бальзам белән бер бу сезнең,—диде Гаскәров, чәйне тәмләп чөмерә-чөмерә. Аннары бер түшәмгә, бер идәнгә карап, уйчан гына сүзен дәвам итте:—Апаның өе дә таушалган икән. Тәбәнәкләнгән. Сезгә торыр урын

кирәк булачак бит инде.

—Үз өен—агач кашыгың,—дип куйды Ирек елмаеп.

—Сезгә Әхнәф Хәсәнович үзләренен өен тәкъдим иттем, дигән иде. Алар көзгә Арслановныкына күчәчәкләр. Минемчә, сезгә дә күчәргә кирәк.

—Без андый йортка ничек керик инде, Сәет Мөбәрәкович?

—Андый йорт? Ул да әллә кайчан салынган. Гади генә авыл өе. Мөмкинлек барында керергә кирәк.

—Унар ел чират көтүчеләр бар бит.

—Бар, Ирек Хәйриевич, бар! Иҗат кешесенә без аерым шартлар тудырырга тиешбез югыйсә.

—Анлык иҗатым юк минем. Сизеп торам, сез Әхнәф кушуы буенча килгәнсез.

—Үз талантыгызны үзегез бәяләп бетермәвегез кызганыч. Үкенмәссезме икән?

—Үкенерлегенә үкендем бугай инде.

—Яхшы булып күренү, яхшы булып кылану заманнары үтеп бара, Ирек Хәйриевич.

—Сез дә шушы сүзне сөйлисезме?!

—Метафора буларак кабул итегез. Иҗат кешесе метафораларны дөрес аңлап, дөрес бәяли белергә тиеш.—Гаскәров чәен кабып, әллә аның тәмен тоярга теләп, әллә югалган фикер җебен эзләп, шактый гына утырды, аннары әллә нинди сак, кисәтүле тавыш белән дәвам итте:—Өстә ниндидер житди үзгәрешләр бара, ил буенча... Таныш булмаган җилләр исә... Кеше күңелен киптерүче җилләргә охшаган.

—Мин тормыштан шул кадәр аерылдым микәнни?—дип куйды Ирек, үз-үзеннән сорагандай.

—Сез хыял белән яши торган халык. Ә хыялны кысрыклый торган нәрсәләр арта бара. СССР дигән гранит кыяны да селкетә башладылар. Гариза биреп партиядән чыгуларның да булганы юк иде. Бөтен системаның асты өскә килергә мөмкин. Әгәр шулай булса?.. Ярык тагарак кырында калмагыз, диюем.

Гаскәров урыныннан торды. Ирек аны озатып кергәндә, Зәнфирә бик күңелсез утыра иде.

—Нәрсәгә кәефең кырылды?—диде Ирек, аның иңбашларына кулын салып.

—Мин сине аңламыйм, Ирек.—Зәнфирә аңа туры карамады, үпкәләгәндәй йөзен тәрәзәгә таба борды.—Әллә артык кыланасың? Быел кышны да ничек чыкканыбызны беләсең. Бәрәңгеләргә салкын тиеп бетте. Әҗәттән башка акча күрәсебез юк.

Гаскәровның килүе Ирекнең кәефен күтәреп җибәргән иде. Шуна күрә ярым шаяртып, ярым чынлап болай диде:

—Кайгырма юкка, карчык. Минем Минзәлә театрындагы пьесам чыкса, аны культура министрлыгы әйбәт кенә бәягә сатып алса, пьеса куюдан гонорар килеп торса, тотарбыз да бер өй сатып алырбыз.

Тик хатынының йөзе тагын да караңгыланды. Ирек кисәтүле тавыш белән болай диде:

—Алтын өйдән баш кыйбат. Ишетәсеңме?

Зәнфирә дәшмәде.

## 5

Арсланов акрынлап шәһәр тормышына күнегә башлады. Министрлар Советы аппаратында аның элекке танышлары, пенсиягә чыккан партия-совет җитәкчеләре шактый иде. Биредә авыл райкомындагы сыман иртә таңнан төнгә кадәр чабу, нервы туздыру дигән нәрсәләр юк, кешеләр бер-

берсе белән бик җылы мөнәсәбәттә, ниндидер йомышың бар икән, берәрсенә әйтеп китәсең дә барасың. Ярты көн йөрисеңме, артыгракмы—сиңа үпкә белдерүче юк. Өч бүлмәле фатирда Эльза белән ире тора иде. Әтиләре Казанга күчкәч, кияү кеше үз йортларына кайтырга ниятләде. Ләкин Минзаһит аның әти-әнисе янына ашкынудан түгел, ә бәлки үзенең килүе аркасында гына биредән кузгалырга теләвен яхшы аңлады. Хәят әле Болынкырда иде. Шуңа күрә «бу ялан кадәр фатирда берүзең хыялланып үләргә кирәк бит», дигәч, алар бергә яшәргә риза булдылар. Өчәүләшеп эшкә чыгып китәләр, өчәүләшеп кайтып керәләр.

Беркөн Эльза аңа газета алып кайтып бирде: «Укы, кешеләрнең ничек яшәүләрен күр әнә»,—диде. Газетаның икенче битен тутырып, Ирек Сабитовның «Болынкыр таңнары» дигән язмасы урнаштырылган иде. Анда Шәрифуллинның эш стиле сурәтләнгән, районда кузгатылган зур-зур эшләр күрсәтелгән. Кыска гына арада файдалануга тапшырылган ясленең, анда тәрбияләнүче балаларның, яңа күтәрелүче төзелешләрнең фоторәсемнәре урнаштырылган.

Минзаһит бу мәкалә тәэсиреннән күп вакытлар айный алмады. Болынкырга ул атна саен диярлек кайта, кайткач, урамда бик үк күренәсе килми иде. Инде хәзер гомумән чыгарлыгы калмады.

Алар Хәят белән әйберләрен акрынлап барлыйлар, яхшылап бәйлиләр, тутырырдаен капчыкка тутыралар. Бу ялда да ике көн буе әйбер җыйнап эт булдылар. Минзаһит әле тагын өч көнгә Болынкырда калырга рөхсәт сорап та кайтты. Һич югы октябрь башларына күченергә кирәк иде.

Алар энгер-менгер төшкәндә генә өйгә керделәр. Хәят чәй куйды, ашарга көндез пешергән пилмәнне кайнарлады. Инде өстәлдән кузгалып кына китәбез, дигәндә ишек шартлап ачылып китте.

Ишек кыңгыравына басмыйча берәүнең дә кергәне юк иде. Аптырашып, икесе дә урыннарыннан тордылар һәм өнсез калдылар: ишектән керүче бер кулына дипломат, икенчесенә юл сумкасы тоткан Рашат иде.

—Исәнмесез, көтмәгән идегезме?—диде ул, дипломаты белән сумкасын идәнгә куеп. Аннары, үрелеп, ярым ачык калган ишекне япты.

Миңзаһит кулын сузып аңа атлады. Алар салкын гына күрештеләр. Хәят, урыныннан кузгала алмыйча, очып китәргә теләгәндәй, кулларын күкрәгенә куеп, терсәкләрен җәйгән, күзләре зур булып ачылган, иреннәре калтырый һәм бөтен өйгә ишетелерлек итеп сулыш ала иде. Кинәт ул аякларын бөгеп чүгәләгәндәй итте дә идәнгә егылды. Минзаһит йөгереп барып аны күтәреп алды һәм үз бүлмәсенә атлады. Аның артыннан ияргән Рашат әнисенең пөхтәләп җыелган йокы караваты өстендәге эш планы дәфтәрләрен читкә алуга, Миңзаһит Хәятны шунда китереп салды. Рашат кухняга чыгып салкын су алды, учына салып әнисенә су сипте, Миңзаһит аны читкә этәрде дә, мамык белән нашатырь спирты алып, Хәятның борынына китерде. Ул шундук күзләрен ачты. Мондый чакта нишләргә кирәген белгән Миңзаһит, аның халат кесәсеннән ингаляторын алып, авызына берничә мәртәбә өрдергәч, йөрәк даруы эчергәч, Хәятка ныклап торып җан керде. Миңзаһит аны иңбашыннан күтәреп утырткандай итте, аркасы турына икенче кулы белән мендәр салды. Рашат ашыгып чыгып китте, сумкасыннан абрикос согы тутырылган шешә алып керде. Әнисенә бокалга салып сок сузды. Хәят иреннәрен бераз ачкандай итте, бокалның чите аның тешләренә тиде, ләкин ул авызын ачмады, тамак төбеннән әллә нинди өзек куркыныч тавыш кына килде һәм ул калтыранып елый башлады. Рашат бокалны читкә алып куйды. Бераздан Хәят тынычлангандай булды һәм:

—Бар, ашат баланы...—диде.

Алар кухня ягына чыктылар. Рашат өстәлгә үзе алып кайткан апельсин,

мандарин, виноград кебек күчтәнәчләрне таратты, колбаса кисте, бер коньяк чыгарып утыртты. Зур гына тәлгәш виноградны юып килде дә аның бер өлешен, чәй тәлинкәсенә салып, әнисенә алып кереп китте. Карашын каядыр почмакка төбәп утырган Хәят аны күрү белән күзләрен йомды.

—Әни, менә виноград кабып кара әле...

Хәят тәлинкәне кулына алды һәм, бар чык, дигән мәгънәдә кулын ишеккә таба селтәде. Рәхмәт тә әйтмәде, дип уйлап куйды Рашат. Ул кергәндә, Минзаһит рюмкаларга коньяк салган иде инде.

—Әйдә, с приездом!—диде ул малаена. Чәкештерделәр дә җинел генә эчеп куйдылар. Шунда әтисе нишләптер зал ягына чыгып китте. Бераз торгач, Хәят бүлмәсенә үтте, аннары кабат кухняга керде. Аның күзләре дымланган иде. Бусында алар Рашат тотырып куйганны эчтеләр.

—Ни хәлләрдә ятасыз сон?—диде Рашат, суган белән колбаса чәйни-чәйни.

—Безме? Без менә шушылай инде...—Минзаһит сүзен әйтә алмады, улын кочаклап алды һәм тавышсыз гына еларга кереште.

Рашат аны читкә этте:

—Әртисләнмә әле, җенем сөйми!

—Нәрсә?!—дип пышылдады Минзаһит. Ул тозлы күз яшьләренен ирен читләреннән йөгереп авызына керүен сизде.—Син мина ышанмыйсынмыни?

—Мин күз яшьләрен күреп туйдым инде, чынын да, ялганын да.—Ул җәһәт кенә рюмкаларны тутырды да шешәне шапылдатып урынына утыртты.—Күз яшьләре күрергә дип кайтмадым мин.

Арсланов, шулай йомшап китүенә хәйран калып, үзен-үзе тиргәп утырды. Малаена болай җебеп төшүен һич тә күрсәтәсе килми иде. Рашатның соңгы сүзләре аның күнелен айкалдырып-чайкалдырып җибәрделәр.

—Күз яшьләрен күрәсең килмәсә, вакытында кайтырга идең!—диде ул, йодрыгы белән өстәлгә сугып.—Һич тә булмаса исән икәнеңне белдерергә идең!

—Әгәр белдерергә ярамаса?

—Андый нәрсә булмый! Болар барысы да боргалану, җавантан качу,—диде Арсланов бармак селкеп.

Аннары ул тагын җәһәт кенә Хәят янына чыгып керде. Ул кергәндә, Рашат рюмкасын аударып куйган иде инде. Минзаһит үпкә сүзләрен тезүен дәвам итте:

—Мин сине ничекләр генә эзләмәдем! Укуыңны ташлагансың. Ярар, анысына кул селтәдек. Бөтенләй хәбәрең ишетелмәгәч, хат яздык, моннан барган инструктор кереп чыкты. Квартира хуҗаларың кайдалыгыңны белми. Кеше шулай яшиме сон?

—Яши бит. Мина сезнең белән элемтә тотарга ярамый иде. Исәнлегегезне саклау өчен.

—Сакладың, сакламый ни! Чамалыйм мин синең кайда булганыңны. Мин коткармасам, әле һаман да чыга алмаган булыр идең.

Аның бу сүзләреннән Рашат сискәнеп китте.

—Ничек коткардың син мине?

—Килделәр мина...

—Кемнәр?—диде Рашат пышылдап.

—Белмим. Берсе озын гәүдәле, озын башлы, ап-ак чырайлы, куркыныч күзләре эчкә баткан.

Аның һәр сүзеннән Рашат куырыла барды һәм акрынлап урыныннан кубып, аягүрә басканын сизми дә калды.

—Тагын кемнәр?—дип сорады ул, Минзаһитның йөзенә йөзен якын китереп.

—Берсе тәбәнәк буйлы. Дүрт менне биреп җибәрергә туры килде...

—Соң бит сине алдаганнар!—диде Рашат кычкырып.

—Тсс, шаулама! Бу хакта әниең белсә, хәзер йөрәге ярыла.

Рашат шактый вакыт хәрәкәтләнмичә, уйланып утырды.

—Ярый, мин сиңа аны биш мең итеп бирермен,—диде ул.

Миңзаһит тагын Хәят бүлмәсенә юнәлде, аңа Рашат та иярде. Хәят мендәрен җайлап салган да йоклап киткән иде. Рашат әнисенең бер генә виноградны да өзеп капмаганын күрде. Алар утны сүндереп, аяк очларына гына басып, кухняга чыктылар. Сөйләшер сүз калмаган иде инде.

—Мин ике төн йокламадым, берәр җиргә урын салып бир әле,—диде Рашат .

—Үзеңнең бүлмәңә кер, анда һәммә нәрсә бар.

Рашат, дипломатын алып, бүлмәсенә үтте. Чыннан да ул нәкъ элеккечә. Әйтерсең лә Болынкырдан чыгып киткәндә ничек җыештырып калдырган, шул хәлендә аны көтеп торган. Бераз гына ниндидер тынчу ис кенә килгән сыман. Ул тәрәзәне ачып җибәрде, әйберләрен тиз-тиз анда-монда ыргыткалап, урынны җәйгәндәй итте, дипломатыннан бер төргәк акча алды да, залга чыгып, әтисенә сузды:

—Менә монда биш мең.

Миңзаһит акчаны шикләнеп кенә алды. Ялган түгелме дигәндәй, әйләндереп-әйләндереп карады.

—Нинди эштә эшлисең соң син?

—Акчаң күп, дип әйтмәкче буласыңмы?

—Әйе, шулай дип әйтмәкче булам, Хәрам акча килешми ул безгә.

Рашат әллә нинди гырылдавык тавыш белән көлеп җибәрде:

—Райком секретаренең хәләл акчасы буламыни? Син аны берәр авыл гыйбадына сөйлә инде,—диде дә бүлмәсенә кереп китте.

Миңзаһит сүзсез генә чыгып китте. Ул, әле Хәят бүлмәсенә кереп, әле залда телевизор карап, Рашатның бүлмәсеннән ишетелгән гырылдауны тыңлады, төнге берләргә кадәр керфек тә какмады.

Иртән Хәят мәктәпкә киткәндә, Рашат йоклап калды. Ул көндез генә торды, башын төзәтә-төзәтә ашады. Миңзаһит алып китәсе әйберләрне җыештыру белән мәшгуль иде. Рашат белән бергәләп зал ягындагы зур сервантны сүттеләр, шул чакта Рашат аңардан ничек эштән алулары турында сорады. Миңзаһит сөйләп биргәч, янагын чәйни-чәйни:

—Әхнәфне тотып ярыйммы соң?—диде. Миңзаһит аңа усал итеп карады:

—Син монда джунгли законнарыңны оныт!

Алар өчәүләп табын янына утырдылар. Шактый вакыт сүзсез генә ашап-эчкәч, әнисе Рашатка:

—Йә, сөйлә: кайда йөрдең? Ник безгә берниндидә хәбәр бирмәдең?—диде, ачулы күзләрен елтыратып.

—Миңа чит илгә чыгып китәргә туры килде. Бер фирма акчалы эш тәкъдим итте.

—Кайда инде ул?

—Сүриядә.

—Синең бит берниндидә һөнәрең юк,—диде Хәят.—Син анда нишли аласың?

—Кеше эшләмәгән эш юк бит, өйрәнергә туры килде. Измә дә ясадым, кирпеч тә салдым.

Хәят кулындагы чәнечке-пычакларын шалтыратып өстәлгә атты да:

—Ялган, һәр сүзең ялган!—диде.

Аннары үкереп елап, Рашатны уңлы-суллы яңаклый башлады. Ул күзен йомган хәлдә, селкенмичә утыра бирде. Хәят ярсыганнан-ярсый барды.

—Беләсеңме син безне вакытыннан алда гүргә керткәнеңне?! Син хайван

өчен бөтен йөрәгебезне бетердек, елап сукыр кала яздым!

Рашат дәшмәде, Хәят, куллары тәмам авырткач, туктады да тагын бүлмәсенә кереп ятты. Рашат, шуны гына көткәндәй, сикереп торып киенергә кереште. Әйтерсең, аның өчен Минзаһит бөтенләй юк иде.

—Кая барасың?—диде ул ачу белән.

Рашат киенеп беткәч, дипломатын кулына алды.

—Ник җавап бирмисең?

—Урап кайтам әле...

## 6

Урамда кичке утлар кабынган иде инде. Рашат, беренче секретарь бүлмәсенең тәрәзәләрен күзәтә-күзәтә, әллә ничә мәртәбә райком тирәсеннән үтте. Ниһаять, берәм-берәм утлар сүнеп, сәгать алты тулгач, райком ишегеннән җәйге пәлтә, эшләпә кигән Әхнәф килеп чыкты. Ул баскычтан төшеп уңга борылуга, Рашат аның каршына килеп басты:

—Нихәл, иптәш секретарь?

Аның каш астыннан гына карап, теш арасыннан сыгып әйтелгән бу сүзләре Әхнәфне куркытып җибәрде, ул артка чигенеп, куйды. Ниһаять, танып алгач:

—О-о-о, Рашат! Нинди җилләр ташлады?—дип ана кул сузды.

—Заман җилләре.—Рашат аны култыклагандай итеп:—Бәлкем серләшә-серләшә урам әйләнербез?—диде.

—Юк, алай булмый.—Әхнәф көчәнеп елмайды.—Син кунак кеше. Минем бүлмәгә керик.

Бүлмәгә кергәч, хөрмәт күрсәтеп, Әхнәф аның киемнәрен, үзе шифоньерга элде, кунак бүлмәсенә алып кереп, түрдәге йомшак кәнәфигә утыртты, суыткычтан азык-төлек чыгарды. Рюмкаларга аракы салды.

—Йә, синең тәмам Мәскәү кешесе булуың өчен!

—Юк, моның өчен эчмибез,—диде Рашат.—Бу ялган тост була.

—Ничек инде алай?—диде Әхнәф гаҗәпләнеп.

—Анысын соңрак әйтермен. Беләсеңме, без моны синең тагын да югарырак баскычка күтәрелүең өчен эчәбез.

Әхнәф, кунакның сүзләрендә нинди кинаяә ятканын аңласа да, каршы килеп сүз әйтүне кирәк тапмады. Бераз капкалаганнан соң, Әхнәф рюмкаларны тагын тутырды да:

—Нишләп соң әле син Мәскәү кешесе булуга каршы килдең?—диде.

—Тотып куйыйк, аннары җавап бирермен.

Бу юлы эчкәч, Рашат бер әйбер дә капмады, урыныннан торып әйләнеп килде дә шапылдатып кулын Әхнәфнең иңбашына салды. Әхнәфнең тәне эсселе-суыклы булып китте, тез буыннарын калтырау алды. Ул авырлык белән генә аягына баса башлады. Әмма кунакның кургаштай авыр кулы аны дыкылдатып урынына утыртты. Аның кыргый җанварныкы төсле рәхимсез күзләрен күреп, Әхнәфнең коты очты. Рашат, ташланырга әзерләнгәндәй астыртын елмаеп, кузгалып чыгып китәрлек араны томалап кәнәфиен аның каршына ук шудырды, тезен Әхнәфнең тезенә терәп килеп утырды. Әллә нинди салкын, астыртын, кинаяле тавыш белән сүз башлады:

—Миңа хәзер җавабын бирәм. Беләсеңме, Әхнәф Хәсәнович, безнең әти-әниләр Казанга күчеп китә бит.

—Әйе,—диде Әхнәф сагаеп.

—Ә миңа мин күчәргә теләмим. Болынкырда яшисем килә.

—Син бит Мәскәүдә яшисең.

—Ялгышмагыз, Әхнәф Хәсәнович, мин Болынкырдагы йортка язылган, пропискадан төшкәнем юк.—Ул паспортын чыгарып, Әхнәфкә күрсәтте.—Йорт миңа кирәк.

—Син бөтенләй мөмкин булмаган әйбер сөйлисен,—диде Әхнәф.

—Ләкин син минем калырга хаклы икәнемне онытма!

Әхнәф бармаклары белән мангаен, ике чигәсен сыпырырга кереште.

—Әйдә, без аңлашып сөйләшик әле, Рашат. Син Мәскәүдән кайтмакчы буласынмыни?

—Юк, кайтмакчы булмыйм. Мин инде кайттым.

—Сиңа квартира кирәк. Шулаймы?

—Миңа квартира кирәкми. Мин шушы үзем туып-үскән йортта яшәргә телим. Барысы да законлы.

—Бу әйбернең Болынкырда гына хәл ителмәячәген, өлкә комитеты да барлыгын син онытасың.

—Мин законны гына беләм.

—Әйе, законны саклау өчен хокук органнары бар. Әле бит синең фәлән ел буе яшәмәгәнеңне алар башка юллар белән дә расмый алалар. Моның бер кыенлыгы да юк. Болынкырның акыл ягыннан зәгыйфь булмаган һәрбер кешесе шаһит була ала.

—Әгәр дә мин, шаһитларсыз гына эшлик, дисәм?

—Син юкка көчәнмә, Рашат. Бу барып чыкмаячак.—Әхнәф шулай дисә дә, эчендә әллә нинди шомлы уйлар бөтерелде. Рашатның күзләрендәге кыргый очкыннар аның теләсә нинди нәрсәгә сәләтле икәнен расмый иде. Әгәр кайтырга ниятең бар икән, бәлки башка вариант табарбыз?

—Нинди?

—Мин сиңа Чаллыдан бер дигән квартира алырга ярдәм итә алам. Үзе шәһәр, Болынкырдан да ерак түгел. Бәлкем бергәләп берәр кибет кебек нәрсә дә ачып җибәрербез.

Рашат рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

—Син минем тәртәне бөтенләй икенче якка борасың бит әле. Минем өчен заманчиво бу.

—Соң әйдә, уйлашыйк,—диде Әхнәф.—Эшмәкәрләргә хәзер бөтен җирдә юллар ачыла. Мин синең белән хезмәттәшлек итәргә һәрвакыт әзер.

Алар, шактый вакыт гәпләшеп утыргач, анык карарга килмәсәләр дә, икесен дә канәгатьләндерә торган уртак вариант эзләргә, дигән ният белән аерылыштылар.

Рашат квартира мәсьәләсен Әхнәфнең ачуын китерергә, ызгыш-талаш чыгарырга, куркытырга, җае чыкса, бераз аны типкәләп-бәргәләп алу нияте белән генә кузгаткан иде. Сөйләшүнең һич көтелмәгән борылыш алуы Рашатны дәртләндереп җибәрде. Ул Болынкыр урамыннан очына-очына атлады, ләкин үзләренә кайтып җиткәч, нидер уйлап, ялт кире борылды да аскы урамга төшеп китте. Ул урамның ике ягын бер итеп атлады, алдында киң юллар ачылгандай тоелды. Менә ул таныш тыкрыкка борылды, Иректәр яши торган өйнең капкасын ачып ишек алдына керде. Тәрәзәләрдә утлар яна, ләкин эчтә ни барын күрерлек түгел—пәрдә тартылган иде. Рашат ишеккә килде. Ул бикле түгел иде. Өй ишеген кагып тормады, яртылаш ачты да:

—Мөмкинме?—диде.

—Өйдә, керегез,—диде Ирек, аны каршылап.

Өйдә ул үзе генә иде. Алар кул биреп күрештеләр. Өстәлгә таратып ташланган кулъязмаларга карап, Рашат:

—Нәрсә язасың?—дип сорады.

—Үзебез яшәгән тормышны,—диде Ирек, елмайгандай итеп.

Ирек плитәне кабызып чәй куя башлауга, Рашат аны туктатты:

—Кирәкми, мин ашап кына чыктым. Әгәр инде тегесе булса.. Анысыннан баш тартмыйм.

—Гафу ит, анысын өйгә керткән юк. Мин ул нәрсә белән араны өздем.

—Начар эшләгәнсен. Бу жир йөзендә бөтенебезне дә якын итә торган, бөтенебезгә дә үзен жәлләмичә бирә торган бердәнбер зат бит ул. Хатыннар белән үз гомерендә әллә ничә мәртәбә аерылышып була торгандыр. Ә моннан башка яшәү яшәү түгел. Нык ялгышасын син.

—Бөтенләй дә ярамый ул мина. Башыма ярамый.

—Андый кешеләрне күп беләм мин. Ярамый, ярамый, диләр дә шундый итеп эчеп жибәрәләр, аяк асларында жир яна башлый.—Рашат иелеп Ирекнен өстәлдәге язуларын караштыргалады да башын күтәреп болай диде:—Монда мина кирәк әйбер күрмим әле мин. Теге китапны тәржемә итеп куйгансындыр бит?

—Юк,—диде Ирек.—Мин аны тәржемә итмәячәкмен.—Ул шкафтан алып, китапны Рашатка сузды.

Ләкин Рашат аны алырга уйламады.

—Бу ни дигән сүз була инде, дустым? Мин сина бер үтенеч белән килдем, ә син шуннан да баш тартып торасың. Нәрсәсе ярамый?

—Син үзеннен мина ни биргәненне беләсенме?—Ирек китапка берничә мәртәбә кул сырты белән суккалап алды.—Бу бит фашизмны жәелдерүгә юнәлтелгән әйбер.

—Әйе, шулай шул.

—Безнең илгә фашизм китергән бер афәт житмәдемени? Инде хәзер үзебезнең яшьләрдән фашистлар ясыйбызмы?

—Син гел әллә кем булма әле,—диде Рашат, Ирекне урындыкка таба этеп, үзе каршына утырды.—Фашистмы, түгелме—синең белән мина пычагымамы алар? Аның бит инде дөньясы барыбер беткән. Тәржемә итеп бир дә акчаны кесәңә салып куй.

—Син бик куркыныч эшкә алынгансын. Артында кемнәр торганын мин белмим, тик моның ахыры әйбәт булып бетмәячәк.—Ирек китапны Рашатның тезе өстенә шапылдатып китереп салды.—Бу атом бомбасыннан да куркынычрак әйбер.

Рашат күзен кысып, аны мыскыллагандай озак итеп карап торды.

—Әгәр хәзер менә мин сина ике «Жигули» машинасы алырлык акча бирсәм? Тәржемә итәсенме?

—Син, Рашат, мине бөтенләй белмисен. Әгәр дә акчага кызыга торган кеше булсам, мин бу өйдә дә яшәмәс идем.—Ул шкафтан ак кәгазьгә төреп кара жеп белән чорналган кечкенә генә төргәкне алып, әлеге китап өстенә куйды.—Бусы син теге вакытта калдырган акчалар. Минем беркемнән дә аванс та, хәер дә алганым юк.

Рашат, иреннәрен кыегайтып, мыскыллы елмайды.

—Ну что ж,—диде ул сикереп торып.—Баш тартасың алайса?

—Баш тартып кына калмыйм. Сиңа да бу хәтәр эшкә кул тыкмаска киңәш бирәм. Куркыныч нәрсә бу. Син кемнәрнеңдер ятьмәсенә эләккәнсен. Тик алар бит бүген йә иртәгә юк ителәчәк.

Рашат ямьсез итеп көлеп жибәрде. Шул чакта Ирек анын алтыннан ясалган куш коронкасынын төшәм-төшәм дип калтырап торуын күрде.

—Кем юк итәләр микән? Карарбыз! Әле мин үзем генә кайттым. Киләчәктә ялгыз булмам. Безне беркем дә буйсындыра алмый. Уйлый тор, сиңа моны барыбер тәржемә итәргә туры киләчәк. Безнең таләп шундый.

—Кем соң ул «без»?

—Яңа көч. Ул көч килгән жирендә һәркемне буйсындыра.

—Син ата-анаңа, әби-бабаларыбыз корган тормышка каршы барасың. Бу китап милләтләрне көчләп юк итүгә корылган. Сиңа барыбермени?

—Барыбер булса, мин алар белән булмас идем бит.

—Менә хәзер барысы да аңлашылды,—диде Ирек.—Ә минем тормышка

тыкшынма. Мин үзем теләгәнчә яшәргә телим.

—Берәүнең дә үзенең генә тормышы була алмый, дустым. Алай булсын өчен айда яшәргә кирәк. Яхшы чакта ал син бу китапны.

Рашат китапны Ирекнең бугазына терәде. Ул аны кулы белән читкә какты.

—Син элекке чакларыңны оныт әле, Рашат,—диде Ирек, аның үзе кебек басым ясап.

—Син хәзер беренче секретарь малае түгел, диюең инде. Әтине төшерүдә кулыңны нык уйнаткансың.

—Кул уйнатырга ул капчык сугышы түгел,—дип Ирек аңа үзе кебек мыскыллы караш ташлады.

—Куанырга ашыкма, дустым. Сез Шәрифуллин белән икегез, Арслановны җиңдек, дөньяның кендегеннән алдык, барысына да хуҗа булдык, дип уйлыйсыз. Ә сез тома сукырлар. Сез бит барыгыз да болындагы үләннәр,—Рашат тагын көлеп җибәрде.—Исеме җисеменә туры килеп тора: Болынкыр! Ха-ха-ха! Печән чабучылар әле килмәгән, үләннең калынаюын көтәләр. Җиләк тә өлгермәгән. Аны җыярга тубал тотып шулай ук әзер торалар. Бөтенесе көтә. Шулай да чалгы янаган тавышлар инде ишетелә. Мангаеңны җыерма, сез ул тавышларны ишетмисез. Сез генә түгел, алар өчен бөтен җир шары—олы болын, печәнлек.

—Кемнәр өчен?—диде Ирек, Рашатның фикерен ачыграк аңламакчы булып.

—Беләсең киләмени? Юк алар, юк! Оныт минем сүзләрне! Күп сораштыра башласаң, муеныңны сындырулары бар. Сезнең өчен алар юк, алар өчен сез юк. Бернинди бәйләнеш юк. Булыр иде—сез күптән тере түгел, язмышыгызның инде әллә кайчан хәл ителеп куелганын да белмисез.—Рашат шунда имән бармагын Ирекнең күзенә тери язып аңа юнәлтте, үзе туктаусыз хихылдады.—Әнә, күзләреңдә курку, куркасың бит, шыр җибәрдеңме?!

Аның өенә бәреп кереп, шулай мыскыллавы Ирекнең йөрәгенә китереп бәргәндәй итте.

—Мин сиңа бер әйбер әйтимме, Рашат?

—Әйт.

—Без бәләкәй чакта тычканны тота идек тә артына салам тыгып өреп кабарта идек. Тычкан бик зур булып, әүмән-тәүмән йөгереп китә иде. Беркөн телевизордан сөйләделәр: үзбәкләр сарыкны исертәләр икән дә, тире арасына насос белән һава тутыралар икән. Аннары базарга алып чыгалар. Сарык пел кебек булып кабарып басып тора.—Ирек туктап калды.

—Шушының белән беттемени?—диде Рашат.

—Әйе.

—Ник сөйләдең син моны?

—Нишләптер келт итеп исемә төште.

—Ярый, аңладым кебек мин сине...—Рашат тешләрен шыкырдатып куйды.—Тик кабатлап әйтәм: мин дигәнчә булачак. Хатыныңа сәлам әйт.

Ул ишекне шартлатып ябып чыгып китте...

## 7

Менә ничә көннәр инде Рашат белән очрашуны хәтереннән чыгара алмыйча йөри Әхнәф. Ничә көннәр буе үзен-үзе калтырап төштең, дип сүгә. Югыйсә Мәскәүдән кайткан ул җилкуарның ике сүз белән авызын томаларга да бүлмәсеннән куып чыгарырга иде. Терсәк бик еракта калды шул. Чаллы квартирасын ишеткәч, Рашатның күзләрендә хәтәр очкыннар кабынганын Әхнәф бик ачык тоеп, тартышып йөрде. Кичләрен телефон шылтыраса, Рашаттыр, дип коты алынды. Ул хәзер, җилкәнә бер атландыргач, тимер авызлык каптырылган атны үрле-кырлы сикерткәндәй, рәхимсез кыланачак. Бәгырен телгәләгән шушы чарасызлык аңа күптән баш ватып йөргән кыен

мәсьәләне хәл итәргә дә этәргеч бирде бугай. Турысын гына әйткәндә, Арсланов йортына күчәсе килми иде аның. Аларның хәзер яши торган йорты белән чагыштырганда, сүз дә юк, ул әйбәт, әмма заманадан ерак тора. Бүгенге район җитәкчеләре башкача яши. Эшли башлау белән үзенә йорт салу бик хәтәр нәрсә. Иң элек моны халык өнәмәячәк. Болынкырда гына да өч йөзгә якын кеше квартирга чират көтә. Партия өлкә комитеты да бу мәсьәләдә район җитәкчеләрен, бигрәк тә беренче секретарьларны, туктаусыз кисәтеп тора. Бу борчуларны Әхнәф үзе кайнатты, хатынына сиздермичә генә, ачуташ капкандай, йөзен җыерып йота бирде. Фәһимә исә күнеле белән инде әллә кайчан Арслановлар йортына күчкән иде, ул анда яши, төрле-төрле җиһазлар ала, ремонтлар үткәрә, бакчасына чәчәкләр, агачлар утырта. Әле хыялында гына йөргән шул мәшәкатьләре хакында очына-очына Әхнәфкә сөйли һәм шуның белән аның болай да борчулы күнеленә тоз сипкәнен уйлап та карамый. Күнелен көне-төне бимазалаган каршылыклы уйларны хәл итә алмагач, Әхнәф эшне хатыныннан башларга уйлады.

Бүген ул көне буе фермаларда йөрде. Кич эштән кайтып кергәндә, Фәһимә пилмән ясап маташа иде. Мондый чакларда булышсаң, хатынының ефәктәй йомшавын белгәнгә күрә, Әхнәф кулларын юып өстәл янына килде һәм җайлап кына сүз башлады:

—Мин бит әле бүген әти белән әни янына кагылдым. Үзең беләсең, икесенең дә рәтләре чамалы. Кышка әллә безгә килергә микән, дип торалар. Сыйдырырбыз бит инде аларны?

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Фәһимәнең карлыгач канатыдай кара кашлары берничә генә секундка җыерылып алды, иреннәре дә кысылып куйдылар.

—Сыйдырмый нишләрсең?—диде мөмкин кадәр тыныч тавыш белән.—Үзләре сагынып интекмәсәләр...

—Бер кышка түзәрләр.

—Кайчан килмәкче булалар соң?

—Анысы инде аның синең белән миннән тора,—диде Әхнәф, камырны тишеп чыккан ит кисәген савытка атып.—Арсланов йортына күчкәч алып килербез.

Шулчак аларга үзләренең урамында хат ташучы Сәрия килеп керде. Әхнәф аның иненә асылган сумкасы булмавыннан, ачулы чыраеннан нindидер күңелсез хәл барлыгын аңлады.

—Әйдәгез, түргә узыгыз,—диде ул.

—Юк, узмыйм. Хәерчегә нишләсәң дә көн юк.

Сүзен әйтеп бетермәстән, ул елый да башлады.

—Ни булды, аңлатып сөйләгез,—диде Әхнәф.

Ул арада Фәһимә дә атылып алар янына чыкты.

—Мин инде сезгә әллә ничә мәртәбә кермәкче булдым,—диде Сәрия, күз яшьләрен кул сырты белән сөртә-сөртә.—Сезнең Таһирыгыз минем Илшатны кыйный да кайтара. Өченче көн киемнәрен ертып бетергән. Мин бит сезнең кебек кесә тутырып акча алмыйм. Ялгыз хатын дигәч тә...

Фәһимә аны кулыннан тотып кухня ягына алып чыкты.

—Сез ялгышасыздыр, Сәрия. Безнең малайның беркайчан да кеше белән сугышып йөргәне юк.

—Таһирыгыз мәктәптә укыганда ук ике мәртәбә кыйнаган иде инде. Хәзер Казаннан кайтып кыйнаган. Нинди үче бардыр? Унынчы класста укый торган баланы кыйный ала инде ул.

—Моның булуы мөмкин түгел,—диде Әхнәф.—Кем күргән?

—Кем күрсен, малай үзе әйтте. Кайтып кергәненә әле аның ярты сәгать. Нәрсә беләндер сугып иренен ярган. Курткасы кара канга баткан. Чыксын әле үзе.

—Ул бит әле кайтмады,—диде Фәһимә, нишләргә белмичә өзгәләнеп.

—Мин аның кайтканын көтәм,—диде Сәрия, бераз тынычлангандай булып.

Фәһимә, аны чишендермәкче булып, өстендәге иске җәйге пальтосының сәдәфен ычкындырырга үрелде.

—Әйдәгез, чишенегез. Таһир кайткач, аңлашырбыз.

Ләкин Сәрия кире чигенде.

—Сезнең кебек кешедә ничек курыкмыйча чишенмәк кирәк? Шушында гына басып торам.

Аның бу сүзләренә Фәһимәнең чырае бозылды.

—Без кеше ашамыйбыз, Сәрия. Бу йортта кеше каны эчә торган аждаһа да яшәми.

—Аждаһасын белмим, малаегыз ник минем Илшатыма үчләшә?

Күпме генә кыстасалар да, Сәрия узмады. Аның сүзләре Әхнәф белән Фәһимәне олы хафага салды. Бер атнага ялга кайткан Таһирның сугышып йөрүе, кеше кыйнавы алар өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде. Сәрия бераз тынычлангач:

—Мин моны болай калдырмыйм. Хәзер үк милициягә барам,—дип урыныннан кузгалды.

Әхнәф белән Фәһимә аның икесе ике ягыннан килеп туктаттылар:

—Зинһар өчен сабыр итегез!—дип өзгәләнде Фәһимә.

—Без аңа җәзаның иң катысын бирербез,—дип өстәде Әхнәф.

—Илшат белән кайтып сөйләшәм. Ул ни әйтсә, шул булыр. Безгә үпкәләмәгез...

Сәрия чыгып киткәч, Әхнәф бәлән Фәһимә икесе берьюлы кухня өстәле янына барып утырдылар. Пилмән кайгысы беткән иде.

—Минем моңа мәңге ышанасым юк,—диде Фәһимә, ирексездән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртә-сөртә.—Үз гомеренә беркем белән сугышканы юк бит.

—Син күз яшьләреңне агызырга ашыкма әле. Гаепнең Сәрия малаенда булуы да бар. Таһир дуамал егет түгел. Сугышкан суратта дә мин ул хаклыдыр, дип уйлыйм.

—Мин хаклы, дип кенә кеше кыйнамыйлар бит, Әхнәф.

—Без хәзер синең белән бу хакта күпме генә бәхәсләшсәк тә, очына чыга алмыйбыз. Әйдә, пилмәнне ясыйк. Ә әниләрне барыбер алып килергә туры киләчәк.

Алар шактый вакыт бер сүз дә дәшмичә пилмән ясадылар. Аннары Фәһимә болай дип сүз башлады:

—Минем бит Хәят апаларда булганым бар. Әллә ничек ваклап бүлгәләнеп беткән өй инде ул. Бүлмәләре бәләкәй. Минем әнкәйнең дә ялгыз яшәрлек рәте юк.

—Иркенләп яшәрлек түгел икәнен беләм инде мин ул өйнең.

Фәһимә аның беләгенә кагылып куйды.

—Янкорма салырбыз! Кешеләр бит шулай зурайталар өйләрен.

Фәһимәнең шул сүзеннән соң гына Әхнәф яшереп сакланган фикерен, оста уенчы уен тузын ыргыткандай, әйтеп салды:

—Арслановлар йорты безгә тәтемәс тә кебек әле ул...—Фәһимәнең фаршлы калагы кулыннан төшеп китте:

—Нәрсә?!

—Малае белән кызы кайтырга йөри, диләр.

—Йортның аларда калуы мөмкин түгел! Обком бар бит әле.

—Обкомда Арслановның үз кешеләре. Барысы да мөмкин.

—Ә без?!—диде Фәһимә ачыргаланып.

Әхнәф хатынының нәкъ үзе теләгән якка килеп төшкәнлеген аңлады.

—Мине дә шул сорау борчый шул.—Ул көмеш кашык белән өстәлгә шакы-шокы суккалап шактый вакыт торды.—Әллә безгә яна йорт салу турында уйларгамы, карчык? Анда күчеп, олылыклап ремонт ясатып, янкорма төзеп җәфа чиккәнче, шулай әйбәтрәк булмас микән?

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәһимәнең йөзе кояштай балкып китте, күзләре уттай янарга тотынды.

—Ну, баш та үзендә!—Өйдә икесе генә булсалар да, ул як-ягына каранып куйды, Әхнәфне биленнән кочаклап, колагына пышылдады:—Төзик бер диган итеп! Син бит моны булдырасын!

Әхнәф аңа җавап бирергә өлгермәде, Таһир кайтып керде.

Ул мышык-мышык борынын тарта, ун як янагында кып-кызыл яра эзе ярылып ята иде.

—Битенне кайда сыдырттың, улым?—диде Әхнәф, аңа якын ук килеп.

—Парктан агач арасыннан бара идек, ботакка эләкте,—диде дә Таһир җәһәт кенә үз бүлмәсенә кереп китте.

Әхнәф белән Фәһимә бер-берсенә сүзсез генә карашып алдылар. Күпме көтсәләр дә Таһир чыкмады.

—Чакырыйк,—диде Фәһимә, түземлеген җуеп.

—Бар, эндәш. Мин залга чыгып утырам.

Аның артыннан ук Таһир белән Фәһимә керде.

—Әллә берәр нәрсә булдымы, улым?

Әтисенең бу соравыннан Таһир сискәнеп киткәндәй булды.

—Ю-у-у-ук,—дип сузды ул акрын гына.

—Син яшермә,—дип сүзгә кушылды Фәһимә.—Кулларың да тырналган.

Таһир аның бу сүзенә бөтенләй җавап бирмәде.

—Йә, сөйләп бир. Без бит әниең белән барысын да беләбез.

Бу сүзләр аның кыяфәтен шундук үзгәртте: йөзе кып-кызыл булды, ул, чыгып китәргә теләгәндәй, ишеккә таба омтылды, тешләрен кысып туктап калды.

—Йә, көтәбез.

—Бер әйбер дә юк, дидем бит инде...

—Илшат белән ни булды?—Фәһимә малаенын күзләренә туп-туры карады.—Аның әнисе безгә килде, милициягә хәбәр итәм, ди.

Әнисенең бу сүзләреннән соң, Таһир башын аска иде.

—Ул бит үзе... өч малай ияртеп каршыга чыкты...

—Университеттан кайтып, бала-чага белән сугышып йөргәч, әйбәт инде ул,—диде Фәһимә шелтәле тавыш белән.—Әтиеңә шуннан соң ничек халык каршына чыгарга, ничек аларны тәрбияләргә кала инде? Милиция хәбәр итсә, университеттан да куарга мөмкиннәр.

—Гаеп аның үзендә,—диде Таһир, каш астыннан күзләрен усал елтыратып.—Аны мәктәптә беркем дә яратмый. Кызларга чат ябыша, бәйләнә. Кайберләренә кул да күтәргән.

—Ә-ә-ә, син шул кызларны яклаучы булып Казаннан кайттың инде, әйеме?—диде Әхнәф киная белән.

—Мин берсен генә якладым.

—Сер булмаса, әйт инде: кайсысын?

Таһир эндәшмичә шактый торды. Дулкынланудан аның каш-керфекләре сикерешә.

—Айгөлне якладым. Илшат аны былтырдан бирле кыерсыта.

—Кайсы Айгөлне?—диде Фәһимә.

—Сөембикә апа кызын.

—Ә сиңа ник кирәк ул?—диде Фәһимә чәрелдәп.—Кем ул сиңа?!

Гаҗәпләнүдән Таһирның күзләре зураеп китте:

—Ничек инде, әни?! Сез бит Сөембикә апа белән...

—Ирек абый белән—дуслар идегез, диген,—Фәһимә ачуыннан аяк тибеп куйды.—Яшь чакта булган да җилгә очкан! Кайчандыр аралашкан һәрбер кеше өчен сугышып йөри башласаң, безгә монда ничек яшәргә?!

—Ярый, барысы да аңлашылды,—диде Әхнәф.—Эшне зурга җибәрмәскә кирәк. Син хәзер үк киенеп Сәрияләргә бар, Илшаттан гафу үтен. Шау-шу университетка барып җитмәсен.

—Син нәрсә, әти?!—диде Таһир ярсулы тавыш белән.—Алар бит үзләре мине кыйнарга килделәр. Егып, туйганчы типкәләделәр. Гафу үтенү... Алайга китсә, мин үзем милициягә әйтергә тиеш.

—Син бит булачак юрист. Шаһитларың бармы соң?

—Каян булсын? Без бит аулак почмакта.

—Димәк, барыбер син гаепле. Гафу үтенмәсәң, өйләренә бар, әнисе белән сөйләш.

—Юк, үзен генә җибәрмим,—диде Фәһимә ярсып.—Бергәләп барабыз, бергәләп аңлатабыз?!

—Нишләп мин сине ияртеп йөрим инде, әни?—Таһир беразуйланып торды да ныклы карарга килде:—Ярый, сезнең хакка барам. Тик үзем генә.

Таһир чөйдә эленеп торган курткасы янына барды да, аның кесәсеннән нидер алып, аларның каршына килде:

—Менә Илшат минем яңакка нәрсә белән сыдырды,—диде.

Таһирның кулында велосипед чылбыры иде. Әхнәф малаеның кулыннан чылбырны алды да җентекләп карарга кереште.

—Сез бөтенләй башка тормыш белән яшисез бугай, улым,—диде ул баш чайкап.—Безнең дә яшь чаклар бар иде. Күпме еллар комсомолда эшләдем. Әмма мондый рәхимсезлекне күргән булмады. Хәзер көн саен әле бер, әле икенче авылдан яшьләр арасында булган тәртипсезлекләр турында чәчләренне үрә торгызырлык хәбәрләр килә. Чылбырыңны өйдә калдырып тор әле...

Таһир чыгып киткәч, Әхнәф Фәһимәне тынычландыра алмыйча бик озак азапланды.

... Әхнәф авылларына бөтенләй кайтмаган иде. Әйе, ул алдады. Инде күптән эчендә яшереп йөрткән уен башлап Фәһимә авызыннан әйттерү өчен алдады. Шуңа күрә иртәгә иртүк әти-әнисе алдындагы гаебен юарга авылга кайтырга карар кылды. Әтисе инде алтынчы ел параличланган хәлдә. Гомер буе физкультура укыткан, йөгерү, чаңгы буенча разрядлы спортчы. Чирнең ни икәнен белмәгән әтисен инсульт бәреп еккач, авыл халкы аһ итте. Ул коточкыч авыр әйберне бау белән үзенә таба тарткан кешедәй, гәүдәсен алга авыштырып, юньләп бөгелмәгән аякларын көч-хәл белән сөйрәп, капка төбенә чыгып утыра. Кем килсә дә, йөзе кинәт чалшая, һәм ул тавышсыз гына еларга керешә. Аның туктаусыз яшь агучы күзләренә, йөзендәге газаплану билгеләренә карагач, Әхнәфнең үзенең дә күңеле тула...

Әйе, иртәгә иртүк кайтып киләчәк ул алар янына.

## 8

Бүген эштән кайтканда, Сөембикәгә култыклашып баручы әллә ничә пар очрады, алар көлешә-көлешә сөйләшеп урамнан атлыйлар, йөзләрендә канәгатьлек билгесе, алар иртәсен-кичен дә, бүген-иртәгә дә гел бергә. Сөембикәнең исә сөялеп торыйм дисә, бакчасында ялгыз миләше генә бар. Тик аның белән серләренне уртаклашып булмый, ул синең күкрәкләрең белән терәлүеңә дә битараф... Соңгы вакытларда ялгызлык дигән нәрсә бәгыренә кадалган усал сөлек кебек суырды да суырды аны. Ул суырган саен, кояш яктырак, тормыш матуррак, кешеләр бәхетлерәк кебек тоелды. Элек аның өчен агач яфраклары шаулашкан, кошлар чыркылдашкан кебек

тоелса, хәзер ул тавышлар Сөембикәгә аларның үзара сөйләшүе булып тоелды. Хәтта аларның да сөйләшерлек нииндидер уртак нәрсәләре бар, бары тик мин генә ялгыз, дип сагышланды Сөембикә. Ул алардан көнләшә, кайчакларда бөтен дөньясына ачуы килә, кайчакларда бөтенләй төшенкелеккә бирелә, кайчакларда күзенә бер генә якты нур да чалынмый, хәтерен котырган этләр өере кебек гел караңгы истәлекләр генә ялап тора. Шушы тойгылар әледән-әле йокыдан уяталар, ул әйләнә-тулгана җәймәсен, одеалын бау кебек ишеп бетерә, бер рәхәтләнеп еласам, җиңеләеп калыр идем, ди, әмма елый алмый. Андый чакта күктә ай булса, күңеленнән шуның белән сөйләшә. Сөембикә инде хәзер айның гашыйклар өчен түгел, йоклый алмыйча газаплаучы ялгызлар өчен чыгуын аңлады. Ул, су сибелмәгән гөл кебек, көннән-көн сула баруын сизде. Авылда чакта әнисенең ни өчен кич клубка чыгармаганлыгын төшенә башлады. Сөембикәдән, кая да булса укырга керәм, эшкә керәм, дигән сүзләрне ишеткәч, әнисенең елый-елый, «Беркая да җибәрмим! Синнән башка мин үләм!»—дип ни өчен өзгәләнүләре ана хәзер генә барып җитте. Авыл мәктәбендә укыганда, Сөембикә әнисен куралмый, аның юри ачуын китерә, каршы әйтә, аның белән әрепләшә иде. «Синең яныңда шешәң, стаканың бар», дип аны елаткан чаклары да күп булды. Ялгызлык дигән аждаһа үз өстенә килеп ингәч кенә, тавышсыз кычкырып тыпырчынырга тотынды. Айлы төннәр ялгыз адәм баласының уйларын җил кебек әллә кайларга очырып алып китеп, урманнар-кырлар өстеннән, йолдызлар-айлар яныннан йөртеп, әллә ничә катлам елларны үтеп, яшьлек чорларына, балачакларга ук алып кайта ала икән. Ах, ул айлы төннәр! Яшь чакта сихри булган ул төннәр нишләптер уйларны, үзләренең көмеш нурларына күтәреп, менә шулай йөртәләр-йөртәләр дә, җиһанның кайсыдыр урынында дулкынланып торучы сагыш диңгезләрендә чайкап, сина кире кайтаралар.

Шушындый айлы кичләрдә, Сөембикәне хәйран калдырып, бер вакыйга хәтеренә килә башлады. Алар ничәнчедер класста укыганда, җәй көне Казанга экскурсиягә барганнар иде. Барысын да тулай торакка урнаштырдылар, ә тулай торакның ишек алдында су колонкасы бар. Көне буе шәһәр карап йөреп, тирләп-пешеп, аяк табаннары ут булып янып кайткач, шул колонкага чыгып, барысы да рәхәтләнеп юыналар, су сибешәләр, туйганчы чыркылдашалар иде. Сөембикәләр Казанда дүрт-биш көн булдылар. Иртәгә кайтабыз дигән көнне кич ул йоклый алмыйча азапланды.

Төнге уникеләрдә, ичмасам салкын су белән аякларны юып керәп ятыйм әле, дип теге колонкага чыкса, төннең яктылыгына, күктәге айның кояштай балкуына хәйран калды. Аяк астында яткан энәне дә аермачык күрерлек төн иде бу. Сөембикә, ике тезен бергә терәп, колонкадан су агыза башлады. Шулчак кемдер, арттан килеп, колонканың тимерен күтәрде, су агудан туктады, Сөембикә ялт итеп артына борылды, суны туктатучыга карады. Ул ап-ак күлмәк, шундый ук чалбар кигән, кояшта янып каралган, кап-кара чәчле егет иде.

—Гафу итегез,—диде ул, тигез, ак тешләрен күрсәтеп елмая-елмая.—Гомерлек чир алуыгыз мөмкин.

—Ә бәлки мин чирләргә телимдер,—диде Сөембикә чытлыкланып һәм кабат су агыза башлады.—Бәлки минем бу дөньядан китәсем килә торгандыр.

—Алай булса,—дип егет колонка тимерен күтәрде:—сез ялгышасыз. Адәм баласы дөньяга бик авырлык белән килә. Ә сезнең кебек чибәр кызлар бигрәк тә сирәк туа,—диде егет, серле итеп карап.

Сөембикә, кинәт кенә колонканың тимеренә басып, учына су агызды да егеткә чәчеп җибәрде һәм көлә-көлә:

—Борын астына су чәчрәде, сорт!—дип йөгереп кереп китте.

Малайлар торакның икенче башында торалар, бу егетне аның килгән көнне дә күргәне бар иде. Икенче көнне автобуска утырганда, теге егет аны эзләп тапты.

—Минем исемем Айдар,—диде ул, мәхәббәтле караш ташлап.—Сез кайдан?

—Болынкырдан.

—Ә исемегез?

—Сөембикә,

—О-о-о, нинди тарихи исем!—диде Айдар.—Мин Молдавиядән.

Аларны автобуска чакырдылар, икесе дә нидер әйтмәкче булды, ләкин вакыт калмаган иде инде. Айдар да үзенең автобусына таба йөгерде. Айлы төннәр нишләптер шушы сихри очрашуны Сөембикәнең хәтерендә туктаусыз яңарттылар. Яңарган саен ул очрашуга яңадан-яңа матур бизәкләр өстәлде, егетнең уң як теше бераз китегрәк икәне дә хәтеренә төште. Әмма шушы китек теш аңа әйтеп бетергесез сөйкемлелек бирә иде...

Ялгызлык, йокысыз төннәр аша ул тагын бик күп нәрсәләрне аңлады. Айгөл белән алар арасындагы мөнәсәбәтләр торган саен җитдиләнә бара. Соңгы вакытта кызындагы нindидер яшерен үзгәрешне Сөембикә чамалый, гөманламакчы була, әмма моның асылына төшенә алмыйча җәфалана. Әйтмичә кинәт кенә өйдән чыгып китүләр, кичләрен соң кайтулар, көндәлегендә моңарчы булмаган «өч»ләрнең күренә башлавы аны бик тә борчый иде. Менә хәзер кичләрен Ирекләргә китә. Икешәр, өчәр сәгать шунда булып кайта. Ниләр сөйләштегез, дигәч, берни дә әйтми. Вак-төяк инде шунда, ди дә куя. Ирек белән Зәнфирә аңа начар йогынты ясарлар, дип һич тә уйламый ул. Ләкин йогынты төрлечә була. Әгәр ул анда еш бара башлаган икән, аңардан ерагая, дигән сүз.

Сөембикә бүген эшеннән арып-талчыгып, кәефсез кайтты. Өйдә булмагач, Айгөлне ул мәктәптәдер дип уйлады. Әмма кызы караңгы төшкәч тә, сәгать төнге ун тулгач та күренмәде. Ул машинасын ишек алдына куйган иде. Унберенче киткәч, түзмәде, кабалана-кабалана киенде дә, машинасын кабызып, Чукаевага юл тотты.

Гандәлифә аны ачык йөз белән каршы алды.

—Мин Айгөл юк микән, дип килгән идем.

—Юк шул. Нишләптер кагылмый башлады әле ул.

Сөембикә ишек янындагы урындыкка утырмыйча булдыра алмады.

—Берәр төрле йөрәк даруыгыз юкмы?—диде ул, кукрәгеп тотып.

Гандәлифә кашыкка корвалол салып бирде. Аны эчкәч, Сөембикә сулышының иркенәюен тойды, әмма күңеле тынычлана алмады.

—Болай тупса янында утырып булмый инде. Зинһар узыгыз.

Аның сүзләренә буйсынып, Сөембикә курткасын, итеген салып, өстәл янына узды. Гандәлифә термостан агызып икесенә дә мәтрүшкәле кайнар чәй алып килде.

—Бик борчылгансыз, берәр нәрсә булдымы әллә?

—Булуын булмады да... Ялгыз кешенең хәлен сезгә сөйләргә кирәк түгелдер. Айгөл—минем күз нурым. Ә аның кайтып та кергәне юк. Берүзем көтәм дә көтәм. Мин шулкадәр ялгыз, шулкадәр ялгыз!..—Сөембикә күзеннән яшь бәреп чыгуын сизми дә калды. Кульъяулыгын чыгарып, ул күзләрен, битен сөртеп алды.—Аның сезнең янга килгәләп йөрүенә куанам, рәхмәт сезгә. Ул да бит ятим бала, кая барып бәрелергә белми торгандыр. Шулай да сез аны кичләрен кагылганда тизрәк кайтарып җибәрсәгез иде.

Гандәлифә аның бу сүзләренә «ә» дә, «җә» дә димәде.

—Турысын әйтүем өчен гафу итегез,—дип башлады ул сүзен, шактый күп вакыт үткәч.—Сезне япа-ялгыз итүче, гаепле кешсне беләм кебек мин.

Сөембикә аптырап китте. Чукаевадан ул мондый сүзләр көтмәгән иде.

Әллә Айгөл берәр нәрсә сөйләде микән?

—Мин андый кешене белмим, бу минем өчен яңалык,—диде Сөембикә аптырап.

—Юк, сез аны бик яхшы беләсез. Ул кеше—сез үзегез!

«Минем үткәндәге тормышым турында хәбәрдар микәнни бу?»—дип уйлады Сөембикә ана рәнҗеп. Халык арасында аның турында гайбәтләр йөри микәнни? Инде бит ир-ат кулы тотып карамаганына да ничә еллар. Әнә бит Чукаеваның карашы нинди усал, ачулы. Димәк, ул Сөембикәне гаепли.

—Рәхмәт турысын әйтүегез өчен,—диде Сөембикә, чыгып китәргә урыныннан торып.

—Әз генә сабыр итегез!—дип туктатты аны Чукаева.—Әгәр түземлегегез җитсә, әйтеп бетерәм.

Аның сүзләре Сөембикәне бер яклап куркытсалар, икенче яклап кызыксыну уятты. Чыннан да халык аның турында ни сөйли икән?

—Мин сезне тыңлыйм. Тик яшермичә сөйләгез...

—Йокысызлыктан интеккән карчыкның саташкан уйлары, димәсәгез, сөйлим.—Чукаеваның кырыс карашы кинәт ягымлылангандай булды, тавышы да йомшарып китте.—Сез берничек тә ялгыз була алмыйсыз. Ник дисәң, һәркөн кешеләр арасына мәҗбүриләп тартып алып керә торган эшегез бар. Сез сау-сәламәт, яшь, чибәр, талантлы. Мин санаган әйберләр—үзләре генә дә сезнең иң якын дусларыгыз инде. Аларның һәрберсе кешеләрне ымсындыра, үзенә тарта. Теләсәгез дә ялгыз була алмыйсыз сез! Сез әнә шул ялгыз дигән уегыз белән тормышыгызны агулыйсыз, үз-үзегезгә бикләнергә азапланасыз. Ә бу иң әшәке чир, ул кешене үтерә!

—Болар барысы да сүзләр бит, Гандәлифә апа,—диде Сөембикә авыр сулап.—Китап сүзләре, шигъри сүзләр.

—Ашыкмагыз! Китаплар да тормыштан алына,—дип дәвам итте Чукаева.—Менә мин сезгә үз тарихымны сөйлим. Авыл хуҗалыгы институтында укый башлаганда, мин куркак куян баласы идем. Мине, гарип бәбкәне сау-сәламәт бәбкәләр туктаусыз талаган кебек, рәнҗетеп, кыерсытып, тулай тораклан да сөрделәр. Бәхетемә, шундагы бер укытучы кызганып, квартира табып бирде. Ул—рус театрында эшләүче ялгыз маржа иде. Ире татар булган, безнечә теттереп сөйләшә. Берәр атна торгач, бу минем кем икәнне аңлады бит. «Тормышта син болай яши алмыйсың, балам,—ди.—Сине таптап, изеп китәчәкләр. Шәһәрдә яшәргә теләсәң, усал булырга кирәк»,—ди. Мин инде моны үзем дә аңлый башлаган идем. Ничәмә-ничә мәртәбәләр мине сәгатьләр буе торган чиратымнан төртеп чыгардылар. Трамвай, троллейбуска утыра алмыйча калучы да мин идем. «Мин усал була алмыйм»,—дидем мин ана. Ә ул болай ди: «Менә мин сәхнәдә, кирәк булса—карак булам, кирәк булса—фахишә, кирәк булса—министр,—ди.—Ә асылда барыбер үзем килеш калам. Әйдә, мин сиңа бер роль бирәм, ди. Син шуны гына уйна. Коточкыч усал булып кылан. Кемдер сиңа ташланганчы, син үзенә ташлан. Кемдер сиңа бер сүз әйткәнче, син унны әйт. Ташбаканы сыртындагы каты кабырчыгы саклаган кебек, шушы сине саклар, ди. Башта ул мине җитәкләп, үзе өйрәтеп йөрде. Тирләдем, пештем, ниләр генә булып бетмәде. Өйрәндем бит, әй! Үзебезнең группадагы иптәшләр дә минем шулай кыюланып, усалланып китүемә хәйран калдылар. Ярар, хәзер Казанда патша булып йөрим. Мине белгән кешеләр куркалар, бәрелешкә керергә теләмиләр. Болынкырга институт бетереп эшкә килеп төшкәндә, эчемдә һаман шул элекке куян калтырап утыра, ә үзем усал итеп карыйм, усал итеп сөйләшәм, пәрмә-пәр талашам. Болынкыр халкы арттан пышы-пышы килеп кала, йөзләрендә курку билгесе, ә мин эчтән генә көләм. Бу гадәтем миңа бик күп дуслар китерде. Җыелышларда районлагы гаделсезлекләрне тәнкыйтьлим, булдыксыз

житәкчеләрне пыр туздырып сугәм бит, хәтта урамда кычкырып йөрим. Әнә шулай курка-курка усаллана торгач, курыкмый торганга әверелдем. Әкияттәге камырдан әвәләп ясалган Камыр батыр кебек, үземне үзем әвәләп ясадым. Менә мин кем! Ә ялгызлык онытылды! Качты ул. Минем хәзер, гомер буе инспекциядә эшләгәндә үз кулларымнан тикшерү узган чәчү орлыклары кебек, якыннарымның, танышларымның исәбе-хисабы юк.

Чукаева туктап калды. Сөембикә хәйран калып баш чайкады:

—Бу мөмкин әйбер түгел! Үз-үзеңне үзгәртү, белмим, монысы әкияттә генә буладыр.

—Алайса тере әкият каршыгызда утыра. Безнең бер этебез бар иде. Аның кебек усал итеп тешен ыржайткан, аның сыман куркыныч өргән этне белмим. Өргәндә, өзәм дигәндәй, буыла-буыла тамак төбе белән ырылдый, башларын чайкый. Аны күрүгә, кешеләрнең коты алына. Ә менә шул котырып өргән чакта янына кем дә булса килсә, аякларын күтәреп чалкан ята, койрыгын ялагайланып болгый иде. Ялгызлык дигән уйга юл куйсагыз, ул әлеге эт кебек сезнең котыгызны алачак! Ә курку кердеме—кеше бетте дигән сүз. Эшләгез бер батырлык! Ялгызлык дигән уйны күнелегездән куып чыгарыгыз!

Чукаеваның сөйләгәннәреннән айный алмыйча, бик озак уйланып утырды Сөембикә. Ахырда:

—Тырышып карыйм әле, Гандәлифә апа,—диде.

—Ниятенә керсәгез, һичшиксез булдырачаксыз!—диде Чукаева зур жанлану белән.—Мин сезгә тагын бер серемне ачыйм әле. Сезгә, яшь кешегә, бәлкем кирәге чыгар. Адәм баласының тормыштан әйбәт булып китәсе килә икән. Картайгач бу нәрсәне мин бик нык аңладым. Кеше үзеннән нәрсә калуын уйлый. Олы эшләрен булса, әйбәт тә, ә булмаса? Халык хәтерендә истәлек кенә кала. Әйбәтме ул, начармы? Бу барыбер түгел икән. Шуңа күрә жай чыккан саен, кешеләргә куркак, йомшак куян икәнемне сөйлим. Рәхәт булып китә, каһәр. Тик бу серне күпме генә сөйләсәм дә, мин инде бу дөньядан барыбер «усал Чукаева» булып китәрмен. Бөтен кешегә дә үземнең эчемне ачып бетерергә өлгерә алмам шул. Ә «усал» дигән исемне юып китәсе килә...

Сөембикә аның яныннан чыкканда, ялгызлык тойгысыннан котылгандай жиңеләеп калган иде. Менә сиңа усал Чукаева! Күпме рухи жегәр бу карчыкта! Теге батырлыкны һичшиксез эшләячәк Сөембикә. Ул кайтышлый яшьләр үзәгендәге дискотекага кагылырга булды. Акрын гына, сиздермичә генә керде дә почмактан күзәтеп тора башлады. Төрле утлар белән балкып торучы ярым караңгы залда кызлар, егетләр кыргый музыкага дөньяларын онытып бииләр. Бераз читтәрәк әле бала-чагалыктан чыгып житмәгән яшьләр төркеменә күз ташлагач, Сөембикә тынычланып китте: Айгөл шунда иде. Аның башкаларга караганда сыгылмалырак, матуррак хәрәкәтләр ясавын ул шатланып күзәтте. Ничек кергән булса, шулай тып-тын гына чыгып та китте. Машинасына утырып кайтканда да, кайтып өйгә кергәч тә, башыннан бер уй чыкмады: Айгөл үсеп житкән икән бит! Ул инде балалыктан чыгып бара, яшьлек хисләре аны үзе кебек кызлар, егетләр янына тарта. Димәк, ул атна буе дискотекага йөргән. Күрәсең, ул әле моны үзе өчен ярамаган эш дип кабул итә. Әгәр шулай булмаса, «Эти янына барам», дип алдашыр идемени? Димәк, икесе арасындагы мөнәсәбәтләр турында гына түгел, кызының киләчәге хакында ныклап уйланыр көннәргә дә әллә ни ерак калмый...

## 9

Әхнәфнең үзләренең өен тәкъдим итүе әллә нинди бер серле әйбергә әверелде. Ирек инде ул өйдән курка ук башлады. Артык күп кеше тырыша

иде аны башы белән анда тыгарга. Ирекне шул сагайтты да. Әхнәф тә, Гаскәров та берничә чакырдылар. Зәнфирә көн саен диярлек жайлап кына сүз унаен китерә дә шул өйне кузгата. Алар тырышкан саен, Ирек үҗәтләнеп баш тартты. Арслановлар кыш башында күчеп китеп бардылар, ә йортларын орлыкчылык инспекциясенә бирделәр. Әхнәфләр үзләренә яна йорт салалар икән, дигән сүз таралды.

Бер көнне Ирек Гаскәровка кирәргә дип кабул итү бүлмәсендә Зәнфирәнен утырганын ишетте. Хатынының нигә керүен сорагач, ул:

—Авылдагы өйне сату турында кинәштем,—диде.—Акчасына берәр өй алырбыз.

—Ә Зирәк? Заһит абыйның сеңелләре шунда яшәп ята.

—Ничек тә килешербез әле,—диде Зәнфирә.

—Син бу уенны ташла!—диде Ирек, ачуын яшерә алмыйча.—Кешелекле әйбер түгел бу. Сатkan суррәттә сине авылдашлар мәңге гафу итмәс.

Ирек аның ялгышын аңлатырга теләде, ә хатыны һаман үзенекен тукыды. Күпме бергә яшәп, әйткәләшкәннәре юк иде, бозылышып туктадылар. Атна буе юньләп сөйләшмәделәр, ашаган ризыкның тәме китте, күздән йокы качты. Шулай яшәгәндә, беркөнне Зәнфирә эштән очынып кайтты. Ирек сорарга да өлгерә алмады, ул шатлыгы белән үзе уртаклашырга ашыкты:

—Больница безгә квартира салачак!

—Кемгә ул безгә?

—Миңа инде алайса, миңа!

Эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенгән Ирек ни әйтергә белмичә телен тешләде. Берничә көннән баш врачның хуҗалык буенча урынбасары кереп, «Иртәгә фундамент блоклары кайтачак, кран белән бушатырга урын әзерләгез»,—дип китте. Иртәгесен бәрәңге бакчасының коймасына терәп блоклар бушаттылар. Аларны ташу шактый дәвам итте. Язга таба йортның бурасы да кайтарып утыртылды. Ихатага такталар да килеп керде. Эчтән өнәмичә, тыштан эндәшмичә йөрсә дә, үзенең бәләкәй иске өе белән уртада бөрешеп калуын тойды Ирек. Тай ни хәтле тәртәгә дошман булса да, ат булгач үзе кергән кебек, Ирек тә бирешүен аңлады. Май аенда бәрәңге бакчасын экскаватор белән казып, блокларны салдылар. Ишек алдында бүрәнә эшкәртү башланды, олы хәрәкәт кузгалды. Нирг(ә) арты нирг(ә) күтәрелде. Зәнфирә язгы күбәләкләр белән бергә очып кына йөрде. Ирек инде үзе дә берн(и)гә дә карышмады, осталар чакырганда, бүрәнә башына барып ябышты, күтәрешеп салышты, эш коралларын җыеп алып керде, иртән алып чыгып бирде. Ә үзенең эчендә ниндидер килешмәүчән нәрсә утыра бирде. Кысрыклаучы теге билгесез көчкә каршы тора алмавына, йомшаклыгына эченнән акрын гына сызды, алдың белән керсән, артың белән дә чыга алмавың бар дип хафаланды...

• • •

...Быел урак бик авыр башланды. Техника туктаусыз кырыла, шуның өстенә явымнар да комачаулый, оешу да житми. Бүген иртән тагын ару гына яңгыр явып узды. Тагын эш туктады. Яшен тизлегендә телеграмма бирдереп, Әхнәф барлык хуҗалык житәкчеләрен, агрономнарны, инженерларны, партком секретарьларын, авыл Советы председательләрен райкомның киңәйтелгән бюросына чакыртты. Берәм-берәм трибунага менгереп, колхоз-совхоз житәкчеләрен тыңладылар. Соңыннан Әхнәф һәр хуҗалыкка атналык задание житкерде. Аны өзгән суррәттә, партбилетларын кесәләренә салып, райком бюросына киләчәкләрен искәртте. Ул сөйләгәндә, утырышлар залының президиум өстәле турындагы пыяла ишеге берничә мәртәбә ачылып ябылды.

Аны ачып ябучы район эчке эшләр бүлеге начальнигы майор Мохтаров иде. Майорның түземсезләнүе Әхнәфнең ачуын китерде, фикерен таркатты. Ишек ачылган саен президиумда утыручылар да шул якка борылып карадылар. Ахырда Фәнис Сәлахов түзмәде, Мохтаров ачкан ишектән коридорга чыкты һәм ачуын яшерә алмыйча:

—Сез нәрсә, Мохтаров, астыгызга корт кергән кебек кыбырсыйсыз?! Бюро барганын күреп торасыз бит.

—Ашыкмыйча булмады шул,—диде Мохтаров, телеграмма сузып.—Алу белән монда йөгердем.

Сәлахов, телеграммага күз салгач, эсселе-суыклы булып китте. Анда райкомның барлык бүлмәләрен бикләп печатьләргә, милиция сагы куярга, бер сәгатьтән үтәлеш турында турыдан-туры республика эчке эшләр министрлыгына хәбәр итәргә кушылган иде.

Сәлахов телеграмманы тагын бер мәртәбә укып чыкты. Аның мәгънәсе әле һаман да аның башына барып җитми иде.

—Бу хакта беркемгә дә әйтмәдегезме?

—Юк.

—Алайса әйтми торыгыз. Бюродан соң элемтәгә керербез.

Сәлаховның кулына кәгазь тотып керүеннән, йөзенең агарып китүеннән Әхнәф ниндидер гайре табигый хәл булганын аңлады. Аның бу фикерен ныгытып, Сәлахов бармагы белән түгәрәк ясагандай итеп һәм күз карашы белән бюроны төгәлләргә ишарәләде. Әхнәф сүзен бетергәч, бюро яисә киңәшмәнең тәмам булуын әйтә һәм зал урыныннан кубып тора башлый иде. Бу юлы алай эшләмәде, Сәлаховтагы яңалыкны белеп, бәлкем ашыгыч әйтергә туры килер, дигән уй белән урынына барып утырды. Сәлахов аның алдына телеграмма куйды. Әхнәф телеграммадагы сүзләрне өч мәртәбә укып чыкты, алар аның күз алдында тере җан ияләре кебек сикерештеләр. Берәрсе күрмәсен, дигәндәй, ул телеграмманы арткы ягы белән әйләндереп салды, бармакларын кара-каршы китереп, бер-берсенә керештергәч, телеграмма өстенә бастырып куйды. Ул үзен бөтен тормышы бер селтәнүдә сызып атылган кеше итеп тойды. Аның өчен хәзер үзенә төбәлгән залдагы бу кешеләр бер чокырга кисеп аударылган агач өемедәй тоташ масса булып чайкалалар иде. Күрәсең, аның мондый халәте озаккарак сузылды, Сәлахов аңа иелеп:

—Халыкны кайтарып җибәрик инде,—дип пышылдады.

Аның сүзләре Әхнәфне айнытып җибәрде. Ул, үзен кулга алып, көч-хәл белән аягүрә басты:

—Бюро тәмам,—диде ул тоныкк тавыш белән.—Барыгыз да урыннарыгызда булыгыз. Андый-мондый...—Әхнәф телен тешләп туктап калды. «Андый-мондый хәл булса, хәбәр итәрбез»,—дип чак кына ычкындырмый калды ул.—Урып-җыю бүгенге генераль бурыч булып кала. Аңладыгызмы? Кайтырга мөмкин!

Әхнәф белән Сәлахов бюро члennарының чыгып киткәнен дә, залның бушап беткәнен дә урыннарыннан кузгалмыйча көтеп утырдылар. Менә утырышлар залы тып-тын булып калды.

—Ишекне яп әле,—диде Әхнәф.

Сәлахов президиум өстәле турындагы ишекне ябып килде. Әхнәф телеграмманы, язулы ягы белән өскә әйләндереп, тагын бер мәртәбә укыды, кулы белән сыпырып куйды һәм анардан күзен алмыйча:

—Йә, нишлибез?—диде.

—Минемчә, буйсынмый чара юк,—диде Сәлахов.—Без барыбыз да китәбез, сез бүлмәгездә каласыз.

—Ә нишләп мин калам?

—Сез бит район Советы председателе. Безнең баш очында Татарстан флагы җилферди.

Оештыру бүлеге мөдире урыныннан торып чыгарга әзерләнде.

—Туктале, Сәлахов,—диде Әхнәф.—Чыкмый тор әле анда.

Ул һәр кинәшмәдән соң кабул итү бүлмәсенә халык җыелганын белә, һәммәсе дә бер житешеп килгәч, аның янына кереп, ни дә булса хәл итәргә тырыша. Ә бүген алар менә хәзер шушы минуттан беренче секретарьның юк икәнлеген белмиләр.

—Алдан һич нәрсә сизелмәде,—диде Әхнәф.—Берәр авантюра гына түгел микән бу? Партияне юк итү өчен төрле омтылышлар булганын мин сизә идем инде. Тик бу дәрәҗәдә кинәт...

—Минемчә, Әхнәф Хәсәнович, дискуссия оештырып тора алмыйбыз. Безнең буйсынмый хакыбыз юк.

—Мин дә шулай уйлыйм. Алайса болай итәбез,—Әхнәф сәгатенә карап алды.—Унбиш минуттан барлык райком работникларын минем бүлмәгә алып керегез.

Алар чыкканда, әле коридор тулы халык шау-гөр килеп тора иде. Кабул итү бүлмәсендә дә йөрмәле түгел. Әхнәф халыкны ерып керде дә ике кулын өскә күтәрде:

—Иптәшләр, гафу итегез, беркемне дә кабул итә алмыйм.

—Әхнәф Хәсәнович, бер генә минут!

—Минем бер генә нәрсә сорыйсым бар...

—Мин үзегез кушкан документларны алып килгән идем, кул гына куегыз.

—Юк, юк, юк!—диде Әхнәф, бүлмәсенең ишеген ачып.—Ярты минут та вакытым юк!

Кемнәрдер көтеп торачакларын әйттеләр.

—Аңлыйсызмы, бүген беркемне дә кабул итмәячәкмен. Барыгыз, кайтыгыз, эш оештырыгыз!

Ул бүлмәсенә керде дә секретарь кызга шылтыратты:

—Барысын да чыгарып җибәрегез. Бүген дә, иртәгә дә беркем дә кабул ителмәячәк.

Әхнәф өлкә комитетының берничә телефонына шылтыратып караса да, җавап бирүче булмады. Ул арада ике секретаре, бүлек мөдирләре, инструкторлар, кыскасы, райком аппаратының барлык кешеләре аның бүлмәсенә кереп утырдылар, һәрберсенең йөзендә аптыраш билгеләре иде. Әхнәфкә алар нишләптер якын кешеләрен теге дөньяга озатырга җыелган халыкны хәтерләттеләр. Ул акрын гына басты да кычкырып теге телеграмманы укып чыкты һәм:

—Моның нәрсә икәнлеген барыгыз да аңлыйсыздыр?—дип өстәде.

Ул сүзен әйтеп бетерер-бетермәстән, машинистка Бәдрия Минһаҗева аның каршына йөгереп килде, куркыныч булып тартышкан чыраен әле ана, әле җыелган кешеләргә борып, нидер әйтергә маташты:

—Иптәш Шәрифуллин. . . иптәш Шәрифуллин! . .

Гомере буе райком инструкторы сыйфатында районнан районга күчеп йөргән, ял көнен дә, көнне-төнне дә белмәгән, гаилә төземәгән, ябык гәүдәле бу хатын, пенсиягә чыккан көненнән машинистка булып эшләүче хыялый бер зат иде. Бәдрия Минһаҗеваның бөтен тормышы партия эшеннән генә торды. Аның эчке халәтен, ник өзгәләнүен бүлмәдәгеләр яхшы аңладылар. Ахырда ул аһырып ике сүз әйтә алды:

—Партияне бетергәннәр! ! !

Моны ул шундый ачыну белән, үтә дә куркыныч итеп әйтте ки, барысының

да тетрәнүдән тәннәре чемердәп куйды. Авызын ачкан килеш өзек-өзек сулыш алган Бәдрия Минһажева чигенеп, артындагы урындыкка ауды. Кемдер аңа су бирде, дару эчерделәр, шуннан соң култыклап бүлмәдән алып чыгып киттеләр. Әхнәф сүзен дәвам итте:

—Ярты сәгать эчендә һәрберегез шәхси әйберләрегезне жыештырып бетерегез, сейфлары булган иптәшләр бикләп, ачкычны үзегез белән аласыз. Шоферлар машиналарын куеп гаражны биклиләр һәм ачкычларын мина тапшыралар. Соныннан сүзе булмасын өчен, бүлмәләрегезне үзегез карап торып сургучлатыгыз. Шушыннан ары мин бер сүз дә әйтә алмыйм. Чөнки үзем дә берни белмим, һәрхәлдә паникага бирелергә кирәкми. Беркем дә эшсез калмас. Кемнәрнедер хөкем итәргә дә жыенмыйлардыр, дип уйлыйм. Сораулар бармы?

Беркем дә бер сүз дә дәшмәде. Барысы да, башларын игән хәлдә, акрын гына чыгып киттеләр. Кырык минут үтүгә, барлык бүлмәләрнең сургучлануы, печать басылуы, ишек төбенә бер милиционер куелуы турында Фәнис Сәлахов кереп хәбәр итте.

—Ярый, кайтыгыз,—диде Әхнәф аңа.

Райком бинасы тып-тын калды. Казаннан бер генә шылтыратучы да юк иде. Әхнәф түзә алмыйча өлкә комитетының оештыру бүлегенә шылтыратты. Әмма, җавап бирүче булмады. Башка бүлекләр белән дә шул ук хәл кабатланды. Ул инде батып баручы корабның капитаны кебек, ишеген ачык калдырып, коридорга чыкты. Биредәге тынлыкка исең-акылың китмәле иде. Ул беренче катка төшеп китте. Ишек янындагы дежур торучылар утыра торган өстәл янындагы милиционерга күз ташлады. Ул моннан күп еллар элек Казанда Әхнәф алдап качкан Иван Урусов иде. Беренче секретарьны күргәч, ул урындыгыннан кузгалып, торып басты. Аңа якын килгәч, Әхнәф инде хәзер капитан дәрәҗәсен йөртүче Урусовның үзенә кызганып каравын сизде. Аның һич тә кызганыч хәлгә каласы килми иде. Шуңа күрә көчәнеп булса да елмайды да:

—Менә бит тормыш дигәнең ничек, иптәш капитан,—диде.—Казанда мин синнән бик ансат котылган идем, ничә ел куа торгач, тәки китереп каптырдың бит.

Урусов саран гына елмайды да:

—Янадан куышырга язмасын иде инде, Әхнәф Хәсәнович,—дип куйды.

—Менә анысын кистереп әйтә алам: кабат минем белән куышу булмаячак.

Коридор буйлап барганда, бүлмәләрдә туктаусыз телефон шылтыравы ишетелде. Димәк, әле халык нәрсә булганлыгын белеп бетерми. Бүлмәсенә кергәндә, аның телефоны да бик каты шылтырый иде. Трубканы алуга, Наратбаштан Нуриевның калтыранган тавышы ишетелде:

—Әхнәф Хәсәнович, без ишеткән хәбәр дөресмени?

—Әйе, дөрес,—диде Әхнәф, мөмкин кадәр ышанычлы тавыш белән җавап бирергә тырышып.

—Ни була соң инде бу? Безнең эш урыны да бетәмени?

Болай да шартларга торган күнелен басар өчен Әхнәф ачу белән:

—Синең эш урының сакланыр инде, Нуриев агай. Тик райком гына булмаячак,—диде дә трубканы куйды.

Шуның ише мәгънәсез шылтыратулардан тыш Казан тарафыннан берниндн хәбәр дә, күрсәтмә дә булмады. Әхнәф ни уйларга да белмәде. Гүя аяк астындагы жир убылып төште. Аяк астында гына түгел, аның гомер буе корган мәһабәт сарае , ул сарай тирәсендәге чәчәкләр белән бизәлгән бакчасы—бөтенесе юкка чыкты. Тормышны яңадан башларга туры киләчәк иде. Ә инде башлау өчен хәзер соң, хәзер башлау түгел, аны яхшы итеп төгәлләү

турында уйларга вакыт житкән иде. Ул хакта Әхнәфнен инде күнелендә эшләнгән ачык планы да бар иде. Бу план тормышка ашса, анын үзен дә, гаиләсен дә искиткеч якты көннәр көтә иде. Хәзер инде ул планнар турында беркемгә дә авыз ачып әйтмәгән өчен куанырга гына кала. Әгәр әйткән булса, кайсылары бармак төртә-төртә көләрләр, мыскыл итәрләр иде. Ә болай Әхнәф инде аны үз күнелендә яшерен генә учак ягып, шунда дөрләтеп яндырыр да, көлен һавага очырыр. Анын нинди гөнаһлары өчен килеп чыкты икән бу бәла? Ә бәла ялгыз йөрми, анын артыннан шәүлә булып икенчесе килергә тиеш. Анысы хакында уйласан, күз алды бөтенләй карангыланып китә. Тораташ булып, башыннан мен төрле уй үткәреп, кичке алтыга кадәр урыныннан кузгалмыйча утырды ул. Аннары акрын гына киенә башлады. Шулчак телефон шылтырады. Шылтыратучы Рашат иде.

—Добрый вечер, Әхнәф Хәсәнович!—диде ул бераз гына исерегрәк тавыш белән.—Как дела?

—Әйбәт кенә әле,—диде Әхнәф.

—Әхнәф Хәсәнович, мин сезнен исәнлекне белешергә дип шылтыратмыйм, Чаллы мәсьәләсе ничегрәк? Мина крыша мәсьәләсе?

—Хәзергә берни дә әйтеп булмый, Рашат.

—Минем ничә мәртәбә шылтыратканны беләсенме син, Шәрифуллин? Шушы моментта мин Ленин мавзолее каршындагы бер йорттан шылтыратам. Переговор өчен түләгән акчаларны сездән даулаячакмын бит мин.

—Анла: квартира мәсьәләсе бик нык катлауланды.

—Ә нигә алдадын мине, Шәрифуллин?!

—Алдамадым. Алай жинел генә хәл ителми ул.

—Ярар, мин кайтып килермен әле.

Рашат трубкасын куйды. Әхнәф йодрыгы белән өстәлгә шартлатып сукты. Бик кирәк иде синен кайтуын, диде ул эченнән ярсып.

Фәһимә аны, югарыга ыргытып төшергән туп ничек сикергәләсә, шулай сикергәләп каршылады.

—Менә булдырдын!—дип ташланды ул ана, тупсаны атлап керү белән.—Арсланов йортына күчеп калган булсак, ак сакаллы карт була идек!

—Ә анда күчәргә теләмәүче син түгелме сон?—диде Әхнәф.

Фәһимә ана очып кына кунды:

—Мин түгел, син! Менә хәзер шымытыр башы тотып калдык инде!

—Кит каршымнан, ахмак!—диде Әхнәф, бөтен ачуын ана чыгарып.—Башны кискәндә, чәч кайгысымы монда?!

Фәһимәнен тавышы ысылдап чыкты:

—Кабатла әле, нәрсә диден син?

Әхнәфнен инде күптән ана алай тупас бәрелгәне юк иде.

—Минем хәлемә керер чакта, эт сыман ташланасын. Ахмак булып тугансын, ахмак булып үләрсен.

Әхнәф жилләнеп залга керде дә, партия мәсьәләсендә яна хәбәр тапшырмаслар микән, дип телевизорны кабызды. Күнелгә ятышлырак берәр хәбәр көтеп, баскан килеш зал уртасында торды. Шулвакыт артында Фәһимәнен нидер кычкырганы ишетелде. Ул борылып карарга өлгерә алмады, баш түбәсенә уклау килеп төште. Бу хәл күз ачып йомган арада булды. Әхнәф авыртудан кычкырып жибәрде, баш түбәсеннән стенага кан чәптерде. Үзенен нишләгәнен анлап алган Фәһимә кычкырып еларга тотынды һәм ашыгыч ярдәм чакырырга телефонга ташланды. Әхнәф бер кулы белән башын тотып, икенчесе белән телефон трубкасын анын кулыннан тартып алды.

—Нишлисен?!

—Ашыгыч ярдәм чакырам.

—Ахмак кына түгел, дура син! Бәйлә тизрәк! Алып чык бирәр нәрсә!

Фәһимә каушавыннан, шифоньердан юрган сырырга дип алып төрелгән ике килограмм мамыкны эләктереп, Әхнәфнең каршына килде. Мамыкны куйды да кухня ягыннан ялтыравыклы чәй кәгазе, бер кәшимир яулык тотып йөгереп килде. Әхнәф бер кулы белән мамык умырып алды да калганын телевизорга таба тибеп очырды. Фәһимә мамык өстеннән кәшимир яулыкны калтырана-калтырана, елый-елый бәйләп куйды. Шулай итеп партия беткән көн Әхнәфнең тормышыннан кан белән китте...

## 10

Партиянең бетерелүен, СССРның таркалуын ишеткәч, Хәйри коелды да төште. Җанындагы җегәре кинәт юкка чыкты, тәнендәге каны суынгандай булды. Ул сәгатьләр буе уйланып ята башлады, туктаусыз авыр сулап уфылдады, йөрәк дарулары эчте. Вакыт-вакыт хәлсез аякларын сөйрәп, басулардан урап кайтты, колхоз идарәсенә сугылды, кешеләр белән сөйләште, әмма үзенә урын таба алмады. Нидер эзләгәндәй, күпме генә йөрсә дә, бушлык томанына барып керде. Халыкны яктырак тормышка чыгарыйк, дип көне-төне түккән мангай тирләре, күкрәк көчләре, сугыш михнәтләре, аннан соңгы дәверләрдәге ашкыну-талпынулар—бөтенесе дә элекке мәгънәләрен җуйдылар, әһәмиятсез, төссез чүбәләнүгә әйләнеп калдылар. Аның мәгънәле тормышы сызып атылган иде.

Бер көнне кичкырын Хәйри идарә тирәсеннән урап кайтырга, кешеләр белән сөйләшеп, җанының сызлауларын әз булса да басарга дип урамга чыкты. Үзләренең турыннан үтәргә дә өлгермәде—күкрәген яндырып нидер кысып алды, күз алдында кара нокталар биешергә тотынды һәм ул кесәсендәге нитроглицеринын авызына кабарга да өлгерә алмыйча җиргә ауды. Ашыгыч ярдәм машинасының килүен, больницага илтеп салуларын, Ирек белән Зәнфирәнең үзе янында бөтерелүләрен ул төштәге кебек кенә хәтерләде...

Әтиләренең авыруы барысын да хафага төшерде. Интенсив терапия нәтиҗәсендә аның хәле күзгә күренеп әйбәтләнде. Бер ай дигәндә Хәйрине больницадан чыгардылар. Әмма врачлар Мэлс белән Ирекка куандырырлык сүз әйтмәделәр. Сездән яшереп торуның файдасы юк, әтиегезнең йөрәге соңгы чигендә эшли, бүген-иртәгә ни буласын әйтүе кыен, диделәр...

Беркөн төштән соң Хәлимә музейга шылтыратты. Аның тавышын ишетү белән Иреквнең эче жу итеп китте.

—Әтинең хәле ничек?—диде ул кабаланып.

Хәлимә көттереп кенә җавап бирде:

—Сезне чакыра ул. Кайтып килсәгез әйбәт булыр иде...

—Хәле начарланмагандыр бит?

—Алай ук дия алмыйм, үзегез белгәнчә инде. Айгөлне дә алып кайтыгыз,—диде.

Ирек шундук шылтыратып абыйсына хәбәр итте. Аннары ул Сөембикә белән элемтәгә керде, хәлне анлатып бирде.

—Мин Айгөлне үзем генә алып кайтырмын,—диде Сөембикә, Мэлсларның ничәдә кайтачагын ишеткәч. Аннары сүзләренә басым ясый-ясый өстәп куйды:—Минем кайтуга син каршы килмәссең бит?

—Үзенә кара,—дип куйды Ирек.

Кич Мэлс белән Нәфисә кайтып төште. Алар күтәртеп түбәсе ябылып куелган яна өйне эченнән дә, тышыннан да карап йөрделәр, бик шәп була, дип мактадылар, исән-имин бетереп керергә язсын, диделәр. Капкалап алганнан соң, дүртәүләп авылга юл тоттылар.

Алар кайтып кергәндә, әтиләре ястыкка аркасы белән сөялеп утырган

иде. Күрешеп хәл-әхвәл белешкән арада Айгөл белән Сөембикә дә кайтып житте. Айгөл керү белән бабасына барып сарылды, бабасы аның чәчләрен сыпырды, иннәреннән сөйде, бик озаклап карап торгач:

—И, кызым, син дә үсеп життен бит,—диде. Күзеннән бер тамчы яшь чыкты, аны Гөлжамал җәһәт кенә алъяпкыч итәге белән сөртеп алды.

—Безнең Алмаз белән Гөлназ икесе дә эштә бит әле, әти, Казан артында ук,—диде Нәфисә.

—Беләм, кызым. Кайту белән алып килерсез. Сагындым...

Гөлжамал аларны кече якка әйдәде:

—Капкалап алыйк, балалар. Син утырасынмы, әтисе?

—Берни дә кабасым килми. Барыгыз, ашагыз. Без монда малайлар белән сөйләшә торыйк әле.

Хәйри инбашын селкетеп ястыгын күчерергә азапландымы, Мэлс белән Ирек аның гәүдәсен турайттылар да, ястыкны кабартып салдылар. Әтиләре рәхмәт әйткәч, аларның икесенә дә бик житди итеп озаклап карап торды. Шуннан соң әллә нинди, йөрәк өзгеч тавыш белән пышылдады:

—Әйтегез миңа: партиягә ни булды?

—Таралган иде бит инде ул, әти,—дип куйды Мэлс.

Аның сүзләре белән килешмичә, Хәйри баш чайкады:

—Без төзегәнне сез харап иттегез...—Әтисенең сулышы кысылды, күзләре йомылдылар, гүя ул тавышсыз гына елый иде.—Ил юкка чыкты. Без шул ил дип яшәдек...

Әтисе сүзеннән туктады, аның маңгаена, битләренә тир бәреп чыкккан иде. Ирек кульяулыгы белән аның тирен сөртеп алды.

—Бакчаны чүп-чарлардан чистарту кирәк бит инде, әти,—диде Мэлс.—Ул яшәреп, үсеп китәчәк.

—Чистартуны күргән бар,—дип сузды әтиләре.—Ата абруе бетсә, гаилә таркала. Партия миңа атам кебек иде. Ә менә ата-баба үстергән бакчаны балалары кисеп ташласа, бу инде хәтәр нәрсә. Иң олы афәт шунда.—Әтиләре тынып, тагын бераз хәл җыеп торды.—Мин үзем сездән канәгать, балакайларым. Төчеләнә алмадым. Анысы өчен кичерерсез инде. Шулай да... мәхшәр килә. Бөтенесен сатачаклар, моның азагы хәтәр булачак. Менә әти әйткән иде, диярсез.

Хәйри күзләрен йомып, башын бераз кыйгайтып ястыкка терәлде. Мэлс белән Ирек сүзсез генә бер-берсенә карашып куйдылар.

—Арыттык бугай, теге якка чыгыйк,—диде абыйсы пышылдап.

Ләкин әтиләре аларның сүзен ишетеп яткан булып чыкты. Күзләрен ачты да:

—Туктагыз,—диде.—Сезгә васыятем бар. Үлгәч, партбилетымны күкрәгемә куярсыз.—Ул, аңладыгызмы, дигән мәгънәдә һәр икесенә озаклап карап торды.—Мин инде үзгәрә алмыйм. Уйланмадым түгел, күп уйладым. Әнә күрше Гариф абыегыз мәчеткә йөри, аның гомер буе коммунист икәнен беләсез. Мин алай булдыра алмыйм. Андый кешеләрне аңлый да алмыйм. Ялгышамдыр бәлки... Миңа шул заман кешесе булып китәргә рөхсәт итәрсез бит?

Ирек кабаланып:

—Син бүгенге заман кешесе, әти!—диде ул аны тынычландырырга теләп.—Барлык коммунистлар да синең кебек булсыннар иде әле.

—Үтәрсезме минем әйткәнне?

—Үтәрбез,—диде Ирек.

—Рәхмәт, балалар,—диде әтиләре әллә нинди жылы, ягымлы тавыш белән.—Чакыруым шуның өчен иде. Зинһар авырыксынмагыз. Мөмкинлек барында әйтеп калыйм, дидем. Ә хәзер барыгыз, әниегез янына чыгыгыз. Мин бераз

ял итәм...

Әтиләре шулай диде дә күзләрен йомды. Аның утырып торуына, сөйләшүенә, зиһененең сафлыгына сокланып кайтып киттеләр алар. Дүрт көннән Хәлимә кабат Иреккә шылтыратты :

—Хәйри абыйның хәле әйбәт түгел,—диде.

Сәгать ярымнан Мэлс белән Ирек авылга кайтып җитте. Дүрт көн эчендә әтиләренең кыяфәте үзгәрүенә ышанырлык түгел иде. Ул суырылып, саргаеп, кечерәеп калган. Хәтта үзе яткан караватта гәүдәсенең калкып торуы да сизелми кебек. Сүзләрен дә бик авырлык белән, туктап-туктап кына сөйләде.

—Кичә кич әнә шул аралыкка әниең белән тышка чыгарга көчкә бардым. Бүген инде кузгалырлык рәтем юк...

Ирек аның яныннан китмәскә булды. Икенче көнне кич Хәйри телдән калды. Әтисенең сәгатьләп түгел, минутлап сула баруын күрү Ирекнең үзеген өзде. Аның күңелендә әтисе әле һаман бернидән курыкмаучы, тормышны аяусыз ерып баручы илаһи зат буларак яши иде. Әтисенең хәле авыраюы яшен тизлеге белән бөтен авылга таралды, өч көн буе иртәдән кичкә кадәр өйдән кеше өзелмәде. Сөйләшә алмаса да, ул аңында иде. Хәлен белергә килүчеләрнең «Мине таныйсыңмы?»—дигән сүзләренә керфек кагып җавап бирде. Өченче көнне төштән соң ул күкрәге белән сулыш ала башлады. Зәнфирәне алып, Мэлс белән Нәфисә дә кайтып җиттеләр. Әнисе Иреккә:

—Кулыннан тот, улым, юкса аңа бик кыен булачак,—диде.

Ирек әтисенең кулыннан тотты. Ул инде нык суынган, җан билгеләре сизелми иде. Алдагы көнне үк каралган аяклары һаман төсен үзгәртә бардылар. Сәгать дүртләрдә икенде вакытларында әтисенең сулышы өзелде...

Хатын-кызлар елашырга керештеләр. Җанын кая куярга белмичә, Ирек тә әле ишек алдына чыкты, әле өйгә керде. Абыйсы гына салкын канлылык саклый алды. Җирләү мәшәкатьләрен хәл итү өчен ул машинасы белән авыл Советы председателен, колхоз җитәкчеләрен күрергә китте. Әтисенең өстенә ак простыня ябылган, күкрәк турына аркылыга пычак куелган, тирә-юненә карт-коры, үзенең замандашлары җыелып утырган иде. Ирекнең ике чигәсе сулык-сулык килеп сызлый башлады. Ул өйдән чыгып китте, йөгереп диярлек бәрәңге бакчасы аша үтеп, ындыр коймасы буена барып утырды. Биредә талгын гына җил исә, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, чикерткәләр чырлый, берни булмагандай, кояш бүген батып, иртәгә чыгу өчен офыкка якынлаша иде. Әтисе юк! Мәңге булмаячак. Ул бу вакытта җирдә дә, һавада да түгел, ниндидер хыялый дөньяда йөзде, кешенең туудан юкка чыгуына кадәрге юлын барлады.

... Кеше ана карынында ярала, шунда үсә, соңга таба хәтта тышкы дөньядагы тавышларны да ишетә, диләр. Бервакыт аңа нидер төртә, кыса, бөтен җирен авырттыра башлый. Ул ахырда каядыр шууын сизә. Ниндидер каты, рәхимсез нәрсәләр аны капшый, тарта, ул гәүдәсенең таш булып ката баруын тоя һәм аны коточкыч курку били. Бу курку—бөтен галәмгә җитәрлек кара курку. Әгәр кеше туып яши алса, мондый куркуны тагын бер мәртәбә соңгы сулышын алганда тоячак. Кеше үз дөньясыннан ниндидер коточкыч тирәлеккә күчүен сизә, әмма берни дә аңламый. Тәүге сулыш белән эченә ниндидер ят, салкын нәрсә керүен тоя, тончыга-тончыга үкереп елый. Кеше сукыр, саңгырау, акылсыз булып туа, яши-яши ишетә, күрә, фәһемли башлый. Ана бөтен тереклектән өстен итеп акыл бирелә, дөньяны күрә башлый, берни дә аңламый, әнисенең сөтен имә дә йоклый. Тора-бара әнисен таный, көлә, ләкин әле берни дә аңламый. Аңларга тырыша, гомере буе аңлап бетерә алмый. Шатлыклар, газаплар кичерә. Газаплары шатлыклардан күбрәк була, әмма барыбер җирдә тормышны аңлый алмый. Күпләр, дөнья малына, ләззәтләренә алданып, кабат

сукырая, чукраклана, аның югалта... Гомер азагы җитә. Иң бәхетле кешеләр—кинәт үлеп китүчеләр. Газапланып үлүчеләр бала булып туган чактагы барлык халәтне дә кичерәләр: авырту, дөнья дигән карыннан җиргә күчкәндәге коточкыч тартышу! Әгәр озак ятса, кеше көннәрен, сәгатьләрен саный, үзе белән хушлашырга килүчеләрне күрә, сөйләшкән тавышларны ишетә. Соңгы сулыш, соңгы авырту, җанның бүтән дөньяга талпынуы һәм инде хәлсезләнгән тәннен аны тота алмыйча ычкындыру дәһшәте... Бөтенесе бергә бутала... Җан адәм баласына карында инә, җанның яшәгәндә үк авызга килгән чаклары була, җан белән тән гомер буе тартышалар, шул ук вакытта берсе икенчесеннән башка яши алмый. Никадәр гаделсезлек! Ике дошманны бер тәнгә бикләү нигә кирәк булган? Бу гомер буе тартышуның азагы барыбер җанның тәнне ташлап, китүе, кешедән котылуы белән тәмамлана...

Ирек уйларына батып бик озак утырды. Инде кызарырга өлгергән кояшка күз кабагын күтәрмичә, керфекләре арасыннан нишләптер рәнҗеп, үпкәләп карады...

* * *

Хәйрине җирләргә авыл халкы гына түгел, районның барлык җитәкчеләре җыелды. Килгән җинел машиналар Болынкырның ярты юлыннан башлап, Баллы Төбәккә кадәр сузылганнар иде. Әтиләрен юып кәфенләгәч, Ирек белән Мэлс картлар янына керделәр. Ирек әтисенең партбилетын кесәсеннән чыгарып:

—Әтинең әйткән васыяте бар иде бит, агайлар,—диде. Мулла вазыйфаларын башкаручы Минлегәрәй:

—Әйдә, әйт, улым, нинди васыяте бар иде?—дип сорады.

—Җирләгән чакта партия билетын күкрәгенә куярга кушкан иде.

Бу сүзгә картлар дәррәү ризасызлык белдерделәр. Арада, аның васыятенә каршы килмәскә кирәк, диючеләр дә табылды. Минлегәрәй, бөтен кешене тынычландырып, үз сүзен әйтте:

—Шәригать кануннары буенча бу һич тә ярый торган эш түгел. Мин үзем монда каршы.

—Без бит ана сүз бирдек!—диде Ирек дулкынланып.—Әтине ышандыргач, әгәр васыятен үтәмәсәк, бу бит безне гомер буе борчый торган бер яра булачак. Шулай бит, абый?

Мэлс бер сүз дә әйтмәде. Картлар тагын шаулаша башладылар. Кемнәрдер, монда баш бетәрлек нәрсә юк, дип Ирек ягыннан сөйләделәр, икенчеләре каршы төште. Ахырда Минлегәрәй нидер уйлап:

—Барыгыз әле, Гөлҗамалны алып керегез,—диде.

Кече өйгә чыкканда, Ирек абыйсына:

—Ник бер сүз дә дәшмисең?—диде, үпкәсен белдереп.

—Ничек дәшим белмәгәч? Йола зурракмы, әллә кешеме?

—Син бит әтигә, куярбыз, дидең.

—Каршы әйтергә идемени?

Әниләре авызын яулык очы белән каплап керде дә, түргә узмастан, ишек янагына сөялде. Аның йөзе кәфендәй агарган, күз карашы битараф, күңелендә дөнья кайгысы калмаган иде. Картлар хәлне аңлаткач, барысы да Гөлҗамалга төбәлделәр.

—Мин ни әйтим соң инде?—диде ул авыр сулап. Аннары Хәйри янына ук килде дә ничектер кинәт кенә башын күтәрде, күзләренә нур инде.—Барыгызга да мәгълүм, бу фани дөньяда ул баш иярга яратмады, үз кануннары белән яшәде. Әгәр аның васыятен үтәмәсәм, теге дөньяга баргач, мин аңа ни дип җавап бирермен? Безнең хөкем ярамас монда, хөрмәтле картлар, Ходайның

үз хөкеменә тапшырыйк...

Әниләренең шул сүзе мәсьәләне хәл итте дә куйды: кәфеннең бер урынын ачып, партия билетын нәкъ йөрәге турына куйдылар. Хәйринең гәүдәсен ишек алдына чыгаргач, урам яклап капка төбендә зур митинг булды. Аны Гаскәров алып барды. Беренче булып Әхнәф чыгыш ясады, эштә дә, шәхси тормышында да халыкка үрнәк булуын, шундый күркәм шәхесне югалтуның авырлыгын әйтте. Аннары районның башка җитәкчеләре, авыл кешеләре чыгыш ясадылар. Соңыннан Мэлс та сөйләде, әтисен соңгы юлга озатырга килүчеләргә рәхмәт әйтте. Алар арасында Батталов кебек колхоз-совхоз җитәкчеләренең булуы, аларның һәркайсының килеп кайгы уртаклашуы Ирекне чиксез дулкынландырды. Кызы Айгөл әбисе янынннан китмәде. Бабалары исән чакта ук кайтып җиткән Алмаз белән Гөлназ да күбрәк әбиләре янында булдылар.

Менә Хәйринең мәетен күтәреп ишек алдыннан алып чыктылар. Кайгы ташкыны, тавышсыз гына чайкалып, капка төбеннән кузгалды. Шушы урам чирәмнәрендә тәгәрәп үскән, нәни аяклары белән шушы урамның кайнар тузаннарын таптап йөгергән, дөнья кубарып кычкыра-кычкыра гөрләвек суларын ерган малай шушы урамга бүтән беркайчан да кайтмаска тып-тын гына китеп барды...

## 11

Сөембикә, биючеләрнең республика смотрында быел беренчелекне алабыз, дигән уй белән ашкынып яшәде. Чөнки болынкырлылар гомер-гомергә бию белән дан казандылар, соңгы вакытларда райондагы күп кенә талантлы яшьләрне табып, сәхнәгә тарта алдылар. Турлап-турлап оештырылган зона ярышларында иләнгәннән соң, Казанга узулары аның ышанычын тагын да ныгытты. Тик киемнәрнең искелеге эчен тырнап торды. Яз көне мәдәният хезмәткәрләре алдында чыгыш ясаганда, район хакимият башлыгы Әхнәф барысының да күзләренә карап: «Быел биючеләр ансамблен тулысынча яңа киемнәр белән тәэмин итәргә сүз бирәм», дигән иде. Озын җәйләр дә үтте, инде көзләр дә онытылды, хәзер салкын кыш, ә киемнәр һаман юк.

Хакимият башлыгы бүлмәсенә кереп, шуны исенә төшергәч, ул авыр итеп сулады да:

—Биргән вәгъдәм исемдә, тик берничек тә ярдәм итә алмыйм,—диде.

Сөембикә аңа зур өметләр белән кергән иде. Әхнәфнең уен белү белән, күңелен кимсенү тойгысы биләде, бит очлары кызышып чыкты. Әгәр хәзер ул берәр сүз әйтсә, һичшиксез чәкәләшеп туктаячаклар иде. Шуңа күрә тешен кысып урыныннан торды.

—Ярый, аңладым,—диде дә ишеккә таба юнәлде.

—Туктале, Сөембикә!

Әхнәфнең шулай эндәшүе аның күңелендә өмет чаткысы уятты. Ул аның каршысына килде.

—Йөзеңнән күреп торам—үпкәләдең. Финанс хәлебез коточкыч кыен. Аңлый алмыйсыңмыни?

—Аңладым, дидем ич...

Сөембикә кызу-кызу атлап чыгып китте.

...Казанда аларның чыгышларын көчле алкышларга күмделәр. Болынкырлылар күршеләреннән шактый өстен торалар иде. Сөембикәнең татар кызлары биюен зал әсәренеп карады. Ахырда халыкның бердәм кул чабуы, тулы бер ритмга көйләнеп, бик озак яңгырап торды. Ул ике мәртәбә чыгып баш иде, алкышлар туктамагач, биюнең азагын тагын кабатлады. Аңа бер-бер артлы чәчәк бәйләмнәре күтәреп менделәр. Чәчәк сузучылар арасында

ул Арслановны да күреп алды. Сөембикә сәхнә артына ашыкты, чәчәк күтәреп менүчеләр аның артыннан иярделәр. Ниһаять, алар берәм-берәм төшеп киттеләр, Арсланов үзе генә торып калды.

Ул искиткеч эре кызыл розаларны Сөембикәгә сузды. Сөембикә чәчәкләрне кулына тотарга да өлгермәде, Арсланов аны кочаклап күкрәгенә кысты һәм «Рәхмәт» дип пышылдады. Сөембикәнең күкрәгенә роза чәчәгенең чәнечкесе кадалды. Ул авыртудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Аларга кызыксынып төбәлгән күзләр аның тәнен өттереп алгандай булды.

—Рәхмәтне аларга әйтегез, Минзаһит Усманович,—дип, үзе белән килгән үзешчәннәргә таба атлады.

Арсланов аңа ияреп барды, үзе таныганнарының да, танымаганнарының да кулларын кысты, аннары, хакимият башлыгы урынбасары Зәйнуллин белән исәнләшеп, район хәлләрен сораштыра башлады. «Шактый бирешкән, сагына, күрәсең», дип уйлады Сөембикә эченнән генә һәм аңа тагын бер карап куйды да киемнәрен алыштыру өчен бүлмәгә юнәлде. Шунда ул өч кенә адым ераклыкта кемнәргәдер чәчәк биреп маташкан Хәятны күреп алды. Аларның күзләре очрашты һәм Сөембикә түбәнчелек белән баш иде.

—Концертыгыз искиткеч булды. Рәхмәт,—диде Хәят, аның белән күрешеп.

Ул арада Арсланов алар янына килеп басты.

—Безнең янга буфетка керегез,—диде Сөембикә, нишләптер битенең ут яна башлавын тоеп, һәм йөгереп китеп барды.

—Әйдә, кереп чыгыйк. Зәйнуллин да чакырган иде бит.

Минзаһитның бу сүзләренә Хәят усал караш белән җавап бирде:

—Безгә шунда керү килешер, дип уйлыйсыңмы?

Минзаһит бераз уйлап торды да:

—Кайтып киттек алайса,—диде.

Алар кышкы Казан урамыннан ашыкмыйча гына култыклашып кайттылар. Артык салкын булмаган ап-ак шәһәр төне иде бу. Минзаһитның Болынкырдан килеп Казан урамнарында кем белән дә булса парлашып йөргән чаклары хәтеренә төште. Менә алар кайтып җиттеләр, ишекне Минзаһит ачты һәм алдан кергән Хәят бусаганы атлауга авызын ачып туктап калды. Кухня ягында чырык-чырык көлгән исерек хатын-кыз тавышы ишетелде. Башын сузып кухняга карауга, ул егылып китә язды: бөтен киемнәрен салып ташлаган Рашат, анадан тума бер хатынның башын беләгенә салып, имиен имеп утыра иде. Хәят ничек чыгып йөгергәнен дә сизмәде. Минзаһит аптырап:

—Нәрсә бар?—диде.

Хәят ингаляторын чыгарып авызына дару сиптерә башлады, Минзаһитның соравына, кереп кара, дигән мәгънәдә кулы белән ишарәләде. Минзаһит кереп аларны күргәч:

—Что это такое?!—дип кычкырып җибәрде.

Рашат урыныннан сикереп торды һәм аны да уздырыбрак җикеренергә керешге:

—Ты чего, не видишь что ли?! Перед тобой женщина. Совсем стыд потерял!

Ул әтисен этеп җибәрде, Минзаһит сөгенеп идәнгә тәкерде, һәм, күзләрендә ут уйнатып, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Хәят тавышсыз гына елый иде.

Алар бер-берсенә карамыйча, йөзләрен кая яшерергә белмичә, шактый гомер ишек төбендә тордылар. Ниһаять, эчтә дөбердәгән тавышлар ишетелде, келәләр, йозаклар шылт-шылт килде һәм тимер ишек ачылып китте. Сары чәчләре тузгыган, башлыгын кулына тоткан хатын аларга бәрелә язып үтте дә, култыксага тотынып, чайкала-чайкала баскычтан төшә башлады. Рашат та килеп чыкты. Аның чалыш-чолыш китереп ялгыш элэктерелгән күлмәге

чалбарына да кыстырылмаган, пәлтәсе ачылган, җәен-кышын кия торган күн фуражкасы баш түбәсенең бер як читендә генә эләгеп тора иде. Ул:

—Постой, паскуда! Разобьешся еще, за тебя буду отвечать!—дип кычкыра-кычкыра, марҗасына иярде.

Миңзаһит белән Хәят тавыш-тынсыз чишенделәр дә, кухняга чыгып, хәйран калып, өстәлгә төбәлделәр. Анда чәлпәрәмә килгән чынаяк ватыклары ауный, идәндә ике буш шешә утыра. Ашый башлап ташланган тозлы балык кисәге эскәтергә ябышкан, аның янында ук кетчуп шешәсе авып, эчендәге томаты кып-кызыл булып өстәлгә җәелгән, агып төшеп, идән келәменә сеңгән. Бөтен җирдә тәмәке төпчекләре ауный. Табада яртылаш күмергә әйләнгән колбаса калдыкларыннан чыккан ис, тәмәке төтене белән кушылып, тынны буа. Алар, сүз берләшкәндәй, берсе ишекне, икенчесе балкон тәрәзәсен ачып җибәрделәр. Үтәли җил өйдәге укшыткыч исне коридорга суыра башлады. Миңзаһит, салкынлыкны да сизмичә, балкон култыксасына таянып, урамны күзәтергә тотынды. Рәшат белән тарткалашып маташучы теге хатын карга барып төште, көч-хәл белән торып аягына басты. Алар нәрсәгәдер талашалар иде, күрәсең. Бер-берсенә йодрыкларын селти-селти, почмакка борылып юк булдылар. Миңзаһит туңудан калтыранып куйды, өйгә кереп, балкон тәрәзәсен дә, ишекне дә япты. Кухняны җыештырып маташучы Хәят янына чыкмас өчен, үзләре бүлмәсенә керде. Дөпелдәп диванга утырды да күзләрен йомды. Әгәр банкетка калган булсак, бу мәхшәрне күргәнче, рәхәтләнеп утырган булыр идек, дип үкенде ул эченнән. Рәшат алар өчен чын афәткә әйләнде. Ул инде аларның баласы да түгел, читтән килгән явыз рэкетчы кебек иде. Берничә урынга эшкә урнаштырып караса да, аны бик тиз куып чыгардылар. Кайда торуын аңламалы түгел иде: әллә һавада, әллә җирдә, әллә Мәскәүдә, әллә Казанда—моны бер Алла гына белә. Ул айлар буе югалып тора да, кабат кайтып керә, беркая чыкмыйча, кырынмыйча эчеп ята. Аңа туктаусыз нindидер кешеләр шылтырата, ул тагын чыгып югала, кесәсен акча белән тутырып, тагын кайтып керә. Рәшат инде күптән Хәят белән Миңзаһитка бала түгел, ул үз-үзен бу хокуктан мәхрүм итте, аларга каршы көрәшүче, аларны җәберләүче явыз көчкә әверелде. Аңа баштарак өйнең ачкычын бирмәделәр, әмма бервакыт эштән кайтуларына йозакларын ватып кергәч, моның котылу юлы түгеллеген аңладылар. Ачкычларны Миңзаһит үзе күбәйтеп алып кайтты, үз куллары белән аңа бирде. Алар анардан бары бер генә нәрсә—ишекләрен бикләп йөрүен генә үтенделәр. Шуңа да карамастан, аның ике ишекне дә шыр ачык калдырган чаклары күп булды. Исерек вакытта аңа дингез тубыктан, ул гыйфриткә әверелә.

Хәятнең эндәшкән тавышына ул залга чыкты. Хәят залның уртасында басып тора, бөтен гәүдәсе калтырый иде. Нәрсәдер тоткан кулын ул Миңзаһитка таба сузды да елау катыш тавыш белән:

—Юри генә карале...—диде.

Миңзаһит, берни дә аңламыйча, аның кулыннан паспорт һәм тагын нindидер кәгазьләр алды. Паспортны ачып җибәргәч, башы әйләнеп китте. Анда Рәшатның фоторәсеме, өстенә «Боголюбов Иван Степанович», дигән сүзләр язылган иде. Калган өлешен ул укып тормады, паспорт эчендәге язулардан нибары аның Мәскәүгә теркәлгәнлеген генә аңлады. Димәк, аларның улы Боголюбов Иванга әйләнгән. Ул сораулы карашын Хәятка юнәлтте һәм аның газаплы, куркыныч карашына тап булды.

—Кара, тегесен кара...

Миңзаһит, дүрткә бөкләнгән теге кәгазьне ачкач, егылып китә язды. Бу—Рәшатка нindидер мәчетнең имам-мөхтәсибе булуын раслап бирелгән

шаһәдәтнамә иде. Алар, ят бер дөньяга эләккәндәй, аптырашып басып тордылар. Шул ук вакытта икесе дә ул дөньяны нәкъ менә үзләре тудырганны аңлыйлар, аны кабул да итә алмыйлар, анардан котылу да юк, шуннан чыга алмыйча һәлак булачаклары да көн кебек иде.

Кинәт шалтырап ишек ачылды. Рашат киемнәрен әллә нинди исерек, чайкалулы хәрәкәтләр белән салып элде, ботинкаларын селтәп ишеккә таба очырды да бүлмәсенә атлады. Шул чак Хәят әллә нинди тавыш белән аңа кычкырып җибәрде:

—Кил!

Рашат, йөзен бөтенләй аңламаслык чалшайтып, аның каршына килеп басты.

—Бу ни бу!!!

Рашат айнып киткәндәй булды. Ул күз ачып йомганчы әнисе кулыннан документларны тартып алды да, ана таба ияген чыгарып, йөзен якын ук китерде.

—Син нәрсә?!—диде ул, әнисенең борынына укшытырлык исле һава өреп.—Ник син минем кесәне актарасың?!

—Синең пычрак кесәңә керәсем калган! Оятсыз! Аяк астына чәчеп киткәнсең.

—Чәчсәм, кагылма!

—Кагылмам менә! Урыс та, мулла да булдыңмыни? Тагын ничә төрле ялган документың бар?!

—Ничәү кирәк—шул кадәр бар. Сезнең катышыгыз юк.—Сыгыла-бөгелә атлап, ул үзенең бүлмәсенә юнәлде.

Хәят, тагын куркыныч тавыш белән кычкырып, аны туктатты:

—Әгәр ялган документлар белән җинаять юлында йөрисең икән, сиңа бу квартирада урын булмаячак!

—Нәрсә?! Куасызмыни?!

Рашатның авызы ямьсез булып ачылды, ул әнисенең әйткәннәрен зиһене белән бәяләргә азаплана иде.

—Син квартираны нинди хәлгә китергәненә кара!—диде Минзаһит, кухня ягына кулын селтәп.—Хатын-кыз алып кайтып, шәрә килеш йөрергә оят түгелме?.!

—Ә син ояла идеңме соң, Арсланов? Авылда чакта өйгә сөяркәләреңне алып кайтырга ояла идеңме?

—Тукта хәзер үк!—дип кычкырды Минзаһит.

—Да пошшел ты!

Рашат, саз каены шикелле чайкала-чайкала, бүлмәсенә кереп китте, эчтән ишеген бикләп куйганы ишетелде.

—Барысы да синең аркада,—диде Хәят, елый-елый.—Әнә бит әйтеп тора. Читтә генә сөйрәлүең җитмәгән, өйгә дә алып кайткансың. Гарьлегеннән үләрсең!

—Шул исерекнең сүзләренә ышандыңмы?

—Ул сиңа караганда дөресрәк сөйли. Тьфү! Бу шөпшә оясын син оештырдың. Үлмичә котыла алмам мин сездән.

Хәят ярсыганнан-ярсый барды, аннары, йокы бүлмәсенә кереп китте.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Харрас
Әюп

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Гомер

**Бер башында сабый бала—
Чәчләре җитен генә:
Әллә кайларга җитәсе,
Йөгереп китсен генә!**

**Бер башында йөзьяшәр карт,
Ак сакалын җил тарый,
"Их, куып җитсә шул бала!.."—
Каерыла да карый,
Каерыла да карый...**

* * *

**Баш очында күкләр нинди тирән,
Офыклар киң, көннәр нинди якты!
Үтәр юлың шул яктылык аша—
Тууыңнан туфрагыңа чаклы.**

**Мәңгелеккә китеп югаласың,
Шул яктыга кереп чыгасың да;
Үзең белән көн яктысын түгел,
Алып киталмыйсың чырасын да.**

**Яктылыкта калып буладыр ул
Кушсаң гына аңа үз яктыңны.
Тууыңнан туфрагыңа чаклы
Түгәсең бар әле йөз яктыңны!**

Харрас ӘЮП (1946) — *шагыйрь; "Җәяүле буран", "Сабыр савытлары", "Йөз яктысы" һ.б.китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Кояш чыгышларын карап торам...

Кояш чыгышларын карап торам—
Садә чагын көннең, тын чагын;
Нурга куям җанны,
Ничәнчедер
Гөнаһлысы булып дөньяның...

Ничәнчедер кеше булып җирдә
Кояш белән бергә яшим мин.
Бәхетләрем—аның яктысында,
Ул—шаһите тамган яшемнең.

Күгеңдәге караңгылыкларны
Сылтап барсаң һәрчак болытка,
Яктылыкны белми калуың бар,
Кояш белән чордаш булып та.

...Кояш баешларын карап торам—
Ал яулыгын болгый китәргә;
Мин болыттан аралаган кояш
Кемнәр өчен чыгар иртәгә?!.

* * *

Бер яман сүз җиткерделәр миңа...
Эчкә йомдым аны, таратмадым,
Җаным кара көеп янса-янды—
Якты калды дөнья, каралтмадым.

Җилләрне дә тыңлый белү кирәк—
Колагыңа килеп, ниләр салмас!
Каян иңә аклык җир йөзенә?
Үзе каралмаган—аңлый алмас...

* * *

Барыбыз да—ата балалары,
Һәркайсыбыз—бала атасы.
Никадәрле тармаклансак та без,
Тамырыңа кире кайтасы.

Кемдер кайта йөз яктысы булып,
Йөз карасы булып—кемнәрдер.
Утлар-сулар кичкән нәсел-ыру
Ак-караны байтак күргәндер.

Гасыр иңләп кайтыш...
Йөзләренә
Кер кундырмас өчен тырышам.
Бер ягымнан әткәй җитәкләгән,
Бер кулыма улым елышкан...

* * *

Ишетми калма берсен дә:
Җырласын, еласыннар;
Илгә сайрарсың—мең елдан
Сандугач буласың бар...

* * *

Матурлык алдында телсез
Калмаган кемнәр генә!—
Батырлыклар ачкыч булган
Сылулар йөрәгенә.

Башым исәм, көчсезлектә
Гаепләмә, и сылу!—
Батырга да язык түгел
Матурлыкка буйсыну...

* * *

Һаваларга җырлар язам
Еракларда син күрсен дип;
Төне буе җемелдәшеп,
Серләремне белдерсен дип.
Сибеләмен... күкләр тула...
Мескен йөрәк чыдасын ла!—
Син шуларны сүндерәсең,
Кояш булып чыгасың да...

* * *

Акрын гына китеп барам синнән—
Сәгать белән китәм, көн белән...
Мәңгелеккә аерылу ич бу!—
Туктатыйм соң ләкин ни белән?

Ераклашкан саен яктырасың,
Күләгәләр бетә синдәге;
Син бер йолдыз инде...
Ә җылыңны...
Ә җылыңны тоям мин әле!

Мәңгелеккә китеп барам синнән,
Тамга итеп җанга күркеңне;
Тик бер сине күздән югалтырмын...
Дөнья бетәр ләкин ул көнне!..

* * *

Күкләргә йолдызлар чәчелгән,
Бер калка җемелдәп, бер сүнә...
Карыймын күзләрем талганчы—
Нигә соң син түгел берсе дә?!

Тирән шул дөньялар, әй тирән—
Җитәлми карашым, җитәлми...
Җирдәге сөюнең яктысы
Йолдыздан арырак микәнни?

Сине соң тәкъдирләр нигә дип
Бу чаклы еракка яшергән?—
Күкләргә ашкына гомерләр.
Алдыма йолдызлар чәчелгән...

## Учак

Күкләргә сузылып карый—
Буе җитми учакның;
Кемнәре бардыр биектә,
Ник талпына бу чаклы?

Нинди омтылыш аңарда,
Каян килгән кайнарлык?
Берәр хәсрәте бар микән
Дулый-дулый янарлык?

Ерак күкләргә кадәрле
Ашканмы очкыннары?
Нинди аваз ишетелә,
Кемнәрнең кычкырганы?

Никләр шулай ялкынлана,
Ниләр яна учакта?
Нигә тыныч түгел җаным,
Ник ямансу бу чакта?

Яктылык булып учактан
Карый берәү—кем икән?
...Кайсыбыз яна далада—
Учак микән, мин микән?..

* * *

Япа-ялгыз яланнарда йөрим:
Берүземә күпме яктылык!
Кул тимәгән гөлләр никадәрле...
Күкләремдә күпме ак болыт!

Ничә төрле кошлар сайрап тора—
Миңамы соң болар барсы да?
Бутамадың микән, и Табигать,
Мин кем әле синең каршыда!

Җәберсенеп калган чакларымда
Кул бирәсең миңа—малайга.
Зурлыгымны оныттырмас өчен
Янәшәмдә син бар алай да...

## Гөлләр исән...

Әй, дөньяда гөлләр исән әле...
Тамырланып элек-электән,
Тәрәзеннән балкып күренеп торган—
Күңелендә халкым гөл йөрткән.

Кайсы чорда ни күрсә дә башы,
Яшәсә дә ничек көн итеп,
Кайгысын да җирнең, шатлыгын да
Ул үстерә белгән гөл итеп.

Тәрәзәдән йодрык күрсәтмәдек
Узып барган чакта читләргә—
Өебезгә бүген кем килсә дә,
Гөлебез бар бүләк итәргә.

Тамырлансын көчеп һәр күңелгә,
Сөенсеннәр әле, көлсеннәр;
Өйдән-өйгә, илдән-илгә китсен—
Калмасыннар җирдә гөлсезләр...

Әй, дөньяда гөлләр исән әле,
Бу күңелләр нигә боексын!
Гөлләр булып сибелик җилләргә без,
Һәр тарафка бездән нур йоксын...

## Болын

Болын төрләрендә ал рәшә,
Җәйге ялкын капкан болынга.
Җилфердәшеп яна алсу җырлар—
Кем хакында,ниләр турында?

Күтәрелеп астан, бик тирәннән,
Гөлләр буйлап үрли югары,—
Нинди моңга, кайсы бәгырьләргә
Кагылалар минем кулларым?

Кайсыгызның күңел аклыклары
Ак чәчәкләр булып яктыра?
Нинди хыял шытып чыкты икән
Кулын сузып үскә, яктыга?

Болын өсләрендә ал рәшә,
Уйнавына исең китәрлек!—
Тирбәлешеп басып тора гөлләр
Заманнарны күккә күтәреп...

* * *

Сандугачлы һәм тургайлы дөнья,
Нинди серләр сөйлисеңдер миңа?
Тик аңламыйм,
И тел белмәгәнлек!—
Күпме уйлар шулай онытыла...

Хәтерләтер өчен кемнәреңне
Күрсәтәсең нәфис гөлләреңне?—
Искә төшерәлмим,
Җуйган тарих
Еракта алсу көннәреңне.

Ачылыр дип, бәлки, боларга син—
Сылуларны каршы чыгарасың,
Ни үкенеч адәм баласына!—
Нигә, дөнья, болай соңарасың?

Газаплама бүтән, җитәр инде,
Кайтар миңа, кайтар хәтеремне:
Сандугачлар төшенерлек итеп
Әйтеп китим җиргә әйтеремне!..

* * *

Бу дөньяда мине яраттылар.
Дөньяларын мин дә яраттым:
Ак җанымны җилләренә җәеп,
Шул дөньяда йөзеп караллтым.

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да—
Яратканнар—кала...
И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

**Редакциядән:**

***Бу айда күренекле шагыйрь Харрас Әюпнең 60 яшьлек юбилее. Каләмдәшебезне ихластан тәбрик итәбез, аңа сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.***



Илсөяр
Иксанова

# ОФЫКЛАРДА—БЕЗ БЕЛМӘГӘН ХАКЛЫК

## Шагыйрь

**Гади иде.**
**Аң җитмәслек иде.**
**Һәм.. бер катлы иде сурәте:**
**Шагыйрьләрне чын фәрештә итеп**
**Дәреслекләр безгә өйрәтте...**

**Дәреслектән аерды да тормыш**
**Фәрештәне җиргә төшерде:**
**Мин таныдым анда**
**Язмыш суккан,**
**Җаны бәргәләнгән Кешене.**

**Үз язмышы белән Ил язмышы**
**Икесе тиң җанын талкыган...**
**Фәрештәләр сурәтенә кереп**
**Китеп бара кояш артыннан.**

## Өзелү

*Очты дөнья читлегеннән*
*тарсынып күңелем кошы.*
Г. Тукай.

**Очты, очты ак күбәләк.**
**Аһ, кыска гомере җәйнең.**
**Җәй дә китә,**
**Күбәләк тә.**
**Кайсы җәл,**
**Кемне җәллим?**

Илсөяр ИКСАНОВА — *шагыйрә; «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Синязган язмышым» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Җәл түгелме канатлары
Көйгән ул күбәләкләр?
...Тып та тып алма коела,
Алсулар, түгәрәкләр.

Алма булып өзелә җәй.
Җәй түгел,
Өзелә өмет.
Түм-түгәрәк,
Кояш төсле,
Гомернең үзе кебек.

Тып та тып тама бүген дә
Алма кебек өметләр.
Өзелә җыр,
Өзелә җан,
Аһ, өзелә, егетләр.

Әйләнә дә кайта тарих,
Җилкетеп, алдап ала,
Ашкынган күңел—алдауны
Соң гына аңлап ала.

Аһ,Тукай,
Сөйгән бу халкың
Туярмы бер хаклыкка?
...Кайтмаска очар төсле кош,
Түзалмас бу ваклыкка.

Кайтмаска очар төсле кош.
Ник тар бу дөнья безгә?
Син—татар,—дип,
Шуңа тар,—дип,
Карый да күзебезгә,
Пышылдый тарих,
кабатлый.
Ишетү кирәк, аңлау.

Очты, янды ак күбәләк:
Канатны өтте алдау...

## Ана

Мин кызымны сөям кысып-кысып,
Йөрәккәен куеп күкрәгемә.
Әй аптырый сабый,
Өзгәләнеп,
Елый-елый шулай үпкәнемә.

Кызым, кызым,
Ана назы туймый
Сулган җаннар барын бeләм шул мин.
Синең белән бергә...
Кысып-кысып,
Нәни Апушны да сөям шул мин.

## Парадокс

*(М. Җәлил улы—Альбертны уйлап)*

Без бик сәер.
Сәер кавем:
Буталышкан Хак вә Нахак.
Казына да эзли һаман
Актан кара, карадан ак.

...Сөйләштеләр чышын-пышын:
«Бу—Җәлилнең улы икән.»
Гаҗәпләнеп карап йөрдек
Без—студент халкы—читтән.

«Аморально була, имеш,
Таный калсак рәсми итеп.»—
Бу соң нинди парадокс?
Уйлап йөрдем исем китеп.

Кәгазьләрне кадерләдек,
Күрсәк бер юл—Җәлил кулын...
Тик бик озак танымадык
Тач үзенә охшаш улын.

* * *

Саубуллашып киткән бу кошларның
Кышларгадыр юлы,
Кышларга.
Кышлар озын, суык.
« Йә кайтмабыз...»—
Каңгылдашып үткән «хуш»ларда.

Бәхилләшеп бездән киткәннәрнең
Офыккадыр юлы, офыкка.
Офык ерак,
Офык ымсындыргыч.
Ашкынмыйдыр кеше бер юкка.

Саубуллашып киткән кошлар моңын
Кемнәр аңлар,
Кемнәр аңламас.
Офыкларда без белмәгән хаклык—
Җаның тыңла:
Җаның алдамас.

* * *

Дөнья фани.
Бар да үтә, үтә...
Кала хәтер,
        кала хатирә.
Хатирәңне үтереп китә күрмә!
...Ялгыз китәсеңне хәтерлә!

* * *

Агачларга кагыла
бөре булып,
яфрак булып,
чәчәк булып,
җимеш булып—
Кагыла агачларга
Тормыш.

Яңгыр булып,
ак кар булып,
сыкы булып,
Агачларга кагыла
Тормыш.

Мин
Күзәтеп торам читтән.
Гүя
Миңа кагылмыча үтә...—
Әллә
Җырлы халәтемне көтә
Сизгер
Тормыш?!

## Кырык кыл

Кырык кыллы күңел,
Кырык кыллы дөнья.
Тап дөньяңның җаен—
Үз көеңне уйна!

Чиртә күрмә ялгыш,
Кырык кыллы язмыш.
Бер кылында—шатлык,
Бер кылында—сагыш.

Кырык кыллы күңел,
Кырык кыллы гомер.
Кырык кыл арасы:
Утлы учак—күмер...

Күпме алда юлым?
Артта кырык елым.
Моңлы гомеремнең
Тарттым кырык кылын.



Рәфкать Кәрами

# ОЛЫ ЮЛ ДА СИКӘЛТӘЛЕ

РОМАН

## I

...Ленинградта өр-яңадан комиссия үттеләр. Монда да Габделнурга Казандагы бәяне бирделәр: бик яхшы. Әйе, кергән бер бүлмәдә аны караган табиблар шул сүзне әйтеп чыгара тордылар. Тик ин соңгы кабинетта гына аны караган озын гәүдәле, ак халат астыннан кара төстәге хәрби кием кигән офицер-хирург "Медицина картасы"на нидер язар алдыннан, каләмен бер читкә куеп:

—Яле, борыл да ишеккә таба бар!—диде.

Габделнур ишек катына барып туктады, борылырга кушканны көтеп калды. Хирургның командасы яңгырады:

—Кру-гом! Ко мне!

Габделнур ялт борылды да аның каршына, өстәл янына килеп басты.

—Ә син нишләп аксыйсың?

Егет бермәл югалып калды. Табибның күзләренә туры карамыйча гына:

—Юлда, вагонда аягымны каймыктырдым,—диде.

—Сугыштыгызмыни?

—Юк,—диде егет ашыгып.—Малайлар белән көрәшкәндә...

—Сабантуй оештырдыгыз инде... Татарлар бит... Юк, егет, мин сине су асты көймәсенә яза алмыйм.

—Ул авыртмый. Бетә ул...

—Юк!—дип кырт кисте хирург һәм өстәлдә яткан кәгазьгә тиз генә нидер язып, егеткә бирде.

Кабинеттан чыгуга, Габделнурны бергә комиссия торган иптәшләре сырып алды.

—Нишләп озак тотты?

—Кая эләктең?

—Нинди команда?

Габделнур җилкәләрен сикертеп алды.

---

Рәфкать КӘРАМИ (1942)—*язучы; «Каргышлы эталлар» һәм «Очар кошлар белән янәшә» романнары һ.б. әсәрләр авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

—Белмим.

"Карта"да «БЧ» дип язылган иде. Ләкин берсе дә аның ни-нәрсә анлатканын тәгаен гына әйтә алмады. Яннарыннан узып баручы, погонында буйлы озын сары тасма сузылган бер мичманга мөрәҗәгать иттеләр.

Ул кәгазьгә күз төшереп алды да:

—Яр буе частьларына эләккәнсең, бәхетең!—диде.

—Нигә алай дисез?

—Өч ел хезмәт итәсең.

Мичман китеп тә барды. Кемдер Габделнур өчен сөенде, чөнки дүрт ел урынына өч кенә ел бит, ә кемдер көенде. Хәер, көенүче Тәтеш егете Морат кына иде. Ул вагонда Габделнур белән бик дуслашып китте бит... Ә үзе дүрт еллыкка эләккән.

—Болай булгач аерылышабыз,—диде ул көрсенеп.

Кемдер сүз кыстырды.

—Ничава, кунакка йөрешерсез.

—Юләр,—диде аңа каршы берәү.—Бу сиңа гражданка түгел. Әбиеңә коймак ашарга бара алмассың. Әле кай тирәгә эләгәсең...

Кыскасы, шул көннән эшелонда бергә килгән егетләрнең юллары аерылды: берәүләргә кара төстәге матрос киеме, икенчеләргә яшькелт гимнастерка кигерттеләр. Габделнур да соңгылар рәтендә иде.

Ул үзе моңа шатланмады да, уфтанмады да. Ләкин үрле-кырлы сөенүчеләр булды. Бер грузин егете (ул өр-яңа кара костюм, ак күлмәк һәм кара галстук, ялтыравык җәйге ботинкадан иде) өстенә яшькелт гимнастерка һәм шундый ук төстәге галифе чалбар, кирза итек киеп алгач, үзенең бөтен әйберләрен җыеп, рәхмәт укый-укый бер мичманга бирде. Күрәсең, теге аңа ничек итеп флотка эләкмәү юлларын өйрәткән булса кирәк.

Габделнурның кеше кызыгырдай киеме юк. Дөрес, аның замоклы, өр-яңа сырган курткасы бар иде. Ләкин ул аны Флот экипажына китергән көнне үк, подвалга төшеп, андагы рәссамга биреп калдырды. Ә рәссам аларның сәгатьләренә (алар өч егет иде, икесе акча түләде) диңгез маягы һәм хәрби кораб сурәте ясады. Юантык гәүдәле, тулы битле, граждански киемле рәссамның кечкенә тәбәнәк өстәлендә аракы шешәсе, стакан һәм кабымлык. Ул авыз эченнән гел бер көйне кабатлый:

Вэ пап, пап, вэ пап, пап.
Вэ пап, паб, ба, пап.
Все мосты разводятся,
А поцелуев—нет.

Габделнур якташы Шишкинның монда укуын әйткәч, ул егетне кочаклап ук алды.

—О, Шишкин—гений!—диде ул нәзек кенә пумала тоткан кулын югары күтәреп.—Син аның якташымыни?!

—Алабугада өч ел укыдым.

—Беләм ул шәһәрне, биографиясен дә яхшы беләм. Әллә үзең дә художникмы?

—Бераз гына.

—Шулай да мин сиңа бушка ясамыйм, гафу ит. Курткаңны бирәсеңме? Барыбер алып калалар... Рәсем сиңа гел юньгә туры килә...

Хәрби кораб сурәте ясап бирде. Ә подвалдан казармага күтәрелгәч, Габделнур үзенең бәләкәй чемоданын бер матрос белән баш старшина актарып маташканын күрде. Алар чемоданны тәрәзә төбенә куйганнар да, ачып, эчендә булган әйберләрне берәм-берәм бушаталар иде.

Габделнур йөгереп диярлек килде дә, аны-моны уйлап тормыйча, чемоданын тартып та алды.

—Син нәрсә, салага?—диде бескозыркасын кыңгыр салган матрос коры гына.

—Бу—минем чемодан!

—Ә нишләп анда тиешсез әйберләр бар?—дип катгый тавыш белән сорады тәбәнәк гәүдәле, пөхтә кара киемле, погонында аркылы кин сары тасма сузылган баш старшина.

—Нәрсә?

—Менә бу!

Баш старшинаның кулында жыелма пластмасса стакан иде. Аның төбендә көзге дә бар.

—Бирмим. Бу—минем абыйның бүләге. Ул аны Германиядә хезмәт иткәндә алып кайтты.

Матросның да аңа күзе кызыккан иде ахры.

—Тиеш түгел!

Ләкин Габделнур стаканны кисәк кенә тартып алды да кесәсенә салды.

—Бирмим!

Күрәсең, баш старшина үзенең хаксыз икәнен сизә иде булса кирәк, тавышын йомшартты. Нәкъ шул вакыт алар яныннан бер офицер да узып китте.

—Ярар, калдыр. Ә монысы—ярамый.

Анысы—Казан военкоматы янында телсез егеттән бер сумга сатып алган карточкалар жыелмасы—шәрә хатыннар сурәте иде.

—Алыгыз,—диде Габделнур һәм ашык-пошык чемоданын жыештырып, иптәшләре янына шылды.

Ә тегеләр янына тагын икәү—икенче статья старшина белән өлкән матрос—килеп калдылар һәм тел шартлата-шартлата карточка карарга керештеләр.

Ноябрь ахырында Татарстан төбәгендә инде кыш керә—кар ята, суыта. Ә монда—әле жылы, көн саен янгыр ява, тынчу, авыр һава, кояш күренми—караңгы болытлар тәбәнәк күк йөзен каплап алганнар да, берөзлексез талгын гына каядыр агылалар. Шуңа күрә туган ил кайда да, Кронштадт кайда икәнен егетләр чамалап та белә алмыйлар иде. Хәер, бу уй аларның башларына да керми әле. Чөнки алар Ленинградта! Ул ни житте генә шәһәр түгел—революция бишеге, үзен мәңгелек данга күмгән «Аврора» крейсеры да шушында, тарихларга кереп калган Нева елгасы да шәһәрне аркылы кисеп ага... Казан белән чагыштырганда аның йортлары да биегрәк, төрледән-төрле орнаментлар белән чуарланган. Кая карама—гүзәл биналар, истәлекле урыннар...

...Аларны яр буенда зур гына үзйөрешле баржа көтеп тора иде, кереп урнаштылар. Әкрен генә кузгалып та киттеләр... Эреле-ваклы йортлар, чиркәү манаралары, шпильләр отыры артка чигә-чигә күздән югалдылар. Менә порттагы корылмалар һәм күтәрү краннары да күренмәс булды.

Өстән янгыр ява. Аста—су, әйтерсең, бөтен дөньясы фәкать судан гына тора. Каршыга әлләничә палубалы ак төстәге теплоход килә. Ләкин ул Габделнур Чаллыда һәм Казанда күргән пароходлардан өч-дүрт тапкыр зур, биек иде. Ерякта сылу гәүдәле, туплар куелган бер хәрби кораб силуэты да күренде. Ә егетләр утырган баржа бернигә карамый, бернигә исе китми алга баруын дәвам итә.

Кронштадт үзе күренгәнче аның әйләнә-тирәсендәге фортларның берсе пәйда булды. Ул урта гасырлар чорындагы замокны хәтерләтә—кечкенә генә утрауда кызыл кирпечтән корылган биек түгәрәк бина. Аның утрау икәне дә беленми, чөнки форт су эчендә утыра. Якын-тирәдә башка берни юк. Аның эчендә дә берни дә юктыр шикелле. Жан әсәре беленми. Ләкин бу

беренче карашка гына шулай иде. Ул—хәрби ныгытма икән.

Күзлекле бер егет, суга карап барды да үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

—Шулай да ничек бу фортларны су юып җимерми икән? Борынгы кытайлар әйткән бит: «Судан да нәфис һәм көчсез нәрсә юк, ләкин бу су бөтен нәрсәне җимерергә сәләтле».

Алда биек торбалар, ике-өч күтәрү краны һәм чиркәү гөмбәзе күренде.

Менә шәһәргә дә килеп җиттеләр. Хәрби кораблар тезелеп торган пристань—Усть-Рогаткадан читтәрәк, причалда баржага да урын табылды.

Егетләр тиз-тиз генә ярга чыгып, сафка тезелделәр дә, Арсенальный тыкрыгы буйлап ары киттеләр. Унда тәрәзәсез, биек, озын кызыл бина (склад шикелле нәрсә), сулда бакча калды.

Таш түшәлгән, асфальт җәелгән, күбесе ике-өч катлы гына, бик сирәге дүрт катлы йортлардан гыйбарәт булган урамнардан шап-шоп атлап, Флотская урамындагы дүрт катлы бинага—Флот экипажына якынлаштылар.

Тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган ихата каршында туктадылар. Сулдагы КППдан бер матрос чыгып якорь ябыштырып куелган тимер капканы ачты. Солдатлар эчкә уздылар. Уңда кызыл кирпечтән салынган дүрт катлы казарма, сулда ике катлы йорт—клуб һәм складлар. Киң ишек алды—плац чиста, асфальты ялтырап тора. Агачлар казарма буйлап кына утыртылган, биек түгел.

Шушы минуттан төрлесе төрле тарафтан алынган, типсә тимер өзәрдәй сау-сәламәт егетләрне хәрби хезмәт үз эченә йотты, суырып алды.

## II

Ленинградтагысы шикелле үк монысы да Флот экипажы дип атала икән. Шушы арада гына экипаж урын күчкән, хәзер инде ул Кронштадтта тупланачак, имеш.

...Көндәгечә сафта йөргәннән соң таралырга һәм казармага керергә рөхсәт бирелде. Ләкин Габделнур, («гөнаһ шомлыгына каршы», дияр иде әбисе) керәсе килмичә, дөресрәге, урамга күз салу нияте белән КППга таба атлады. Капка янына килеп басты да, башта каршыдагы ике-өч катлы сары йортларга, аннары күз күреме җиткәнче әле уңга, әле сулга карады. Озак кына уйланып торганнан соң борылып китеп барды. Каршына, сул беләгенә киң кызыл тасма бәйләгән, часть буенча дежур офицер килә иде. Ул алан-йолан карана, күрәсең, ихатадагы тәртипне тикшерә... Менә ул Габделнур белән тигезләште.

—Рядовой, туктагыз!—диде офицер һәм аяк астына төртеп күрсәтте.— Тәмәке төпчеген алыгыз.

—Мин тартмыйм, иптәш лейтенант!

—Барыбер күтәрегез!

—Алмыйм!—диде дә Габделнур йөгереп казармага кереп тә китте.

Кичке сәгать ун тулганда ротаны сафка тезделәр. Командир белән янәшә часть буенча кизү офицер да тора иде. Габделнур, нидер сизенеп, куырылып куйды. Юкка булмаган икән: офицер плацта үзеннән качкан солдатны таныды һәм капитанга нидер әйтте.

Рота командиры коры гына:

—Рядовой Гаделжанов, сафтан чыгарга!—дип әмер бирде.

Лейтенантның да чырае кырыс, тавышы каты иде.

—Ну-ка минем белән киттек!

Габделнур урыныннан кузгалмады.

—Кая? Нәрсәгә?

Ротный:

—Синме тәмәке төпчеге алмаучы?—дип сорады.

—Әйе. Мин бит тартмыйм.

Сафтан берәүнен теләктәшлек күрсәткән авазы ишетелде.

—Иптәш капитан, ул чыннан да тәмәке тартмый.

—Отставить разговоры!—диде рота командиры кискен рәвештә һәм Габделнурга карап әйтте.—Сез үзегезнең кайда икәнегезне оныттыгызмы әллә? Монда тәртип гражданкадан үзгә: белмәсәгез—өйрәтербез, теләмәсәгез—мәҗбүр итәрбез! Анладыгызмы? Рядовой Гаделжанов, часть дежурные артыннан—шагом марш!

Габделнурга алагаем зур ашханәнең идәнен юарга, бер тирән миски суган чистартырга туры килде. Аннан сон кизү бүлмәсенә кереп эш бетерүен әйтте һәм унике тулганда гына казармага кайтты.

Габделнур янәшәсендәге солдат уянды.

—Кайттыңмы?

—Әйе.

—Карале, ул синнән, бу кем төпчеге, дип сорамадымы?

—Юк. Тәмәке төпчеген алырга гына кушты. Нигә сорыйсың?

—Бер мәзәк искә төште. Генерал килә тикшерергә. Плацта йөргәндә бер тәмәке төпчеге күрә. "Кемнеке бу?" дип өч тапкыр сорый. Дәшмиләр. Шунда бер жор телле солдат әйтә: "Иптәш генерал, иясе юк, алыгыз".

—Мина да шулай әйтәсе калган,—диде Габделнур көлеп.—Аннан, нәрәт биреп кенә калмас, өч тәүлеккә губага ябып куяр иде.

Ул чишенде, урын-җирен җәйде. Ләкин тиз генә йоклап китә алмады. Дежурныйга үпкәләп, хәтере калып, озак кына рәнҗеп ятты. Нигә сон ул кемдер ташлап калдырган шакшы төпчекне чүпләп йөрергә тиеш? Кем ташлаган, шул җыйсын иде! Аннары, бераздан икенчерәк төрле уй да баш калкытты: армия һәм дисциплина—аерылгысыз. Әйе, офицер, командир сүзе үтәлергә тиеш! Хаклымы ул, түгелме—аны тикшерү хокукы солдатка бирелмәгән...

Ләкин еллар үткәч, азмы-күпме дөнья күргәч, хәрби хезмәтнең әүвәлге чордагы кыенлыгы онытыла төшәчәк. Бик хәтәрләре генә истә калачак. Әлбәттә, әле кичә генә иректә булган, ә хәзер калын табанлы олы кирза итекләре белән көненә дүртәр сәгать буена асфальт таптап сафта йөрергә мәҗбүр ителгән таза егетләрне иң нык борчыганы—ашау җитмәү. Югыйсә ашаганнары юклы-барлы ризык түгел: шулпалары да төрле-төрле (әчегән кәбестә эштие сирәк бирелә), икенчегә—итле токмач, ботка яки балык белән бәрәңге, мае-шикәре, өченчегә компот ише туклыклы нигъмәтләр. Ләкин кысанлыкка өйрәнмәгән, гел хәрәкәттә булып торган яшь организмга, көненә өч тапкыр ашатсалар да—барыбер җитми. Өйдән биреп җибәрелгән тәмле ризыкларның инде валчыгы да калмаган, кесәгә салынган акчалардан да күптән җилләр искән. Үзбәк егетләре кебек сәгать саен буфетка кереп, ап-ак йомшак булка белән чәй эчәр идең югыйсә... Хәер, аларның чәйгә әвәслеге, бердән, кесәләре әле бушамаганнан килсә, икенчедән, дуңгыз ите салып пешерелгән ризык капмаудан иде. Габделнурга аларның тәмәке тартмаулары да сәер тоелды.

Беркөнне Габделнур үзе шикелле берничә яшь солдат белән кухняга эләкте. Монда аны камбуз дип йөртәләр. Аңа казарма аша кереп-чыгып йөрисе, чөнки ул аның артында, шулай ук кызыл кирпечтән төзелгән ике катлы иске бина. Сул ягында исә озын торбалы котельная.

Бәрәңге чистартып, аларны идән уртасындагы сулы зур кәстрүлгә ташлаган арада, ул алан-йолан каранды: кайда нәрсә ятканын чамалады. Эшләрен бетереп казармага кайтканда ул Арча егете Хөрмәтне читкәрәк тартты:

—Тагын камбузга дәшсәләр, сало сугарга кирәк.

Коры җир булса да, монда кораблардагы кебек флот сүзләре күп кулланыла иде. Әйтик, камбуздан тыш әле поварны да «кок» дип кенә җибәрәләр, бәдрәф исә туалет түгел—гальюн, казарма—кубрик һәм башкалар. Беренче көннән үк Габделнурлар да ул атамаларны эләктереп алдылар.

Җәлпәгрәк борыны астына яңа гына мыек чыгып килүче Хөрмәтнең күзләре очкынланып китте.

—Аны мин дә уйлап йөри идем. Без болай коры сөяккә калабыз ич!

Хөрмәт төптән юан, уртача гәүдәле таза егет, көрәшчеләр нәселеннән. Аның тулышып торган кызгылт бите соңгы көннәрдә бераз сулыга башлады. Шулай да алар—Хөрмәт, Сергач мишәре Атаулла, Ырынбур егете Шәрип, Габделнур һәм тагын берничә татар егете—көн саен спортзалда көрәш оештыралар.

Хөрмәт яшь кенә булуына карамастан ике ел рәттән авыл Сабантуенда батыр калган, көрәш кагыйдәләрен һәм аның рәтен белә. Намуслы көрәшә. Габделнур белән Шәрип тә таза егетләр, ләкин алар көрәш алымнарын белмиләр.

—Сез—көчле, тик сезнең белән көрәшүе читен,—ди Хөрмәт көлеп.—Нинди приемга каршы торырга әзерләнәсеңне белмисең. Күкрәккә дә төшәсез, алай ярамый. Оста көрәшчеләр бер-берен саклыйлар, ә сезнең белән имгәнүең дә ихтимал.

Шулай дисә дә, ул алар белән озак маташмый—матрас шикелле калын матлар җәелгән идәнгә ларсылдатып сала. Тегеләр саннарын җыя алмыйча яталар.

Ә менә Атаулладан ул алай җиңел генә котыла алмый.

—Син аяк чалма,—ди ул аптырагач.

—Мин аңгара алмыйм, берцәк, ницек үрәнгән, шылай көрәшәм,—ди Атаулла үпкәләп.—Шкулда укыганда да шылай көрәштек, Сабантуйда да. Син көрәшмәк келәмисең, шкуранны җәллисең!

—Ә, әле шулаймы?! Хәзер мин сине...

—Бик куркындым инде... Багып багарбыз...

Төптән юан Хөрмәт белән чандыр гәүдәле, ләкин бик елгыр Атаулла җан-фәрманга китәләр кызып—спортзалның түшәменә хәтле тузан күтәрелә.

Аннан егетләр, бераз хәл алгач, ике потлы ике герне чөеп уйныйлар, бер-берсе белән ярышалар.

—Во татары дают!—дип әледән-әле тел шартлата ачык авызлар.

Дөрес, матрослар арасында да таза егетләр бар. Берсе, кап-кара чәчле, еш кырынудан яңаклары, ияге зәңгәрләнеп торган матрос, аларга үзенең көчен дә күрсәтте.

Дәррәү җыелып, беравыздан, түшәм җимердәй булып, хор белән кычкырып санап, егетне дәртләндереп тордылар.

—Өчәү... бишәү... унау...

—Санап кына өлгер,—диде Шәрип башын чайкап.

—Доа, атот!—дип шаккатуын белдерде Атаулла да.

Унбишкә хәтле күтәрде дә, карап торышка какча чырайлы күренгән матрос герләрне ипләп кенә цемент идәнгә куйды һәм, кара чалбарының кин балакларын каккалап, китеп барды.

Кемдер әйтте шулчак.

—Ул дисбаттан кайткан, өенә җибәргәнне көтә. Алты ел хезмәт иткән.

Яшьләр бөтенесе аптырашта калды: ничек, матрослар дүрт кенә ел хезмәт итә бит. Менә шунда Габделнур беренче мәртәбә «дисбат» дигән сүзне ишетте. Тәртип бозган, җинаять кылганнарның кайберләрен гауптвахта яки төрмәгә генә утыртмыйлар, ә дисциплинарный батальонга да җибәрәләр икән. Теге матрос су асты көймәләренә каршы торучы корабльдә дүрт елын хезмәт

итеп, кайтырга әзерләнгән көннәрдә, команда старшинасы белән телгә килә, ана суга һәм... тагын ике ел мәҗбүри рәвештә хезмәт итә.

Беркөнне, тагын камбузга, Атаулла әйтмешли, картуф әрчергә баргач, пешекчеләр чыгып киткән арада, Габделнур белән Хөрмәт уртача калынлыктагы китап зурлыгында дуңгыз салосы чәлдерделәр. Габделнур тиз генә урамга чыгып аны кар эченә тыгып керде.

Эш беткәч казармага кермичә дүртәүләп ишегалдының түренә киттеләр.

—Мә, тозла,—диде Шәрип кесәсеннән шырпы кабы чыгарып.

Габделнур, каптан учына тоз салып, ышкый-ышкый аны салога сеңдерде. Таш диварга күз салды. Шактый биектә бер уенты бар иде.

—Шәрип, син озынрак, минем җилкәгә менеп бас та әнә теге куышка яшереп куй,—диде Габделнур.

Ул иелгәч, Атаулла Шәрипне бер кулыннан тотыбрак торды. Габделнур көчкә тураеп басты.

—Буең җитәме?

—Җитә,—диде Шәрип һәм салоны урнаштыргач Габделнурның иңбашыннан сикереп төште:—Кар белән каплаштырдым.

Монда йортлар да, ихата диварлары да бер метр калынлыкта кызыл кирпечтән корылган иде. Сугыш вакытында снаряд кыйпылчыклары тиеп, күп урында уентылар хасил булган. Шуларның берсенә менеп урнашты сало. Һәм өч көннән, тагын камбуздан суккан арыш ипие белән егетләр сало ора башладылар.

Ипине Хөрмәт юнәткән иде.

—«Белинский» булмады, «Чернышевский» гына,—диде ул буханканы юантык, кыска бармаклары белән сындырып.

—Ярамаган татарга каз ите,—дигән булды Шәрип тәмләп, ипи белән аралаштырып сало чәйни-чәйни.

Солдатлар арасында ак ипи—«белинский», арыш ипие—«чернышевский», ә чәй—“чайковский” дип йөртелә иде.

—Моның янына мунча аракысы да булса,—диде Атаулла уфтанып.

—Анысы нәрсә тагын?—дип сорады Габделнур.

—Нәстә булсын, самогон!—дип көлде Атаулла, шуны да белмәскә дигән сыман.—Аракы тугайтмый, канишны.

—Сүләп торасың тагы,—диде Шәрип аны ирештереп, сүләп сүзенә басым ясап.

— Ә син мине үртәмә, мин кочык түгел. Болай гына әттем, кәбәм.

— Ярар, үпкәләмә,—диде Шәрип дустының җилкәсенә кулын куеп.—Ә тегене бездә, төнге көмешкә, диләр.

Бер үзбәк егете боларның дуңгыз мае бүсәннәрен күреп, чүт кенә косып җибәрмәде. Ләкин... тамак тәмугка кертер ди...

Үзбәкләр исә, плацка чыгып сафта йөргәч, унбиш минуттан отделение командирына ялына башлыйлар. Командир, карадан киенгән булса да, сержант званиесендә.

—Товарищ сежант, я замез.

Бүрек колакчыннарын төшерү дә ярдәм итми көньякның җылы, иркә кояшында үскән малайларга. Алар туңудан авазларны тотырып әйтә алмыйлар, шуңа күрә сүзләре өтек-сөтек килеп чыга.

—Зур Себергә караганда бәләкәй Ташкент яхшырак,—дип үчекли аларны сафта кемдер.

Нишләсен, сержант та адәм баласы—хәлләренә керә.

—Бар алайса, Хамракулов, жылын.

Мескен солдат йөгереп кереп китә. Ә биш минуттан сержантның командасы яңгырый.

—Хамракулов, чык! Син бар, Бәйрәмкулов.

Ишектән кергәч тә коридорда җылылык батареясын кочаклап торганы тышка чыга, аны урамнан йөгереп кергәне алыштыра. Ә Габделнурлар, кып-кызыл булып, тирләп-пешеп, тырыша-тырыша сафта йөрү күнекмәләрен үзләштерә.

Үзбәк егетләре бергә укмашыбрак, бүтәннәр белән аралашмыйчарак яшәргә тырышсалар да, татарларга мөнәсәбәтләре уңай иде. Шуңа күрә беркөнне Габделнур һәм тагын дүрт-биш татар солдаты алар белән сөйләшеп-гәпләшеп утырдылар. Моңа башта Шәрипнең, аннары Габделнурның баянда уйнавы сәбәпче булды. Ул бер-ике урыс көе уйнагач, татарча «Шахта», «Сарман» кебек моңлы җырларга күчте. Аны солдатлар сырып алды, арада үзбәк егетләре дә бар иде. Күрәсең, безнең җырлар аларның да күңеленә хуш килде, бәлки кайберләренә кечкенәдән үк таныштыр: Урта Азиядә татар кешесе яшәмәгән шәһәр түгел, кышлак та юк ич.

Сүз, әлбәттә, ашау-эчүдән башланды. Аннары өй, гаилә хәлләренә күчте.

—Сезнең арада төрле елгылар күп, өйләнгәннәр дә бармы?—дип сорады Габделнур гармунын бер читкә куеп.

—Юк,—диде барысы өчен дә үзбәкләргә бигүк хас булмаган озынча, ябык гәүдәле, әмма каратут йөзле, кара кашлы Халмурадов фамилияле егет.—Хале без хезматтан киген тиз уйланмеймиз.

—Нишләп?—дип сорады Хөрмәт аптырап.

Уртача буйлы, табак битле Хамракулов атлысы:

—Атам-анам хал кыладе,—диде.—Чунки алдын безлорда өй-җайне кыладе, киген уйланаде.

—Үзбәк башта малаен үстерер өчен эшли, аннары—өйләндерер өчен,—диде Шәрип бик белдекле кыяфәттә.—Әти-әни рөхсәтеннән башка өйләнми егетләр.

—Бездә дә элек шулай иде, хәзер бик әти-әнидән сорап тормыйлар, өйләнәләр,—диде Хөрмәт тигез ак тешләрен ялтыратып көлеп.

—Бездә—юк,—диде тәбәнәк гәүдәле Бәйрәмкулов башын чайкап.—Безлорда туй катта буладе, миһманнар киладе. Узбекда икки катта байрам: туй белән суннат.

Шәрип көлеп җибәрде.

—Ә сез барыгыз да сөннәткә утыртылганмы?

—Һа. Угыл баланы бер, уч яки биш яшьтә суннатлашаде. Жудо катта байрам: кариндаш-уруглар хархил-буюм яки пул совга кыладе.

—Ә кызның ата-анасына калым биреләме?—дип сорады Атаулла.

—Һа. Туй икки-уч кун буладе, шунча миһман чакырыладе: кариндаш-уруглар буладе, махалла кешеләре белән туй кыламыз. Пул хам жудо күп кирәк.

—Бөтен эш акчада икән. «Пүл, пүл, пүл, пүлгә карап үл», ди торган иде сезнең якларда йөреп кайткан бер зимагур абзый, белеп әйткән икән. Алайса, сезнең өйләнә алмыйча кырыкка да җитүегез ихтимал,—диде Хөрмәт тегеләрне кызганып.

—Берәр татар кызын эләктерсәләр генә инде,—диде Габделнур якташына күз кысып.—Безнең авылның ике-өч кызы Үзбәкстанда кияүдә. Берсенен дә әти-әнисенә калым түләмәделәр. Так что, әле сезнең безгә әҗәтегез бар икән... «Катта рахмат», белән генә котыла алмыйсыз...

...Авылыннан чыкмаган кеше, тик яткан таш шикелле мүкләнеп, бертөрлелеккә ияләнә. Тормыш гел шулай гына барадыр кебек тоела аңа. Аны чолгап алган мохит тар, кешеләр—санаулы. Ул инде аларның барысын да белә, аларга ияләнә. Һәрхәлдә, аның даирәсен ничәмә-ничә еллар гел бер үк кешеләр чолгап алган була, тормыш та бер агымда гына диярлек, йокысын

китерерлек итеп кенә, тирбәлеп агып бара. Ә менә авылыннан чыгып китсән, тормыш—ярсу елгадай—көн саен булмаса да еш кына син төрле җирләр, сала-калалар белән танышасың.

Габделнур Әлмәттән чыгып киткәч байтак шәһәрләр, ят җирләр күрде.

Кронштадтта яшь сугышчы курсын узганда бу фикернең хаклыгына тагын бер кат инанды. Чөнки кемнәр генә юк иде алар ротасында! Егетләрнең күбесе унтугыз яшьтә, ә менә Сарьев фамилияле берәү алардан алты яшькә олы иде. Ул грек кавеменнән икән.

—Мин укыганда география фәнен бик ярата идем,—диде ана Габделнур.—Грецияне кайдадыр Әдрән диңгез буенда дип белә идем. Ә син Ставропольдән икән.

Ни хикмәттер, Сарьев ачылып китте, караватыннан торып ук утырды. Ул уртача буйлы, тулы гәүдәле, янак-ияген кара тук баскан, күкрәк һәм беләкләре генә түгел, кул аркаларына хәтле йонлач.

—Мин Грецияне белмим дә, анда булганым да юк. Безнең бабайлар да Ставрополь краенда яшәгән.

—Ә син грекча беләсеңме соң?

—Беләм, билгеле. Өйдә ана телендә сөйләшәбез, мәктәбебез дә булган, япканнар гына.

—Ә нишләп армияга соң киттең?

—Туры килде инде... Ә син Ставрополь краенда татарлар яшәгәнен беләсеңме?

—Юк.

—Анда бер авылның исеме үк Татарка. Шәһәрдән унбиш чакрымлап кына бугай.

—Кызык,—диде Габделнур, аннары, әйтергәме-юкмы, дигәндәй уйланып торды да, тәвәккәлләде.—Алар аралашып беткәндер инде башка халыклар белән. Сезне дә бит: мама—турок, папа—грек, а я русский человек, диләр.

—Ишеткәнем бар,—диде Сарьев Габделнурга үпкәләмичә.—Ләкин минем—икесе дә грек, үзем дә.

—Мин дә татар,—диде Габделнур Сарьевның хәтерен калдырмавына сөенеп.

Габделнур аның армияга ни өчен соң китүен тагын сорашмакчы булган иде, тыелып калды, төпченеп тормады. «Үз хәлен үзе беләдер»,—дип уйлады.

Сарьев казармада күп вакытын караватка сузылып ятып, дәшмичә үткәрә. Ул, кулларын баш астына куеп, чалкан ята, сирәк сөйләшә, ә солдатлар белән бөтенләй диярлек аралашмый. Бүген үзе белән сөйләшеп китүенә Габделнур сәерсенде хәтта. Чөнки ул өченче елын хезмәт итүче солдатлардан да дүрт яшькә олырак бит инде. Аның өендә хатыны, баласы калган. Шуларны уйлый идеме ул (хәер, анысы да булгандыр), башка нәрсәнеме, берәү дә анык кына белмәде. Нindидер бер грек егетенең үзләре белән бер елда хәрби хезмәткә алынуы да Габделнурга аңлашылып бетми иде. Кайчагында отделение командиры яки икенче бер сержант аңа кисәтү ясый:

—Сарьев, урынга ятма!

Солдатның калын кашларында бер бөртек тә селкенми.

—......кит!—дип ул аларны аты-юлы белән өч хәрефкә җибәрә.

Баштарак мондый әдәпсезлеккә җен ачулары чыкса да, олы яшьтә һәм гаиләле икәнен исәпкә алыпмы, әллә һәрчак уйчан булгангамы—кече командирлар аңа каты бәрелмәскә тырышалар.

Алар взводында тагын бер гаҗәп солдат бар иде. Габделнурларның яшьтәше Хромов иске дин кешесе булып чыкты. Башта моны берәү дә сизмәде, белмәде. Ул солдатлар белән бергә дәрескә йөри, ашханәдә туклана, бер үк казармада ятып йоклый. Ә шулай да күзәтүчән кешегә сизелми калмый бит. Беркөнне кич белән, Габделнур энә-җеп алып, гимнастерка якасына яна ак ситсы

тегеп утыра иде. Аның белән янәшәдә каеш аелын чистартып утыручы Соловьев фамилияле солдат сүз башлады.

—Сиңа бер әйбер әйтим әле,—диде ул.

—Нәрсә?

—Безнең Хромов икенче тапкыр инде киногa бармый.

—Ничек?—дип сорады Габделнур энәсен кулыннан төшермичә генә аңа карап.

—Белмим. Теге көнне дә әйттем—бармады, кичә дә.

Хромов Габделнурдан бер караваt аша гына ята, Соловьевка ул да күрше иде. Әле үз урынында күренми.

Габделнур белән Соловьевның сөйләшүен алар янына килгән Хөрмәт тә ишетте.

—Хромов иртән юынмый да бугай,—дип әйтеп салды ул.

Өчесе дә аптырашта калдылар. Гаҗәп хәл иде бу! Ышанасылары да килмәде. Тиктомалдан кешегә бәйләнеп тә булмый. Күзәтергә, дигән карарга килделәр. Бер-ике көн күзәткәч, чыннан да Хромовның юынмавы ачыкланды. Соловьев моны тагын берничә егеткә тишкән.

Солдатка кызык кына булсын: ике-өч көн күзәтеп йөрделәр дә, иртәнчәк Хромовны күтәреп, юынгычның озын калай ялгашына илтеп салдылар, ә кичен, ике ягыннан икәү култыклап, казарма каршындагы ике катлы бинаның аскы катына—клубка кино карарга алып керделәр.

Ул еларга җитешеп:

—Миңа ярамый, мин—старовер, белсәләр, мине үтерәләр!—дип серен чишәргә мәҗбүр булды.

—Курыкма,—диде Соловьев аның аркасыннан кагып.—Монда синең авылдашларың юк бит.

Шуннан соң Хромов иртән кеше рәтендә юына һәм башкалар белән бергә клубта кино карый торганга әйләнде.

Озынча буйлы, мокыт кыяфәтле Хромовның сөйләшүе дә кызык иде: «эти» диясе урынга ул «энти» ди, «этот» дип әйтәсене—«энтот», ди.

Соловьев, Хромовны шефлыкка алгандай, гел үзе белән ияртеп йөртә башлады. Беркөнне алар икесе Габделнур янына килделәр.

—Мин Хромовны бер кыз белән таныштырмакчы булам, хат язып бир әле,—диде Соловьев.

—Нинди кыз белән?

—Үзебезнең авылныкы. Аның йөргән кызы да булмаган икән әле. Әйдә, бергәләп языйк әле.

Габделнур, чынлапмы, дигәндәй Хромовка күтәрелеп карады. Тегесе кызлар кебек кызарынды, авыз эчендә ботка пешереп, нидер әйтте.

Габделнур Соловьевтан кызның исемен генә сорады да, бөтен шартын китереп, беренче биткә томшыкларын терәшкән күгәрчен сурәтләре ясап, сүз арасына җырлар кыстырып, аларга ике битлек хат язып бирде. Аны кычкырып укыгач, Хромов янә кызарды, шулай да канәгать икәне күзләрендә, ирен читендәге елмаюында чагыла иде.

—Рәхмәт,—диде ул.

—Үз кулың белән күчереп яз. Монысын үзеңдә калдыр. Мин сиңа һаман-һаман язмам. Юкса кыйбатка төшәрсең,—дип шаяртты Габделнур.

Соловьевның аңа гозер белән мөрәҗәгать итүе тикмәгә генә түгел иде. Чөнки Габделнур көн аралаш хат ала, үзе дә еш яза. Моны барысы да белә.

Яшьтән үк өеннән чыгып киткәнгә күрә ул хатларны һич иренмичә яза, җавап килсә, кош тоткандай шатлана иде. Хатлар аны авылы, әти-әнисе, туганнары, дуслары белән бәйләп торучы ышанычлы, өзелмәс ефәк җеп иде. Әлмәттән дә, еш булмаса да, хатлар килә. Сөеклесеннән килгәне аеруча күңелне җилкендерә.

...Габделнур Рәйсәнәдән бүген килгән хатны кулына алды. Хаттан борынны кытыклап торучы ят ис килгән шикелле булды. Ләкин бу ислемай исе түгел. Әйе, чынлыкта ул Габделнур ярата торган, авыл әбиләре теле белән әйтсәк, «бүлнис» исе иде. Бу ис кызның чәчләреннән дә тарала, Габделнур Рәйсәнәнең үзенә сиздермичә генә бу баш әйләндергеч тәмле исне рәхәтләнеп сулый, үзенә сеңдерә иде. Чөнки ул аның яраткан кызының, сөйгәненең шомырт кара чәчләреннән килә иде бит...

Шуны тою, истәлекләргә бирелү егеткә шулхәтле рәхәт булып китте ки, ул күзләрен йомды. Сагынуын ничек басарга белмәде... Күрәсең, Рәйсәнә бу хатын эштә, дежур торганда язгандыр... Егет күзләрен ачты. Янә бер мәртәбә хатның кечкенә хәрефләрдән тезелгән тыгыз юлларын укып юанды. «Үзем бер көе генә яшәп ятам. Аһ итәрлек үзгәрешләр юк. Яңа ел да килеп житте. Сизми дә калдым. Гомер бигрәк тиз уза инде: әйләнеп карасаң, сәгать йөргән шикелле, үтеп кенә тора көннәре... Синсез ямансу көннәр... Фотомны салам... Матур чыкмады».

Габделнур, хат укудан туктап, янә карточканы кулына алды, йотылып Рәйсәнәнең йөзенә текәлде. Матур булмыймы соң?! И бу кызларны... Кыланчыкларны... Ә артына ни дип язган бит:

Идел дулкыннары жем-жем итә
Ай нурлары балкып торганда;
Мин бәхетле шундый өзелеп-өзелеп
Юксынырлык кешем булганда.

Габделнур үзе турында: «Ә мин синнән дә бәхетле, сөеклем,—дип уйлады.— Син дә мине яратасың бит. Их, бер кайтып күрәсе иде! Бар, жәяү кайтып кит, дисәләр, ике дә уйламас идем...»

...Декабрь, гыйнвар, февраль айлары Кронштадтта иң хәтәр вакыт: Котлин утравы диңгездән—Фин култыгының һәр тарафыннан—искән барча ачы жилләрне кабул итә. Кар явамы, буран котырамы, чатнама суыкмы—солдат-матрос үз эшен эшләргә—ил сагында торырга тиеш. Ләкин анарчы ул әле яшь сугышчы курсын үтәргә: төз атлап сафта йөрергә һәм кулына мылтык тотарга өйрәнергә, химик һәм атом-төш коралларыннан саклану чараларын үзләштерергә, аннары белгеч буларак осталыгын арттырырга, сәяси яктан чыныгырга тиеш.

Соңгы көннәрдә Габделнур һәм аның иптәшләре дүртәр сәгать сафта йөриләр: аяк табаннары ут яна. Чолгавынны ашык-пошык урасаң, бармаклар суелып бетә; отбойдан соң йокыга китә алмыйча иза чигәләр... Аларны смотрга әзерлиләр.

Житмәсә, Габделнурны иң алга куйдылар. Югыйсә анардан бер башка диярлек озын Белобородов фамилияле солдат бар иде. Ул егетнең буе ике метрга якын. Ләкин ике норма ризык бирү өчен аңа ике сантиметр житми. Өстәл артына утырып, иптәшләре порциянең яртысын да ашарга өлгерми, ул инде миски тотып «амбразура»ны каплый.

—Өстәмә бирегез әле,—ди ул һәм үзенчә шаярткан була.—Сыеграгын... казан төбеннән.

Бик ялынгач, камбуздагы егетләр хәленә керәләр—савытына ботка салалар.

Менә шул егет сафта иң алда йөри иде. Күрәсең, Габделнурның аяк атлавы күңеленә хуш килгәндер, рота командиры—ыспай жинел гәүдәле, һәрвакыт диярлек кызу-кызу атлап йөрүче офицер—беркөнне аларның урынын алыштырды.

—Гаделжанов, алга чыгып бас!—диде капитан читтән генә солдатларның сафта йөрүен күзәтеп торганнан соң.—Ә син, Белобородов, аның урынына.

Ант кабул итү көненә Ленинградтан адмирал киләсе, дип сөйләнәләр иде. Һәр командирның үз кул астындагыларны югары башлыкларга яхшы яктан гына күрсәтәсе килә. Күркәмрәк сыйфатлы солдатларны, ышанычлы белгечләрне һәрчак шулай алгарак «этәрәләр».

Ил сакчыларын идеологик яктан тәрбияләү, чыныктыру өчен сәяси хезмәткәрләр бар. Майор Каргиев—озын гәүдәле, каратут йөзле, калын кашлы, тулы битле кеше. Өстендә кара кием, ләкин ул дингез офицеры түгел, чөнки кителенең җин очында алтынсыман саргылт тасмалар юк. Шуңа күрә ул өченче ранг капитаны түгел, ә майор дәрәҗәсендә. Ул үз эшен белеп, яратып башкара. Сөйли башласа, сәгатьләр буе авызына каратып тора ала: һәр сүзе дәлилләнгән, ышандырырлык. Фикерләрен дә тынлаучыларның күзенә карап әйтә.

—Кораллы көчләрдән башка дәүләт—ул кабырчыксыз ташбакага тиң,— дип башлады ул беренче дәресен.—Ә Советлар Союзының Хәрби Дингез флоты—кабырчыкның үзәк өлеше. Сез үзегезнең флотта хезмәт итүегез белән горурланырга тиеш. Чөнки Хәрби-Дингез флоты ике йөз илле ел эчендә үзен данга күмде. Патша Россиясенең Бояр думасы 1696 елның утызынчы октябрендә карар чыгара: «Морским судам быть». Шул чордан бирле Макаров, Нахимов, Ушаков һәм башка адмиралларның осталыкларын, матросларның һәм офицерларның батырлыкларын барыгыз да ишетеп белә булыр... Рус флотының дингездә иң беренче җиңүе 1714 елның 7 августында була. Петр Беренче командалык иткән флот шведларны Гангут борыны янында җиңүгә ирешә. Аннан соңгы дингез алышлары—дистәләгән, морякларның ул орышларда күрсәткән батырлыгы—тиңдәшсез. Мәсәлән, 1904 елның 9 февралендә, Рус-Япон сугышының беренче көнендә,—дип дәвам итте сүзен замполит,—ундүрт корабльдән торган япон эскадрасы безнең «Варяг» крейсерын һәм «Кореец» канонеркасын чолгап ала, ультиматум куя: «Бирелегез!» Әмма безнең куркусыз моряклар алар белән каһарманнарча сугыша башлыйлар: бер миноносецны батыралар, ике крейсерга зыян салалар. Безнең дә йөз егерме ике матрос һәм офицер һәлак була. Калганнары, корабльләрне дошман кулына төшертмәс өчен, «Варяг»ны батыралар, канонерканы шартлаталар.

Аннары майор Каргиев командирлары Әсгать Җиһаншин булган дүрт дингезченең батырлыгын да искә алды. 1960 ел башында аларның кырык тугыз көн буена океанда дрейфта булуларын, ачлыктан интегүләрен, ләкин көчле рухлы совет диңгезчеләре булып калуларын әйтте.

Габделнур янында утырган бер солдат шыпырт кына:

—Бәхетләре инде, Америка авианосецы «Кирсардж» аларны табып ала,— диде.—Бөтен дөнья шаулады, орденнар бирделәр. Үзебезнекеләргә эләксәләр, йә губага утыртырлар, йә төрмәгә үк тыгып куярлар иде.

—Нигә алай дисең?

—Качып китәргә маташканнар дигән ярлык тагарлар иде.

Солдат моны бик белдекле кыяфәт белән әйтте. Гәзиттә язылган, радиодан сөйләнгән һәр нәрсәгә карусыз ышанучан Габделнур иннәрен сикертеп куйды: бу егетнең тел төбен анлап житкермәде. «Башкача фикер йөртүчеләр дә була икән,—дип уйлады ул.—Безнең шикелле, кем нәрсә әйтсә шуңа сукырларча ышанып, ә ме—ә, жә ме—жә, дип кенә тормыйлар икән».

## III

Габделнур Хөрмәтне үтә дә тыныч холыклы, хәтта ки бераз пошмасрак кеше дип йөри иде. Алай түгел икән, ялгышкан булып чыкты.

Ашханәгә кереп өстәл янына утырып кына өлгерделәр, Хөрмәт янындагы

бер солдатның мангаена нидер очып килеп бәрелде. Өстәлгә төшкән нәрсәне жентекләбрәк карасалар—бер телем ипи.

—Кем ыргытты?—дип сорады Хөрмәт янәшә утырган, мангаена ипи катысы эләккән солдаттан.

Солдат, күрәсең, шәйләп калган.

—Әнә, Трофимов,—дип Габделнур башы аркылы күрше өстәлгә күрсәтте.

Габделнур исә Хөрмәт белән кара-каршы, бер өстәл янында утыра иде. Ул артына борылып карады. Чыннан да Трофимов, алар өстәленә күзен текәп, елмая иде.

Хөрмәт, ипи телемен кулына алып, сикереп торды да Трофимов янына килде. Солдат иң кырыйда иде.

—Син ыргыттыңмы?

—Әйе.

Хөрмәт, әле һаман елмаеп торган, батыр кыяфәтле Трофимовтан шундый җавап ишетүгә, күз ачып йомганчы тегенең янагына тартты.

—Син нәрсә?—дип сикереп торды Трофимов. Ябык чырайлы булса да, ул Хөрмәттән буйлырак иде. Сугып өлгерә алмады, Хөрмәт аның кулын читкә этәрде.

—Ә син?—диде ул ярсып.—Нигә ипи белән атышасың?

Габделнур, Атаулла белән Шәрип, урыннарыннан сикереп торып, алар янына килделәр. Хөрмәтне беркайчан да мондый кыяфәттә күргәннәре юк иде: аның юка иреннәре тагы да кысылган, авыз читендә аксыл төкерек күбеге хасил булган, күзләре зәһәр елтырый, йөзе—бурлаттай.

—Атышса соң?—диде Трофимов ачу белән.

—Тамагың туйдымыни?

—Ә мин ач түгел. Беркайчан да ач булмадым.

—Мин—булдым. Бер телем ипигә тилмердем. Шуңа күрә үскәч комбайнга утырдым. Менә шушы кулларым белән үзем иген үстердем.

Хөрмәт үзенең юантык, кыска бармаклы зур кулларын, учын өскә каратып, җәеп салды.

Атаулла исә:

—Моның өчен гүргүненә бацкыс куеп, йөгереп менеп, бәбәкләрен цукып алырга кирәк,—диде.

Камбуздагы пешекче егетләр белән амбразура аша сөйләшеп торган сержант, шау-шу ишетеп, йөгереп килеп житте.

—Нәрсә бар монда? Ник жыелдыгыз? Кайсыгыз жәнжал кубара?

—Ипи белән ыргытты,—диде Хөрмәт сул кулындагы ипи кисәгенә ымлап һәм Трофимовка төртеп күрсәтте.

—Соңыннан ачыкларбыз, барыгыз урыннарыгызга,—диде сержант күрше өстәлне уратып алган егетләргә.—Ә сез нәрсә бастыгыз? Утырыгыз!

Соңгы сүзләре Габделнурларга кагылмый иде. Чөнки Трофимов утырган өстәл артыннан да, чәкәләшүчеләрне араларга яисә үз күршеләрен якларга ук әзер булып, бер-ике солдат торып баскан иде инде.

Иң гаҗәбе шул: өченче өстәлдән дә бер литвалы егет алар янына килде һәм Хөрмәтнең сүзен жөпләде.

—Мин дә күрдем,—диде ул сержантка.—Ул ипи атты. Яхшы түгел.

Хөрмәтнең ярсуы әле басылмаган иде.

—Тагын бер сыйпыйсы калган икән,—дип сөйләнә-сөйләнә ул, ниһаять, урынына барып утырды.—Иманын киим... Әле селтәнгән була тагы... Тетмәсен тетәсе... Безне, «яманнан ярты кашык аш калыр», дип, ризыкны ашап бетерергә, жиргә коймаска, коелган валчыкны идәннән жыеп, өреп кабарга өйрәттеләр.

—Берцәк угомонись,—диде Атаулла аны тынычландырып.

—Мәнсез, ипи ыргыта бит...

Габделнур тамак туйдырганда теге литвалы егеткә карап-карап алды.

Литвалылар монда унбиш-егерме кеше иде. Алар гел бергә йөри. Бүтәннәр белән аралашмыйлар. Монысы, урысча вата-җимерә сөйләшсә дә, кысылуны кирәк тапкан. Ничек бу җәнҗалга борын тыгарга җөрьәт иткәндер, Габделнур башта аңламады. Ә бер-ике көннән Заранка фамилияле, Иозас исемле бу егет белән якыннан танышырга җай чыкты.

Армия—гадәти тормышның кечерәйтелгән чагылышы. Монда хәрби хәзерлек кенә өстәлә. Ә калганы—барысы да нәкъ гражданкадагыча. Бигрәк тә көнкүреш мәсьәләсендә. Әйтик, пешекче кирәкме? Кирәк. Итекче дә кирәк. Ә чәч алучы? Әлбәттә. Дөрес, «чибәрләнү» өчен чәчтарашханәгә барырга мөмкин. Акчаң булса һәм... шәһәрдә. Ә бәләкәй генә берәр «нокта»да яки чик буе заставасында?

Шуңа күрә солдат шулхәтле шомара—ул күпчелек эшне үзе башкара, ягъни, үз арасыннан һөнәрчеләр таба, тәрбияли.

Литва егетләреннән Бразаускас фамилияле солдатның чәч ала торган машинкасы бар икән. Гап-гади, җыйнак кына, ак төстә, кул белән хәрәкәткә китерелә. Сул кулына тарак тотып, уң кул бармакларын өзлексез тиз-тиз хәрәкәтләндереп, ул якташларының чәчен тәртипкә китерде. Ләкин үзенә чират җиткәч, арадан берсе дә аның чәчен тиешенчә кыркый алмады. Тотынып караучылар булмады түгел, ләкин кайсы йолкый, кайсы тигез алмый. Моны күреп торган Габделнур түзмәде.

—Кая, мин алып карыйм әле!—дип батырчылык итте, машинкага үрелде.

Чөнки аларның өендә нәкъ шундый машинка бар иде, тик тоткасының бармак тери торган урыны сынык, бер-ике төштә никеле дә купкан. Шулай да туганнар үзләренекен дә, әтиләренең чәчен дә тырыша-тырмаша шуның белән алалар иде.

Бразаускас, сары чәчле башын борып, бик ышанып та җитмичәрәк Габделнурга зәңгәр күзләре белән карап алды. Шулай да кыркырга рөхсәт бирде.

Башта Габделнур машинканы сүтте, өреп тузаннан һәм чәч бөртекләреннән азат итте—чистартты, кабат җыйды.

—Сиңа нинди прическа кирәк?

—Ничек?—дип, аңышмыйча сорады Бразаускас.

—“Бокс”, “Полубокс”, “Полька”, “Подполька”, “Канадка”...

Солдат кул гына селтәде, янәсе, үзең кара, барыбер андый сүзләрне ишеткәнем юк.

—Аңладым,—диде Габделнур машинканы эшләтеп карап.

Биш-ун минут үтте микән, юк микән, ул эшен тәгәлләде...

Шул көннән Литва егетләре аны үз итте. Бигрәк тә Заранка белән сөйләшеп киттеләр. Ул бер хутордан, ягъни ипи кадерен белүче авыл малае икән. Шуннан алар сөйләшеп-аралашып йөри башладылар. Иш ишен эзли, дигәндәй, ничектер күңеле тартылды ул тыныч холыклы егеткә.

Беренче карашка гына алар халкы кеше сөймәүчән, йомыкыйрак сыман тоела икән. Озын буйлы, яңаклары алсуланып торган түгәрәк йөзле, сары чәчле, мөлаем кыяфәтле Заранка бик дустанә холыклы, яхшы әңгәмәдәш һәм намуслы иптәш булып чыкты. Җитмәсә, алардан ерак түгел генә Кырык Татар авылы бар икән.

—Анда татарлар яшиме соң?—дип сорады Габделнур.

—Әйе. Мәчетләре дә бар. Тик алар безнеңчә сөйләшә инде...

...Мунча керү—солдатлар өчен иң шатлыклы, бәйрәмгә тартым көн. Чөнки мунчага бөтен шәһәр аша диярлек барасы.

Салкынча көн. Бүген көчле җил юк—сизелер-сизелмәс кенә. Әкрен генә

кар ява. Сирәк агачлар акка күмелгән, юллар, сукмаклар чистартылып, кары читкә өелгән. Сирәк кенә машиналар узгалый, урамда хәрбиләр күренә, күбесе—офицерлар. Шәһәр чиста, һавасы башларны әйләндерерлек саф, сулавы җинел. Салкын яратып кына колак яфракларын чеметә, шунадыр аяк атлавы рәхәт.

Сафта барсалар да—строй адымы белән түгел. Сөйләшергә дә мөмкин. Караштырып-күзәтеп баралар. Бигрәк тә кызлар очраса күнелләре күтәрелә егетләрнең. Кыз-кыркын янынннан үткәндә (солдатлар—урам уртасыннан, ә алар—тротуардан) эндәшмичә түзә алмыйлар.

Бүген дә, яшь кенә бер кыз күренүгә, солдатлардан кемдер аваз салды:

—Ризасызлык белдерергә!

Шуннан бөтен взвод бертавыштан:

—У-у-у!—дип үкерде.

Уенчак кыз булса—елмая, кул болгый, житдирәге очраса—чигә тирәсендә бармагын борып күрсәтергә дә күп сорамый.

Бүген соңгысына юлыктылар.

Шунда бер солдат, ачуы килеп:

—Ах, как идет!—диде.

Икенчесе күтәреп алды.

—Не идет, а пишет!

Өченчесе өстәде.

—Пишет как Лева!

Беренче солдат йомгаклады.

—А Лева пишет хреново!

Взвод командирынын ярдәмчесе:

—Сөйләшмәскә!—диярга мәжбүр булды.

Солдатлар тыналар. Ләкин шәһәрдә кызлар күп бит—очрап кына тора. Янә баягы хәл кабатлана.

—Да, чибәр, ырларга да ярый моны,—дип куя Атаулла.

Габделнур белән янәшә барган Шәрип, уфтанып:

—Безгә шул сүз зинасы белән күз зинасы гына калды инде,—диде.—Борын белән җибәреп...

—Син әйтәсенме аны, мин әйтимме, әллә икебез бергә әйтикме,—диде Габделнур да көлеп.—Ничә ай инде кызлар кулы тоткан юк.

—«Их метро юллары, йомшак иде куллары», дип җырларга гына калды.

—Йомшак кулларыннан тотып, бер үбешкән булмадымы?

—Анысы гына булды,—диде уфтанып Шәрип.

—Җәмиләне тагын бер искә төшер әле,—диде Габделнур көлеп.—Ул мина бик ошады.

Шәрип ялындырып тормады.

—Җә, Җәмилә, життек Жаекка. Жаек җәрминкәсендә җөрдек, җиләк җыйдык, җырлап җибәрдек. Жаек җәрминкәсендә җырлап җөргәч, җанадан җир җимертеп җырладык.

—Жаек—Урал елгасымы инде ул?

—Әйе.

Шәрип, гомумән, җор телле. Иптәшләре белән сөйләшкәндә генә түгел, сафта йөргәндә дә мәзәк сүзләр кыстырып куярга ярата. Әле беренче көннәре иде. Плацта басып торалар. Сержант ана сафтан чыгарга кушты.

Шәрип, есть, дип кенә калмады:

—Есть, товарищ генерал, пять солдатым умирал, остальные окопта, чыгарып булмый атып та,—дип такылдады.

Татар малайлары көлешеп алдылар.

—Нәрсә, нәрсә?—диде сержант, ана күзен алартып.

—Болай гына, иптәш сержант. Онытылып киткәнмен.

Икенче юлы мәрткә китмәсен өчен сержант аны йөгертеп ишегалдын өч тапкыр әйләндерде. Ләкин аңа карап кына Шәрип теленә салынудан туктамады, билгеле, чир—китә, гадәт—кала, диләр бит. Икенче вакыт рота командирына да ул: “Есть товарищ капитан, ач артыңны чап итәм”, дип җибәрде. Тегесе сизмичәрәк калды. Аңышса, сержант кебек урамда чаптырып кына калмас иде. Әле дә ярый “башы тишек” түгел.

Берәрсе саф алдында исәнләшкәч, гадәттә солдатлар, «исәнлек телибез, иптәш фәлән», дип командирның дәрәҗәсен атап сөрән сала. Шәрип шунда да җор сүз кыстырырга җай таба һәм: “Здравия желаем, чыгараем салаем...” Ул баштагы ике сүзне тамагы ертылганчы акыра да, соңгыларын күршедәгеләр ишетерлек кенә итеп әйтә. Габделнурлар пырхылдап җибәрүдән көчкә тыелып калалар.

...Трофимов Хөрмәткә ачу саклап йөри: янагына сукканын онытa алмый. Ләкин берүзе килеп ябышырга шүрли. Бәйләнергә җай эзләп йөргән көне. Мунчада да бер талпынып карады.

Габделнур күргәндә берничә егет Хөрмәтне уратып алганнар иде.

—Атаулла, Шәрип, әйдәгез әле!—диде ул һәм тегеләр янына барып та җитте.

Бер блатной гына солдат, бөеренә таянып алган да, күзләрен кысып, иреннәрен чалыштырып, Хөрмәт каршында боргаланып-селкенеп төкерек чәчә, теленә салынып маташа иде.

—Ты чего возникаешь? Тазамыни, бер тапкыр да авырмадыңмыни? Әллә сине гражданкада аз кыйнадылармы?

Хөрмәтнең бу лыгырдавыкка исе дә китмәде. Кысыграк күзләрен тегенә төбәгән дә көлемсерәп тик тора. Ул Габделнурга татарчалап:

—Тотып бәримме таш идәнгә башы белән?—диде.

Болар янына Шәрип тагын берничә дус егетне дәшкән иде инде.

—Син нәрсә, теге юлы судан коры чыкканыңа сөен,—диде Шәрип, куркаклардан булмаса да, аңлы егет.—Нәҗескә тисәң, сасысы чыгар.

Габделнур да:

—Бәйләнмә шул әнчеккә!—диде.—Алар юри син башлаганны көтә. Кара тавыш кубарырга маташа.

Хөрмәтнең бирешәсе килми, күрәсең, кулы кычыта иде.

—Үзләре котырта бит.

—Син эт түгел бит котырырга,—диде Габделнур Хөрмәткә һәм Трофимовка карап өстәде.—Гаеп үзендә. Без ипинең валчыгын да идәннән чүпләп ашарга өйрәнгән.

Атаулла да бу егетне кисәтүне кирәк тапты.

—Син безнең тирәдән читтәрәк йөр.

Нидер мыгырданып китеп барды Трофимов. Аңа әшнәләре дә иярде. Чөнки отделение командирлары—сержантлар да алар ягына караштыра башлаганнар иде инде.

Ләкин Трофимовның эчендәге үч алу уты сүрелмәгәне көн кебек ачык иде.

...Ни хикмәт булгандыр, шәһәр уртасындагы дүрт катлы бинадан февраль аенда аларны шәһәр читенә күчерделәр.

—Бу казармаларны моннан ике йөз илле еллар чамасы элек Петр патша төзеткән,—диде отделение командиры, ярыйсы гына укымышлы, күп нәрсәдән мәгълүматлы, солдатларына да хәерхаһлы егет.

Кызыл кирпечтән, диварлары берәр метр калынлыкта, түшәмнәре көймәле итеп эшләнгән иде бу бер катлы казармалар. Тәрәзәләре тар, биек түгел. Калай белән тышланган түгәрәк мичләргә утын ягасы. Күп итеп яксаң, җылы төшә үзе. Стеналар гына түгел, түшәм дә кирпеч, идән—цемент. Монда

да тормыш—гадәти солдат хезмәте, дөресрәге, әле карантин узу вакыты—сафта йөрү, уставлар өйрәнү, ант кабул итәргә әзерләнү.

Менә ул тантаналы көн дә килеп житте һәм аларны янә һәйкәл сыманрак итеп су асты көймәсенең рубкасы урнаштырылган Флотская урамына, әүвәлге казармага кайтардылар.

Кичтән үк кием чистарттылар, үтүкләделәр, итекләренә гуталин сылап куйдылар, башка вак-төякне барладылар. Иртән торгач, физзарядкадан соң, итекләренә су бөркеп, щетка белән көзгедәй ялтыраттылар, юындылар-кырындылар, ашханәгә бардылар. Ашау-эчү дә мулрак иде бүген.

—Адмираллар көн саен килеп торса да шәп буласы икән,—диде тамак мәсьәләсендә үзен рәнжетмәүче Хөрмәт.

Киенеп, карабиннар тотып, урамга чыктылар, сафка бастылар. Сафта юньләп йөрергә өйрәнмәгән Белобородовны исә плацка бөтенләй чыгармадылар.

Бүген бәйрәмчә киенгән офицерлар да өтәләнеп әрле-бирле йөри, казарманың тышкы ишеге өзлексез ачылып-ябылып тора. Көне дә килешкән—кояшлы, жылы. Плац—чип-чиста. Кыскасы, бер сүз белән генә әйткәндә—тантана.

Габделнурның мәктәп еллары исенә төште: мондый дулкынлану—ашкынып нидер көтү—ул Октябрь яки Май бәйрәмнәре вакытында була торган иде. Укучылар, бар булган «затлы» киемнәрен киеп, мәктәпкә жыелалар, сафларга тезелеп урамнарда йөриләр, укытучылар кычкырган өндәмәләрне хуплап, «Ура!» дип авылны янгыраталар.

Бүген дә анарда нәкъ шундый халәт.

—Смирно!

Команда янгырагач, солдатлар кулларын сыннары буенча сузып, тын алырга да куркып, катып калдылар. Андый чакта, башың борылмаса да, күз чите белән генә плацта ниләр һәм кемнәр барын күзәтәсең. Габделнур да кара киемле, уртача буйлы, кырык биш-илле яшьләрдәге адмиралны күреп алды. Погонында бер зур йолдыз—контр-адмирал дәрәжәсендә икән. Бу минутта Габделнурны адмиралга бирелгән рапорт сүзләре дә, бүтән олы һәм кече командирлар да кызыксындырмый иде. Әйе. Аның күзе фәкать адмиралда гына: беренчедән, тере адмиралны беренче күрүе, икенчедән, ул киләсе булганга Габделнурны ин алга чыгарып бастырдылар, дүртәр сәгать сафта йөрергә мәжбүр иттеләр бит...

—Исәнмесез, солдат иптәшләр!

—Исәнлек телибез, иптәш контр-адмирал!

Күбесе ул сүзләрне төгәл әйтми дә, фәкать, һау, һау, дигән шикелле бар көченә күкрәк читлегеннән һава гына чыгара. Ләкин бик игътибар белән тынласаң, барыбер адмиралны олылау сүзләрен аермачык шәйләргә була иде.

—«...Мин—Совет Социалистик Республикалар Союзы гражданины...»

Һәр сүзне ижекләп, чатнатып әйтеп, яттан өйрәнгән текстны сөйләп, кулына корал тоткан хәлдә ант биргәч, солдат өч ел буена туган иленә тугрылыклы хезмәт итәргә тиеш була. Шуңа әзерлеген бүген сафта йөреп күрсәтә...

Адмирал каршыннан күкрәкләрен киереп, югары күтәрелгән аякларын мөмкин хәтле ераграк сузып, каты асфальтка шап-шоп басып, тигез сафлар булып үткәч, иңнәреннән гүя авыр йөк төшкән шикелле тоелды. Командирлар да канәгать иде. Кыскасы, истәлекле, тантаналы көн матур узды.

...Егетләрне беренче мәртәбә ату кырына алып киттеләр. Көн салкын, ләкин кояшлы иде. Иңнәренә карабиннар асып, сафка тезелеп, шактый вакыт баргач, шәһәр читендәге ачык кырга килеп чыктылар. Бер катлы, бәләкәй генә будка янынnan узып, ату урынына керделәр.

Бөтен жир ап-ак. Кары чиста. Еракта форт күренә. Бу Ленинград ягыннан килгәндә күренгәне түгел, ә икенчесе. Ләкин әллә ни аермасы юк: кызыл кирпечтән биек итеп төзелгән түгәрәк корылма, өске өлешендә тәрәзәгә тартымрак тишекләр бар, ләкин рамнары да, пыялалары да күренми. Фортның әйләнә-тирәсе боз белән капланган. Арырак тагын бер форт күренә...

Каршыда очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп ята. Әкрен искән җилләр вак кар бөртекләрен боз өстеннән куа яки үз артларыннан иярткә—басудагы җәяүле буранга тартым бу манзара егетләргә туган як табигатен хәтерләтә.

Габделнурның туган иленнән чыгып китүенә өч ай булды инде. Сагыну хисе отыры сүрелә барырга тиеш иде кебек. Ләкин юк икән: сүнми дә, сүрелми дә икән, арада йөрүче хатлар гына әти-әниенне, туган-тумачаларынны, сөйгән ярларынны күрәсе килү теләген, һич бетмәс бу сусауны баса алмый икән... Боз өстеннән беленер-беленмәс кенә искән җил куган кар бөртекләре дә авыл басуындагы җәяүле буранны хәтерләткәч...

Һәр отделение аерым тезелеп, инструктаж һәм патроннар алып, атарга әзерләнде. Беренче мәртәбә ату, гәрчә моңарчы вак калибрлы мылтыктан атканы булса да, Габделнурны нигәдер дулкынландыра. Ул, каешын ычкындырып, кар өстенә ятты. Аякларын аерып, шинель итәкләрен тез турысынарак җыештырды, өч бармаклы бияләен салды.

Карабин, шактый авыр корал булса да, аның таза кулларында бик җиңел йөри иде. Бу юлы ул аны, терсәкләрен карга батырып, сул кулына сузып салды.

—Түтәсен уң як иңбашыңа ныгытып терә,—диде отделение командиры.

—Ярар.

«Мелькашка» белән эш иткәне булса да, бу—чын сугыш коралы, шуңа күрә командирның киңәше ярап куя.

—Чакмага басканда сулыш алма. Төзәгечне мушка белән тигезлә...

Класста карабинны сүтү-җыю, атарга өйрәнү күнекмәләре күп мәртәбәләр булса да, барыбер каушата, кирәкмәгәнгә дөп-дөп йөрәк кага башлый, сулыш алу ешая. Әйтерсең, суга керер алдыннан күкрәк читлеге үзенә кирәкле һаваны җыеп-сулап калырга тырыша.

Габделнур, сул күзен йомып, еракта күренгән мишеньгә—мәрәгә—төбәп, командирлар өйрәткәнчә атып җибәрде. Тәтегә менә басам, менә басам дип ята торгач, пуляның ничек очып чыгып киткәнен дә сизми калды. Ә менә карабин түтәсе үз эшен эшләде: шактый сизелерлек итеп солдатның кулбашына китереп бәрде. Димәк, мушка, төзәгеч һәм чакма белән мавыгып, ул карабинның тимер кадакланган авыр түтәсе барын исеннән чыгарган икән. Икенчеләй акыллырак булырга, дөресрәге, саграк кыланырга, берсен дә истән чыгармаска кирәк...

Өч патронын да атып бетергәч, Габделнур, урыныннан торды, кагынды, гильзаларын җыеп сержантка бирде. Тезелешеп яткан укчыларның барысы да атып бетергәч, команда бирелгәч кенә, кар ерып, мәрәләргә таба атладылар.

Солдатларның һәрберсе үз мәрәсенә таба ашыга. Чөнки беренче мәртәбә атулары. Ничәгә тиде икән? Ә гомумән тигәнме? «Сөт»кә китмәде микән? «Сөт» дигәне кәгазьнең мишень "алмасы"—кара түгәрәк читендәге ак килеш калган өлеше. Юк, «сөт»кә китмәгән. Габделнур үз күзләренә үзе ышанмады: ике бәләкәй генә тишек ун саны эчендә, берсе—тугызда.

—Ура!—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды ул.

Аның янына килеп житкән отделение командиры да гаҗәпләнүен-соклануын яшерә алмады.

—Ничего себе! Егерме тугыз очко! Әйбәт! Мәргәннәрчә!

Габделнурның шатлыгын Хөрмәт, Шәрип, Атаулла һәм бүтән якташлары да уртаклашты. Аларның да мәрәләре тишкәләнгән: берсенең егерме биш

очко булган, икенчесе егерме өчне җыйган... Бер мишеньнен генә “алмасы”нда гомумән ертылган-тишелгән урын юк иде.

—Ата алмаган—атасына үпкәләр,—диде Хөрмәт Шәрипкә төрттереп.

Ату тәмамланып, кайтырга җыенганда ыгы-зыгы купты: бер солдат гильза югалткан. Әйе, атылган патронның бушап калган гильзасы гына.

Әмма барыбер рота командиры, зурдан кубып, барысын да сафка тезде.

—Гильза табылмыйча—кайту юк!—диде ул әрле-бирле кар өстендә йөреп, күн пирчәткәле кулларын бутап.—Эзләгез!

Башта, әллә кесәсенә салды микән, дип тә шикләнделәр. Ләкин солдат бөтен кесәләрен әйләндереп күрсәтте, алмадым, дип ант итте.

Гильза—энә түгел, чәнти бармак юанлыгы дары савыты. Шулай да эзләү шактый вакытны алды. Ун-унбиш минут, берәмтекләп дигәндәй, тапталган карны куллары белән аралый торгач гильза табылды. Һәрбарчасы җинел сулап куйды. Әйе, патрон гына түгел, һәр гильза исәптә икән армиядә!

## IV

«Үскән чакта үскән идек, тал тамырлары кебек...» дип җырлый-җырлый туган авылыннан, газиз ата-анасыннан, якын кардәшләреннән аерылып киткән егетләр, тагын шул ук җырны күнелләреннән кабатлап, бер-берсе белән саубуллаштылар. Дөресрәге, аларны «сатып алучылар» аерды.

Хөрмәт Ульяновск өлкәсендәге бер частька эләкте. Бәхете—өйгә якынрак.

—Трофимов та сезнең белән икән!—диде Габделнур саубуллашканда.

—Әйе,—дип кенә әйтте Хөрмәт.

Шәрипнең авыз ерык.

—Мин юл йөрергә яратам,—диде ул.—Начар булмас әле, дөнья күрербез. Йөргән таш шомара...

Аны һәм Атаулланы Ленинград өлкәсенә—хәрби йөкләрне озата баручы ротага билгеләделәр. Габделнур Ярославль өлкәсенә—каравыл ротасына җибәреләсе иде, литвалы егетләр белән...

—Через день—на ремень, через два—на камбуз!—диде аңа отделение командиры әллә җәлләп, әллә, шул кирәк сиңа, дигән сыманрак. Беренчесе дөрескәрәк туры киләдер, теләктәшлек күрсәтүедер. Габделнур начар солдат булмады бит.

Кем кая эләгә, нинди частька кемнәр белән—бәхет эше. Киләчәк тормышың, язмышың үз кулыңда түгел. Сайлап—алалмыйсың, сорап—бирмиләр.

Үзбәк егетләре дә кайсы кая юл тотты. Алар арасында иң нык сөенгәне Хамракулов булды. Аны кайсыдыр частька пешекче итеп алдылар. «Сатып алучы» пылау ярата торган кеше булды ахрысы.

—Пылау пешерә беләсенме?—дип сорады ул үзбәк егетеннән бер дә тартынмыйча.

Хамракулов пешерә белә иде микән, юк микән, форсатны кулдан ычкындырырга ярамаганын тиз төшенде булса кирәк.

—Беләм!—диде ул чатнатып.

—Алам!—диде офицер.

Шатлыгы эченә сыймады егетнең—хезмәте җылыда үтәчәк иде.

Бер җырчы егет бар иде—ансамбльгә яздылар. Һәрбер хәрби округта, гаскәр төрләрендә үзенең җыр һәм бию ансамбльләре бар икән. Музыка училищесы бетергән егеткә үз һөнәре буенча “эш” таптылар—Балтик Флоты ансамбленә алып киттеләр.

Эшелонда танышкан, юл газабын бергәләп, гармуннар белән җырлашып-сайрашып күнелле итеп үткәргән егетләрнең күбесе белән дусларча

кочаклашып, кул кысышып аерылышты Габделнур. Чөнки яшь сугышчы курсын—карантинны—бергә үттеләр. Ә менә Тәтеш егете Морат белән хушлаша алмады. Өйләреннән адрес соратып, хат алыша иде югыйсә. Морат та Кронштадтта, ләкин бүтән частьта—учебкада, матрос киемендә, дүрт еллыкка эләккән иде. Әйе, аның белән саубуллашу насыйп булмады.

...Март башы Ленинград тирәсендә дә март башы икән—кояш та мулрак җылыта, чыпчыклар да шатланыбрак чыркылдаша, агач төпләрендә дә кар эреп, былтыргы үләннәр күренә башлаган, басуларда кар эри.

Машина Ленинградка килеп җитте. Аларны вокзалда төшереп калдырды да кирегә борылды—Кронштадка китеп барды.

Тагын Ленинградны күрү бәхетенә иреште Габделнур. Бу юлы анда озак тотмадылар—поезд аларны ары алып китте. Юллары—Ярославль ягына борылган иде.

Авылда җидееллык мәктәпне бетереп чыкканда Габделнурның өчлесе дә, бишлесе дә (тәртибен исәпләмәгәндә) юк, бөтенесе дүртле булды, ләкин иң яраткан фәне география иде. Шуңа күрә ул поезд чакрым баганаларын санаган саен үзенең туган ягына табарак якынлашуын тойды. Гәрчә, Мәскәүдән шактый төньяктарак булса да, өй түбәсеннән, сылаулы ак морҗадан төтен чыкканы күренмәсә дә, Кронштадт белән чагыштырганда Ярославль күпмедер дәрәҗәдә Казанга юл алу иде.

Шәһәргә алар төнлә килеп төштеләр. Маңгаена «Ярославль» дип язылган тимер юл вокзалын һәм якын-тирәдәге станция корылмаларын гына күрү насыйп булды. Вагоннан да чыгармадылар. Аларның юлы ары икән әле.

Таң беленгәндә бәләкәй генә бер станциядә поездан төшереп, хезмәт итәсе частька җәяү генә алып киттеләр.

Өйгә якынрак булса да бу тирәнең табигате кырысрак икәнен Габделнур вагоннан чыгу белән аңлады. Кояш саран җылыта, күрәсең, әле монда кыш уртасы кебек—карның җебергә гамендә дә юк, суыгы да—куырып ала, тынга каплана. Тигезле-тигезсез атлаган солдат итекләре астында кар шыгыр-шыгыр килеп, төнге тыныч һавада әллә кайларга тарала. Монда үзенә бертөрле саф, чиста һава—биек-биек нарат, чыршылардан таралган хуш ис борыннарны ярып, кытыклап керә.

—Табигате матур икән,—диде Габделнур янәшә атлаган Заранкага.

—Әйе,—дип раслады мондый хозурлыкны беренче тапкыр күргән Иозас һәм казармада да алсуланып торучан, ә хәзер кызарып ук чыккан битен ялан кулы белән ышкып алды.—Хезмәт ничек булыр...

—Ияләнербез әле,—диде Габделнур һәм ул да сул колагына кагылып алды.—Без татарларга барыбер: сабантуй ни, сугыш ни—барыбер орышасы.

Габделнур кебек, Иозасны да солдат хезмәте әллә ни куркытмый иде. Ул да, иптәшенә карап, теләктәшлек йөзеннән сүзсез генә елмайды.

...Постта торганда урман эчендә ара-тирә тукран "пулеметтан сиптерә"—агач чукып җим эзли, шарт-шорт иткән тавышлар ишетелә—агачлар суыкка түзә алмыйча ярыла... Нарат ябалдашларына ап-ак кар кунган, саргылт-көрән кәүсәләре уклау кебек төз үзләре. Наратның аста ботаклары юк. Алар, сынган мөгез шикелле, кәүсәдән бераз гына чыгып торалар. Шулай булса да аларга да кар кунган. Чыршылар да карлы, ләкин яшел—күзгә күрекле, горур. Җирдә ак кар астыннан куак, вак чыршы һәм нарат үсентеләре башларын калкытканнар.

Ике сәгать сакта тору әллә ни авыр түгел үзе: башында бүрек, өстендә аксыл төстәге мул якалы толып, аягында калын олтанлы киез итек. Итеге авыррак булса да аякка җылы, олтаны да авыл баласына кечкенәдән таныш. Яңа киез итекне озакка чыдатмыйлар иде алар. Шуңа күрә әтиләре кышкы кичләрдә итекләренә олтан сала торган иде. Малайлар карап-өйрәнеп утыралар,

тегәрҗеп сумалаларга булышалар, әтиләренең кулыннан безе төшеп китсә алып бирергә әзер торалар иде... Кулында бармаклы өр-яңа солдат бияләе. Карабин тоткан уң кулың тунса, коралыңны сулына авыштырасың. Монда син үзенә-үзең хуҗа, йоклама гына. Көндез, иртә-кич ярыйсы, ләкин төнлә һәм бигрәк тә таң алдыннан үзең дә сизмәстән оеп китәсең... Сәгатьнең чылбырга аскан гере сизелмичә генә аска төшә барган кебек, синең баш та әкрен-әкрен аска иелә, күз йомыла. Аягүрә шулай йоклап китәсең вышкада... Нинди дә булса кош агач башында кыбырсып алса яки тиен-мазар сикерсә—уянасың инде... Аннан тагын баягы хәл кабатлана... Бигрәк тә иртәнчәк йокы баса... Үзең дә сизмәстән нәүм базарына китеп барасың... Андый чакларда Габделнур йөренә, уяулыгын югалтмаска тырыша, туган авылын искә төшерә. Ләкин бүген, үч иткәндәй, нәкъ әнә шул йокыга кагылышлы вакыйга хәтерендә янарды.

...Болында ат саклаганда үлеп йокылары килә иде малайларның. Кем әйтмешли, арт якларын кисеп алсалар да берни сизмиләр. Ат караучы, кызык өчен, кайберләрен үшәнрәк, картрак атның койрыгына тагып та җибәргәли иде. Ә чыбыркыларын яшереп куюны әйткән дә юк инде, анысы—һәр төнне.

Бервакыт ат караучы абзый Габделнурга:

—Син йокыга бик сак икән, матри малай, барыбер чыбыркыңны урлыйм!—диде.

—Урлый алмыйсың!

—Ярар, карап карарбыз. Баш астына гына куеп ятма.

Габделнур төне буе йокламады. Ләкин иртәнге якта һич чама юк чыдарга—изрәде, йокысы килә башлады. Сандугачлар сайрый өздереп, атлар шыгырт-шыгырт үлән ашап йөри...

Күзләре йомыла малайның, башын күтәрә алмый, ләкин сизә: агай чыбыркысын алырга килә. Күзен ачарга тели—булмый, башын да күтәрә алмый.

Шуннан көч-хәл белән әйтте Габделнур:

—Чыбыркыны гына алма, башны күтәреп булмый.

—Чистый җен икәнсең. Иманың юк икән!—диде ат караучы көлеп.

Әйе, башына төшсә түзәсең... йокысына да, хезмәтенә дә...

Хәер, түзә алмаучылар да бар икән. Бер солдат постта торганда үзенә-үзе атты.

Габделнур ул вакытта каравыл бинасында, ике сәгатен йокламый үткәрергә мәҗбүр булып, өстәл янында утыра иде. Анда домино, шахмат-шашка уйныйсың, хезмәттәшләрең белән гәп корасың. Кыскасы, каравыл уставы таләп иткәнчә ике сәгать буена йокламаска тырышып утырасың.

Кинәт урамда нидер шартлаган сыман булды—мылтыктан аткан аваз яңгырады. Барысы да тынып калдылар. Каравыл башлыгы—кече сержант—сикереп торды да кычкырып җибәрде.

—Каравыл, коралга!

Уяу смена да, черем итеп алырга ятканнары да—барысы да сикереп торып, карабиннарын эләктереп, тышка чыктылар. Прожекторлар яктысында ерактан ук шәйләнгән суллагы вышкага таба йөгерделәр...

Сергеев фамилияле солдат җиргә төшкән. Үзе ап-ак булган.

Як-ягына карана-карана йөгергән кече сержант тирә-юньдә берninди дә шикләнерлек нәрсә югын чамалады.

—Нәрсә булды?—дип сорады ул килә-килешкә.—Нишләп монда торасың?

Сергеев, башын аска иеп, юаш кына:

—Аттым...—диде.

—Кемгә? Нәрсәгә?—Кече сержант як-ягына каранды.—Кая?

—Үземә.

—Ә?!

Шунда гына Сергеевның уң колагыннан ак карга кызыл кан тамганын абайлап алды кече сержант. Ул Сергеевның кулыннан карабинын бәреп очырды.

—Ананны!.. Нәрсә, үләсең килдемени? Алайса нигә маңгаена атмадың? Сволочь! Манка!

Чөнки каравылда ЧП булса, каравыл башлыгына да рәхмәт әйтмәсләр. Шаукымы аңа да тиячәк иде.

Сергеев елый ук башлады.

—Мин...

—Дәшмә! Атла әйдә! Гаделҗанов, постта кал. Заранка, ал Сергеевның карабинын.

Кече сержант, аты юлы белән сүгенеп, Сергеевны алга чыгарды. Солдат, кулы белән колагын тотып, әкрен генә атлап китте, аның артыннан—башкалар.

Габделнур постта калды. Ул, баскыч араталарын шыгырдатып, каланчага менде, як-ягына каранды, сукмактан тезелешеп киткән хезмәттәшләренә күз салды. Аннары, карабинның түтәсен идән тактасына төшереп, аны җинелчә генә тотты.

Тирә-юнь тыныч. Бернинди дә хәвеф юк. Ләкин барыбер бүтән чактагы кебек түгел. Ниндидер шом йөрәгенә төште. Юк, бу курку түгел. Ниндидер аңлаешсыз борчу катыш ризасызлык уянды күңел түрендә. Нәрсәдән, кемнән разый түгел Габделнур? Бу тойгы теге солдатка карата туган икән. Ничек үз-үзенә кул күтәрмәк кирәк?! Мордар китү гомер-гомергә гаеп, хурлык саналган. Аны беркайчан да өнәмәгәннәр. Хезмәт авыр дисәң, кемгә җиңел иде ул?! Әнә Кронштадтта күргән матрос алты ел хезмәт иткән бит әле... Башкалар дүртәр ел су асты көймәсендә (икешәр-өчәр ай диңгез-океан караңгылыгында) яки башка корабларда үз бурычларын үтиләр, һәр минут сугышчан хәзерлектә торалар. Ә сугыштан соңгыларга җидешәр-сигезәр ел каеш буып йөрергә туры килгән. Элекке заманнарда—егерме биш ел солдат хезмәте... Хәзер тегеңә нәрсә булыр икән? Кайтарып җибәрерләрме, гауптвахтага утыртырлармы? Әллә башта санчасть, госпиталь юлын таптармы?

Габделнурга әтисенең сөйләгәне бар иде. Сугыш вакытында да кайбер «акыллы башлар» үз-үзләренә зыян салганнар икән. «Бәхетлеләре», җиңелчә яраланып, өенә кайтып киткән, ә «бәхетсезләрен»—кеше ышанырлык итеп мәтәштерә белмәгәннәрен—шундук атып үтергәннәр яки штраф батальоннарына озатканнар.

Абыйсы Гатуф сөйләгән дә исенә төште. Кайберәүләр, комиссоваться итәлү өчен, тиен акча йота торган булалар. Ашказаны авыртa дип, госпитальгә баргач, рентген тегендә кара тап күрсәтә икән. Ипи валчыгына әвәләп гуталин кабучылар да булган.

Ә без? Күрәсең, безгә яшьтән икенчерәк тәрбия бирелгәндер... Энесе белән булган вакыйга хәтеренә килде.

Габделнур җәй көне чиннек каршында утын яра иде. Энесе Газиз әле бәләкәйрәк (хәер, үзе дә унике-унөч яшьләрдә генә булгандыр), карап тора. Габделнур, балтасын күтәреп, бүкәнгә чабыйм дигәндә генә, энесе, ни сәбәпледер, аягын бүкән өстенә куйды. Абыйсы балтасын чак читкә борып өлгерде. Энесен каты ачуланды шулчак Габделнур...

Иң истә калганы шул: энесе илереп җылап җибәрде һәм әйтте:

—Армияга бармыйча каладырыем бит!

Әйе, аяк бармаклары өзелү түгел, ә армияга бармый калу аның өчен трагедия, хурлык булачак иде. Чөнки ул чорда армия хезмәтенә караш шундый иде шул.

Габделнур тынлыкка колак сала. Селкенгәли, таптана, йөренә. Тагын туктап кала. Күз күреме житкәнче һәр тарафта урман. Яшел чыршы ботакларын,

нарат ябалдашларын кар сарган. Кары нинди—ап-ак. Куе зәңгәр күк йөзен йолдызлар бизәп тора, алар арасында ай йөзә. Түм-түгәрәк. Габделнурның туган авылы күгендә дә, Әлмәт өстендә дә шул ук ай, шул ук Зөһрә кыз көянтә-чиләк асып суга бара. Гаҗәеп хозурлык, сокланып туймаслык... «Ничек шушы матурлыкның, тормышның рәхәтен, тәмен тоеп яшәмичә үз-үзенә кул саласың инде?! Ахмак, яшьлегеннең һәр минуты яшәү дәрте белән сугарылган бит. Кадерен генә белергә кирәк югыйсә. Күрәсең, кайтарып җибәрерләр, дип өметләнәдер?»

...Ике көн дә үтмәде, төнлә казармада тавыш купты. Бер солдат, сикереп торган да, акырып җибәрде.

—Тагын минем өскә сиясеңме? Ананны...

Дневальный ут яндырды. Ике этажлы караватның аскы катында торып утырган солдат янына килде.

—Нәрсә бар?

Ап-ак күлмәк ыштанлы солдат аягына итеген киеп маташа иде.

—Тагын Черняев астына сигән!—диде ул.

Икенче катта йоклаган яшь солдат та уянган. Күзләрен йодрыклары белән уа-уа:

—Мин юри эшлимме әллә,—дип елап җибәрде.

—Төш,—дип боерды аларның отделение командиры.

Солдат төште, чалбарын кия башлады...

Аны госпитальгә озаттылар. Ул янадан бу частька кайтмады.

Нишләттеләр икән ул бичараны? Кайсы яктан гына карасаң да бичара инде аның ише бәндә: әгәр чыннан да астына җибәрә икән—авыру буларак кызганыч, хәрби хезмәткә түзә алмыйча хәйләгә сабышса—егетлек түгел: кылган гамәле якыннарына барып ирешер, сөйгән кызына да ишетелер. Әгәр комиссовать итсеннәр өчен генә җәймә чылата башласа, кайтаваз булып үзенә кагылгандыр—тиешле җәзасын алгандыр, табиблар алдатмас. Чөнки беренче көннәрне андый гадәте беленмәгән икән.

Менә шундый инде ул солдат хезмәте: кем—түзә, кемнең буыны сыек—сыгылып төшә.

Әйе, берәүләр, түзә алмыйча, хезмәттән котылу юлын эзли—төрле хәйлә кора, икенчеләр исә уйлап та бирми—курортка килгәндәй хис итә.

Бертуган Карасевлар Мәскәү өлкәсеннән алынганнар. Башта алар ике тамчы су шикелле бер-беренә охшаганнар иде. Ләкин тора-бара игезәкләрне таный-аера башладылар. Чөнки берсе унөч килога тазарды, ә сынары—алтыга гына.

...Каравыл бинасыннан чыккач, карабиннарын корып, иңнәренә асып, олтанлы киез итекләре белән тар сукмакны тыгызлап, ак толыплы солдатлар постка китә. Карасевларның Володя атлысы, йокыдан айнып җитмәгәнлектән, бара-бара да кар өстенә авып төшә.

Разводящий, өченче елын хезмәт итүче ефрейтор, сүгенә.

—Тор, дуңгыз! Уян! Һаман йоклыйсың...

Тагын китәләр. Карасев каланчага менә, постта кала.

—Нинди сакчы инде бу?!—ди аңа җирәнеп караган разводящий һәм, солдатларны ияртеп, ары китә.

...Каравыл ротасында Габделнур Башкортстаннан чакырылган Нурмөхәммәтов фамилияле татар егете белән танышты. Ул—тәбәнәк гәүдәле, чандыр гына, өченче елын хезмәт итә, коптерщик. Беркөнне Габделнурга үз башыннан үткән хәлләрне сөйләде.

—Мине беренче елны берәү бик интектерде,—дип башлады ул сүзен коптеркада утырганда.—Сина да бәйләнүләре мөмкин. Беренче көннән үк нык тор, үзеңне бастырма, басымчак итәрләр. Не надо оказаться в роли

битой собаки. Син—таза, буйлы да. Мине, кечкенә булгач, баштарак кыерсыттылар. Федоров фамилияле берәү нык бәйләнде. Казармада да, плацта да, караульный помещениедә дә, вопщем, кайда туры килсәм дә тынгы бирми бит бу. Ротныйдан собаководлар взводына күчерүен дә үтенеп карадым, урын юк, диде. Шуннан түзәргә калды инде. Ә күпме түзәргә була? Бервакыт, постка басар алдыннан, урамга чыккач, карабинны кордым да тегенең корсагына китереп терәдем. «Туктыйсыңмы миңа бәйләнүдән, юкмы? Атып үтерәм!»—дип кычкырып җибәрдем. Чөнки түзәр әмәл калмады. Ул көнне дә мине майсыз калдырган иде.

—Ничек?—дип сорады Габделнур.

—Кичен май бүлгәндә, шаярган булып, миңа, сиңа, тагын миңа, дип минем өлешне үзенә салды... Мин корсагына китереп төрткәч, катып калды бу: бер агара, бер күгәрә. Шунда каравыл буенча дежур офицер да бар иде. Ул тиз генә минем карабинны читкә этәрде. Мине сүгә башлады. Ә мин ярсыган идем инде, елый-елый тегенең җәберләвен сөйләдем. Бүтән яшь солдатлар да аннан гарык иде инде, алар да эшнең нидә икәнен әйткәч, мине яклагач, офицер Федоровны әрләргә тотынды. Ләкин эшне зурга җибәрмәделәр. Шуннан соң гына туктады теге хайван.

—Ә хәзер ничек?—дип сорады Габделнур.

—Ул китте бит инде. Мин хәзер үзем «картлач». Ләкин ана карап кеше рәнҗеткәнем юк. Безнекеләр арасында да юньсезләр җитәрлек. Алдынны-артыңны карап йөр, сак бул. Берәр хәл килеп чыкса, үземә әйт. Тартынма.

—Ярар.

Солдатлар арасында гына түгел, солдатлар белән офицерларның үзара мөнәсәбәтләрендә дә шактый четерекле хәлләр булгалый кайчак.

...Каравыл буенча дежурный иркенләп, каешын салып, изүен ычкындырып, йокламыйча утырырга тиешле смена егетләре белән домино сукты. Кызып-кызып уйнадылар: ул үзенең офицер икәнен, егетләр солдат икәнлекләрен оныткандай тугарылдылар. Чөнки кече лейтенант әле үзе дә солдат-сержантлардан өч-дүрт яшькә генә олы иде. Егетләр аны үзара "микромайор" дип йөртәләр.

Офицерның үзен иркен тотуы да аңлашыла: постлар тикшерелгән, часовойлар үз урынында, солдатларның тамагы тук, бер смена тулысы белән монда утыра, икенчесе ял итә. Кыскасы, тышта да, каравыл бинасында да тәртип, тынычлык хөкем сөрә. Борчылырга сәбәп юк. Дөрес, вакыт-вакыт йокы бүлмәсеннән берәрсенең гырлаганы ишетелеп ала да, нәрсәдер дөпелдәгәч, кисәк туктый. Андый чакта дежурный, тавышка колак салып (кулында домино, күзе өстәлдә булса да), үзалдына елмаеп куя, чөнки белә: гырлый башлаган солдатка кайсы да булса берәү йокы аралаш олтанлы итек белән тондырган... Янә тынлык урнаша.

Шактый озак утыргач, кече лейтенант кузгалды.

—Миңа вакыт,—диде ул һәм киенә башлады.

Каешын биленә буып, өйрәнелгән гадәт буенча кобурасын капшап, җайлабрак куймакчы булды. Һәм... кинәт аның йөзе агарынды, үзе торараштай катып калды: корал савыты җинел, буш иде.

—Кем минем пистолетны алды?—дип кычкырып җибәрде ул.—Сержант, тез каравылны! Тиз бул!

Уяу смена да жыелды, эчкәре бүлмәдә йоклаганнар да торгызылды—тәмле төшләреннән бүлгәнгә ачуланып, шешенгән кызгылт чырайларын сытып, ялкау гына сафка килеп бастылар.

Габделнурга әле генә үзләре белән балаларча шатланып, уен-көлке сөйләшеп, шап-шоп домино суккан дежурныйның шул тиклем тиз үзгәрүен һәм ачуы кабаруын аңлавы кыен түгел иде: корал югалту, бигрәк тә офицер кешегә, ин хәтәр нәрсә. Моны гаеп эш дип кенә карамыйлар, ул—җинаять санала.

Саргылт кашлары жыерылган, ярсудан, каушаудан тотлыга ук башлаган офицер, үз-үзен белештермичә жикеренде. Читлектәге киек жанвар кебек строй алдында әрле-бирле йөренде.

—Кайсыгыз минем пистолетны алды? Кем? Бирегез хәзер үк!..

Сержант куркып калды.

—Бәлки идәнгә төшкәндер, иптәш кече лейтенант?

—Син нәрсә, сержант, ул бит энә түгел! Кобура элэктерелгән иде, ә хәзер—ачык. Ачык калган! Анлыйсынмы? Димәк, кемдер тиз генә алган. Йә, кем алды? Танмыйсызмы?!

Каравыл башлыгы һаман үзенекен тәкрарлады.

—Иптәш кече лейтенант, беркем дә алмагандыр. Бәлки...

—Дәшмә!

Шулай диде дә офицер кинәт кенә йөрүеннән туктады, аннары, саф алдында үзе белән янәшә ык-мык итеп торган сержантны кырыйга этеп жибәрде. Ул бер солдатның каршына барып басты, күзләренә текәп карады. Нидер исенә төште бугай.

—Малдышев, син алдыңмы?—дип сорады ул бөтенләй икенче, тыныч тонга күчеп.

Янаклары чыгынкы битле, кысыграк күзле, тәбәнәк гәүдәле Алтай егете Эркелей Малдышев дәшмәде. Ул үзе дә каушады ахры. Уеннан уймак чыгуы ихтимал иде.

Сержант та:

—Әйт, син алдыңмы?—дип сорады.

Кече лейтенантның эченә жылы керде. Тавышы йомшады. Үзе элеккеге үрнәк, тәртипле совет офицерына әйләнде. Тавышында—ялвару.

—Бир генә, Малдышев, беркемгә дә әйтмим. Сиңа бер начарлык та эшләмим.

Солдат, сафтан чыгып, каравыл бинасының бер почмагында торган, ком тутырылган мичкәдән офицерның пистолетын алып килеп бирде.

—Гафу итегез, иптәш кече лейтенант.

—Рәхмәт. Син дә мине теге вакыттагы хәл өчен гафу ит.

Эш шунда иде: узган атнада әлеге офицер постта торган Малдышевның карабинын сорап алган. Солдат ни сәбәпледер биргән. Аннан үзенә үк әрләү эләккән—устав буенча ул коралын беркемгә дә бирергә тиеш түгел.

## V

Нурмөхәммәтовның кисәтүе юкка гына булмаган икән: Федоров кайтып китсә, кеше рәнжетеп тәм табучы бүтәннәр табылды.

Беркөнне Габделнур юыну бүлмәсендә кырына иде. Аның белән янәшә басып торучы солдат тиктомалга бәйләнә башлады. Ул үзе дә янакларын, ияген сабынлап алган, әледән-әле Габделнурга караштыра, ахырда, яшь солдатны мыскыл итмәкче булды бугай.

—Син нигә кырынасың?

—Ә нәрсә?

—Синең анда бернәрсә дә юк бит. Әнә сөлге белән генә кырын. Лезвиеңне миңа бир. Синең анда өч төк ике рәткә тезелеп баскан.

Ул үзе кырына, үзе шырык-шырык көлә. Үз сүзеннән үзе тәм таба, күрәсең. Габделнурның ачуы кабынды. Карап торышка метр ярым буе бардыр, чирләшкә сыманрак нәрсә, аксыл, ябык чырайлы. «Замухрышка, и ты туда же, кем әйтмешли, метр с кепкой»,—дип уйлады Габделнур. Ул әле ротадагы солдатларның бөтенесен дә танып-белеп бетерми, мөгаен, бу инде соңгы елын хезмәт итәдер. Шулай да Габделнурның жене кузгалды.

Ул дорфа гына:

—Минем дуңгызчылык хуҗалыгымда син этнең ни эше бар?!—диде.

Солдатның бритва тоткан кулы ярты юлда асылынып калды.

—Нәрсә?

—... җилкә аша! Кайнар булса, икенче җилкәң аша ташла!

Солдат, күрәсең, моны көтмәгән иде. Чыраен сытты, аннан әле яртылаш ак күбекле йөзендә, ирен читләрендә мыскыллы елмаю чалынды.

—Мин күрәм: зәһәр шаяртасың, очлы күренәсең.

—Син дә шаярт. Этнекеннән дә очлырак була алмассың.

—Син, авыл гыйбады!

—Әйе, тууын авылда тудым. Ләкин бөтен гомеремне шәһәрдә яшәп үткәрдем.

—Син, маңка! Кемгә?..—дип кычкырып җибәрде солдат һәм Габделнурга таба омтылып куйды.—Мин бит—«картлач»! Ә син кем? Син нәрсә, аңламыйсыңмы әллә? Син нәрсә, тупыйкмы, ангырамы әллә?

—Син үзең аңгыра, себер итеге кебек тупа башлы.

—Мин сине... Гафу үтен! Ну!

—Хрен гну.

«Картлач» чыгырыннан чыкты, кулын күтәреп, Габделнур өстенә килә башлады. Приборларын куеп, Габделнур боксер торышын алды: аякларын аерып басты, кулларын йодрыклап, берсе белән йөзен каплады, икенчесен күкрәк турысында тотты.

—Кил әйдә, кил, башың ике булса!

Моны күреп, «карт әтәч»нең кикриге шиңде.

Шулай да:

—Ярар, без сиңа күрсәтербез әле,—дип янады ул һәм, ашык-пошык кырынып бетерде дә, әйберләрен җыеп, чыгып китте.

Габделнур, текәлеп карап, аның йөзен хәтерендә калдырды: бетчәле бит, очлы чөенке борын, сары чәч.

Озакка сузмыйча әлеге хәлне Нурмөхәммәтовка сөйләде.

Теге «картлач» белән бик батыраеп әрепләшсә дә, ул тәртәне катырак бөгеп ташлавын аңлады. Беренче көннәрдән үк алай тупас кылану бәлки кирәк тә булмагандыр? Ә икенче яктан уйлаганда, Нурмөхәммәтов аны кисәтте бит: бастырма, басымчак итәрләр. Әле кешесе адәм рәтле егет булса бер хәл иде—солдат бияләе белән бәреп егарлык нәрсә.

—Кем икән ул? Миңа күрсәтерсең әле,—диде якташы.

—Ярар.

Җаен туры китереп, Габделнур теге солдатны өлкән иптәшенә күрсәтте.

—Әнә теге...

—Ә, Нелидов. Бер бәйләнчек инде шунда. Дуслары бар, исендә тот.

Габделнур белән Кронштадттан, нигездә, Литва егетләре килде. Ул аларга да бу хакта сүз катты. Чөнки алар да яшьләр. Кемнең кем икәнен белеп торсыннар. Бу минутларда ротада дневальный вазифасын башкаручы, коридордагы тумбочка янында басып торучы Заранка яшьтәшен игътибар белән тыңлады. Биләгендәге тасмасын рәтләбрәк куйды. Аннары:

—Мин үзебезнең егетләргә әйтермен,—диде ул һәм шундук казармадагы бер якташын дәшеп алды.—Красаускас, кил әле.

Тегесе килгәч, ул аңа үзләре телендә нидер әйтте.

Анысы да озын буйлы, тырпаеп торган сары чәчле, ләкин ябыграк егет иде. Бер генә сүз әйтеп, баш какты да, ул китеп тә барды.

Алар халкы, гомумән, аз сүзле. Дөрес, үзара алар сөйләшәләр, ләкин башка милләт егетләре аларның телен аңламый. Ә гомуми әңгәмәләргә алар кушылмый. Моның серен соңыннан белде Габделнур.

Литвада совет власте кырыгынчы елны гына урнаша. Аннары дүрт ел сугыш. Аннан соң да әле алар тиз генә яңача яшәүгә ияләшә алмыйлар. Бәлки теләмәгәннәрдер дә? Күбесенең чит илләрдә туганнары бар, әйберләр җибәреп яталар. Күрәсең, тормышлары—житү, начар урнашмаганнар.

Адомас Рудис исемле, хәтта укый-яза белмәүче солдат, берчак ычкындырды.

—Мин монда яшәгәнче, Канадада яшәр идем.

Аларда жиде сыйныф белемле булу—бездәге урта мәктәп бетерүгә бәрабәр. Чөнки күбесенең—дүрт сыйныф, бишенче—коридор.

Алар бик бердәм егетләр иде. Заранка Габделнурны да үз даирәләренә тартты. Нурмөхәммәтов та Нелидовны кисәткән, ахры, шуңа күрә ул «картлач» тарафыннан нинди дә булса омтылыш сизелмәде. Ә шулай да саклык чаралары күрү комачауламый иде. «Егетләргә әйтеп, дөрес эшләдем бугай»,—дип уйлады Габделнур. Хезмәте тыныч кына дәвам итте.

...Көн кичкә авышкан. Аяз зәңгәр күк йөзенә кояшның соңгы нурлары таралган. Сирәк болыт итәкләрен алсуландырып, көнбатышны гаҗәеп матур төсләргә манып, кояш баерга азаплана.

Урман эчендә кар күп. Агач кәүсәләренең түбәнге өлеше кар эчендә утыра. Бәләкәй генә чыршы үсентеләре кин итәкле яшел тун кигән балалар кебек—алар карга батканнар да, гаҗәпләнеп, туктап калганнар диярсең. Алар монда, олылар ышыгына, ялгышып кына килеп чыккан нәниләр кебек шул. Ләкин өлкәннәр күп, ә болар—берничә генә. Кояш нурлары нишләп безгә килеп житми икән, без туңарбыз бит, дип тә уйлыйлардыр әле.

Әйе, кояш нурлары әкрен генә офык артына төшеп күздән югала бара. Ул инде кыш буена яшеллеген җуймаган киң ябалдашлы нарат, сөңгедәй очлы, зур өчпочмакны хәтерләткән чыршы агачлары аша чак кына беленә. Шуңа күрәдер, болай да салкын көн тагын да суына төште. Тып-тын. Кайдадыр, объект эчендәге агачларда, бернидән курыкмыйча тиеннәр сикерешсә дә, тыелган зона тышындагы урман эчендә берәр кыргый җәнлек ашыкмыйча гына узып китсә дә—аларның хәрәкәт итүе Габделнурның сизгер колагына чалынмыйча калмый. Әйе, әнә чәнечкеле тимер чыбык «койма» артында нәрсәдер әкрен генә йөри ахры.

Солдат, игътибар белән карап аны күрмәкче булды, күзләрен шул якка төбәде. Ләкин... җәнлек түгел, ә кеше булып чыкты ул. Бот тиңентен кар ерып, бер адәм әкрен генә Габделнур вышкасына турылап килә иде. Дөрес, ана килеп житкәнче ул әле ике рәт чәнечкеле тимер чыбык аша узарга тиеш. Әмма ләкин сакчының вазифасы—аны үткәрмәү. Анымы, башка бүтәннеме—кем генә килсә-якынлашса да—тоткарлау. Сакчы шуның өчен куелган. Аның хезмәтенең төп бурычы—хәрби объектны саклау.

Габделнур бөтен көченә кычкырып җибәрде.

—Тукта, кем килә!

Аның калын тавышы, урман яңгыратып, еракларга таралды, әйләнә-тирәсендәге һәр агачка барып иреште. Әмма, гәүдәсен тигез тота алмаса да, башына бер колакчыны тырпаеп торган, икенчесе салынып төшкән мескен бүрек, өстенә иске генә кайры тун кигән теге бәндә киез итекле аякларын тирән кардан көч-хәл белән тартып ала-ала болай таба якынлашуын дәвам итте.

Габделнур, инде эшнең уен-муеннан узганын искәртергә теләп, карабинын кулына алды, баягы әмерен тагын да катгыйрак итеп, кискен рәвештә кычкырды.

—Тукта, атам!

Юк, туктамый. Язмышы белән уйный. Үз башына ашкынамы?!

Габделнур аның гәүдә торышыннан—төз тота алмавыннан, чайкалып-чайкалып китүеннән, башы салынып төшүеннән—ул кешенең аек булмавын

аңлады. Чын исерекме, әллә мәтәштерә генәме?

Нинди җитди объект саклавын яхшы белгән солдат, тревога кнопкасына басты, вышканың читенә үк килеп, алгарак авышып, карабинның көпшәсен һавага караттьї да, саклагычтан алып, атып җибәрде.

Урман эчен яңгыратып, әллә кай тарафларга таратып, шартлау авазы яңгырады. Бер агач башыннан кар коелды—кошмы, җәнлекме куркып урын күченде.

Габделнур теге кешедән күзен алмады, аның һәр хәрәкәтен җентекләп күзәтте. Менә билгесез кеше башын күтәрде, үзеннән бер-ике адымда гына унга да, сулга да тезелеп киткән баганаларга, аларга рәт-рәт сузылган чәнечкеле тимер чыбыкларга һәм «койма» эчендәге вышкага карагач, анда мылтыгын аңа төзәп торган солдатны күргәч, айнып киткәндәй булды ахры: борылып артына карады, беравык тын торды. Аннары ул бер аягын кар эченнән суырып алды, әкрен генә гәүдәсен бора башлады.

Габделнурның кисәтүе тагын урман яңгыратты:

—Тукта, атам!

Исерек исерек тә, хәлбуки мондый усал һәм боерулы тавышны ишетеп, кораллы сакчы белән шаярырга ярамаганын, буйсынырга тиешлеген аңлап булса кирәк (бәлки үзе дә кайчандыр армия хезмәтен үткәндер), ир-ат Габделнурга таба борылды һәм катып калды.

Ул арада каравыл бинасы ягыннан солдатларның йөгереп килгәнен абайлап алды Габделнур.

Теге адәм, ялан кулын сузып, ялварулы аваз салды.

—Солдат, җибәр, мин адаштым.

—Урынында тор, атам!—диде Габделнур карабинын аңа төзәгән килеш.

...Әлбәттә, бернинди диверсант та, шпион да булмады ул бәндә. Гап-гади авыл «мужигы», самогонны күбрәк чөмергән дә, ориентирны бутап, саклана торган объект тирәсенә килеп чыккан. Моны частьтагы «особистлар» тиз ачыкладылар.

Икенче көнне рота командиры, солдатлар алдында булып узган хәлне анализлагач, Габделнурны саф каршына чыгарды.

—Рядовой Гаделжанов, постта уяулык күрсәткән өчен сезгә рәхмәт белдерәм!—диде ул.

—Советлар Союзына хезмәт итәм!—дип казарма яңгыратты Габделнур.

Солдатлар арасында бу вакыйгага караш төрлечә булды.

—Нигә һавага аттың?

—Каравыл хезмәте уставы кушканча.

—Юләр, мондый очрак сирәк туры килә. Син башта аңарга ат иде дә, аннары—һавага.

—Ничек инде башта ук аңа атасың? Ул бит—кеше!

—Булса соң? Сиңа отпускы бирерләр иде.

—Ә губага тыгып куйсалар яки төрмәгә утыртсалар?

—Син—сакчы. Сакчы—лицо неприкосновенное. Аның һәр кылган гамәле дөрес.

—Әгәр мин аткач ул үлсә? Ә аның өендә хатыны, балалары бардыр.

Җыелышып, әңгәмә корган солдатларның берсе бик усал кыланды.

—Анысы инде синең кайгың түгел,—диде ул зәһәрен йөзенә чыгарып.— Мин булсам, чәнечкеле тимер чыбыкка ябышканын көтеп торыр идем дә, чүкер идем. Ике дә уйламас идем.

Габделнурның исенә төште: бу бит Сидоров фамилияле солдат, өченче елын хезмәт итә. Аның белән булган хәлне Нурмөхәммәтов сөйләгән иде.

Узган ел, кухняда бәрәңге чистартканда, сүз иярә сүз чыгып, Костоглотов фамилияле солдат: «Мин дуңгыз чәнчергә җәллим, җан иясе бит»,—ди. Ә

Сидоров әйтә: «Мин дуңгыз гына түгел, кешене дә чәнчи алам»,—ди. Юләр башлар: китә бәхәс. Костоглотов әйтә: «Юк, чәнчи алмыйсың!» Сидоров үзенекен такылдый: «Чәнчим!» «Мә алайса, минем күкрәккә када»,—ди таза гәүдәле Костоглотов һәм гимнастерка изүен чишә дә аягүрә калкына. Сидоров та торып баса һәм әле генә бәрәңге әрчегән пычагы белән кизәнә дә... Бөтенесе өнсез кала: Сидоровның пычагы Костоглотовның күкрәгендә тырпаеп тора...

Бәхетенә, Костоглотов тәненә пычак тирән керми. Госпитальдә бераз ятып чыккач, ярасы төзәлә. Эшне дә хәрби прокуратурага җибәрми командование. Чөнки шаһитлар бар: Костоглотов үзе сораган. Сидоров частьта калган.

Габделнур, бу солдатка карагач, моның чыннан да ике дә уйламыйча, иман нуры булмаган күзен дә йоммыйча башта кешегә, аннары гына һавага атачагына инанды. Ләкин ул үзе алай булдыра алмас иде: тәрбиясе, холык-фигыле, кавеме андый түгел. «Нинди генә кешеләр юк бу дөнья йөзендә?! Ярар, син аттың, ди тегенә. Сиңа чираттан тыш ял бирделәр, ди. Отпускыга кайткач, атаң-анаңа, йөргән кызыңа, авылдашларыңа ни диярсең? Кеше үтергән өчен бүләкләделәр, диярсеңме? Юк инде, күрәләтә коралсыз, бер гаепсез кешене үтерү—егетлек түгел».

Солдат тормышында физик көч—иң кирәкле нәрсәләрнең берсе. Ә моңа даими рәвештә күнегүләр ясап кына ирешергә мөмкин. Частьта чаңгы ярышлары еш була икән. Беренче тапкыр Габделнур эстафетада катнашты. Унбер команда иде. Чөнки алар батальоны солдатлары гына түгел, матрослар һәм стройбат егетләре дә килгән. Беренче этапка барасы чаңгычылар урман авызындагы киң аланда бер рәткә тезелеп бастылар да, судья кызыл флагчык болгап команда бирүгә, дәррәү кузгалдылар.

Габделнур җан-фәрманга алга ыргылды һәм чаңгы юлына беренче булып килеп чыкты. Тизлеген арттырганнан арттыра барып ул шуса да шуды, очса да очты. Бераздан, урман эченә кергәч, артына борылып карады. Ләкин беркемне дә күрмәде. «Әллә ялгыштыммы?»—дигән шөбһәле уй башына килде. Юк, юлдан язмаган, әнә борылмада кечкенә кызыл флажоклар ак карга төртеп куелган. Һәм ул, башлык белән җинел спорт костюмы—трико гына кигән ялан куллы солдат, таяклары белән берөзлексез этенеп, алга баруын дәвам итте. Көчле кулларындагы озын таякларның очлы тимерләре карга кадала, фәкать бөҗралары гына аларга җиргә хәтле батып керергә ирек бирми. Аягында ботинка, чаңгылары җинел, майланган, чаж да чож килә—ак карга салынган пар эз буйлап барды да барды. Ун чакрым—якын ара түгел—тирләп чыкты, бермәл тыны кысыла башлады, әмма бераздан янадан ачылып китте, ягъни, ярыш вакытында ерак дистанцияләрдә була торган хәл—"икенче сулыш" барлыкка килде. Спортчы янә күкрәк тутырып сулый башлады. Күпчелек агачы нарат белән чыршыны тәшкил иткән урман ана гүя үзе берөзлексез саф һава өстәп тора иде. Бу тирә кай ягы беләндер Алабуга янындагы, Шишкин картиналарында тасвир кылынган гаҗәеп матур урманнарны хәтерләтә... Дөрес, чаңгы юлы куе чытырманлыкка керми... Бөтен уе ярыш дәрте белән сугарылган, карашы алга төбәлгән булса да, ул инде йөрешен бер ритмга салган һәм лыжня аркылы үтеп киткән көртлек кебек кош-корт, куян ише киек җәнлек эзләрен дә шәйли башлады... Ә артта аны куып килүче спортчы күренмәде...

Шулай итеп ул старт бирелгән урынга беренче булып килеп җитте һәм, эстафетаны тапшыргач, тынычланып, өченче, дүртенче этапка әзерләнеп торучы үз взводы егетләре белән сөйләшә башлады.

—Нишләп берсе дә минем арттан чапмады?

—Ә монда свалка булды,—диде егетләрнең берсе.

—Ничек?

—Синең арттан ыргылган узышчы егылды да, аның өстенә өч солдат, ике матрос барып менде. Ә син очтың. Тегеләр торып, исенә килеп, юл алганчы синнән җилләр исте.

Взводныйның да, рота командирының да күңелләре күтәренке иде. Чөнки калган өч солдат Габделнур алып килгән кадерле минутларны озайтмадылар. Киресенчә, берсе тагын да киметә төште.

Икенче тапкыр, монысында рота солдатлары һәркем үзе өчен чаба иде, Габделнурның үзенә егылу ачысын татырга туры килде.

Монда инде чаңгычылар, ара калдырып, берәм-берәм киттеләр. Дистанция уртасында Габделнур ике солдатны узды, өченчесенә дә:

—Юл!—дип кычкырды.

Кагыйдә буенча ул чаңгычы да, ике эзнең берсен калдырып, читкәрәк чыгарга тиеш иде. Ул шулай эшләде дә. Ләкин артына карап, кем килүен күргәч, таягын Габделнурның аяк арасына тыкты. Егет мәтәлеп барып төште, чаңгысы сынды. Егылса да ул алга киткән теге солдатны танып алды—Нелидов икән.

Ә өченче ярышта аны бер сержант этеп екты. Күрәсең, Нелидов әшнәләреннән берсе булгандыр. Әмма бу юлы Габделнурның чаңгысы исән калды һәм ул финишка үзеннән шактый алда киткән берничә солдатны узып килеп җитте.

Соңыннан шуны белде Габделнур: аны төртеп екккан сержант ротада иң оста чаңгычыларның берсе булган икән. Димәк, яшь солдат—аңа көндәш.

Вак-төяк сүзгә килүләр болардан башка да булгалады. Ләкин аңа карап кына Габделнурның күңеле төшмәде, хезмәткә булган дәрте сүрелмәде. Ул һәр эшен җиренә җиткереп башкарырга тырышты, рота һәм батальонда уза торган чараларда актив катнашты. Моны командирлар да күрми калмаган, әлбәттә. Габделнур ике айлап хезмәт иткәч, аны рота командирына чакырттылар. Ни өчен икәнен әйтүче булмады. Хәер, аңа әйткән дневальный үзе дә берни белмәгәндер. Аңа—кушканнар, ул үтәүче.

Ишек шакып керде. Рота командиры үзе генә түгел иде. Аның янында таза гәүдәле, юан муенлы батальон командиры подполковник Зирюк утыра иде. Яланбаш, куе яшел гимнастеркадан, күкрәгендә орден-медаль планкалары.

Габделнур, аякларын шапылдатып янәшә куйды, тураеп басты, кулын чигәсенә куеп честь бирде.

—Иптәш подполковник, иптәш капитанга мөрәҗәгать итәргә рөхсәтме?

—Мөрәҗәгать итегез.

—Иптәш капитан, рядовой Гаделҗанов сезнең боерык буенча килде.

Комбат елмаеп:

—Капитан, карале, синең бөтен солдатларың да шундый булса?!—дип куйды.—Һич шикләнмичә Кремль полкына, почетлы каравылга җибәрергә була. Утыр.

Соңгы сүзе Габделнурга адресланган булса да, солдат бермәл югалып калды. Аның монарчы батальон командирын болай якыннан күргәне юк иде. Ул—солдат, ә комбат—йөзләгән солдатның «атасы». Плацта сафка тезелгән чакта гына аны күреп була, яисә казарманы тикшереп-карап йөргән минутларында. Ә болай кара-каршы утыру—ул гайре табигый хәл. Ләкин кушканнар икән, димәк, син утырырга тиеш.

Күрәсең, комбатның кулында Габделнурның шәхси карточкасы иде. Ул әкрен генә укый. Калын иреннәрен кыймылдатып, сүзләрне өзек-өзек әйтеп бара.

—Тәк-тәк... Начар түгел... Бара... Монысы да яхшы...—Ул, кыска чәчле башын күтәреп, рота командирына карады.—Минемчә, бар яктан да туры килә. Ничек уйлыйсың, Степан Максимович?

Рота командиры, егерме биш-утыз яшьләрендәге юка гәүдәле капитан, аның сүзен җөпләде.

—Борис Федорович, җибәрергә кирәк,—диде ул.—Менә дигән командир чыгар. Үрнәк солдат. Бернинди замечаниесе юк. Яхшы ата, спорт белән шөгыльләнә—икенче разрядлы чаңгычы. Сафта йөрүе—карап туйгысыз.

Капитан сөйләгәндә комбат зур башын әледән-әле селкеп, канәгать икәнен белдереп утырды. Аннан үзе сүз алды.

—Якташ,—диде ул Габделнурга карап елмаеп.—Мин—Башкириядән. Әйе, анда да украиннар бар. Инде күптән ул яклардан чыгып китүемә... Сине кабат Кронштадтка, кече командирлар мәктәбенә җибәрергә исәп. Ничек уйлыйсың?

Солдат ничек уйласын инде? Аның өчен «батя» уйлый, рота, взвод, отделение командирлары һәм, ниһаять, рота старшинасы бар. Солдат күп уйламаска тиеш: башың авыртмас.

—Белмим,—диде Габделнур чын күңелдән.—Әгәр булдыра алсам...

—Булдырырсың,—диде подполковник солдатның ихлас җавабыннан разый булып һәм шадраклы тулы йөзе тагын җәелеп китте.—Анда дүрт-биш классы Балтик буе егетләрен җибәреп булмый бит инде.

—Димәк, риза?

Рота командирының сүзенә Габделнур икеле-микелесез, төгәл җавап бирде.

—Әйе.

—Алты айдан кабат үзебезнең частька кайтырсың,—диде батальон командиры.—Аннан соң күз күрер. Һәрхәлдә, синнән яхшы сержант чыгачагына шигем юк. Бар, әзерлән.

—Калганын соныннан әйтермен,—диде рота командиры.

Габделнур торып басты. Бөтен шартын китереп честь бирде.

—Китәргә рөхсәт итегез?

—Барыгыз.

Шулай итеп, Габделнурга инде ияләнә башлаган җиреннән кубып, вакытлыча тагын иске урынга күчәргә туры килде.

## VI

Үзе булмаган кеше хәрби хезмәтне берьяклырак кына күз алдына китерергә мөмкин: солдат яки матрос көне буе дәрестә утыра, ату белән шөгыльләнә, сафта йөри, фәкать кич белән генә, эт булып арып-талып, йокларга ята. Ә кайберәүләрнең фикер сөреше киресенчәдер: солдат көне-төне йоклый, ә хезмәте—бара. Юк шул, солдат хезмәтенең дә үз романтикасы, шатлык-сөенечләре, мәзәк хәлләре була, авырлыклары—анысы да җитәрлек.

Дөрес, солдатның һәр минуты булмаса да, һәр сәгате билгеле бер тәртипкә буйсына: йокыдан тору, физзарядка, иртәнге аш, дәресләр, көндезге аш, эш яки тагын дәрес, кичке аш, буш вакыт һәм, ниһаять, отбой. Ләкин, шуның өстенә, солдат әле кино да карый, атна саен мунчага да йөри, экскурсияләргә дә бара, кайчагында урамда патруль вазифасын да башкара, «ирекка» дә чыга.

Беренче мәртәбә чагыштырмача ирекле рәвештә Кронштадт урамнарында йөрү Габделнур өчен кызык һәм истәлекле булып калды.

Аларны комендатурада озын буйлы (ике метр бардыр) капитан каршылады. Ул шәһәр комендантының урынбасары икән. Морякларныкы шикелле кара киемнән, ләкин погоннары кызыл сызыклы, җиңнәрендә дә алтын тасмалар юк. Тиешенчә инструктаж биреп, патруль булып йөргәндә ни-нәрсәгә игътибар итәргә тиешлекләрен аңлаткач, ул солдатларны ияртеп чыгып китте.

Әле кояш баемаган, шулай да кызыл шар әкрен-әкрен дингез артына

шуышып бара. Анның алсу нурлары еракта гы хәрби корабларның мачталарына, челтәрле радарларына, крейсерның колач җитмәстәй юан, озын, өчәр-өчәр куелган туп көпшәләренә, су асты көймәләренең сырты гына күренеп торган кит түшкәседәй алагаем зур корпусларына һәм алар өстендә калкып торган рубкаларына, кечерәк катерларның торпеда аппаратларына—салкын тимерләргә, шул кораблар эчендә көнне төнгә ялгап, айлар-еллар буена сугышчан вахтада торучы матрос-офицерларга җылы биреп калырга теләгәндәй яктылык тарата. Фин култыгының коңгырт-кара су өстен алсуландыра, тыныч көн булса да сизелер-сизелмәс хәрәкәттә булган вак дулкыннарның ак сыртларын кызарта, янәшәдәге бакчаның—Петр паркының—юкә агачларын иркәли, яшел яфраклар арасыннан каралҗым кәүсәләренә хәтле үтеп керә.

Җәйге бакчада халык берән-сәрән генә әле. Матрослар да, кыз-кыркын да сирәк. Юкә генә түгел, өрәңге, каен агачлары арасында тары ярмасы хәтле генә вак кызгылт таш-ком түшәлгән сукмаклар салынган. Мондый кызгылт сукмакны Габделнурның беренче күрүе иде. Ул, иелеп, бер-ике таш-комны кулына алудан үзен чак кына тыеп калды. Бакча эче җиләс, һавасы саф, өзлексез сандугачлар сайрый, күгәрченнәр йөренә. Өстә сирәк кенә акчарлаклар күренә—чыелдап очалар. Еракта, артта да (су өстендәдер) тавышлары ишетелә.

Егет тукталып калды. Чөнки бакча уртасында почмаклары яфраксыман сырлы чәчәкле орнаментлар белән бизәлгән кызгылт гранит постаментта шәһәргә нигез салучы Петр Беренче басып тора иде. Биек постамент берсеннән икенчесенә тимер чылбырлар сузылган кыска кара баганалар белән (алар җир өстеннән ярты метр чамасы гына калкып торалар, тышка таба авышлар) уратып алынган.

Патшаның сыны буенча салынып төшкән уң кулында камчы, ә сулы белән бөеренә таянган, кыяфәте горур, хәтта тәкәбберрәк. Хәер, алай булса да гаеп түгел, урыс дәүләтен дөньяга таныту, көчен ныгыту өчен байтак эш майтарган бит ул. Әнә түшендә бүрек хәтле орден. Башына да кимәгән, чәчләре бөдрәләнеп тора, мыегы нәкъ рәсемнәрдәгечә, тезенә хәтле җиткән өс киеменнән, аягында ботфорт. Кыскасы, ике метрга якын буйлы, киң җилкәле чын баһадир һәм үз иленең хуҗасы! Юкка гынамы аны Алла урынына күрәләр: кинофильмнар төшерелгән, китаплар язылган, рәсемнәр ясалган.

Хәер, үзе дә бик булдыклы, куркусыз кеше булган. Гангут янында шведларның флотын җиңгәч, аңа вице-адмирал дәрәҗәсе бирелә бит. Постаментта дүрт юллык язу: "Петру Перьвому Основателю Кронштадта 1841 года". Габделнур, язуны укыгач: "Күрәсең, ул заманда кагыйдәсе шулай булгандыр",—дип уйлады. Чөнки Первому дигән сүздә нечкәлек билгесе бар. Елы да, һәйкәл куелу елыдыр, чөнки Кронштадтка ул мен җиде йөз дүртенче елны нигез сала, Петербургны саклау өчен кирәк була.

Габделнур патрульгә чыккан иптәшләреннән аерылып калса да, әле һаман һәйкәлдән, аның тирәсеннән күзен алалмый иде. Кайчан килә, кайчан күрә әле ул моны тагын. Әнә һәйкәл әйләнәсенә куелган бетон-агач утыргычларда ике-өч ир-ат гәп кора. Өлкән яшьтәге бу агайлар элекке дингез офицерларыдыр инде—киемнәре ярым хәрби. Алар әлбәттә монда көн саен чыга алалар. Биек, шакмаклы баганаларны, алар өстендәге ваза шикелле露 тоткалы кара савытларны, әлегеләреннән дә биегрәк, шәм шикелле төз баганалардагы борынгы фонарьларны алар көн саен күзәтә бит. Һәйкәлгә таба сузылган, як-ягында шарлы кыска тимер торбалар утыртылган киң сукмакта көненә ничәмә-ничә кешенең аяк эзе каладыр...

—Гаделжанов, калма!—дип кычкырган тавышка Габделнур айнып киткәндәй булды, ерак гасырлардан бүгенге көненә кайтты һәм, йөгереп, патрульне куып җитте.

Һәйкәл яныннан китеп, парктан башта киң урамга, аннан алагаем зур,

биек өч-дүрт күтәрү краны булган ДОКка килеп чыктылар. Монысы да "Петровский" дип атала, патшаның үзе тарафыннан проектланган һәм аның указы нигезендә хәрби корабларны ремонтлау өчен мең җиде йөз унтугыз—мең җиде йөз илле икенче елларда корылган. Ана пирс ягыннан канал ерганнар һәм корабларны кертү-чыгару өчен култыктан су җибәргәннәр. Әле хәзер дә бер кораб каналда тора. Ул кергәч, суны шлюз—тимер капка—буып куйган. Патруль ДОК яныннан тар гына кыска күпердән үтте. Күпернең аргы башында ак төстәге, биш тәрәзәле маяк, түбәсе кызылга буялган.

Аннары, юлга таш урынына чуен плитә-пластинкалар җәелгән урамны узып үттеләр. Габделнурның дагалы итеге чык-чык иткән һәр адымын санап калды ул урам. Сулга борылып, янә бер киң урамга чыктылар.

Урамның каршы ягында, тротуардан, ашыга-ашыга бер матрос бара иде.

Капитан көр тавыш белән ана дәште.

—Матрос, кил монда!—диде ул сул кулын күтәреп һәм имән бармагын ике-өч тапкыр үзенә таба бөгеп.

Матрос туктады, борылды, йөзенә гаҗәпләнү галәмәте чыгарып, уң кулының имән бармагы белән күкрәгенә төртеп күрсәтте. Минме, янәсе.

—Әйе, әйе, син!—диде капитан янә кулы белән ымлап.

Йөз-кыяфәтенә караганда матросның киеме, авыл карчыклары әйтмешли, "чын ясау"—чиста, үтүкләнгән, үзенә таманлап киселгән-тегелгән, беренче генә елын хезмәт итми иде булса кирәк. Башында кара тасмалары җилкәсенә төшкән ак түбәле бескозырка, зәңгәр якалы ак форменка эченнән зәңгәр-ак сызыклы тельняшкасы күренеп тора, клеш балаклы кара чалбарын якорь рәсеме төшкән ялтыравык аеллы кара каеш белән буган, аягында кара ботинка. Бер яктан икенче якка авышыбрак атлап килде дә бик килешле генә итеп честь бирде. Киемендә дә, йөрешендә дә тел-теш тидерерлек нәрсә сизелми иде. "Ник дәште икән моны капитан?"—дип уйлады Габделнур.

—Иптәш капитан...

—Увольнительный?

Матрос кесәсеннән кәгазь алып күрсәтте. Капитан аны игътибар белән укып чыкты.

—Кая барыш?

—Таныш кыз янына.

—Шешәнне калдыр.

Матросның гаҗәпләнүдән күзләре маңгаена менде.

—Нинди шешә, иптәш капитан?

—Ярар, ярар, матрос, бир шешәнне.

Кемнең инде үзе теләп кулга кергән "мал"ны бирәсе килсен. Бигрәк тә ул күренеп тормаса.

Габделнур янындагы хезмәттәшләре белән карашып алды. Чөнки матросның кулында бернәрсә дә юк, кесәләре дә тырпаеп тормый. Ләкин озак еллар комендатурада хезмәт иткән капитан Катерина (аның фамилиясе шулай иде) үзен алдарга ирек бирмәс: әллә каян сизеп-күреп тора кемдә нәрсә барын. Ул, иелеп, матрос чалбарының киң балагын тиздән түбән чөметеп кенә күтәрде. Беренче мәртәбә патруль булып чыккан Габделнурның күзе шарланды: бер шешә аракы матросның аягына бәйләп куелган иде. Күрәсең, капитан аны йөрешеннән сизеп алган. Матроска, иелеп, аяк балтырындагы шешәне ычкындырып, офицерга бирүдән бүтән чара калмады...

Бераз баргач, урамда тагын бер матросны, дөресрәге, погонында аркылы өч тар тасмалы беренче статья старшинаны, туктатты капитан. Бу юлы да "бер гаепсез" морякның аракысын чыгарттырды. Анысы каеш астына кыстырылган (корсак турысында) булып чыкты.

Комендатурага әйләнеп кайтканда дүрт немец матросы очрады. Эш шунда,

Кронштадтта, ДОКта, ике ГДР эсминцы ремонтта икән. Алар турында хәрби частьларның барысында да беләләр һәм һәрбер солдат-матрос кисәтеп куелган: алар белән аралашмаска, конфликтка кермәскә. Ләкин безнең солдат кайчагында киресен эшли бит ул!

Габделнур ике тапкыр алар белән урамда очрашты: немецләр дә сафта, безнекеләр дә. Алар белән "бәрелешү"дән сак булырга дип әйтелгән булса да, безнекеләр:

—Гитлер капут!—дип каршыладылар.—Хенде хох!

Тегеләр дә җавапсыз калмады.

—Руссиш швайн! Саляга!—дип кычкырдылар.

Сафлар шулай бер-беренә "ягымлы" сүзләр әйтешеп "дусларча" аерылыштылар.

Ә безнең бер матрос, «ирекка» чыккач, урамда очраган ике немец матросының берсен изүеннән эләктереп:

—Ни өчен минем әтине үтердегез?!—дип тегенең ипи шүрлегенә менеп төшкән.

Моңа да һич аптырарлык түгел. Чөнки Габделнурлар белән хезмәт итүчеләрнең байтагының аталары фашистларга каршы сугышта һәлак булган. Ятим үскән малайларның, немец милләте вәкилләрен күрүгә (аның кем булуына карамастан) күкрәгендә нәфрәт уты дөрли башлый иде.

Аннары, аларга бигүк ышанып та җитмиләр иде бугай. Чөнки Габделнурларның замполиты солдатларны кат-кат кисәтеп кенә калмады.

—Ул корабтагы кайбер офицерларның безнең хәрби объектлар белән кызыксыну очраклары билгеле,—диде.—Алар белән танышкан хатын-кызлар да безнең чекистларның күзәтүе астында.

Менә шулай, урысларның «дружба—дружбой, а табачок—врозь», дигәне кебек, немец егетләре белән брудершафтка эчү-үбешү юк.

...Немец матрослары дүртәү иде. Икесенең кулында ятьмә сумка, ә анда сыра шешәләре һәм кәгазьгә төрелгән әйберләр-кабымлык булса кирәк.

Капитан Катерина матросларны туктатты һәм чип-чиста немец телендә алар белән сөйләшә башлады. Габделнур авылда җидееллык мәктәптә немец телен өйрәнгән иде. Аларны сугыш вакытында ничәдер ел әсирлектә булган бер абый укытты. Ул китаптан уку гына түгел, ә сөйләшүен дә чатнатып "нимеччә" сөйләшә иде. Бер-ике елда шактый нәрсә өйрәнделәр укучылар аңардан.

Менә шул, техникумда чит тел кермәгәч, Габделнурның бар белгәне исеннән чыгып очкан инде. Ә капитан Катерина, саф немец телендә тегеләр белән сөйләшеп, аларны комендатурага алып керде, кораб номерларын язып алды да, ятьмәләрен кире биреп, чыгарып җибәрде. Иң гаҗәбе шул булды патрульгә чыккан егетләргә: Катерина сыраларын алып калмады. Ә безнең матросларны аракыларыннан мәхрүм итте.

Икенче вакыт, Габделнур, «ирекка» чыккач, үзе чак кына "янмады". Алар өчәү киттеләр: озын, таза гәүдәле солдат—Новгородтан, ә икенчесе—ябыграк чырайлысы—Псков өлкәсеннән чакырылган егет.

Өч солдат иң беренче нәүбәттә нишли инде, әлбәттә, кесәсендә "рәте" булса, кибеткә керә. Һәм, җыештырып, шулай иттеләр дә.

Флотская урамыннан бераз баргач, сулга, Карл Маркс урамына борылдылар. Бихисап колонналы озын йорт—үзе бер кварталны биләп торучы Гостиный дворның—сәүдәгәрләр курасының—беренче катына сугылып чыктылар. Янәшәдәге бакча эчендә генә хәл итмәкчеләр иде дә, шикләнделәр, чөнки урамда ун кеше очраса, аның сигезе хәрби бит. Гражданская урамындагы өч катлы йортларның (ә монда алар барысы да тәбәнәк—ике-өч-дүрт этажлы гына) берсенә юнәлделәр. Подъездга кереп, иң беренче фатирның

кыңгыравына бастылар. Егетләр кырыйдарак, ә Габделнур ишек турында иде.

Уртача буйлы, илле яшьләр тирәсендәге, ак чәчле ир кеше ишек ачты. Ул спорт костюмы чалбарыннан һәм майкачан иде.

—Исәнмесез.

Хужа аларның сәламен алды һәм:

—Ни йомыш?—дип сорады.

Габделнур читенсенеп кенә:

—Стакан бирмәссез микән?—диде.

Хужа елмаеп куйды.

—Була.—Аннан, нидер исенә төшкәндәй, кире борылды.—Баскычта гына эчәсезмени? Керегез өйгә. Бу йортта офицерлар күп. Күрүләре ихтимал.

Солдатлар бер-беренә карашып алдылар. Берсе дә фатирга аяк басарга кыймый иде. Әмма офицерлар күзенә чалынмавың да хәерле. Новгород егете тәвәккәлләде.

—Мөмкин.

Коридорга кергәч тә, ишек катында ук өчесе дә өнсез калдылар: кием элгечендә ике йолдызлы погоннары ялтырап торган кара китель эленеп тора иде.

Гомерендә тотлыгуның нәрсә икәнен белмәгән Габделнур:

—И-иптәш икенче ранг капитаны,—дип көчкә телен әйләндерде,—гафу итегез зинһар...

Хужа, елмаеп, аңа аркаларын күрсәтә башлаган солдатларга дәште.

—Мин запаста инде, курыкмагыз.

Шуннан соң гына егетләрнең эченә җылы керде. Тулы гәүдәле, әмма хәрәкәтчән хужа, аларны кухняга дәшеп, стаканнар куйды, кабарга әзерләде. Габделнур аңа үзенә дә стакан алырга кушты.

Хужа:

—За тех, кто в море!—дип бушаткач кына егетләр стаканнарын күтәрделәр.

—Сезнең исәнлеккә, иптәш икенче ранг капитаны,—диде Габделнур.

Хужа, күрәсең, аның сөйләмендә акцент барын сизгән ахры.

—Син кайсы милләттән?—дип сорады.—Татар түгелме?

—Әйе.

—Мин дә татар бит!—диде хужа һәм болай да дустанә йөзе тагын да яктырып китте.

...Алар ярты сәгать чамасы утырдылар бу кунакчыл җыйнак кына өйдә. Хуҗаның аларны, бигрәк тә Габделнурны, җибәрәсе килмәгән иде. Чөнки ерак бабаларының туган якларыннан солдатка алынган кеше белән бер сөйләшү—үзе бер гомер иде аның өчен.

Ул хәрби-диңгез училищесын тәмамлаган, су асты көймәсендә хезмәт иткән, сугышта катнашкан, хәзер ялда икән. Гаиләсе дә булган, ләкин сугыш вакытында алар йортына бомба төшеп, хатыны белән баласы һәм әнисе һәлак булганнар.

Офицер укымышлы кеше иде. Киштәләре китап белән тулган. Ул, икенче очрашкач, солдатларга Ленинградның һәм Кронштадтның төзелү тарихы, Петр Беренче, Хәрби Диңгез флоты турында бик күп нәрсәләр әйтте. Үзе татар булгач, аны күбрәк бу якларда яшәгән милләттәшләренең язмышы да кызыксындыра икән.

—Петербургны төзегәндә безнең бабайлар да нык тырышканнар, юрталарда, салкын землянкаларда ачлы-туклы яшәгәннәр, күбесенең сөякләре сазлыкка батып калган... Шәһәр кеше сөякләре өстенә корылган, имән субайларда гына тормый... Әле 1710 елда ук Казаннан Россия флотына биш кораб төзеп җибәргәннәр. Берсенә шәһәр исеме бирелгән була...

Ленинградта татарлар шактый күп икән, ә Кронштадтта—азрак. Нигездә, дингез офицерлары һәм аларның хатыннары икән.

—Элек Кронштадтта безнең халык флотны азык-төлек, кирәк-ярак белән тәэмин итүдә катнашкан, сәүдәгәрләр инде. Владимир урамы чатында Татар йорты да булган. Хәзер дә граждански халык арасында татарлар бар,—диде ул.—Мин күпчелек үз ишләрем белән аралашам. Ә флотта татар егетләре элек-электән намуслы хезмәт иткәннәр, хәтта адмираллар да бар. Патша Россиясендә үк адмирал булган бер татар турында беләм...

Офицерның бүлмәсендә баян күреп, Габделнур аны сорап алды, уйнады. Икенче ранг капитаны өчен бу аерата зур шатлык иде.

—Рәхмәт, энекәш!—диде ул сөенеп.—Мин үзем эч пошканда гына тоткалыйм. Уйнавым да—ташка үлчим, үзем өчен генә. Шулай да—бер юаныч. Татар көйләрен ишеттергәнең өчен аеруча рәхмәт.

Бераз уйланып утыргач, ул көрсенеп куйды.

—Мин ана телен дә бик белмим, фамилиям генә калган. Чөнки минем ерак бабайны унбер яшеннән, ата-анасыннан тартып алып, Петр Беренче мәҗбүри рәвештә флотка китерткән, юнга итеп. Аның оныклары тырыша-тырмаша офицер дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр. Минем әти дә өченче ранг капитаны иде. Сугышта һәлак булды. Зиратта аларның су асты көймәсе экипажы тулысы белән... Барып чыксаң, күрерсең әле. Анда сугыштан соң баткан экипажларга да кабер ташлары куелган...

...Сонрак Габделнур чыннан да аларны күрде: бер кабер ташына дистәләгән фамилия язылган. Төрле милләтләрнең газиз уллары ташка уелган. Кемнәрнеңдер кадерле балаларыннан, баһадирларга тиң асыл егетләрдән фәкать шул язулар гына калган. Чөнки ул морякларның күбесе кайдадыр дингез төбендә, корыч табутлар эчендә яталар булыр. Бу ташлар—христиан зиратында. Моннан тыш шәһәр читендә мөселман һәм лютеран каберлеге дә бар икән әле.

Офицер белән саубуллашып, урамга чыккач, егетләр Якорь мәйданына таба атладылар.

Кызгылт гранит ташта (ә ул галәмәт зур ташны бөтен килеш китергәннәр) сакаллы бер карт басып тора. Сул кулын алга сузган, уңы шинель кесәсендә, башында фуражка. Кызгылт таш өстенә астан кара төстәге дәһшәтле дингез дулкыннары ургый, менә-менә аны юып төшерерләр төсле. Ләкин курку белмәс дингезче аларга һич игътибар итмичә горур кыяфәттә басып тора. Һәйкәлнең һәр дүрт почмагында да чылбырлар белән үзара тоташкан якорьлар, алар хәтта икешәр. Әйләнә-тирәсен чәчәкләр бизи, газонда яшел чирәм үсә, читтәрәк шакмаклы таш түшәлгән. Һәйкәлдә язу: “Адмиралу Степану Осиповичу Макарову”. Астарак ташның каян, кайчан һәм ни өчен китерелүе, һәйкәлнең Император Николай Икенче катнашында ачылган икәне дә (1913 елның 24 июле) язылган. Ләкин Габделнурның иң нык исендә калганы һәм соңыннан күп мәртәбәләр уйланырга мәҗбүр иткәне менә бу язу булды: “ПОМНИ ВОЙНУ.”. Куштырнаклар элек шулай язылган, күрәсең, баш хәреф тә юк, ноктасы квадрат рәвешендә. Рус-япон сугышы каһарманы, күпне күргән адмирал һәрчак сугышны истә тотарга кушкан икән, димәк, бу тикмәгә түгел...

—Кечкенә генә шәһәр,—дип иптәшләренә мөрәҗәгать итте Габделнур,—ә саный китсәң, Макаровтан башка да бик күп мәшһүр исемнәр монда үзләренең эзен калдырган: Белинсгаузен һәм Крузенштейн, Даль һәм Римский-Корсаков, Попов, Николай Гумилев, Айвазовский...

## VII

Солдат-матрос арасында “байка” дип йөртелә торган гыйбарә бар. Ул кеше ышанмастай хәлләр, вакыйгаларга корылган була. Ләкин кайчагында хәрби

хезмәттән кайткан егетләр сөйләгән бу "байка"лар чын дөреслеккә дә туры килә торгандыр. Шулай да, әйтик, Габделнур «мин Оборона министрын күрдем», дип сөйләсә, ышанучы сирәк булыр. Фәкать үзе солдат шулпасы эчмәгәннәр генә авыз ачып тыңлап торыр. Ә аны үз башыннан үткәргәннәрнең берсе, ну, егет, шыттырасың да инде, дияр, ә икенчесе, кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, дияр, өченчесе исә, аны ярты юлда ук бүлеп, алдакчы, дигән ярлык тагарга да күп сорамас. Чөнки солдат кайда да, министр кайда?! Солдат җәһәннәм астындагы бер казармада, ә министр Мәскәү Кремлендә утыра. Ләкин, ни хикмәт, министр да гел үз кабинетында гына утырмый икән шул!

Икенче мәртәбә патруль булып чыккан көн иде. Әлбәттә, министр киләсе, никадәр яшерен гамәл булса да, хәрби частьләрдә сизелми калмый. Андый дәрәҗәле кеше түгел, полк яки батальонга дивизия командиры киләсе булса да бөтен җир чистартыла-тазартыла, солдатның киеме, кыяфәте кат-кат тикшерелә, казармада үрнәк тәртип урнаштырыла, плац һәм сукмаклар себерелә. Кыскасы, карт солдатлар әйтмешли, саргая башлаган үләннәрне дә яшелгә буяткан салдафон-командирлар була.

Шуңа күрә, патрульгә билгеләнгәнче үк, Габделнур Оборона министры киләсен белә иде. Аңлашылса кирәк, аның белән Хәрби-Диңгез флоты командующие да булачак.

Патрульнең үз вазифасы бар: урамнардагы тәртипне (хәрбиләргә кагылышлысын) күзәтү, солдат-матросның төс-кыяфәтен, киемен тикшерү һәм башкалар.

Бүген кояшлы, җылы көн. Яр буенда гадәттәгечә җиләсрәк. Габделнур бу тирәләрдә элекке чыгуында да булган иде инде. Ул чакта капитан Катерина аларны туктатып тормыйча, ары алып киткән иде. Бүген нишләптер пирс тирәсеннән ерак китми, әледән-әле су буена караштыра. Ниһаять, ул адымын акрынайтты, туктады.

Усть-Рогатка пирсында "Киров" крейсеры, эсминецлар, су асты көймәләренә каршы көрәшүче кече һәм зур кораблар, мина тральщиклары, торпеда катерлары һәм су асты көймәләре генә түгел, алагаем зур крейсердан да ике мәртәбә озынрак һәм биегрәк "Юрий Долгорукий" атлы кит аулау флотилиясе дә тора иде. Зифа буйлы хәрби кораблар арасына бу котсыз зур граждански кораб, кем әйтмешли, күн итекләр рәтенә килеп эләккән кирза кебек, ни өчен килеп елышты икән? Күрәсең, бүтән җирдә бу гигант туктарлык урын булмагандыр.

Пирсның бу ягында, кораблардан ындарак, бер катлы озын кызыл бина— Петр Беренче заманыннан бирле сакланып калган "Голланд кухнялары". Ул ярлары гранит ташлар белән ныгытылган "Итальян буасы" белән янәшә. Буаның уртасында өскә таба су сиптереп торучы фонтан. Гомумән, монда чит ил сүзләре еш кулланыла, чит җирләр белән бәйле корылмалар шактый. Буадан ерак түгел, агачларга күмелеп бер бина утыра—аны "Итальян сарае" дип йөртәләр. Капитан Катеринадан Габделнур тагын бер сүз ишетте— футшток. Безнең ил территориясендәге биеклекләр һәм тирәнлекләр Кронштадт футштогындагы нульдән исәпләнә икән.

Әлбәттә, авылына кайткач, Габделнур, малайларның күзен кызыктырып, менә бу—министр белән күрешкән кул, шул көннән соң бер атна буена юмадым, дип тә лаф ора ала. Ничек дисәң дә була, ни әйтсәң дә ышанулары ихтимал. Ләкин ул һич тә алай әйтә алмас иде, чөнки чынбарлык бүтәнчәрәк.

Патрульдәге солдатлар министр Малиновскийны да, флот Башкомандующие Горшковны да ерактан гына, алар ап-ак катердан төшкәндә генә күреп калдылар.

Капитан Катерина, егетләргә карап:

—Бу мизгелне хәтерегездә саклагыз: сез тере Малиновскийны күрдегез,—диде.—Дүрт сугышны—Беренче Бөтендөнья, Гражданнар, Испания һәм Бөек Ватан сугышларын үз башыннан кичергән каһарман ул.

Азмы-күпме газета караштырып барган, телевизор караган кеше буларак, Габделнур аны шундук таныды. Чөнки Родион Яковлевич Советлар Союзы Маршалы булу өстенә, ике тапкыр Советлар Союзы Каһарманы да иде. Сугыш вакытында үсеп чыккан полководецларның берсе, иң тәҗрибәле, иң күренекле маршаллардан санала.

Безнең татар егетләре турында бик күп җылы сүзләр әйткән кеше. "Мин, карт солдат, сугышта татар сугышчыларын һәм командирларын күп күрдем. Һәм аларның сугыштагы түземлегенә, корычтай нык ихтыярына соклана идем",—дигән ул. Габделнур, шул сүзләр хәтеренә килгәч, аның үзен дә туган авылындагы бер абзыйга охшатты: битләре тулышып тора, яңаклары киңчә, калынча кашлар астында кысыграк күзләр, тыныч холыклы, мөлаем һәм хәтта ки ягымлы дип әйтерлек караш. Егерме яшьлек солдат аның рәсми кәгазьләрдә поляк дип йөртелсә дә, асылда төрки кавемнән булган караим халкы вәкиле икәнен каян белсен?! Аның йөзендә күпчелек хәрби башлыкларга хас кырыслык та, кискенлек тә чагылмый. Күрәсең, тәвәккәллек, уйлап эш итү, ихтыяр көче, полководец осталыгы, рухи ныклык кебек асыл сыйфатлары бик нык эчкә яшеренгән. Алар фәкать кирәк чакта гына тышка бәреп чыгалардыр. Менә шундый иде ул батыр ир-егетләребезне зурлаган маршал! Хәер, безнең асыл егетләргә-каһарманнарга Жуков, Конев, Рокоссовский кебек бөек полководецлар да сокланмыйча калмаганнар. Конев хәтта: "Татар егетләре арысланнар кебек сугышты",—ди. Әйтерсең лә Тукай сүзләрен кабатлый: "Без сугышта арысланнан көчлебез".

Малиновский белән янәшә Советлар Союзы Флоты адмиралы Горшков атлый. Сергей Георгиевич күзлекле, таза гәүдәле, уртача буйлы, ак китель һәм алтын кокардалы фуражка кигән. Анысы да сугыш вакытында күп батырлыклар күрсәткән командир, кыю диңгезче.

Ә менә алар артында, элеккечә итеп әйткәндә, свита составында бик яшь—утыз-утыз бишләр тирәсендәрәк—адмираллар һәм генераллар күреп, Габделнур шаккатты.

Ул ирексездән:

—Иптәш капитан, ә каян бу яшь генераллар һәм адмираллар?—дип сорады.

Капитан Катерина бер генә секундка, әйтергәме-юкмы, дип икеләнеп торды. Аннары, егетнең кызыксынуына һәм күзәтүчәнлегенә күңеле булып, үзенең шул сорауга җавап бирә алуына горурланып:

—Алар Корея сугышын үткән егетләрдер!—диде.

Кистереп әйтмәгәнлектән, аның тавышында бераз серлелек тә акланды.

Яңадан сүз озайтылмады. Анысын инде Габделнур үзе дә белә: илленче елларда аның туган авылы өстеннән бик еш кына унар-унбишәр самолет берьюлы көнчыгыш тарафка очып үтә иде. Аларның кай якка баруын кунакка кайткан бер офицер әйтте. Соныннан, техникумда укыганда да, политзанятиеләрдә дә ул сугышның сабаклары турында сүз күп булды. Күрәсең, батырлык кылып, исән калган офицерлар хәрби хезмәт баскычы буенча тиз күтәрелгәннәрдер. Моны гаеп итеп булмый. Бу—гаҗәп тә түгел. Офицер булырга хыялланган егет үзенең ни-нәрсәгә барганын яхшы аңлый. Аңламаса, училище курсантларына моны яхшы төшендерәләр: син—гаскәри, илне сакларга, кирәксә гомереңне дә җәлләмәскә тиеш, исән калсаң—үсәсең, лампаслы чалбар да киярсең. Тик аның өчен намус белән хезмәт ит, кирәк чакта яу кырында яки җай чыкканда батырлык күрсәт! Тора-бара бу офицерның канына сеңә, яшәеш рәвешенә әйләнә. Әллә кайдагы чит-ят

жирләргә дә озаталар аларны. Күбесе ирекле булып та бара. Чөнки ул гомере буе сугышырга өйрәнә, шуна әзерләнә...

Тыныч тормышта да тиз үскән офицерлар очрый. Кичә, Ленин бүлмәсендә, күптиражлы хәрби газета укып утырган Габделнур бер язмага игътибар итте. Анда сүз дингезче-офицер турында бара. Ул татар егете күрше Чувашстаннан, өченче ранг капитаны, егерме жиде яшендә. Һәм менә шушы офицерны атом су асты көймәсе командиры итеп билгеләгәннәр. Димәк, ул хезмәт урыны буенча беренче ранг капитаны булачак—адмиралга бер генә адым кала. Була алырмы бу егет адмирал, юкмы, анысы язмыш эше. Ләкин шул яшьтә баллистик ракеталар белән коралланган куәтле субмарина командиры булу—үзе зур дәрәжә, утыз яшьләрендә беренче ранг капитаны булу да зур бәхет. Мона ирешү жинел бирелмидер. Хәзер бит сугыш чоры түгел.

Габделнурның кайдадыр укыганы булды: кырык өченче елны, Сталинград фронтында егерме ике яшьлек дүрт полковник булган. Ул—канлы сугыш барган заман, ә монда... Габделнур дулкынлануын яшерә алмады һәм:

—Иптәш капитан, сез аларны еш күрәсездер инде?—дип сорады.

Ике метрга якын буйлы капитан Катерина ана сәерсенеп, багана башыннан түбән караган сыман, иелебрәк күзләрен текәде. Анын карашы гүя, кара син нинди кызыксынучан икәнсен, дип әйтә иде. Ләкин ул егетнен күзләрендә самимилек чагылышын гына күрде.

Шулай да жавап урынына үзе сорау бирде.

—Нинди мәгънәдә?

Габделнур иннәрен сикертте.

—Шундый зур кешеләрне безнен беренче күрү бит. Шуна сорыйм. Яналан әллә күрәбез, әллә юк. Ә сез...

—Аларны мин дә көн саен күреп тормыйм,—диде капитан елмаеп, солдатнын жавабыннан канәгать калып.—Ә вагракларын күрергә туры килә. Тикшерүләр еш була. Чөнки безгә, дингез державасы буларак, флотны сугышчан әзерлектә тотарга кирәк. Флотны гына түгел, армияны да. Әле патша Александр Өченче үзенен улына, булачак император Николай Икенчегә: "Исендә тот, Ники, Россиянен рус армиясеннән һәм Хәрби Дингез флотыннан башка союзниклары юк",—дигән.

Капитан Катериналын патша сүзләрен китерүе Габделнур өчен сәеррәк янгырады, чөнки бүгенге көндә безнен союзникларыбыз күп бит: Варшава договоры бар, социалистик илләр дистәдән артык, Куба—Американын борын төбендә үк...

Шулай да сонгы вакытта халыкара хәлләр куерып китте. Габделнурларны еш кына тревога белән күтәрәләр дә, төне буе урамда, бөркәвечле машинанын кузовында утырталар...

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ҮЗ ШАГЫЙРЕБЕЗ

Әдип Маликовның беренче шигъри әсәре—«Атаудагы хисләр» поэмасы журналыбызның 1945 ел июль санында дөнья күрә. Редакция исеменнән котлап, сөенечен уртаклашып, Фатих Хөсни хат яза, ерак Сахалинда хезмәт итүче яшь сугышчыга озын-озак гомер һәм иҗат юлы тели ул һәм бу чынга аша: танылган әдипкә быелның августында 85 яшь тула. Иҗатында да гел солдат, ил улы булып калган шагыйрь Әдип Маликовның «Ташчы», «Фәрдәнә», «Чигүле кульяулык» һ. б. поэмалары, күпсанлы шигырьләре, шулай ук «Яшьлек утравым» исемле повесть-истәлеге, илле елдан артык үзе яшәгән Әлмәт, нефтьчеләр тормышы, Әлмәт язучылар даирәсе һәм тормыш иптәше—күренекле шагыйрә Саҗидә Сөләйманова турындагы «Гомер мизгелләре» исемле мемуар әсәре дә «Казан утлары» битләрендә укучыга ирешә.

Әдип ага Маликов—25 китап авторы, «Почет билгесе» ордены кавалеры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 2001 елдан— Әлмәт шәһәренең Мактаулы гражданины.

Олуг юбилее белән котлап, бу санда укучыларыбызга шагыйрьнең төрле елларда язылган шигырьләреннән бер бәйләм тәкъдим итәбез.



Әдип
Маликов

# ГОМЕР ХАТЛАРЫННАН

## Курилдан

Хатың бигрәк озак килә, диеп,
Үпкәләмә,
        әнкәм,
                улыңа.
Изге җирләр илгә кире кайткач,
Озынайды хатлар юлы да.

*Курил атавы, 1945*

* * *

Шулай кушты Ватан,
Сине, Атау,
Азат иттек шактый кичегеп.
Килмешәкләр кул сузмаслык итеп
Бикләп куйдык океан ишеген.

Сугардык без солдат каны белән
Синең һәрбер карыш җиреңне.
Тауларыңа гашыйк булсам да мин,
Төштә күрәм сагынып Иделне.

## Туган илемә

Туган илем,
синнән читтә
Шактый гомер ителгән.
Җиде дәүләт җиле минем
Сыйпап үтте битемнән.

Ят җирләрдә синдәге күк
Җанга рәхәт тапмадым.
Иңгә иягән комыңны да
Төсең итеп сакладым.

* * *

Зәңгәр күзләреңне йомдырдым,
Күкрәгеңә иеп башымны.
Йөрәк яргыч ялгыз шул таңда
Минем күзләр ныграк ачылды.

*1985*

## Миләшләрем-сердәшләрем

*Саҗидәнең туган көненә*

Ике миләш тора баш очында,
Сулар сибеп, назлап үстердем.
Мин аларны
безнең әзләр калган
Урсал тауларыннан күчердем.
Миләшләрем минем,
сердәшләрем,
Яфрак-өлгеләрен койганнар.
Туган көнен котлап шагыйрәнең,
Кызыл кофта киеп куйганнар.

Тәлгәшләре уттай янып тора,
Яна гүя җырчы йөрәге. ...
Ул сизенә,
белеп ята сыман
Минем монда килеп йөргәнне.
«Беләм инде,
Тере кеше түгел,
Тормышыңда бары бер рух мин...»
Очрашамын шигъри дөньяң белән,
Кая гына барып юлыкмыйм.

Бер күрүдә сине үз итләр
Җаның ачык һәм саф булганга.
Шуңадырмы,
бик күп хатлар килә
Шау миләшле синең урамга!
...Урамдагы таныш миләшләр дә
Яфракларын инде койганнар.
Җыйнаулашып сүз куешкан сыман,
Кызыл кофта киеп куйганнар.

*Октябрь, 1987*

## Муса Җәлилгә

Югалганнар,
җиңеп үлгәннәр,
Чын батырлар кебек, җырларың,
Юк, һаман да нурлый, сугара
Җиңеп чыккан илем кырларын.

Батыр йөрәгенә алгансың,
Сыйдыргансың меңнәр кайгысын;
Дошманнарың башын кисәргә
Гүя яңа кылыч сайлыйсың.

## Юлларым

*Җыр*

Яратам матур яз айларын,
Һавада тургай сайравын.
Кырларга чыксам,
шатлыгым арта,—
Илтегез еракка
юлларым, юлларым!

Яратам яңа көн туганын,
Илемнең агым суларын.
Күңелем кош сыман
очардай була,—
Илтегез еракка,
юлларым,
юлларым!

Яратам хисләрнең кайнарын,
Дусларның тугры булганын.
Авыр юл җиңел,
чын дустың булса,—
Илтегез еракка,
юлларым, юлларым!

*1963*

## Хәсән Туфанга

Киртә түгел юлыгызда,
Өермә дә, ташкын да.
Әйләнә җир, Туфан абый,
Сезнең табан астында.

*1961*



Әнәс Хәсәнов

# ЕФӘК ПӘРӘВЕЗ

*ХИКӘЯ*

Кояш сизелерлек түбәнәя барса да анын нурлары жиһанга юмарт жылылык сибә. Талгын гына жил исеп куя, биегрәк үләннәргә кунган нечкә ефәк пәрәвез жепләре тирбәлеп-тирбәлеп ала. Кипкән чирәм өстенә ятып Галимулла абзый зәңгәр күктәге ап-ак болытларга карап башын чайкап куя: дөньяда нинди хозурлык, жылы, рәхәт. Каядыр мәңгелеккә юл тоткан ак болытлар әкрен генә агып, төрле кыяфәтләргә керә. Әле әнә берсе йөгереп баручы чебеш сыман иде... Инде менә икенчесе, бөдрәләнеп, бәрән төсен алды. Ул гади сурәтләр Галимулла абзыйның хәтер төпкеленнән әллә кайчангы өзек-өзек вакыйгаларны, аларга бәйләнешле кешеләрнең йөзләрен калкыта. Алар нәкъ шушы ак болытлар шикелле шуалар да шуалар.

Бүген Галимулла абзыйның кәефе әйбәт. Кып-кызыл булып өлгергән помидорларын жыйды, фанер өсләренә тигезләп тезеп куйды. Уллары, киленнәре килеп алыр, әзерне алып китәргә генә вакытлары табылыр. Помидор түгәленнән калган таякларны да Галимулла абзый, тыгызлап бәйләп, дачасының подвалына кертеп салды. Киләсе елга чаклы алар да ял итсен, быел әнә нихәтле уныш күтәреп тордылар... Әйе...

Помидор таяклары исенә төшкәч, Галимулла абзыйның йөзенә тагын елмаю йөгерде, аларны бакча күршесе Сәйфи бүләк иткән иде. Әйбәт кеше... Яшь булса да бик күп белә—прафиссыр.

—Менә сиңа, Галимулла абзый, чикләвек урманыннан кисеп таяклар алып килдем. Әйдә, рәхәтен күр. Үзләре жинел, үзләре нык, тиз череми дә,—диде прафиссыр.—Менә ничәнче ел инде безгә шундый казыклар «әтличне» хезмәт итә. Мактап бетерерлек түгел.

Автобус тукталышына килгән кешеләр картның коры үлән өстендә күккә карап, хәрәкәтсез ятуыннан шикләнеп, якынрак киләләр дә, елмаеп, рәхәтләнеп, изрәп, буыннарын яздырып ятканын сизеп, аны-моны әйтми, читкәрәк китәләр.

---

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935) — *публицист, шагыйрь һәм прозаик. «Жырым — ал жилкән», «Мин кешеләрне яратам» дигән китаплар, пьеса, повестьлар һәм күпсанлы сценарийлар авторы. Казанда яши.*

Автобус көттерә. Кайтырга җыенган бакчачылар, аяклары аргач, җиргә чүмәшеп, берәр нәрсә җәеп утыру җаен карыйлар. Шикләнәсе юк, җир коры, кипкән үлән шытырдап тора. Читтәрәк инде табигать каршында изге вазыйфаларын үтәгән тук кош-кортлар иренеп кенә үлән арасыннан нидер эзләп йөри. Алар да җәйнең соңгы көннәреннән рәхәт күреп калырга теләгәндәй, ашыкмыйлар, башларын әле бер, әле икенче якка кыегайтып, күкне күзәтәләр.

Ә мең төрле җан иясе—кырмыскалар, чикерткәләр, коңгызлар—мәхлуклар һаман эштә: йөгерәләр, сикерешәләр, аяз, матур, рәхәт көннән файдаланып калыр өчендер инде, бетмәс-төкәнмәс эшләре белән кыштыр-кыштыр киләләр... Әйе, дөнья бу. Исән-саулар өчен шатланып бетмәслек рәхәт дөнья. Ә инде... Ярар ла, бүген көне ул түгел. Авыр уйлар читтә йөреп торсын.

Сәйфигә теге «Дибарау» сортлы помидор орлыгын бирдеме соң әле ул? Шайтан алгыры, юк бугай. Хәтер түгел инде бу, тишек чиләк. Заманында Коръәнне яттан су урынына эчкән кеше... хәзер менә ялгышкалап ала. Юк, ул изге китап сүрәләрен ялгышып укырга ярамый. Монысын Галимулла абзый гөнаһка саный. Коръән инде ул. Ә «Дибарау» орлыгын биргәненбирмәгәнен хәтерләмәү—бусы инде бернигә дә сыймый. Кара син, ә!

Карт җиргә җәйгән иске плащыннан торып утырды. Кәефе кырыла башлады мәллә? Ул тирә-ягына каранып алды. Шәһәргә кайтучы кешеләр шактый җыелган икән. Һәй, бу автобус йөртүчеләрне! Теге колга сыман озын буйлы җилбәзәкләр нишли анда тагын? Сигарет кабын җиргә аттылар түгелме?!. Тирә-юньдә аунап яткан тәмәке төпчекләре, буш шешәләр, конфет кәгазьләре генә житмәгән. Табигатьне һәркем шулай быкырдата башласамы?

Галимулла абзый тезләнеп әкрен генә торды да, теге үсмерләр ташлаган кәгазьне алып, каршыларына китте. Барды, туктады, дәшми-нитми генә чүпне сузды. Тегеләр, картлач әллә җиңеләя башлаганмы диптер, күрәсең, гаҗәпләнеп аңа текәлделәр. Аларның кәгазьне алырга ниятләре юклыгын күргәч, карт аны берсенең җирдәге сумкасы өстенә куйды да кәрҗине янына китте.

—Эй, старик, ты че, очумел? Маклашки захотел?!—дип «колгаларның» берсе картка таба юнәлде.

Тукталышта басып торган хатын-кыз түзмәде:

—Оятлары да юк, олы кеше дип тә тормыйлар.

Кайберләре:

—Үзе дә инде... Сөт тешләре дә төшмәгән нәмәстәләргә бәйләнергә,—дип каршы килде.

Карт кабат урынына барып утырды. Үсмерләрнең берсе, якын ук килеп, тибәргә җыенган иде, аны кемдер кинәт кенә муеныннан кысып, кулын каерып тотып алды.

Икенче «колга»:

—Мужик, мужик, ты че?! Отпусти его!—дип иптәшенә ярдәмгә ашыкты.

—Яшьләр, кисәтеп әйтәм, ачуымны чыгармагыз. Бабай хаклы!

Моны беренче «колганың» кулын каерып тоткан кыска буйлы, юан муенлы, күзләре ут кебек янып торган ир кеше әйтте.

—Бар, энем, бар,—диде ул.—Олы кешеләргә генә түгел, үз ишегезгә дә кул күтәрмәгез. Ахыры начар бетәсен онытмагыз.

Кинәт кенә килеп чыккан бу хәлне көтмәгән егет кисәкләре әтәчләнеп тормадылар. Нык бәдәнле, беләкләре күлмәгенең кыска җиңнәрен кабартып торган ирдән шүрләделәр, бәхәсләшә-бәхәсләшә тукталыштан ук китеп бардылар. Ир кеше Галимулла абзый янына килеп, җиргә утырырга ниятләгән иде, карт плащының читенәрәк шуды да кулы белән дәшми-нитми үз янына урын күрсәтте.

Әйтерсең лә әле генә нәкъ менә шушында берни дә булмаган, беркем дә берни дә күрмәгән, ишетмәгән кебек Галимулла абзый сорап куйды:

—«Дибарау» дигән помидорың бармы? Бик яхшы сорт. Эре түгел. Тип-тигез. Тозларга дисәң—үтергән дә бетергән инде менә.

—Юк ул миндә. «Бычье сердце», ... тагын әллә нинди сортлар бар. «Дибарау» юк.

—Бирермен. Виноград шикелле кат-кат булып үсә. Тәме дә шәп.

—Рәхмәт.

—Киләсе елда шушында очрашырбыз. Помидорларның иң шәпләрен сайлап алып килермен. Орлыкка калдырганнардан. Орлык киптерә беләсеңме?

—Беләм анысы.

—Алайса бик шәп.

Галимулла абзый кызгылт тамырлар белән чуарланган күзләрен ерактагы зәңгәр урманга озак кына текәп торгач:

—Әй, дөньяның хозурлыгы, ә?!—дип куйды.—Менә карап ятам да, бу якты дөньяда кешенең илаһи бөеклегенә сокланам, әйе. Син, энем, кем дип әйтим, гаҗәпләнмә әле... Шул ук вакытта...

—Булат исемле мин...

—Мин Галимулла. Син, Булат энем, гаҗәпләнмә әле... Бу матур дөньяга Ходай Тәгалә кешене сәгадәт тавына менсен дип, рәхәт күрергә яраткан бит. Кара әле бу камиллекне, бу матурлыкны... Кояш кояш урынында... Җир җир урынында. Бар җан иясе яшәр өчен, буын калдырыр өчен мәш килә. Шулар арасында әнә теге корыкуык кыдрачлар да очрап куя, кәнишне.

Галимулла абзый җирәнсу-аксыл сакалын җиңелчә генә кашып ала. Мондый матур көндә, җаның рәхәтләнеп, иркенләп киткән мизгелләрдә сөйләшеп торуны гөнаһ санагандай, кинәт кенә тынып кала, аннары тагын үз уйларын сүтә башлый.

—Этнең теше бар. Мәченең тырнагы. Кошның томшыгы. Һәр җан иясенең дөньяда яшисе килә. Ул яшәү өчен көрәшә... Әйе... Ә кеше? Ходай аңа иң зур, иң көчле корал биргән. Акыл. Акыл! Ә ул аны менә хәзер, менә бүген куллана беләме, ә? Кара инде бу чүплекне! Кеше шушы табигатьнең таҗы бит ул. Нишләп соң кеше дигәнең үзен шушы хозурлыкка каршы куя? Ә?!

Галимулла абзый, онытылып бугай, соңгы уйларын кычкырып ук әйтеп салгач, уянып киткәндәй, янәшәсендә утырган Булатка карап алды.

—Гел болай барса, кеше дигән җан иясе үзен-үзе югалтачак,—диде Булат.— Сез дөрес әйтәсез, Галимулла абзый.

—Ә-ә, юк!—Карт кинәт аңа каршы төште.—Юк. Ходай аны үзен-үзе бетерергә дип яратмаган энем, кем... Булат. Алай булмый ул, юк. Стал быть, кеше яшәргә тиеш. Камилләшә барып... яшәргә тиеш, кәнишне. Хөрмә төше була алмаса да. Әйе. Ярар, Булат энем. «Дибарау»ны утырт син, утырт. Мин сиңа аның менә дигән орлыгын бирермен. Үзе бит һәйбәт шыта, һәйбәт үсә... Әйе...

Автобус озак килми торганга ачулары чыккан кешеләр картның тыныч кына шулай әңгәмә корып, гапләшеп утыруын ишетепмедер, тына төштеләр.

—Менә син, кем... Булат энем, бу көмеш пәрәвезләргә кара әле. Бөтен дөньяны басып, сарыла алган нәрсәгә сарылып, таралып, җилфердәп торалар. Әйе. Бөтен гомерләре... бер-ике көн инде аларның... Әйе. Анда да яңгыр яумаса. Ә төптән уйласаң, ай-һай... Коры, матур көз көннәрендә, ел саен янарып, бөтен дөньяга таралалар. Ел саен. Мәңгелек бит алар.

Кеше дә шулай... мәңгелек. Үзен-үзе тота белсә... Әйе. Эчкечелеккә бирелеп, тәмәке тартып, борчуга сабышып эштән чыкмаса... Борчу да бик бетерә кешене, борчу да. Әнә бит... автобус килмәгәнгә ничек җеннәре чыга. Кая ашыгалар? Ә бер уйлап карасаң, шушы хозурлыкта, рәхәтләнеп саф һава

сулап тик утыр бит инде, югыйсә? Шулаймы, юкмы? Бәхет бит бу.

—Бәхет дип... Бәхет анда гына түгелдер инде ул, абзый...

—Һәй, энем... кем... Булат, мин алай димәдем ләса. Юк, анда гына түгел, кәнишне. Ә менә дөнья куып, яшәүнең рәхәтен татый белмәсәң, аның ни кызыгы бар соң? Саранланып, ишек шыгырдаганнан да төсең качса, эченнән сызып, тирә-юньне, әйләнә-тирәндәге кешеләрне күзең, күңелең күрмәсә, ул инде бәхет түгел, бәхетсезлек, ягъни мәсәлән... Автобус күренмиме соң, халык тынычланыр иде, диюем.

—Юк бит әлегә...

—Ярый, алайса. Тыңласаң, мин сиңа, Булат энем, бер гыйбрәтле хәл сөйлим әле... Бу карт чистый чыршы сагызы булды димәсәң...

—Юк, Галимулла абзый, юк. Син әллә кайсы ягың белән минем әтине искә төшердең бит әле. Ул да шулай җае килгәндә тәфсилләп сөйләшеп утырырга ярата иде. Хәзер мәрхүм инде.

—Ярар, авыр туфрагы җиңел, гүре нурлы булсын. Мин аның шәрифләренә дога кылып алыйм әле. Атаңның исеме ничек диден?

—Габделбәр иде.

—Хуш...

Карт авыз эченнән генә дога укып, сакал баскан битен сыпыргач, ерактагы зәңгәр урманга кабат күз төшереп алгач, салмак кына сөйли башлады. Гыйбрәтле хәл дигәнне ишеткәнгәме, башка юлчылар да әкренләп болар янына елыштылар.

—Фронттан без авылга берничә кеше генә исән кайттык. Шуларның берсе Гарәфетдин ие. Күкрәге тулы орден-медаль. Ул миннән олырак ие. Гомерле булды. Тик тормышы кызыксыз үтте.

—Хикмәт нәрсәдә иде соң?

—Тыңла син. Авылда алар тау өстендә гомер иттеләр. Мул яшәделәр. Ә тау астында, үзләре алдында гына Гарәфетдиннең ата-анасы яшәде. Бик картлар ие инде. Карт белән карчык җиен-кышын җитәкләшеп урманга утынга йөриләр, өйләре чыпчык оясы хәтле генә булса да, ягарга кирәк бит, язын бакча казып бәрәңге утырталар, ә менә Гарәфетдин таудан төшеп ник бер ярдәм итеп карасын. Тамаклары тукмы, өс-башлары бөтенме, өйләре җылымыюкмы, әйләнеп тә карамады. Хатыны бик үчле, усал, саран, түгелгәнне кире ялар бер нәрсә ие. Шуның алдында тез чүкте инде ул, шуның сүзеннән чыга алмады. Ничек йөрәге чыдагандыр ул әрекмән боламыгының. Әтисе сукыраеп, ничә ел сәке өстендә утырды, бу пошынмады, төшеп тә карамады, әллә бар аңа ата-анасы, әллә юк. Хатынының култык астында ышык тапты. Күршекүлән мунча ягып кертте, ә болар юк.

Ахырдан нәрсә белән бетте диярсең инде, син, иеме? Ямьсез бетте шул, ямьсез. Казанда яшәгән олы улы да, сугыштан соң туганы да эчкечегә әйләнде. Кечесе әллә кайларга Себерләргә китеп, айдан-айга: «Мине куып чыгаргандай чыгарып җибәрдегез, кайтам да малны бүләм»,—дип җанын талап торды. Атасының күзенә малы күренмәде, рәхәте дә булмады. Картая-картая Гарәфетдин акылга да җиңеләя башлады, ярый әле үлеп котылды. Ә теге малае кайтып, абыйсы, әнисе белән судлашып бетте. Вак-төякне кулга төшереп, җанына җылы урын таба алмыйча, янә китеп югалды. Соңыннан кайдадыр поезд астына эләккән дигән хәбәре килде. Кызының да бәхете булмады, ирдән-иргә йөреп, аннары бер урыска чыгып, этле-мәчеле яшәде. Әниләре йөрәге ярылып үлде. Менә ул, энем Булат, тормыш хәлләре. Ходай Тәгалә белә, күрә ул. Анаң каргышыннан сакланырга кирәк. Гөнаһың өчен үзең генә түгел, җиде буын балаң да җаваплы була. Ата-ана хакы дигән нәрсә бар ул бу дөньяда... Әйе... Теге автобус килә бугай, иеме?

—Әйе, шул... Ниһаять.

Юлчылар, бакчачылар кәрҗиннәре, сумкалары янына ашыктылар. Галимулла карт та салмак хәрәкәтләр белән торып, плащын какты да, кәрҗинен күтәреп автобуска юнәлде. Булат аңа ярдәм итәргә теләгән иде дә, карт:

—Кирәкми, энем. Кул-аягым йөргәндә мин бөтен эшне үзем эшләргә тиеш,—дип каршы төште. Ул автобус янына килеп җиткәндә ишекләр ачылып китте. Һәй, ни гаҗәп, әле генә шау-гөр килеп тукталышка ябырылган кешеләр:

—Әйдә, бабай, әйдә кер,—дип Галимулла абзыйга юл бирделәр. Картның йөзенә елмаю йөгерде, ул рәхмәт укый-укый автобуска кереп утырды. Аның янына Булат урнашты. Алар үз уйларына бирелеп, шактый гына сөйләшми кайттылар. Бераздан Булат әйтеп куйды:

—Кеше—ефәк пәрәвез дисең инде... Шулай шул... Табигатьнең иң сөекле баласы... Ефәк пәрәвез...

* * *

Икенче атнада Булат тукталышка шактый алдан килде. Тора-бара бакчачылар күп җыелды, тик Галимулла абзый гына күренмәде. Нәрсә булды икән картка, сүзендә тора торган абзый кебек иде ләбаса, дип Булат түземсезләнеп көтте. Бер мәлне аның күзенә унбер-унике яшьлек малай чалынды. Ул әле бер ир кеше янына, әле икенчесе янына килеп, нидер сорашып йөри иде.

—Кара инде, ә! Өс-башы да матур үзенең, чәче дә пөхтә итеп алынган, димәк, тәрбиясе бар, ә үзе кешеләрдән нидер соранып йөри,—дип Булат ачуланып та өлгерде.

Ул арада малай аның янына килеп туктады. Булат аны шелтәләргә генә дигәндә, малай:

—Абый, сезнең исемегез Булат түгелме?—дип сорады.

—Әйе, Булат мин. Ә бу сиңа нигә кирәк булды әле?

—Әй, таптым бит тәки. Бик яхшы булды әле. Менә сезгә дәү әтием Галимулла помидорлар бирергә кушты. Орлыкка дип. Мә, алыгыз,—диде малай һәм пакетка салган кып-кызыл биш помидор сузды.

—Ә дәү әтиең үзе кайда соң, ник килмәде?

—Авырып китте әле ул. Бик йөткерә. Карт бит инде... Ничек тә таба күр, кулына тоттыр,—дип кабат-кабат әйтте.

—Ярар, энем. Бик зур рәхмәт әйт үзенә. Тизрәк терелсен!

—Ярар, Булат абый. Хушыгыз!—диде малай. Аннары кулындагы очкычының пропеллерын зыр-зыр әйләндереп йөгереп китеп тә барды...



Сирень
Якупова

## АЛМА ИСЛЕ АВГУСТ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

* * *

**Иннек сөрттем, аннан үптем дәфтәр битен,**
**Ал күбәләк пәйда булды ак кәгазьдә.**
**Шундый сак һәм назлы иде сулыш-тыным,**
**Җан индерми күбәләккә калдым әздән.**

**Әздән генә калган кебек яшьлегемдә**
**Җан индерми күбәләктәй ал хыялга...**
**...Иннек сөрттем, янә үптем дәфтәр битен,**
**Яшь тамчысы тәгәрәде ал буяуга.**

* * *

**Тын бакчада сихри иртә,**
**Күбәләк саф чык эчә.**
**Әнә шулай Галәм сере**
**Бу нәни җанга күчә.**

**Серне чишеп өлгерер ул**
**Бары тик алсу гөлгә...**
**Йә күбәләк, йә гөл булып,**
**Туасы мәллә җиргә?—**
**Белер өчен Галәм серен...**

* * *

**Алма коя итәгемә август көне,**
**Йолдыз коя чәчләремә август төне.**
**Алма исе килеп торган йолдыз булып,**
**Яшим микән хәтереңдә әле дә синең?**
**Яшим микән?**
**Дәшим микән еллар аша, сискәндереп,**
**Уятыйммы җан-тәнеңне хисләндереп?**
**Кайтарыйммы үткәннәргә тизләндереп,**
**Елатыйммы «бәхил...» дигән сүзгә төреп?**
**Нишлим икән?**
**Сүзсез генә, синсез генә**
**Күзләремә кереп китәм...**

Сирень ЯКУПОВА — *шагыйрә; көндәлек матбугатта шигырьләре даими күренә килә. Чаллыда яши.*

* * *

*Исте җилләр ил эченнән...*
Дәрдемәнд

Асты-өскә ник, дисәм,
Ил эченнән җил искән.
Байлыкларны, халыкларны
Өермә җилләр кискән.

Кем аягүрә ауган,
Кем качып-посып калган.
Хәйләкәр һәм куркаклардан
Безнең буын баш алган.

Куркакка соң нигә тел?
Дәшми-тынмый тора гел.
Нигә ил хәйләкәргә?
Тик җай булсын яшәргә.

Ил эченнән җил искән—
Халкымның җанын кискән...

* * *

Берәм-берәм буар елан йота
Дер-дер килгән мескен куяннарны...
И татарым, елан күзләреннән
Күзләреңне алыр хәлең бармы?

Беләм, авыр, хәтта мөмкин түгел
Карышырга сихри кара көчкә.
Йә, Ходаем! Үз аягың белән
Тере килеш керү утлы мичкә
Язганмени, халкым, сиңа да бер,
Югалулар, әзсез, язганмени?
Куян белән Барс арасында
Аермалар бүген азданмени?

Чытырдатып йом да күзләреңне,
Ачып җибәр зәңгәр күккә төбәп!
...Еланнарга азык булу язык,
Меңьеллыклар кичкән исән милләт!

* * *

«Сиңа гына кирәкме бу дөнья?»—
Дисең кайчак, мине кызганып.—
«Азапланма, җитешмәссең барыбер
Һәр карага аклы сүз ябып.»

Сиңа гына кирәкме бу дөнья?..
Миңа гына түгел-түгелен.
Тик, нәкъ бүген мин дөньяга кирәк
Аңа терәк моңлы күңелем.

* * *

Язмыш җиле, шөкер, минем яклы.
Җилкәнем дә ак шикәрдәй аклы.
Гомер суым киңме?
Белгәнем шул:
Ярдан ярга чаклы.
Ярдан ярга чаклы...

Хыялларым таулардан да биек,
Болытларга китә хәтта кереп.
Кайсы чынга ашты?
Буламени
Болыт аша күреп.
Болыт аша күреп...

Дәвам минем—кызым килә үсеп.
Каләмемнән җырым кала күчеп.
Бәхет—җырмы инде?
Кем соң киткән
Яшәү серен чишеп?
Яшәү серен чишеп...

* * *

Тормыш юлы—ефәк җеп ул.
Кул эше белгәннәргә.
Җитеш кенә, дөнья, басып
Без чиккән келәмнәргә!

Тик...ялгыш та басма—җанга,
Очса да түбәннәргә...

* * *

Исәнлектә күрешергә язсын
Исәнлектә күрешергә язсын—
Бу теләктә күпме өмет бар!
Исәнлектә күрешергә язсын,
Иртәгесен явар юеш кар.

Исәнлектә күрешергә язсын,
Яз җилләре, сезнең белән дә.
Кояш нурын кушып наз эчәрбез
Тузганактан алтын келәмдә.

Исәнлектә күрешергә язсын,
Ал чәчәкле җәйге мут алан.
Мин генәме синнән исергән дә.
Син генәме миннән ут алган?!

Исәнлектә күрешергә язсын,
Шагыйрь көзнең моңлы һавасы:
Ефәк җебе булып пәрәвезнең
Их, бер синдә эленеп каласы!

Исәнлектә күрешергә язсын—
Бу теләктә күпме өмет бар!
Исәнлектә күрешергә язсын,
Куллар биреп көлешергә язсын—
Еллар, айлар, көннәр, минутлар...



Эльвира
Һадиева

# ЯШЬ ХЫЯЛ СУРӘТЕ

## Тылсым

**Ай куйнында**
**Игезәк йолдыз—**
**Тылсым туган...**

**Ялгыз усак күкрәгендә**
**Бишек—уйдан.**

**Үткәннәрдән**
**Киләчәккә**
**Чапкан җилләр**

**Яшь хыялны танып,**
**Бәлки**
**Шашып сөяр?!**

## Үтенеч

**Алдансам да, хыялыма**
**Саксыз кагылма, яме:**
**Айсыз төнемдә дә төштә—**
**Әбелхәят-су тәме.**

**...Керфекләргә язгы төндә**
**Чык тисә дә сүз әйтмә:**
**Яшьме? Җанда наз ярасы...**
**«Ярам»ны сүзсез бәйлә.**

## Нур сулышы

**Күңел тәрәзендә**
**Ят карашлар,**
**Ят кояшлар.**

**Пәрдә—ефәк.**
**Нур сулышы бик сак**
**Кагыла өметемә.**
**Кем ул әйтте:**
**—Тимә!**

* * *

**Уйлы дөньяң, кыйпылчыклар булып,**
**Учларыңа батса бер төндә,**
**...Үкенмә.**

**Син сагышлы чакта берәү көлсә,**
**Башың имә «назлы» ят җилгә—**
**...Үтенмә!**

---

Эльвира ҺАДИЕВА—*яшь шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килде. Балтачта яши.*

*Хикәяләр конкурсына*



Рифә Рахман

# СӨННӘТЧЕ ӘБИ

*99 баланың сөннәтчесе—әбиемнең энисе Мәлихага багышлыйм*

Мәфруза карчыкның үлем түшәгенә егылганлыгы көне-сәгате белән бөтен авылга таралды. Тиз арада авылның икенче башында яшәгән кызына, еракагы оныкларына хәбәр җиткерделәр. Инде килә алырдай кеше җыелып беткән кебек булгач, карчык, терсәкләренә таянып, торып утырды да:

—Мөхәммәтгалиемнән хат юкмы әле?—дип сорады.

Мона кадәр җир җимертеп йөргән, гомерендә дә көндез караватта ятуны бар дип белмәгән Мәфруза түтинең җәй уртасында якты дөнья белән хушлашырга җыенуы үзе бер сәер хәл тоелса, инде, бернәрсә булмагандай, ястыкка янтаеп сөйләшеп утыруы хәер-фатиха алырга дип килгәннәрне тәмам аптырашта калдырды.

—Урын табып, утырышыгыз инде, балалар,—диде ул, җайлап кына,—ерак юлдан килгәннәргә самавыр яңартыгыз.

Газизәнең яна гына агартылган мич янында төтенләгән кыңгыр салып утырган самавырга күзе төште. Якын әбисе янында кунакта булып кайтканнан соң, кызы: «Әбием, инде икенче килүенә мин булмам, күркәләрне бер еллык итеп кенә әзерлә, миннән соң нарат чәе эчәргә теләүче табылмас»,—дип сөйләнгәләде. Янадан күрмәс кебек, кочаклап бик нык аркамнан сөйде, дигән иде. Карасана! Бөтен тормышын елга агышларыдай гел белеп, сизеп тора бу олы кеше дигәнең... Ул чагында артык игътибар да ителмәгән бу сүз бик тирән мәгънәгә ия булгандай тоелды, күз төпләренә яшь бөялде, дәшмәде, кеше күрмәгәндә генә, кулмәк җиннәре белән сыпырып алды. Үзе эченнән, бәхетле әби дә инде, оныкларының балаларын күреп, карашып китә бит, дип сөенде.

Газизә узган җәйдә кызы Нәфисә җыеп киткән күркәләрдән самавыр тергезим дип, чоланга, алар салынган кәрҗингә таба атлады. Керде дә имәнеп китте: кәрҗин төбендә нибарысы биш-алты тапкыр чәй кайнатырлык күркә тәгәрәп ята. Житсә дә, өч көннән артыкка житмәс, моның кадәр кунак төшкән өйгә... Кунак диярга дә тел әйләнмәслек бер көн булды кана!

Газизәнең йөрәк эчендә—бик тә кадерле кешесен югалтудан курку, үткәннәр турында уйлаудан туган сагыш хисе иде. Кызына кат-кат: «Киләсе җәйгә, киләсе җәйгә...»—дигәне әллә чын ук булыр микән?

Инде орлыклары да коелып беткән, әмма күрер күзгә симез, матур күркәләргә үрелгәндә, кулларының аларны бик аралап, санап, саранланып алганын тойды. Житсә дә, өч көнгә житәр, дип уйлады ул, тагын бер тапкыр кәрҗиннән күтәрелгәндә, икеләнебрәк торгандай. Шунда кылт итеп әбисенең намаз укыганда калдырмый торган бер теләге исенә төште: «Өч көннән артык урын өсләрендә яткырмасанчы, Ходаем, әҗәл чирләренең шул өч көненә чыдарлык түземнәр бирсәнче...» Бу дога Мәфруза әбекәченең теләк сүзләренең иң башында булып, кызны гел аптырата торган иде. Озаграк торса соң, аның якты дөнья белән шулай бик тиз хушлашасы килә микәнни?

Әле ул чакта сораулы карашларын эләктереп алган әбисе гадәтенчә җемелдәп кенә елмайды да, и кызым, кеше кулларына бер дә каласы килми шул, дип куйды, үз акылында, үз көчендә китүгә житми инде ул... Кеше куллары дип... Кем авырсына соң аны карарга? Чит-ят куллар түгел ләбаса! Бөтенесенә карап торган бер «якын әби»ләре бар!

Учлап күкрәгенә кыскан күркәләрнең берсе кире кәрҗингә төшеп китте дә почмакта җыелышып яткан ишләре янына тәгәрәде. Газизә аны кире күтәреп алмады. Күркәләрне күпмегә озагракка житкерсән, әбисе шуның кадәргә артыграк яшәр кебек идеме... Язмышны алдарга теләгәндәй, ул бер күркәне үзе үк кире кәрҗингә ыргытты.

Бик тә ярата иде шул аның әбисе нарат, чыршы исләренә буылып кайнаган, чишмә суыннан пешергән бөтнек чәен, бигрәкләр дә ярата иде инде менә.... Бөтен халыкны аптыратып, авыл гадәтләрен санга сукмагандай, бер алар гына бакча түренә ылыслы агачлар утырттылар, бер ул гына өй каршындагы үзе белән килен булып килгән көнне төртелгән нарат төбенә ире Галимнән пар кеше сыярлык утыргыч ясатты.

Балачагында, якын әбиләренең өй турындагы чирәмлектә мәш килгәндә, аларны шул нарат сайгаклы утыргычтан, каз бәбкәләрен саклаган кебек, таяк белән төрткәләп кенә уйнатып утырырга ярата иде ул. Аннан—йомшак бәпкә үләне өстендә изрәп, кояшта кызынып яткан күркәләрне бергәләп җыялар да чәй эчәргә кереп китәләр. Каз йомышлаганчы, кеше аягы басканчы, алып калыгыз инде балалар, ди иде Мәфруза әбиләре, самавыр эченә тутырылган күркәләрдән ят, зарарлы исләр килүен, самавырның нәҗесләнүен теләмәгәндәй.

Якын бабалары вафатыннан соң олылардан нарат төбендә бүтән кемнең дә булса ял иткәнен хәтерләми Газизә. Әллә сөннәтче карчыкны олылап, үзләреннән аерып куепмы, әллә бу бәхетне Галләм абзыйларыныкы гына санапмы, каршысына утырырлар, наратның икенче ягына елышырлар, Мәфруза карчыкның артында басып торсалар торырлар, әмма ләкин янәшәсендә урын алмаслар .

Туктале, әби, берни булмаган кебек, түр башында күрше-күлән белән сөйләшеп утыра, ә мин инде аның турында үткән замандагы кебек сөйлим, диде Газизә, үзен уйлаудан ничек туктатырга җай тапмыйча.

Әле оныкларының оныкларын да күрерлек кыяфәттәге, мәңге яшәр кебек тоелган Мәфруза өчен сөенмәслек идемени?!. Алай да, эссе җәй уртасында, печән өстендә, бөтен дөньяның башына тимер белән суккандай, карчыкның халыкны хушлашырга чакыруы күрше-күләнне дә, балаларын да тәмам аптырашта калдырган иде.

—Ә-ә, син икәнсең, Мин Гайфулланың төпчек малае кирәме икән әллә дип торам тагын,—диде Мәфруза түти, үзе көткән кешеләрнең исемлеген күңеленнән тагын бер кат барлаган кыяфәт белән.—Мөхәммәтгалием дә кайтып житсә, сөннәт улларым каберлеккә килеп булса да хәлемне белерләр... Кайсы-кай якка таралып беткәннәр шул инде. Монда яшәгәненең дә—үз

тормышы. Эш кешесенең мондый җәйдә эштә булганы яхшы.

Карчык утырырга урын җайлагандай мендәрләрне тоткалап карады. Шунда ук барысы да, хәзер әбкәй, хәзер әбкәй, диешә башладылар.

—Юк ла, мин болай... Тик тора алмаганнан гына. Әле менә сөннәт дигәннән... Туксан тугыз угылның сөннәт әнкәсе бит мин. Туксан тугыз! һәр бөртегенең гомере минем кулдагы пәке үткененнән узган...

Мәфруза карчык ерак Шуләнгер якларыннан бу авылга килен булып төшкәндә, сөннәтче әбигә әйләнермен дип башына да китермәгән иде. Приказщик картының кочагында җылынып, затлы киемнәр эчендә матурланып, йомшак түшәкләр өстендә түш киереп яшәргә иде аның исәбе. Менә бу җайсыз, җансыз булып калган ястык өсләрендә түгел...

Каралты-кура турында кайгыртасы юк. Бар нәрсә килен төшешкә янадан, ике катлыдан салдырылган, йортның тирә-ягын инде мул нигъмәт китерүче җиләк-җимеш бакчасы бизи. Су буендагы ак мунча морҗасыннан, кунакфәлән төшкәнне хәбәр итеп, көн буена төтен төти, абзарда тук маллар мөгри, капка төбендә ялтырап торган тире кошевкага җигелгән кап-кара туры айгырлар биешә.

Яшь килен бирнәсеннән чыгарылган жиз коштабаклар, бакыр комганнар, ойалды стенасындагы кадаккка элеп куелган чигүле сөлгеләр монда яңа тормыш башланганны хәбәр итеп тора. Аларның кайсына ян бакчадагы алмагачларның кызыл, сары алмалары чөмәкәйләп тутырылган. Сандугач сурәте төшкән көянтәләр, яшь киленгә су буйларын күрсәтергә әзерләнеп, шундый ук сурәтле әлюмин чиләкләргә үрелгәннәр.

Өй эченә керсәң, кире чыгасы килми: бирнә сандыгында ничә еллар буылып ятканнан соң тынчулыктан котылганнарына сөенешкән өем-өем чәчәкле-чуклы тукымалар, кашагалар, чаршаулар, утыргыч япмалары, өстәлгә ямь биргән ашъяулыклар, көзге өсләре... Чигешле өлгеләр белән матурлап та җибәргәч, болай да гөлгә күмелеп утырган тәрәзәләренә эчке яктан да нур ташкыны агылгандай, яктылык ингәндәй булды.

...Өй түрендә, ылыс исләре чыгарып, самавыр гөжелди.

Галләмнең борын яфракларына кунган тир тамчыларына исе китеп карап утыра ул. Бөтерелеп киткән мыекларына төшәрләр дә аннан кәрәзле бал тутырып иреннәренә якынлашкан калак өсләренә сикерерләр кебек.

Галләмне Мәфруза бер күрүдә яратты. Ялындырып тормады, сорап килгән көнне үк, әти-әнисен аптырашта калдырып, бирнә тупларга тотынды. Без, ярар, дисәк тә, көтәсең мәллә, бер дә күргән-белгән кешең түгел бит, тагын бер ныклап уйла, әле эш узмаган, диештеләр алар. Кыз, алар каршында гомерендә беренче тапкыр зур батырлык күрсәтеп, барам булгач барам, дип ярды да салды.

Ә бит ире, чыннан да, бер дигән. Эшкә кулы ятып тора, белегеннән көч ташый, укымышлы, динле, заманнан да артта калмаган. Шаянлык та житәрлек үзендә: капка алдына шәп атларында килеп туктауга, яшь егетләр кебек сызгырып кына җибәрә. Ул да булмый, Мәүлиха абыстай чыгып, турыайгырларны өзәнгедән тотып тынычландыра да көмеш тәңкәле каешларны капка башына кагылган алкаларга бәйли.

Аннан, җылы су салынган комганны алып чыгарга дип, тиз генә өйгә кереп китә. Мәфрузаның бу өйдә яраткан вазыйфасы—эштән арып кайткан иренә тәһарәт алырга булышу. Ул моны яратып, гомер буе шуны гына эшләп үскән кебек оста башкара. Вакытында сабынын бирә, вакытында суын сала, чигүле тастымал белән картының кулларын үзе корыта, битләрен икенче бер сөлге йомшак кына итеп үзе сөртә. Шул арада җаен туры китереп, Галләм дә аны бит алмаларыннан җинелчә генә үбеп ала. Бу йортта каенана-каената булмаса да, алар иркенләп сөешергә әле бер-берләреннән кыенсыналар, әдәпсезлек, тупаслык саныйлар.

Галләмнең авылдашларына аңлашылмый торган бер гадәте бар. Җәйге,

күзгә эшләр беттеме, дөнья күрәм, дип, хуҗасыннан ял алып, ерак шәһәрләргә чыгып югала. Саквояжын жинел генә селкеп китсә дә, капчык-капчык кучтәнәч, асыл тукымалар, беләзек-йөзекләр күтәреп кайтып керә ул. Аннан ай буена авылдашлары аның күргәннәрен тыңларга йөриләр. Галләм абзыйлары бер шәһәрдән икенче шәһәрне тынлатучы чыбыклар, жир казучы машиналар, тагын әллә ниләр турында сөйли, әмма күбрәк ул әле нәрсә булачагын фаразларга, кешеләрне хыял дөньясында йөздерергә ярата.

Уналтынчы елның язында шундый сәфәрләреннән берсеннән Галләм бөтенләй башкача кайтып керде. Башына ниндидер уй тулганы әллә каян-күренеп тора иде. Кечкенә төенчегенә салып кайткан вак-төяк, такта чәй белән сыйлангач, инде барысы да өстәл тирәсеннән кузгалабыз, дип торганда, төпчеге Хәдичәне алдына утыртып сөйде дә:

—Анасы, дөньялар бозылырга тора бит әле, балалар турында уйламый булмый, бу ел кышка утын әзерләп тормабыз, йортның бер өлешен турап ягарбыз,—дип куйды.

Аскы катның аш бүлмәсен сәер тынлык тутырды. Түшәмгә карап-карап утырса да, Мәфруза карты кылган ныклы карарның сәбәбе хакында тикшеренергә батырчылык итмәде. Яулык почмагын тешләп тынып калды.

Ихата кечерәеп, каралып, мескенләнеп китте. Сыер да моңлырак мөгери, тавыклар да монсуланып кыткылдый кебек тоелды. Мәфруза белән Галләм кичләрен нарат төбендәге утыргычта бик сирәк күренә башладылар, аларны йорт үзгәртү, дөньяны башкача көтү мәшәкате басты. Мәфруза да элеккечә кош кебек талпынып, дәртләнеп йөри алмады, чөнки ире бай абзасыннан да эштән чыгып өлгергән, акча яклары шактый кыенлашып киткән иде.

—Патша төшәчәк бит, карчык. Кешегә генә сөйли күрмә, безнең авыздан чыкмасын: үзең генә ишеттең! Тормышның кайдан тәгәрәсен бер Алла үзе генә белә. Шунысы хак: байларга көн бетәчәк ди. Андый вакытта баенны, бай түгеленне дә карап тормаслар... Авыл тулы хәерче яшәгәндә, ике катлы пулатларың белән син дә шулар арасына эләгәсең инде...

Патша кадәр патшаны төшерәселәренә дә, авыл мужигына көн киләсенә дә Мәфруза ышанмады билгеле, иллә мәгәр каршы да төшмәде. Галләмнен урыс-урагай арасында да, Казанның укымышлы кешеләре арасында да таныш-белешләре күп иде, утсыз төтен булмый, алай да дөньяларның бозылырга торуы хактыр дип уйлады.

Авыл уртасында бай йортларыннан да матур булып утырган күркәле йортның ай эчендә шул хәлгә килүе, Галләмдә соңгы йөреп кайтуыннан соң, кеше жыеп, күргән-белгәнен сөйләргә ашыкмавы күрше-күләнне генә түгел, тирә авылларны да пошаманга төшерде, кайсы нәрсәгә юраса юрады, эшнең асылына һичкем төшенмәде.

Барысы да унжиденче елга килеп кергәч аңлашылды. Яманыннан куркыта, шул ук чакта яхшы тормышка ниндидер өметләр дә уята торган әле бу, әле теге хәбәрләр авылга көн булмаса, ай саен килеп тора башлады. Аларның чыңга ашасын озак көтәргә туры килмәде: патша да төште, властька большевиклар да килде, авыл байларының байлыгын тартып алу да башланды.

Иң элек Галләмнең олы кызы Маһибикә килен булып төшкән йорттагы—ларның барысын урамга чыгарып ташладылар, каралтыларын, әйберләрен—кайсын кемгә тараттылар. Ата кеше кызы бусагасына килеп егылыр, шул мәхшәрдә тора алмас дип көткән иде, алай булмады, ире белән бер булып, тешләрен кысып, күршеләре йортының бер почмагында, чаршау белән бүлеп алынган аш-су ягында яшәп киттеләр. Эшләрен дә эшләштеләр, үзләренекенә кушып, балаларын да караштылар. Абзарларындагы маллары да ят итмәде, аларын сәвит кешеләре кайчандыр үз абзарларыннан туп-туры кертеп кенә куйган иде...

Галләмгә инкыйлаб җилләре кагылмады: аласы әйбер калмаган, болай да өләшеп бетерелгән иде. Гади халыктан урысча язу язарлык кеше тапмаганга,

ярлыларның кәмититенә үк сайлап куйдылар үзен, каршы төшеп карамады, артык сүз көрәштерүнен мәгънәсезлеген аңлады, писер булсам гына дип ризалашты, өчне өчкә куша белмәгән сәвитчеләр белән бергә эшләп китте.

Ел арты ел узды, яңа көн арты көн туды, бөтенләй башкача, динсез, Алласыз тормыш башланды... Сөннәт бабалары да, мулла-мунтагай да, хәреф таныткан хәлфә дә авылдан йә куылды йә, берни янамаса да, үзләре үк чыгып качты. Монарчы җомгадан, җомга арты сөбхәтләреннән калмаган Галләм алай да намазын ташламады. Өйдә кылган догадан куркырга кирәк дип тапмады.

Ирләрнең кайсы сугышта кырылган, кайсы болай юкка чыгарылган шундый бер заманда угыл өстенә угыл туды, әмма шәп, шөлдерле, бизәлгән дугалы чаптар атларда авыл әйләнеп уздырылган бәби туйлары да, зурлап исем кушулар да онытылды. Алай гына түгел, тора-бара сөннәткә утыртырлык, баба булырлык кеше калмаганлыгы да беленде. Ул авылга чаптылар, бу авылга... Сәвит тыя дип тә тормадылар, сөннәт дигәне, һәркем өчен яшәү кебек бер гап-гади гамәл иде. Бабалардан килгән бу йоланы бозарга һичкем яхшысынмаса да юлы һич табылмады: Сөннәт бабаларын җир йоткан идемени?! Ахырда, ирләрчә ныклыгын, чисталыгын, батыр йөрәклелеген белгән авылдашлар Мәфрузага килеп баш иделәр: балаларыбызны чирле итмә, фәлән-фәлән абзыйдан калган сөннәт пәкесе бар, риза булып, шуны үзенә корал ит, диделәр. Ризалашса ризалашты, ризалашмаса—юк (аны сорап тордылар микән әле?), шул көнне үк Мәфруза түтекәй Сөннәтче әби булып китте.

Ире Галләм белән йорт кенәгәсенең соңгы битенә сөннәт балаларының аты, нәсел кушаматы, туган, аруландырылган елын теркәргә кинәштеләр. Мәфрузаның инде илле бере тулып килә, үзе дә сизмәстән, карчыклар рәтенә кереп бара иде. Алай да төсе, тотышы, кием-салымы белән башкалардан аерылып торган, һаман да приказщик хатыны икәнлеге әллә кайдан күренгән Мәфрузаны сүз белән дә картайтырга кыймаганнары, олылап, якын итеп, сөннәтче әнкә дип атый иде.

Бала туса туа, күлмәк-ыштан кия, көндә кашык тотып ашарга утыра—колхозлашасыңмы син, юкмы, үстерергә хәлеңнән киләме әле—сорап тормый икән. Ике-өч ел дигәндә исемлектәге балаларның саны туксан тугызга житте дә, дәфтәрнең ул бите, култамга салынып, бөкләп, ябыштырылып куелды. Диндарлыгыннан ырым-шырымнарга артык игътибар бирмәгән Мәфруза сөннәт дигәндә әллә нәрсә эшләде. Бабасыннан, йөзенче баланы сөннәткә утыртырга ярамый, үлә, дип ишеткәне бар иде, акылы белән шул сүзне кире какса да, күңеле тыңламады, нindидер зур бер көч аннан сөннәт пәкесен еракка—келәттәге кием-салым салынган сандык төбенә яшертте.

Үч иткән кебек, икенче көнне үк иртә таңнан аларның капкасын дөбердәтепме-дөбердәтеп кагарга тотындылар. Урам тәрәзә аша Мәүлиха килүченең күмхуҗ рәисе икәнлеген күрде, үзен чакыра дип уйламыйча, колхозда баш агроном булып эшли башлаган ире Галләмне төрткәләп уятты:

—Нидер булганмы, әнә Мотыйк абзый капка кага, чык тизрәк!—диде. Галләм, каударланып-кабаланып, мич башындагы үзе серкәләндереп ясаган яңа сорт ашлыкларның тишелешен тикшерергә утырткан агач савытны бәреп төшерде. Урынына алып куймады. Мәфрузага гына кушып, ияге белән ящикка ымлады. Ишек катындагы элгечкә үрелгәч, анысы, кадагыннан ычкынып, киемнәре-ниләре белән идәнгә килеп төште. Галләм өстендәге киеме белән генә урамга, капканы ачарга йөгерде.

Тик Мотыйк Мәфрузаның үзенә килгән икән.

—Коткар, җиңгәчәй,—дип сүз башлады ул кирә-керешкә.—Малайның ят җире тәмам эренләгән, сөннәткә утыртмасаң, иртәгә бүген үләсе...

Мәфруза карчык җавап бирергә ашыкмады. Ул үзен сөннәткә утыртып йөргәне өчен генә күпме җәфалаган бу кешенең күзләренә туры карый алмады.

—Ялгышлык миндә булган,—дип дәвам итте сүзен Мотыйк.—Үз башына төшмичә, белмисең икән ул...

Сөннәтче әбинең һаман да берни әйтмичә тораташтай торуын Мотыйк астыртынлыгы, үпкә саклавы, үлем түшәгендә яткан баласы өчен эчтән генә сөенүе дип фаразлады.

—Кичер, җиңги, ялгыш—миндә,—диде ул тагын бер кат.—Сәвит кушканча яшим дип...

—Без дә сәвит кушканча яшибез анысы, Мотыйк,—дип әйтә башлаган Мәфрузаны рәис ярты юлда туктатты:

—Мин бит син сәвитчә яшәмисең дип сөйләп тормыйм, сине сөннәтчелектә гаепләргә дип тә килмәдем, малайга ярдәм ит дип, олы башымны кече итеп... үлә бит... Үлә!!! Син эренләнгән ярысын кисеп төшермәсәң, билләһи, үлә!!! Сиңа аның нәрсәсе бар инде?!

Үзеннән ничә яшькә кече Мотыйкның шундый чакта да үзенә бәясенә Мәфрузаның исе китмәде. Ул монаияләнгән иде инде, шуңа күрә сүзне озынга сузылуыннан курыккандай, чоланга чыгып китте. Ул да булмады, чисталап ак тастымалга төрелгән сөннәт пәкесен тотып та керде:

—Аның нәрсәсе бар дип уйлыйсың икән, кисәсен дә төшерәсең,—дип, Мотыйк кулына тоттырды.

—Ник, мин бит... Сөннәтче түгел...—диде рәис, башка ни диярга дә белмәгәнгә.

—Мин дә Сөннәтче булып тумаган, кирәк киртәгә кертә, итекчегә дә, пешекчегә дә әйләнәсең. Кисәсен кискән инде мин, сиңа үчлек белән түгел, йөзенчегә кулым бармый.

Үзеннән мондый сүзләрне һич ишетергә теләмәгән, күзләре атылырга торган Мотыйкка карап:

—Баланның гомерен уйлап кына...—дип өстәде.

Мотыйк хорафатлардан көлә торган бер кеше иде. Авылның иң акыллы карчыгы дип уйлаган Мәфрузаның шул булыр-булмас ырым-шырымга сылтап, ярдәм күрсәтергә ашыкмавын ул аңларга да теләмәде.

—Соңгы тапкыр сорыйм: утыртасыңмы малайны, сөннәткә, юкмы?!—диде ул җикергән, боерык биргән бер кыяфәттә. Мәфруза да нәкъ шулай ук җавап кайтарды:

—Юк!

Юк, дисә диде, әмма ләкин ире Галләмне ерак авылдагы бер танышына, сөннәт картына ат җигеп йөгертте. Мотыйктан битәр сабый кызганыч иде. Шундый борчулы көннәрнең берендә күктән килеп төшкән кебек сөннәтче карт малайны аяусыз үлемнән саклап калды, әмма инде Мәлиханы рәиснең мәңгелек дошманына әверелдерде. Улының тазарып китүенә ул гына сәбәпче икәнлеген, хәер, Мотыйк белми дә калган иде. Карты Галләм дә, яхшы атлы булып күренергә тырышкандай, бу хакта сүз озайтырга теләмәде. Аның үз сөенече—сөенеч: шушы ук көннәрдә хатыны Мәфруза, бөтенләй аптырашта калдырып, бәби алып кайтырга җыена иде. Ярый әле, шундый вакытта кан күрмәде, өзлегеп китәргә сәбәбе аяк астында бит аның, дип фикер йөртте булачак әти.

Кара син бу Мотыйкны, көмәне борынына җиткән Мәфрузаны кешегә дә санамагандай ду китереп чыгып китте, дип уйлады ул бераздан. Кеше кайгысы белән анысы шул мизгелдә үзенең дә тәмам башыннан чыккан ләбаса! Яше илленең бу ягына чыккан хатынының балага узуыннан ул әле дә исәрләнеп йөри иде югыйсә...

Ай узды дигәндә, Мәлиха тагын бер кызны түр башындагы караватка куелган, чигүле япмалар белән чорналган кәрҗингә китереп салды. Инде аның туганына да шактый көннәр үткән, матурланып, тулыланып килә, кешеләрне күрә башлаганы да тоемлана иде. Уналты көн дигәндә, әнкәсе аны кочагыннан аерды, бай кызлары гына ятырлык, бизәкләп үрелгән савытның елак бер хуҗасы итте.

Оркыя ир бала сыңары булып үсте. Буйга да яшьтәшләреннән ыграк, көчкә дә һичберсенә бирешмәслек, телгә дә кирәгеннән артык үткен булды. Сугышып-фәлән итеп йөрмәсә дә, Мотыйк малае Байрак белән генә серкәләре килешмәде, юллары каршы килсә, юл бирешмәделәр, бәхәс чыкса, икесе ике якта булдылар, чөнки атасы малайга бу нәселгә котырган үгез кебек карарга өйрәтеп үстерә иде. Оркыяның моңа исе китмәде, теләсә ул аны акылга утырта аласын белсә дә, какмады, сукмады, әмма чәкәләшкәндә юл куярга да ашыкмады.

Оркыядан котылуның җаен Мотыйк абзый тиз тапты: сугыш бетеп, тормышлар рәтләнә башлаган кебек тоелса да, Галим абзыйның кәнсәләр тирәсеннән китүеннән, аяктан егылуыннан файдаланып, яше дә тулмаган кызны урман эшенә язды. Исемлек ачыклаган җыелышта, унсигезе тулмаганнарны язмыйк инде, дип каршы төшә башлаган күршесе Салихны:

—Тулган, бик тулган, син беләсенме, минме—мин малайны сөннәткә утырт, дип килгәндә, инде ул аяк арасына керерлек бер кыз иде,—дип кырт кисеп туктатты. Башкалар инде әйтеп тормады. Алдында яшь буенча төзелгән исемлек яткан авыл сәвите рәисе дә телен тешләп калуны дөресрәк санады. Бер мәктәптә, бер үк парталар артында укып йөргән балаларның берсе Казанга—укырга, икенчесе—урман егарга китте.

Нарат куелыгы эчендә, коры җиргә сылап салынган бура йортларда, кыш башлангач, салкын, дымлы иде. Житмәсә, ашау ягы да шактый такырайды, моңа кадәр бирелгән икмәк телемнәре юкарды, сыр шакмаклары бөтенләй юкка чыкты, һәркем алгысынып, тилмереп, әллә нинди өметләр белән, язны көтә башлады. Майга кергәч, алмаш килер, аларны өйгә кайтарырлар кебек иде, тик Оркыялар авылыннан алмаш җибәрмәгәннәр икән, кызны, җәй узганчыга кадәр, дип, тагын урман эшләрендә калдырдылар.

Ачлыкта кычыткан ашап кына түзә алмам дип уйлаган Оркыя жиде төн уртасында күлмәк-ыштаннан гына авылына качты. Бер алып чыкмаса, бер чыгар дип, сукмаклар буенча олы юл ягын чамалап йөгерде дә йөгерде, таң атканда—өендә иде инде.

Мич төбенә ипи тәгәрәтеп йөргән Мәфрузаны кызының бу рәвешчә кайтып керүе тәмам аяктан екты, житмәсә, ире Галләм дә ни сәбәптәндер, Оркыяны уйлапмы, башкасынамы, көтмәгәндә йөрәге хәлсезләнеп егылган, инде соңгы көннәрен яшәп ята кебек иде.

—Кызым, әллә сон, белгән кебек иденме...—диде ана кеше.—Атаң әҗәл белән булышып ята. Инде теленнән дә калды. Авызын ачтырып, су салып, ризык кына ашатып торабыз...

—Юк, әнкәй, кайдан белим ди, качтым мин, әткәйне аннан күрермен, яшер мине тизрәк,—диде Оркыя, атасы янына узарга, аны да борчырга батырчылык итмичә.—Озак көттермәсләр, кем белә, эзләп тә килерләр.

Мәфруза карчык айнып киткәндәй булды. Еламады, сорашмады, борчымады, гадәттәгечә, яулык почмагын тешләп уйга калып торды да, кызына өстәлдәге иске ипине булса да каптырып, бакчага алып китте.

Ихата артында, абзарга якын гына өеп куелган, түтәлгә әзерләгән тиреслеккә ашыкмый гына зур уем ясады, төбенә киртәгә кибәргә эленгән паласларны җәйде, аннан баш селкеп кенә, кызына кереп ятарга кушты, йөз турысына иске морҗа башын куйганнан соң, калган җирен тузган киемфәлән белән каплады да түтәлне матур, тигез итеп яңадан өйде. Торбаның тирә ягына йолкып атылган чүп үлән, корган чыбык-чабык салды. Эшне беркем аңламаслык, сизмәслек булып калды.

Чыннан да, эзләп килүчеләр озак көттермәделәр, әбәт турысында сак кына ишек шакыдылар. Шакулары йомшак булса да, сөйләшүләре каты иде. Өй асты пыран-заран китерелде, чормалар актарылды, абзардан мал чыгарылды... Түрдә яткан Галләм караваты да кузгатылды, телсез дип тә тормадылар, эзләп-эзләп тә, Оркыяны таба алмагач, аңа да янап,

әйтмәгәннәрен калдырмый, пырлап чыгып киттеләр. Сорашып, күршеләреннән дә бер хәбәр алмагач, кайтмагандыр дип ышандылар, ахрысы. Күздән югалдылар.

Колхоз рәисенен эшне зурга илтәсе, үзенең дә тавышка керәсе килми иде, атна дигәндә, икенче берәүне табып, берни белмәгәндәй, Оркыяны кайтарыгыз, әтисе үлем түшәгендә, дип әмәлләгән хат тоттырып, урман эшенә җибәрделәр. Ул арада Галләм абый да вафат булып, әтисен җирләргә тирестән чыгарылган кыз вакыйгасы, баштарак бөтен авылны шаккаттырса да, кеше телендә озакка сакланмады. Әллә Мотыйк инде бу эш белән начальникләр күзенә чалынуыннан курыкты, беркая барып, берни хәбәр итеп йөрмәде, эченнән генә, үчне тормыш алды инде, дип сөенеп тынычланды.

Мәфрузаның олы улы Мөхәммәтгали, кышкы салкында күлмәк-ыштаннан немец концлагереннан качып, аякларына салкын тидергән, урынга калган, туган җирендә кайтып яшәргә хокукы да юк, булса да, мәет җирләргә дә кайта алмаячагы көн кебек ачык иде. Аның каравы гәрнадирдай Нургали, вакытын гына белгәндәй, Кузбасстан чираттагы ялына кайтып төште. Әтисе белән хушлаша ук алмаса да, кабере өстенә бер уч туфрак сибәргә өлгерде:

—Авыр туфрагың җинел булсын, салкын гүрең безнең күңел җылыбыз белән җылынсын...

Әле картлар таралгач та, бик озак китә алмыйча, инде бакыйдагы әтисе белән серләшеп утырды ул.

—Мин дә, синең кебек, җир asларыннан чыга алмый эшлим бит, әтәй,— диде ул, уйчан гына.—Җир асларыннан юл салып, сиңа таба гына барырга да... Булмый шул!

Шулай дигәндә, тавышы өзелде. Бер мәгънә салып әйткән сүзенең икенче мәгънәсенә үзе аптырап калды. Әйткәнен онытырга тырышты, тик кайткач та тынычлана алмады. Мәет чыккан җиргә дога укырга җыелышкан күрше карчыкларының көенә монланып, чыра яктысында әтисенең приказчик чагында төшкән рәсемнәрен карап утырды. Аныкы кебек мутлык бирә торган мыекларын бөтергәләде, рәсемнән караган моңлы күзләрен сыпырды. Керфекләрен йомдыргандай итсә дә, нәкъ үз яшендә булган әтисе һич кенә дә йомарга теләми, канәгатьлек хисе белән туп-туры ана караган иде.

Иртән мич тирәсендә булышып йөргән әнисе, ашларны уздыргач, өйләнеп китәрсең инде, улым, үлгән артыннан үлеп булмый, хәзер дөнья сиңа калды, дип куйды. Нургали үзе дә бу турыда уйлаштыргалый иде. Кузбасста күз төшеп йөргән кызлары да юк, монда да күтәп алган чибәркәйләр күренмиi күренүен, тик менә яшь чагында ук ошаткан берсе бар...

Мотыйкның олы кызы Халисә иде ул. Әнәй дә теләгәндә, әллә өйләнергә инде?! Яучы җибәрергәме? Әнисе генә яучыласа?

Ишек алдына чыгып, баскычлар өстендә бик уйланып утырганнан соң, чоланга башын тыгып кына, әнисен үзе янына дәште:

—Кил әле, әнәй, чыннан да, өйләним мин булмаса, менә Мотыйк абзый олы кызын, синең ризалыгың белән бирел куйса...

Мәфрузаның күз аллары караңгыланды. Егылмаска тырышып, ишек янагына сөялде. Алай да, аягына ялгыш баскан гына бер кыяфәт чыгарырга тырышып, чайкалып киткән җиреннән тураерга маташты, булдыра алмады. Нәкъ йөрәк турысыннан кылт итеп без белән кададылармыни—бөгелеп төшкән хәлендә алъяпкыч эченнән генә күкрәген тотты. Юк, яшим икән әле, диде ул аннан, туктап калгандай булган йөрәгенең тек-тек кенә тибеп китүен уч төпләре белән тынлап.

Йорт ишегенә арты белән утырган Нургали боларны күрми иде. Бераздан ана турайды, улы борылып караганчы дип, сораштыра башлады:

—Халисәгәме? Безгә төшәрме соң ул? Юашлыгың да хәттин ашкан... Халисә биеп торган, башын чөеп баскан ат кебек...

—Шундыйларны ошатам да инде мин, әнәй!

Холыкка юаш булса да, өздереп әйтәсе дип санаганда, Нургалие дә әти-әнисенә охшап кала. Әйтте и вәсссәләм! Шуны белгәнгә, бу турыда кабат сөйләшмәделәр.

Нургалинең китәр көннәре җиткәндә, Мәфруза карчык, яшь чагыннан калса да, әле дә өстендә бер дигән утырган, кызларча төз гәүдәсен тагын да купшылатып җибәргән күлмәкләрен киде дә, желт-желт атлап, югары очка—Мотыйкларга менеп китте. Китте дә Халисәне җитәкләп алып та төште. Кызның, гомерлек дошманына барам, дип әйтәсен көтмәгән Мотыйк икесен бергәләп диярлек йортыннан куып чыгарган иде. Шулай итеп, Халисә Нургали белән куш булып, бәхет кошын тоткандай, Кузбасс якларына китеп барды.

Шушы ике баланың бергә кушылуы ике нәселне дә тоташтырырга тиеш иде кебек. Мәфруза теләгәнчә барып чыкмады. Кода-кодагый, өй тутырып кунак җыйганда, дәшергә ашыкмады, күрше-күлән белән бер-бер эшне өмәләп башкарганда да, балта-көрәк күтәреп килеп житмәде. Кызы урынына почтальон сумкасын тагып йөри башлаган Хариса иреннән дә болайрак булып чыкты. Гомерен рәхәттә уздырган хатын сумка тотырып өй борынча йөрергә кирәклекне башына да китерми иде, кино-фәлән барганда, мунча кадәр клубның экран төбенә килеп баса да урам буенча кушаматларны тезеп китә:

—Ыштансыз Гали, Күпер асты Лотфулла, Кыяр буры Марзыя...

Исеме чыккан бере тиз генә аның кулындагы гәҗитне эләктереп ала да, башкаларны төртә-ега, кире үз урынына барып утыра. Бәхетсезлегенә каршы ул көнне кич чыкмасаң, хатсыз каласыңны көт тә тор.

Мәфруза карчыкны олысы-кечесе хөрмәт иткәнгә, ул урамнан үткәндә, сугышып яткан балалар да шым кала, тәмәке тартканы тәмәкесен чалбар кесәсенә яшерә, бер-бер сәрхүше тизрәк кайда да булса шылу ягын карый иде. Почтальонка кодагый, әллә кеше сүзеннән сакланып, әллә инде кызының каенанасы булганга, бераз йомшый төшеп, хатны үзе үк китермәсә дә, кемне дә булса табып, Мәфруза түтиләренә йөгертә торган иде.

Хатлар гына сирәгәйде. Нургалинең юраганы юш килде: эшләгән шахтасы җимерелеп, гомерлеккә таш астында калды. Киткәндә, озатырга дип җыелышкан яшьтәшләренә, шаяргандай итенеп, таш басмаса, бер кайтырбыз дип, көлеп куйган иде шул. Килене Халисә дә, аталары йортына әйләнеп кайтырга теләмичә, баласы белән шул туфракта берегеп калды. Бу хәл Мотыйгулла белән Мәфрузаны якынайтмады да, ерагайтмады да. Халисәдән килгән хәбәрләр белән бүлешмәделәр, хәсрәт-кайгыларын уртаклашмадылар. Килен кунакка башта каенана йортына кайтып төшсә, аннан үз аталарында ял итте.

Кайчандыр Сөннәтче әбигә эченнән түгел, тышыннан да юньле теләк теләмәгән Харисага, аның түшәккә егылуын ишеткәч, кинәт әллә ни булды. Башта ул туксанын тутырып та җир җимертеп йөргән Мәфрузаның аяксыз калуына ышанмады. Аннан гына, эчке бер тоем белән, бу хәлләрнең чынлыгын аңлады. Аңлады да йөгереп килеп тә житте. Кодагый дигәне түр караватта, мамык мендәрләргә терәлеп, күрше-күлән белән сөйләшеп, хәер-фатихасын таратып утыра. Ничек тә аңа да алып калырга кирәк иде бу изгелеге белән дан алган карчыкның яхшы сүзен. Кызы Халисәнең—каенанасы, оныгы Камилнең әбисе дә иде бит ул...

—Кодагый,—дип сүз башлады Хариса, еламсырап кына.—Инде синең дә ахыр сәгатьләрең житә...

Тирә-яктагылар, бу ни тагын дигән кебек, аңа карап торуларын күргәч кенә, ул үзенең тагын бер хата эшләп ташлавын аңлады, әмма эш узган иде инде. Сөннәтче карчык кына әллә аны ишетмәде дә ,бик сагынган кешесен күргәндәй:

—Әле, Хариса, нәкъ менә синең турыда гына уйлап утырадырыем. Кеше җибәрттем, анысы юк булды, үзең күренмәссенме дип көттем... Юк ла, менә килгәнсен бит,—диде.—Мөхәммәтгалидән хат юкмы, кодагый?

Харисаның йөрәгенә май сыладылармыни: йөзләре яктырып, күзләре ачылып киткән кебек булды. Авыруның бик тә хәленә керергә теләгәндәй:

—Юк шул, юк, нигә килергә тиеш идемени? Бакчи, килгәненә атна-ун көн дә юк ич,—дип җавап кайтарды.

—Күнелгә килсә дөрес килә иде дә... Менә, юк икән бит әле... Тиешен тиеш кебек инде ул... Бик тә көткәнгәме соң?..

Карчыкның гаҗизләнеп әйткән бу сүзләре әле яна гына берни булмагандай сөйләшеп утырганнарның күнеленә сагыш индерде. Аның иң өлкән улын сагынганын, инде сугышка киткәннән бирле бер күрергә тилмереп, гомере узып киткәнлеген барысы да белә иде. Мөхәммәтгалинең өстеннән халык дошманы дигән кара тамга алынса да, туганнары белән күрешергә рөхсәт язуы бирелсә дә, кайтырлыгы калмаган, әнкәсенең исә ерак илләргә чыгып китәрлеге бөтенләй юк иде.

—Һе... кара син аны, ялгышканмын бит,—дип куйды ул үзалдына сөйләнгәндәй генә.—Тагын ике көн эчендә дә килмәсә, риза-бәхиллегемне кодагый үзең җиткерерсең инде.

Монарчы үзара бер юньле сүз әйтешмәгән ике гаилә эчендә шушы рәвешчә сөйләшеп утыру барысының күңелләренә бер җиңеллек тә китерде.

—Булмаганны, ни сөйлисең син?! Нинди ике инде ул?—диештеләр, кич җитсә дә, кайтып китәргә ашыкмаган күрше карчыклары.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә йорттан кеше өзелмәде. Сөннәт әбкәсе янында үлем көтү хәсрәте белән тормыш итү рәхәтлеге үзара буталган кебек булды: мөнәҗәт көйләүчесе дә, дога укучысы да күп иде, алар ялгысытып җибәргәндә, тыныч кына итеп, хәл-әхвәл дә сораштылар, дөнья турында да сөйләштеләр, әмма авыруның сәгатьтән сәгатькә бирешкәне, хәленең киткәннән китә барганы күренеп тора иде.

Өченче көнне, төш вакыты дигәндә, олы кызы фельдшер хатынга йөгерде. Күз яшьләренә буылып:

—Әнәйнең бөтен аркасы шарт та шорт килә, үзе акылында әле, һаман Мөхәммәтгалине сорый. Анысы да бахыр шушы көнне дә әнәй янына кайта алмый бит, үз хәле хәл,—дип өзгәләнде.

—Кан тамырлары шартлый башлаган инде алайса... Нык иде бит, бигрәкләр дә нык! Йөрәк түзгәнгә түзә алмаслык хәлгә килүдән бу... Соңгы сәгатьләредер, Маһикамал, шул улының хәбәре генә яшәтә инде аны.

Татар авылында чит-ят телне тәмам өйрәнеп, гореф-гадәтләргә күнеп беткән Шура түтәкәй әнә шулай сөйләнде.

—Көтеп торыгыз, мин хәзер!

Ул озак көттермәде. Ялтыравык тимер-томырларын төяп килеп тә җитте.

—И-и-и, яшисе дә яшисе әле сина, Мәфрузаттәй,—диде ул, карчыкның инде үлчәгечләр дә көчкә тойган кан басымын үлчәгәндә.

—Шура, тәрәзәдән кара әле, Хариса күренмиме?—дип сорады көч-хәл белән генә Мәфруза карчык.—Мөхәммәтгалиемнән хат килмәде микән? Килмәде микәнни соң...

Ул урынга егылганга нәкъ өч тәүлек дигәндә, Мөхәммәтгалидән кала күрәсе килгән бар кешесе килеп беткән, инде карчыкның соңгы өмете дә өзелгән иде. Менә ул тынсыз калгандай, селкенми ята башлады. Күнелне шик алды. Карчыкның үз-үзен тотышында көтелмәгән якка үзгәрешләр булмагач, бу хакта кызыксынырга кыенсындылар, тын гына көтә бирделәр.

Йортны тагын озын тынлык басты. Бераздан капканың киерелеп ачылуыннан тимерләре ыңгырашып куйган тавышка барысы да айнып киткәндәй булдылар. Инде, ишеккә карап, кем керер икән дип, көтеп тора башладылар. Шул чак, янадан хәл кергәндәй, барысын тагын бер кат исәрләндереп, Мәфруза карчык торып утырды, барысын бер кат күзеннән кичерде дә таныш кешесен күрмәвеннән гаҗизләнеп, ишелеп төшкәндәй генә караватына ятты. Күзләре ачык иде әле:

—Мөхәммәтгалиемнән хат...—соңгы сулыш алганда әйтелә башлаган җөмлә һавада өзелеп калды. Карчыкның башы йомшак мендәрләр йөзенә инде...

Кабаланып алынган тын шул арада кешеләрне ишеккә таба борды. Анда кочак киереп посылка күтәргән Хариса басып тора иде.

—Мәфруза кодагый, монда сиңа хат та, посыл...

Ул шунда үзенең нибары ярты минутка соңга калганлыгын аңлады. Йөрәген айкаган хәсрәткә түзә алмыйча, үгез кебек үкереп, урамга чыгып йөгерде. Анда, өске як урамнан, башкалар баргач, мин дә барыйм инде, дигән кебек, Мотыйк төшеп килә иде. Хариса бу посылка белән хатның моннан өч көн элек үк кайтканлыгын, әллә кайчангы үчләрне актарып чыгарып, эчке бер мәкер белән, көтсен әле дип көлеп иренең яшереп куйганлыгын белеп алган һәм качырылган урыныннан тартып чыгарып, кодагыена йөгергән иде.

Харисаның шушы ир белән узган гомеренең бөтен мәгънәсез сәгатьләре, үчләре, дошманлыклары башыннан кичкән кебек булды. Күзе томаланып, ул алга таба атлады һәм күркәләрен коеп, моңаеп калган нарат кәүсәсенә килеп төртелде. Чүт кенә чирәмлектә чемченеп йөргән каз бәбкәсенә басмады. Аларны саклап йөргән ата каз хатынның итәгеннән эләктереп алды. Хариса аны кумады, куркытмады, башыннан сыйпап, тынычландырып, итәкләреннән ычкындырды, көш-көш дигәләп, читкә җибәрде. Каз ысылдаган булып кына кыланды да яңадан балалары уртасына кереп басты.

Мәфруза карчыкка чәйгә дип коелган симез күркәләрдә казларның гаме юк. Бышылдашып, яшь чирәм өзүләрен беләләр. Йомшак кына исеп куйган җил кечкенә бер күркәне үләндә тәгәрәшкән бибиләр арасына куып кертте. Тәҗрибәсез бәпкә йомшак, ныгымаган борыны белән төртеп-төртеп карады да, таптап, өстеннән узды, егылды, торды, тагын егылды.

Алар да адәм балалары кебек дип уйлады Хариса. Кайда абынасыларын, кайда егыласыларын белмиләр... Аларны, әнә, әнкәләре, әткәләре саклый. Инде миңә шушы зур авылның кадерле бер әнкәсе юк...

Газизә келәттән соңгыларын алып кердем инде дигән иде, җыярга кирәк булыр әле бу күркәләрне... Кеше басканчы, каз йомышлаганчы. Нарат чәенең сихәтенә һичнәрсә җитми ди бит. Сөннәтче әби юкка шулай озак яшәмәгәндер. Әллә кешеләр догасы яшәтте микән?

Юк, аның айкалган күңелен чыра эссесендә генә кайнаган чәйләр басарлык түгел иде. Кылт итеп күңеленә улы Байракны сөннәтләгәннән калган пәке килеп төште. Йорт бүрәнәләренең чолан ягындагы ярыгына кыстырып куйган иде бугай. Кайтырга да алырга кирәк булыр...

Хариса догасын-фәләнен өйрәнеп, бу изге эшкә керешүне күңеленә чын-чынлап беркеткән иде инде. Дөньялыкта ахырынача алынмаган гафуны ахирәттә булса да алырга кирәктер. Бер гомерне кичте, икенчесе башлана гына кебек иде әле... Бер гомер кичте, икенчесе әле башлана гына иде шул...[1]

[1] Исхакый белән интертекстуаль диалог

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

(ТӨРКИ-ТАТАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА)

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар—гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар—сөйлә безгә!*
*Бабалар кабре янында күңел зар,*
*Аталар рухының армандәсе бар...*
*Кара туправ тулы мәзлум нидасы,*
*Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?*

Дәрдемәнд, 1906 ел.

## Тарих мәгънәсе

Бүген татарларның борынгы тарихын искә төшерергә, татар рухын тергезергә кирәк микән соң? Тормыш үзенчә бара, иске үпкәләрне яңарту нигә кирәк? Хикмәт шунда ки, тарихка кул селтәргә ярамый, бүгенге көн дә, киләчәк тә аның геннары эчендә ята. Тарих ул—бер үк вакытта аклау да, өмет тә. "Монголлар явы һәм Алтын Урда изүе рус җирләренең Көнбатыш Европаның алга киткән илләреннән артка калуы сәбәпләреннән берсе булган,—дип язалар "Россия тарихы" дәреслегендә.[34] Бу ялган гына түгел, бүгенге кыенлыкларны акларга тырышу да. Татарларга сылтап куясың да—бетте-китте, барысы да моңа ышаналар. Тарих хәрабәләрендә актарынырга теләүчеләр күп түгел, стереотипларга иярү җиңелрәк ләбаса.

Ә чынлыкта ничек булган соң? Чынлыкта исә кешелек тарихында чыңгызчылар империясеннән дә зуррак дәүләт булмаган, бу исә хәрби өлкәдә генә түгел, гражданнар белән идарә итү эшендә дә югары культура таләп иткән. Хәтта СССР да андый зурлыкка ирешә алмады. СССРның Көнчыгыш Европага һәм Кытайга күзәтчелек итү чоры булды булуын, ул чакта аның йогынты даирәсе чыңгызчылар империясе үлчәмнәренә якынайды, ләкин аңа җитә алмады. Чыңгызчылар шулай ук Персия, Әфганстан белән идарә иткәннәр, Багдадны яулап алганнар, Һиндстанга кергәннәр. СССР моңа омтылды, әмма аның моңа куәте җитмәде.

Чыңгыз хан белән Батый хан ирешкән бик шәп һәм ашкынулы хәрби җиңүләр бүтән кабатланмаган. Урта гасырларда беркем дә аларныкы кебек камил идарә системасына, диннәргә карата тигез карашка (бусы XXI гасырда да юк), коммуникациянең гаҗәеп системасына, икътисадны һәм сәүдәне үстерә торган салым системасына ия булмаган. Хәтта татарларны дошман күргән католик-

[34] А.С.Орлов, В.А.Георгиева, Н. Г. Георгиева, Т.А.Сивохина. История России. Учебник.– М.,2003, с. 58.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 7 санында.*

лар чиркәве дә Көнчыгышка китүче миссионерларга Дон буйлап Сарай аркылы барырга киңәш иткәннәр, чөнки бу юл куркынычсызрак булган. Татар ясагы (ун өлеш, ягъни 10%) турында бүген хыялланырга гына кала. Алтын Урданың төп салымы халыктан талап алынган әйберләр түгел, ә бәлки әйләнешкә салынган салым—тамга булган, русларның "таможня" сүзе шуннан килеп чыккан.[35] Каффа (Феодосия), Солдайа (Судак), Тана (Азов) шәһәрләрендә Генуя кешеләренең үз кварталлары булган, Пантекапеум (Керчь), Коп (Кубань) шәһәрләрендә Венеция кешеләре төпләнгән. Бу шәһәрләр халыкара сәүдә үзәкләре булып торганнар. Ибне Батутта язуынча, Каффа—диңгезнең гаҗәеп култыгы, ул анда "200 ләп зур һәм кечкенә, хәрби һәм йөк суднолары күргән. Бу—дөньяның мәшһүр гаваннарыннан берсе".[36]

Тарихчылар ни сәбәпледер чыңгызчыларның камил финанс ситемасын, кешелек тарихында беренче тапкыр кәгазь акчаның Хубилай хан вакытында кертелүен искә алырга яратмыйлар. Ул акчаның үрнәкләрен—үзәгенә ал төстәге хан мөһере сугылган квадрат рәвешендәге зур кәгазь битләрен "Эрмитаж"да күрергә мөмкин. Алар Алтын Урда биләмәсендә йөргәннәр һәм бәлиш дип аталганнар. Имеш, кыргый монголларның мондый нәрсә уйлап табулары мөмкин түгел, димәк моны акыллы кытайлар эшләгән. Өстәвенә, нәкъ шул вакытта Монгол империясе башкаласын Ханбалыкка (хәзерге Пекин) күчергәннәр, димәк, чыннан да кытайлар. Татарлар үзләре булмас бит инде?!

Алтын Урда чорында нигез салынган 100 дән артык шәһәр бүген Әстерхан, Волгоград, Саратов һәм башка шәһәрләр нигезендә ята. Батый ханныкы яки Бәркә ханнныкы кебек төзелешләр белән кайсы илбашы мактана ала? Андыйлар булмаган шул. Ханнар җимермәгәннәр, алар төзегәннәр. Төзегәннәр! Ибне Батутта болай дип язган: "Сарай шәһәре—иң матур шәһәрләрнең берсе, шәһәр бик зур, ул тигез җирдә урнашкан, халык белән тулы, базарлары—матур, урамнары—киң. Бер тапкыр без андагы бер аксакал белән, шәһәрнең колачын ачыкларга теләп, атка атланып шәһәрне әйләнеп чыкмакчы булдык. Без аның бер башында яши идек, иртән юлга чыктык, шәһәрнең икенче башына без өйләдән соң гына барып җиттек, өйлә намазын укып, ашап алдык та кабат кузгалдык һәм үзебез торган урынга кояш батканда гына кайтып кердек".[37] Алтын Урда шәһәрләренең башкалары турында да күргәннәр шушылай сокланып язалар. "Кыргый" халык шундый үсешкә ирешкән шәһәр культурасы булдыра алыр идеме соң?

Алтын Урда—татар тарихы гына түгел, аннан башка хәзерге заман Россиясе дә булмас иде. Татарлардан башка руслар Польшаның, Литваның, Пруссиянең, Швециянең бер өлешенә әверелерләр иде... Александр Блок үзенең "Скифы" шигырендә болай дип язган:

*Для вас—века, для нас—единый час.*
*Мы, как послушные холопы,*
*Держали щит меж двух враждебных рас*
*Монголов и Европы!*

Чынлыкта исә вакыйгалар бөтенләй башкача барган. XIII гасырдагы рус кешеләренә немец һәм француз рыцарьларын татар-монголлардан нинди мәнфәгатьләрдә сакларга кирәк соң? Ул рыцарьлар бит Руська һөҗүм иткәннәр, Рим папасы кушуы буенча православныйларны "грек йоласы схиз-

---

[35] "Таможня" соңрак барлыкка килгән сүз. XVI-XVII гасырларда «тамга» сүзе йөргән. Мәсәлән, рус патшасы Нугай Урдасына, халыктан җыела торган салымнарның зур булуын аклап, болай дип язган: "Тамга алу электән үк алып барыла, Мәскәүдә тамга алалар, ә инде Рязаньга яки Коломнага барсалар, алар Коломна наместнигыннан да тамга алалар. Бу синең кешеләргә ике тамга кебек күренә. Ә инде Владимирга барсалар, анда башка тамга алалар—Владимир наместнигыннан." Бирედә төрле килешләрдә «тамга» дигән сүз кулланыла: «тамгу», «две тамги»...

[35] Золотая Орда в источниках..., с. 126.

[37] Золотая Орда в источниках..., с. 143.

матиклары" дип үтергәннәр. Русларга аларны якларга бер сәбәп тә юк. Калкан—Русь түгел. Киресенчә, Алтын Урда русларны Европа тарафыннан йотылудан саклап калган. Нәкъ менә татарлар рыцарьларга һәм католикларга каршы калкан ролен үтәгәннәр. Әгәр дә Александр Невский Батый ханның улы Сартак белән дуслашмаса һәм татарларның атлы гаскәре аңа булышмаса, русларга ни булыр иде дә, алар бүген кем дип аталырлар иде һәм православие кайда булыр иде икән?.. Татарлар ярдәмен санга сукмаучылар җирләрен дә, культураларын да җуйганнар.

Бик кечкенә генә "татар ясагы" өчен рус кенәзләре үзләрен тевтончылардан саклауны таләп иткәннәр һәм татарлар аларны саклаганнар да. Хәтта Урдадагы "олы болгак" вакытында да, дәүләттә эшләр бозылып беткән чакта да алар, Көнчыгыштан бигрәк Көнбатыштан зур куркыныч янавын сизеп, ясак түләүдән туктамаганнар. Русьның Европаны татарлардан коткаруы теориясе никадәр яшәүчән булса, шулкадәр үк мөгънәсез дә. Киресен раслау дөреслеккә якынрак: күп гасырлар буе һуннар, төркиләр, татарлар көнчыгыштан кытайлар агрессиясен туткарлап торганнар. Алар, чыннан да, безнең эраның I гасырыннан башлап VIII гасырына кадәр кытайлар экспансиясе юлында калкан булганнар, аннан соң төре йөртүчеләр юлына калкан куйганнар.

"Үткәнгә төбәлгән караш безне кеше яшәешенең серләренә күмә",—дип язган Карл Ясперс.[38] Үзеңнең чын тарихыңны белү—нәрсәгә сәләтле икәнеңне ачыклау, рухыңны коллык хәленнән чыгару һәм үзеңне бу дөньядагы вазыйфаңа тәңгәл рәвештә тоту дигән сүз. Тарих—язмыш ул.

Әлбәттә, бүгенгене үз кулында тоткан кеше—үткәнгә дә хуҗа була, ул уйдырма тарихны көчләп тага ала, ләкин киләчәкне дә үз кулында тота дигән сүз түгел әле бу. "Сәясәт, тарих азат итмәгән очракта, тупас һәм бозык була,—дип әйткән сэр Джон Сили,—ә тарих, гамәли сәясәт белән бәйләнешне күздән ычкындырса, асылы алынып, әдәбият дәрәҗәсенә кадәр төшерелә". Тарих үз карашларыңда нык торырга мәҗбүр итә, вакытлы һәм узгучы нәрсәләрдән саклый. Ул—сәясәт өчен яхшы нигез, әлбәттә,—чын һәм гадел булган хәлдә. Язмышны алдый алмыйсың, үткәнең генетик код сыман киләчәкне билгели. Чын тарих урынына уйдырма язып татарларны тарихтан чыгарып ташлыйсың икән, нәтиҗәдә алдан фаразлап булмый торган билгесез киләчәккә дучар буласың, ул иртәме, соңмы синнән рәхимсез рәвештә үч ала. Россия, үткәннәр турында мифлар уйлап чыгарып, киләчәк турындагы мифлар белән яши. Ул үзүзе була алмый.

С. М. Соловьев үзенең күп томлы "Борынгы заманнардан башлап Россия тарихы" дигән китабына кереш сүзендә болай дип яза: "Тарихчының XIII гасырның яртысыннан башлап вакыйгаларның табигый җебен (бу—кенәзләрнең нәселара мөнәсәбәтләренең дәүләт мөнәсәбәтләренә нәкъ менә акрынлап күчә баруы) өзәргә һәм татар чорын кертергә, беренче планга татарларны, татар мөнәсәбәтләрен чыгарырга хакы юк, нәтиҗәдә төп вакыйгалар, аларның төп сәбәпләре ябыла".[39] Шул рәвешчә, өч гасырлык чорда руслар язмышына гына түгел, бөтендөнья процессларына йогынты ясаган татар дәүләтләре (Алтын Урда, Казан һәм башка ханлыклар) тарихы Россия дәүләтчелеге барлыкка килү вакыйгаларының чылбырыннан төшеп кала. Ләкин "тарихи вакыйгалар үзләрен үз тирәлекләреннән тик кенә тартып алырга ирек бирмиләр" бит.[40] Мондый ысул тупыйкка илтә. Шуңа да карамастан, рус тарих мәктәбе үҗәтләнеп шушы юлдан баруын дәвам итә. Ялгыш юл ялган нәтиҗәләргә китерә.

Икенче бер күренекле рус тарихчысы В.О.Ключевский Россия тарихын колонизация мантыйгына ярашлы рәвештә берничә чорга бүлә. "Россия тарихы,—дип язган ул,—колонияга әйләнүче ил тарихы. Аның колонизация өлкәсе дәүләт территориясе белән бергә арткан". "... Илнең колонияләнүе безнең

[38] Карл Ясперс. Смысл и назначение истории.—М., 1994, с. 29.
[39] С.М.Соловьев. Сочинения. Книга I.—М., Мысль, 1988, с. 54.
[40] Йохан Хейзинга. Об исторических жизненных идеалах и другие лекции.—Лондон, 1992, с. 32.

тарихның төп факты булган, аның барлык башка фактлары моның белән ерак яки якын бәйләнештә торганнар".[41] Ключевскийның тикшерү әйберсе, үзе язганча, дәүләт һәм халык булган: дәүләте—Россия халкы—руслар. Татарлар һәм аларның дәүләтчелегенә урын калмаган, гүяки алар Идел буенда, Уралда, Себердә һәм Көньяк рус далаларында яшәмәгәннәр дә. Татарларның атлы гаскәре болытлар өстеннән чабып йөргән микән мәллә? Алайса, Александр Невский яки Иван Калита кенәзлек итү өчен ярлыкны кемнән алганнар соң? Ключевский үзе үк: "Ул вакыттагы Төньяк Русьның кенәзлекләре мөстәкыйль биләмәләр түгел, татарларга ясак түләүче "олыслар" булганнар; аларның кенәзләре "иректе патша"ның холоплары дип аталганнар, Урда ханын бездә "иректе патша" дип исемләгәннәр".[42] XIII гасырдан башлап руслар Урда походларында катнашканнар. Ипатьев елъязмасында 1274 елда болай дип язылган: "Ул вакытта барлык кенәзләр татар ихтыярында иделәр". Әле тагын рус тарихы өчен татар факторының әһәмияте дә булмаган икән. Дмитрий Донской кем белән сугышкан икән алайса? Алдан ук ялгыш караш күренекле тарихчыларның да күзен томалый.

Лорд Актон болай дип әйткән: "Кеше язмышларының тукымасы тыгыз тукыла, анда буш күзәнәкләр калдырылмый, чөнки җәмгыять, табигатьтәге кебек үк, тоташ төзелмә ул..."[43] Татарларның һәм русларның тарихлары бер-берсеннән мөстәкыйль дип сөйләү идеологик мифлар өлкәсенә карый. "Бөек Яса", башкача әйткәндә, законнар Алтын Урдага көч белән кертелгән яки үзләре теләп кергән бөтен рус кенәзлекләрендә дә гамәлдә булган, акча һәм салым системасы да уртак, моның өчен халык исәбен алу үткәрелгән, кенәзләргә хакимият хан кулыннан тапшырылган, хәтта митрополитлар да, бу дәрәҗәдә расланыр өчен Константинопольгә барганчы ук, ханның ризалыгын алырга тиеш булганнар.

Россия тарихын, димәк ки, аның киләчәген дә татар факторыннан башка аңлап булмый. Россия төрки-татар империясе өверелешләренең соңгы чагылышы булып чыккан. Чумадан һәм эчке ызгыш-талашлардан үлеп баручы Алтын Урда үз төпкеленнән Мәскәү башлангычы рәвешендәге энергия куерыгы тудырган, бу куерыктан төркиләр үзләштергән шул ук территориядә яңадан империя баш калкыткан. "Русьның бәхете зур,—дип язган П.Н.Савицкий,—эчтән таркалу сәбәпле бетүгә йөз тоткан чакта ул башка берәүгә дә түгел, нәкъ менә татарларга эләккән. Татарлар—"нейтраль" культура тирәлеге, бу тирәлек "төрле аллаларны" кабул иткән һәм "теләсә нинди культуралар"га тигез караган, бу тирәлек Русь өстенә Ходай җәзасы буларак ишелеп төшкән, әмма милли иҗат чисталыгын бозмаган. Әгәр дә Русь "Иран фанатизмы һәм экзальтациясе" йоктырган төрекләргә эләккән булса, аның сынаулары да авыррак һәм язмышы да ачырак булыр иде. Әгәр дә Көнбатыш кулына төшсә, аның җаны тартып алыныр иде... Татарлар Россиянең рухи асылын үзгәртмәгәннәр; әмма ул чорда, алар өчен үзенчәлекле булган дәүләт төзүчеләр һәм хәрби оештыру көче сыйфатында, татарлар, һичшиксез, Руська йогынты ясаганнар. Үз үрнәкләрендәме, идарәчеләрнең каннарына кушылыпмы—алар Россиягә хәрби кимәлдә оешу, дәүләт-мәҗбүр итү үзеге төзү, тотрыклыкка ирешү хасияте; куәтле "урда" булу сыйфаты биргәннәр".[44] Россия татарлардан законнар, дәүләтчелек институтлары, хәрби эшне генә алып калмаганнар, "татар изүе" вакытында алар рухларын чыныктырганнар. Византия аның икенче чыганагы булган, әмма Византия ерак, ә татарлар—һәр көн, һәр сәгать руслар янәшәсендә.

Россия тарихының бер яртысы гына руснықы, икенче яртысы—төрки-татарныкы. Россия империясен төзүне башлап йөрүчеләргә Чыңгыз хан рухы күчкән, югыйсә алар мондый гаять зур максатка ирешә алмаган булырлар иде.

[41] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.I—М., 1987, с. 50.

[42] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 41.

[43] Лорд Актон. Очерки становления свободы.—Лондон,1992, с. 140.

[44] П. Н. Савицкий. Степь и оседлость. - "Лев Гумилев. Черная легенда" китабында, 467 нче бит.

Чыннан да, XIII һәм XIV гасырлар "Россиядә гомум төшенкелек, тар хиссият һәм вак мәнфәгатьләр, вак җаннар чоры"[45] булган. Кешеләр шәхси эшләр белән мәшгуль, ни фикер омтылышы, ни дәүләти идеяләр—берсе дә юк; тоташ саранлык, бу аеруча Иван Калитага (кушаматы акча янчыгы дигәнне аңлата) һәм аның нәселенә хас булган. Мәскәү кенәзләре турында В. О. Ключевский "искиткеч тотрыклы сәләтсезлек" белән аерылып торганнар дип язган. "Бу кенәзләрдә бернинди дә яктылык, батырлык һәм әхлакый олылык билгеләре юк. Беренчедән, алар бик тыныч кешеләр, алар сугышка теләмичә генә катнашалар, катнашсалар да, күбесенчә җиңеләләр генә; алар дошманнан имән диварлар, ә Дмитрий Донскойдан башлап Мәскәү Кремленең таш диварлары артында качып утыра беләләр, дошман һөҗүм итсә, алар ашкынып Переяславльгә яки аннан да ераграк барәр җиргә—Идел буена сугышчылар җыярга китәләр, Мәскәүне сакларга исә митрополитны һәм хатыннары белән балаларын калдыралар. Алар зур талантлар белән дә, гайрәт белән дә аерылып тормыйлар, әмма бу кенәзләрдә зур кимчелекләр яки көчле дәрт тә шулай ук юк. Бу аларны күп яктан уртачалык һәм җыйнаклык үрнәкләре итеп күрсәтә, хәтта аларның төшке аш вакытында аракы белән күбрәк мавыгулары да рус кешесенең Изге Владимир әйткән мәгълүм һәвәслеге дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Бу—Борынгы Русьның урта кул кешеләре, тарихи шәхесләрдән бигрәк хронология билгеләре дип әйтергә була".[46] Русларның холкы Мәскәү хезмәтенә татарлар һәм литвалылар, соңрак немецлар килү белән үзгәрә башлый. Явыз Иванның атасы Василий вакытында Литвадан кенәз Глинский (сүз уңаеннан, Мамай токымы) белән бер төркем халык килә, аларны Муром өязенә урнаштыралар. 1535 елда, Елена Глинская идарәсе чорында, Мәскәү патшасына хезмәт итәргә хатыннары һәм балалары белән 300 "литва" гаиләсе күчеп килә. Бу "литва" ның күбесе татар булгандыр,чөнки Мәскәү хәрби кешеләрне чакырган, ә Бөек Литва кенәзлегендә хәрби хезмәттә Мамай һәм Туктамыш урдачылары торган. Казанда әсирлектә булган Василий Темный чорында ханзадә Касыйм белән бөтен бер хәрби отряд юлга чыга, ул Ока буендагы Городецка урнаштырыла, биредә Мәскәү кенәзлеге составында Касыйм ханлыгы барлыкка килә. Явыз Иван күп кенә морзаларны чакырып, аларга Мәскәү, Боров, Калуга һәм башка өязләрдә борынгыдан ук русларныкы булган җирләрне өләшә... Ключевский исәпләве буенча, столбовой дворяннарны теркәүче Бәрхет кенәгәдә "Бөек рус" фамилияләре—33%, Польша-Литвадан чыккан, ягъни күбесенчә көнбатыш рус фамилияләре—24%, немец, Көнбатыш Европадан чыгышлылары—25%, татарлардан һәм гомумән көнбатыштан чыккан фамилияләр—17% тәшкил итә һәм 1%ын билгеләп булмый".[47] Польша-Литва дворянлыгының тамырлары көнбатыш русныкы түгел, татарныкы булганын исәпкә алсак, патша хезмәтендәге татарларның өлеше күп зуррак булачак. П.Н.Савицкий Л.Гумилевка болай дип язган: "Мәгълүм булганча, бөек Рус дәүләтен төзүдә зур роль уйнаган бөек рус дворянлыгының 30, 40, хәтта аннан да күбрәк проценты бу морзаларның, кенәзләрнең, хезмәтчеләрнең нәселеннән торган". Бу хәлнең Мәскәү мөмкинлекләрен никадәр үзгәртүен аның Новгород белән бәрелешү күренешләре дәлилләп тора. 1456 елгы походта Руса янында 200 мәскәүле Новгородның татар атлы гаскәре системасында сугыша белми торган 5 мең атлы сугышчысын тар-мар итә. 1471 елда Новгород 40 мең ополченец җыя, әмма аларны Мәскәүнең 4 500 сугышчысы тар-мар итә, сугыш кырында Новгородның 12 мең сугышчысы ятып кала. Бу күренешләрдә русларның новгородлылар кулланган традицион сугыш алып бару тактикасы белән атлы гаскәр сафында сугышуның татарлар керткән яңа тактикасы арасында аерма ачык күренә. Мәскәү гаскәрләрендә татарлар хәтта сан буенча да мөһим өлеш тәшкил иткәннәр. Маржерет мәгълүматлары буенча, XVI гасыр ахырында даими хезмәттә торган һәм жалованье алган 100 мең

[45] В .О. Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 49.

[46] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 47-48.

[47] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 193.

сугышчының 28 меңе Казан татарлары, чирмешләр һәм мордвалар булган.

Мәскәүгә Урдадан күбесенчә сәләтсез кешеләр түгел, киресенчә, мажаралар эзләүче, хәрби хезмәттә күтәрелергә теләүче, кешеләр белән тынышмаучан, үзсүзле кешеләр киткән. "Изү", Петр Савицкий сүзләре буенча, русның рухи үзенчәлеген коючы ут булган".[48] Татардан килеп чыккан рус фамилияләрен укып карасагыз, рус тарихы да аңлаешлырак булыр. Державин—Нарбековлар, Карамзин—Кара морза, Тургенев—Тургаевлар нәселеннән, тагын Аксаковлар, Огаревлар, Чаадаевлар, Кутузовлар, Тимирязевлар һәм башкалар, һәм башкалар.[49] Нинди мәшһүр исемнәр! Аларны санламый мөмкин түгел, аларны Россия тарихыннан чыгарып ташлап булмый, чөнки алар үзләре ук—Россия тарихы.

Борис Годунов турында Пушкин Рюриковичлар токымыннан булган көнчел Шуйский исеменнән болай дип язган:

*"Какая честь для нас, для всей Руси!*
*Вчерашний раб, татарин, зять Малюты".*

Татарның Морза Чет нәселеннән чыккан Годунов Россия патшасы булган һәм бу ул чорда табигый кабул ителгән, ә рюриковичлар -викинглар токымы, Киев Русена нигез салучылар—түбәнрәк рольләрдә булганнар. Инде Годуновны нәрсәдә булса да гаепләү мөмкин, бу—аның нәсел начарлыгы. Ул чыңгызчы булмаган. Тарихчылар Годуновның татардан чыкканлыгына шикләнеп бәхәс куерттылар. Мәсәлән, Р. Г. Скрынников фикеренчә, Ипатьев монастыре монахлары язган "Чет турында хикәят"не чынлыкка туры килүче чыганак дип санап булмый. "Чет турында нәсел әкияте язганда, монахлар Борис династиясенең кенәзләрдән килеп чыгуын тарихи нигезләргә, бер очтан яңа династиянең үз монастырена борынгы бәйләнешен күрсәтергә омтылганнар. Ипатьев китапчылары раславынча, Сарайдан Мәскәүгә барганда Урда кенәзе Чет, узып барышлый, Костромада православие храмына нигез салган... Годуновның ата-бабалары татарлар да, коллар да булмаган. Кострома кешеләре борынгыдан ук Мәскәү дворына боярлар булып хезмәт иткәннәр. Бу нәселнең өлкән тармагы—Сабуровлар Явыз Иван чорына кадәр муллыкка ирешкәннәр, ә кече тармаклары—Годуновлар һәм Вельяминовлар бетүгә таба барганнар".[50] Ихтимал, "Чет турында хикәят" бәлки "аз гына да ышануга лаек түгелдер", әмма автор дәлилләренең нигезе юк. "Кострома кешеләре"нең руслар да, татарлар да булуы мөмкин һәм өлкән тармак—Сабуровларның татардан чыккан кешеләр түгеллеген һәм башкаларны исбатлап бирү дә зыян итмәс иде. Хикмәт хәтта монда да түгел. Әгәр дә инде монахлар "Чет турында хикәят"тә алдашканнар икән, ни өчен Годунов нәселен рюриковичлар яки башка рус кенәзләре түгел, татар кенәзләре нәселе итәргә кирәк булган соң? Аңлатма бик гади—ул замандагы рус үзаңы татарның рус тәхетендә утыруын табигый хәл дип кабул иткән, бәлки яратмагандыр да, ләкин түзгән. "Нәселле кешеләр,—дип язган Николай Костомаров,—патша тәхетендә табигый татарны—Морза Чет токымын күреп чирканганнар, чөнки аннан да күренеклерәк нәселләр булган".[51] Чыннан да, Годуновка каршы оппозиция булган, ул патша тәхетенә, нәселлерәк кеше дип, Симеон Бекбулатовичны утыртырга теләгән. Литва шымчылары җиткергән: "Кайбер кенәзләр һәм боярлар, аеруча аларның башында торган кенәз Бельский һәм үзенең абыйсы белән Федор Никитич, тагын күп кенә башкалар, әмма барысы да түгел, Годуновны бөек кенәз дип танырга теләмичә үзара киңәшләшә башладылар, нindидер Симеонны сайларга те-

[48] П.Н.Савицкий. Степь и оседлость. - "Лев Гумилев. Черная легенда" китабында, 467 нче бит.

[49] Н.А.Баскаков. Русские фамилии тюркского происхождения. – М., Наука, 1979; А.Х.Халиков. 500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения. – Казань, 1992.

[50] Р.Г.Скрынников. Борис Годунов. – М., 1983, 5 нче бит.

[51] Николай Костомаров. Смутное время Московского государства в начале XVII столетия. 1604-1613. – М., 1994, с. 31.

[52] Русский архив, 1910, № 11, с. 345.

лилəр".[52] Аларга Мстиславский да кушыла, чөнки ул Симеон хатынының энесе. Явыз Иван 1574 елда Касыйм ханы Сəин-Булатны (чукындырылгач—Симеон Бекбулатович) патшалыкка куя, аңа "бөтен Русьның патшасы—бөек кенəз" дигəн титул бирə.[53] Ул ике ел патшалык итə, аннан соң бөек кенəз сыйфатында Тверь шəһəренə сөрелə.[54] Шуңа күрə боярларның кайберлəре "патша" ханы һəм Иван IV нең фатихасы Симеонга начар нəселле Годунов каршында зур өстенлеклəр бирə дип санаганнар",—дип нəтиҗə ясый Р. Г. Скрынников.[55] Борис Годуновның патшалык тарихы татар үткəне белəн араларны тиз генə өзмəгəн рус психологиясе күзлегеннəн караганда бик кызыклы. Шуңа күрə танылган тарихчы Николай Костомаров сүзлəрендə алдан ук ялгыш караш сизелə, ул болай дип раслаган: "Татар токымының Мəскəү тəхетендə килəчəк заманнарга төплəнеп калуы турындагы фикер Рус җиренең тарихын һəм аның изгелеген, кадерен белгəн кешелəрнең горурлыгына тигəн. Əмма эш бик оста майтарылган. Борис бөтен җир тарафыннан сайланган, таҗ кидерелгəн, дин йолаларын узган, патриарх һəм барлык руханилар тарафыннан хупланган патша буларак бик нык утырган. Ул тəмам законлы патша булып күренгəн һəм Рюрикның яки Гедиминнның бернинди токымына да халык сайлаган һəм чиркəү изгелəндергəн патшаның бөек хокукларына каршы үзенең нəсел өстенлеклəрен кую көченнəн килмəгəн".[56] Маржерет мəгълүматлары буенча, Борисны мəскəүлелəр яхшы идарəче буларак яратканнар. Кенəз Катырев-Ростовскийның шəхси хатирəлəрендə мөлаем кеше образы килеп баса: "Бу ир кеше гаҗəеп акыллы, тəмле телле, динле һəм ярлыларны ярата, күп тəзи, ул үз державасына күп ярдəм кылган һəм күп искиткеч нəрсəлəр иҗат иткəн". Явыз Иваннан соң Мəскəү дəүлəте тынычлыкка мохтаҗ булган һəм Борис Годунов нəкъ менə шундый идарəче булып чыккан. "Элеккерəк буын Борисны безгə караганда югарырак бəялəгəн,—дип язган С. Ф. Платонов.—Бу буынның Борис идарə иткəн бəхетле чор, аның күңелгə ятышлы шəхесе турында хатирəлəре яңа булган һəм ул шуңа таянган. Борисның замандашлары аның сөйкемлелеген аның оныкларына караганда ныграк тойганнар, əлбəттə. 1598 елгы собор аны аңлы рəвештə сайлаган һəм нəрсə сайлаганын бездəн яхшырак белгəн".[57] Борис Годунов хəзергəчə билгеле булмаган яңа идеялəр əйткəн. "Безнең барлык җирлəребездə дə икмəк муллыгы, гаугасыз тормыш һəм барсына да тигез рəвештə иминлек, тынычлык булсын",—дигəн ул.[58]

Борис Годуновны тəхеттəн төшерүнең сəбəбе аның чыгышы буенча татар булуында да яки аңа Дмитрийны үтерүне сылтауда да түгел (моны исбатлау өчен дəлиллəр аз). Сəбəп 1601-1603 елларда игеннəр уңмавында, бу бөтен рус җирен тетрəндерə. "Халыкның ни ашаганын Ходай үзе генə белə: үлəн, печəн, хəтта хайван һəм кеше мəетлəре дə, моның өчен кешелəрне хəтта махсус рəвештə үтергəннəр".[59] Икътисад бу казаны күтəрə алмый, аннан соң сəяси тетрəнүлəр башлана һəм Бориска карата нəфрəт туа. Борис Годунов яисə Симеон Бекбулатович шəхеслəренə мөнəсəбəт нинди генə булмасын, ул аларның чыгышлары буенча татар булганлыкларына бəйле түгел.

*Дəвамы бар*

[53] Бу вазифа земский боярларның думасы рəисе вазифасына туры килə. Моңа кадəр земщина башына əсирлеккə төшкəн Казан патшасы Ядегəр куелган була.

[54] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 168.

[55] В.О.Ключевский. Сочинения в девяти томах. Т.II..., с. 122.

[56] Николай Костомаров. Смутное время Московского государства ..., с. 31-32.

[57] С. Ф. Платонов. Полный курс..., с. 274.

[58] Р. Г .Скрынников. Социально-политическая борьба в Русском государстве в начале XVII века. –Л., 1985, с. 46.

[59] С. Ф .Платонов. Полный курс..., с. 283.

# МИЛЕК ҺӘМ ИРЕК

ӘХМӘТ ГАЛИЕВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

*75 ел элек ошбу милләттәшебезнең дөньяга килүе республика өчен бик тә кирәк булган.*

*Татарстанның яңа чор тарихын гавәм-массалар язмады. Берничә дистә мең кешенең ихлас теләктәшлеге; берничә мең кешенең, оран арты оран салып, урам-мәйданнарда кайнавы; бернечә йөз кешенең нинди дә булса тәгаен эш майтаруы — Татария-Татарстанны Татар ыстаны итеп менә шушылар үзгәртте. Һәм тагын, әлбәттә инде, олы тәвәккәллек, олы фикер иясә олы гамәлләре белән катнашкан, исемнәрен һәркайсыбыз белгән бер-ике дистә кеше.*

*Аларның берсе, һичшиксез,* ***Әхмәт Мөхетдин улы Галиев****.*

*Яңа Татарстанның көпшәк мускулларына егәр иңдерәчәк олы гамәленә керешкәндә ул Казан компрессор заводына инде 18 ел җитәкчелек иткән, өч орден белән бүләкләнгән, заводын дөньякүләм таныткан көчле һәм тәвәккәл директор була.*



**—Әхмәт абый, әйдәгез, шул 1991 елның җаенә кайтып килик әле. Татарстан инде бер ел чамасы суверен. Ләкин аның, район промкомбинаты, сөт заводы кебекләрдән гайре, завод-фабрикалары юк. Татарстан карамагына беренче булып сезнең завод күчте. Ни уйлап алындыгыз сез бу эшкә?**

—Икътисадның ни икәнен аңлаганнан килеп чыкты бу. Байлыгың, милкең юк икән, синең бер хокукың да юк... Суверенитет турындагы Декларация кабул ителгән елны безнең заводтан СССРга 5 миллион сумга якын акча китә иде. Татарстанга күп булса шуның 10 проценты күләмендә калгандыр.

**—Соң, Әхмәт абый, сезнеке генә китмәгән ләбаса. Андый заводлар күп булган бит инде ул.**

—Күп иде, бик күп иде. Республикадагы предприятиеләрнең 80 проценты — Союзга, 18 проценты — Россиягә һәм нибары 2 проценты гына Татарстанга карый иде.

**—Ул йөзләрчә директорның моңа исе китмәгән ләбаса. Берсе дә кычытмаган башка тимер тарак әзләмәгән. Нигә сезнең генә баш кычытты икән?.. Тагын бераз арткарак чигик әле без. 1990 елның 30 августына. Декларация кабул ителгәнне белгәч, ни хис иттегез?**

—Ул көнне безнең гаиләдә бәйрәм булды.

*Гаиләдә тагын: Әхмәт абыйның хатыны, тиздән «Тулгак» дигән романы белән популярлык казаначак педагог Гөлчәчәк Галиева һәм Шамил, Булат атлы инженер уллары.*

**—Бу хакта хәбәре килеп ирешкәч кенә белдегезме, әллә алдан ук ишетеп, көтеп алдыгызмы?**

*Әңгәмәдәшем миңа озак кына көлемсерәп карап тора.*

—Ул көнне Ирек мәйданында суверенитет даулаган халык эчендә безнең егетләр-кызлар да бар иде. Безнекеләр генә дә түгел. Сер сыйган егетләр, Сәмигуллин, Бәйрәмов кебекләр аша мин башка заводларга да хәбәр салдым. Ул вакытта артык шаулап, үземне күрсәтеп йөрү кулай түгел иде.

Тәгәрмәчкә таяк тыгарга теләүчеләр бар иде. Монысын соңыннан гына белдем: партком секретаре да әнә тугыз ел буе өстемнән анонимкалар язып яткан икән.

Кичкә таба үзем дә мәйданга баргалап йөрдем. Машинаны читтәрәк калдырадыр идем дә, әйләнеп килә идем. Шул һаваны сулап, шул татлы көтү киеренкелеген тоеп.

**—Йөрәк түзмәгән инде. Ярый, хуш, теге эшкә нигә беренче булып тотынуыгыз аңлашылды хәзер. Тик... каян килгән ул сезгә мондый аң? Җитәкче кешегә?**

—Милли хиснең тамыры балачакта инде аның. Гармун белән дә кермәде микән әле ул? Безнең нәселдә гармун уйнамаган кеше юк. Мин дә шул татар көйләре уйнап, татар җырлары җырлап үстем... Аннан, иң шәп милли тәрбияне миңа урыс малайлары бирде. 5 нче класста Иске Чүрилегә йөреп укый башлагач. Хәтта дус булып йөргән малайларда да татарларга карата кимсетүле мөнәсәбәт үзен сиздерми калмый иде... Мине бик тә Алексейга әйләндерәселәре килде. Шулай дип дәшәләр, мин җавап бирмим.

—Алексей! — дип арттан килеп тоталар. — Я же тебя!

—Какой я тебе Алексей? — дим инде. Шөкер, моңа бирешмәдем. Бер көнне кайтышлый ике малай миңа ияреп китте. Сөенәм, үз итеп, озата баралар бит, дим. Ә алар мине кыйнамакчы икән. Ләкин үзләренә күбрәк эләкте.

**—Бу җәһәттән Разил Вәлиев белән тәңгәллек бар икән бит. Аңа да беренче милли сабакларны рус малайлары биргән. Түбән Камада укый башлагач...**

—Очраклы бер хәл генә түгел бу, димәк... Заводта мин, баш инженер чакта да, директор булгач та, татар кешесе белән бервакытта да урысча сөйләшмәдем. Бары татарча гына сөйләшә торган идем. Янында торганнарның моны өнәмәвен сизгән хәлдә дә.

**—Еш кына моның киресен күзәтәсең шул. Редакцияләрдә татарча белгән, ләкин русча сөйләшә торган бер-ике татар кызые яки малае була. Милләт, милләт дип лаф орган егетләребез дә шуларга дәшкәндә русчага күчәләр инде! Мескенлек куәтле, шаукымга бик тиз бирелебез.**

—Үткәндәге буйсынып яшәүләр, коллык чаткылары үзен сиздерә шул ул. Марсель Сәлимҗанов белән гәпләшкән истә. Мин, завод директоры, татар театрының баш режиссерын Татарстанга суверенитет кирәк дип үгетләп маташам! Юк, без ничек Россиядән башка яши алыйк, ди инде. Соңыннан фикере үзгәрде кебек. Юкса театр үзенең спектакльләрен Татарстанда куя инде, читкә гастрольгә генә чыгып керергә мөмкин. Ә безнең завод бөтен продукциясен диярлек Союзга эшли, һәм әле материаллар һәм комплектлау әйберләрен дә меңнән артык предприятиедән ала торган иде.

**—Әйе, хәзер менә төп мәсьәләгә күчсәк тә буладыр. Чыннан да, шундый четерекле эшне ничек башкарып чыга алдыгыз сез? Ничек тәвәккәллек җитеп тотындыгыз? Нидән башланды бу, беренче булып сезгә кем тәкъдим итте?**

—Миңа тәкъдим ясаучы булмады.

**—Ничек инде, суверенитет Татарстан дәүләте тарафыннан игълан ителде бит, дәүләт суверенитеты бит ул. Һәм... шуннан соң бер еллап вакыт үтеп тә... Агайлар безнең дөньяны колхоз икътисадына таянып күтәргә уйлады микәнни?**

—Дөресен әйтим, минем үземдә дә башта икеләнү-фәләннәр булмады түгел. Чөнки зур заводлар Татарстан эчендә генә яши алмый ул. Әмма фикер барыбер күчү ягына авышты. Әгәр дә без икътисади яктан бәйсез булсак, эшебезнең нәтиҗәсе тулаем үзебезгә калып бара, ул инде кешенең тормышын рәтләшә, аңа торагын да яхшыртырга, кием-салымын да алырга, укырга да мөмкинлек бирә... Ул чакта минем күз алдымда гел Финляндия тора иде. Россиянең колониясе булган Финляндия революциядән соң аннан аерылып чыга. Шуннан бирле үсеш параллель бара. Россия әнә һаман мантый алмый, бәпбәләкәй Финляндия исә халкын мул, тыныч тормышта яшәтә торган бай һәм имин бер илгә әйләнде.

**—Әйе шул, бик гыйбрәтле мисал. Берсеннән-берсе кыйммәтлерәк файдалы казылмалар өстендә утырган Россия һәм урманнан гайре бер байлыгы да булмаган Финляндия!**

—Мәсьәләне үзем өчен хәл итеп бетергәч, Кабминга, премьер-министр Сабиров янына бардым. «Мөхәммәт Галләмович, менә шундый хәл бит, безнең бөтен байлык СССРга һәм Россиягә күчеп бара, безнең үзебезгә берни дә калмый, мин шушындый нәрсә оештырмакчы булам, сез моңа каршы түгелме?» — дидем. Ул исә: «Бик әйбәт булыр», — диде.

**—Моны бит алар әллә кайчан үзләре уйларга тиешләр иде!**

—Уйлавын уйлаганнардыр инде. Юкса Декларацияне кабул итмәсләр иде.

**—Соң бит инде бер еллап вакыт үткән! Әгәр шунда компрессор заводы директоры Галиев түгел, бүтән фамилияле кеше булса? Мондый тәкъдим белән беркем дә килмәсә? Рафаэль Хәким тикмәгә генә, икътисад өчен җавап биргән җитәкчеләрне шелтәләп: «Без икътисадта үз сәясәтебезне кора алмадык, уртак икътисади кыр дип мавыктык», — димәгән инде. «Тоталар да Мәскәүгә чабалар, ни табалардыр анда?» — дип тә әйткән иде ул.**

—Мәскәү юлын мин дә күп таптадым. Эшли башлаган көннән алып. Акча сорап. Үзебезнең министрлык кабинетларында да, Госпланда да, КПСС Үзәк Комитетында да күп тапкырлар булдым. Шул кабинетларга йөргәндәге хурланганнарымны әйтеп-сөйләп бетерә торган түгел... Үзебез хуҗа булырга тиеш дигән уй әнә шул интегүләр нәтиҗәсендә дә туган инде ул.

Авиация институтына кадәр мин Авиация техникумында укыдым. Кыюрак, хөррәк фикер йөртү шунда туа башлагандыр ул. Анда безгә Мәскәү ВУЗларыннан Казанга сөргенгә җибәрелгән укытучылар да дәрес бирде. Алар кыюкыю фикерләр әйткәлиләр иде.

**—Ничек курыкмаган соң алар? Тоташ күзәтү, шымчылык заманында?**

—Алар бит тора салып кына сөйләми. 5-6 егетне аерып алып, кайвакытны берүзең белән дә шөгыльләнәләр, төрле-төрле сораулар биреп, алдан сине сыныйлар. Мәскәү университетыннан килгән Смолин тарих укытты безгә. Керәшен татары булып чыкты ул. Менә шул Смолин, икәүдән-икәү генә чакта, Сталинның кем икәнлеген әйтергә җөрьәт итте... Рус теленнән Кәрим Тинчуринның хатыны Заһидә Гәрәевна укытты безне. Ул сәясәткә кагылышлы әйберләр сөйләмәде. Ләкин, берничә очрашудан соң, үземне генә алып калып, болай диде: «Бу нәрсәләр белән ваклашып йөрмә син, урыс теле буенча белгәнең болай да бик җиткән, математика, сопромат кебек нәрсәләрне ныгытып укы». Шул заманда, урыс телен укып торма, дип әйтә алырга кирәк бит! Бу инде миңа карата бик зур ышаныч та... Заһидә апаны соңыннан да онытмадым мин, кулдан килгәнчә ярдәм иткәләп тордым...

**—Шәп. Сөбханалла!.. Ярый, Сабиров сезнең тәкъдимне хуплады. Завод үзе бар бит әле,—сезне күралмаган партком секретаре белән.**

—Партком секретаре теш-тырнагы белән каршы иде. СТК — хезмәт коллективы советыннан башладым. Председателе бер яһүд малае иде. Аның белән байтак кына сөйләшү алып барылды. Күндердем мин аны. Төп дәлилем шул булды: Мәскәү хезмәт хакын 380 сумнан арттырырга рөхсәт итми. Юкса бу безнең көчебездән килә. Татарстан юрисдикциясенә күчсәк, аны 480 сумга җиткерергә мөмкин булачак... Завком председателе дә бар бит әле, марҗа хатыны. Аны да күндердем. Башта менә шулай лидерларны өзерлисе булды. Аннары, цехлардан, бүлекләрдән делегатлар сайлап, конференция җыйдык. Шунда чыгыш ясап, бу эшнең безгә нилектән файдалы булуын аңлатып бирдем. Без Россиянеке булмагач, безнең компрессорларны кем алыр? Элекке багланышларны җуячакбыз, безгә комплектлаучы детальләрне бирмәячәкләр бит — сораулар һәм чыгышларда яңгыраган төп фикер шул булды. Мондый уйлар үземне дә озак кына бимазалап, җавабын табып куйган идем инде. Килешү буенча эшлисең. Аларга үз продукцияләрен башка җиргә җибәрделәр ни дә безгә җибәрделәр ни, — акчасы гына вакытында килсен. Бөтен дөнья

шулай яшәп ята ләбаса. Конференциядә дә шуны әйттем инде.

**—Мондый «дәлил»дән референдум алдыннан бик оста файдаландылар. Татарстанда теге юк, Татарстанда бу юк, ничек итеп мөстәкыйль яши алсын ул, диделәр. Һәм шуның белән шактый халыкны куркуга салдылар. Гаҗәп, моңа сезнең кебек чатнатып җавап бирү дә булмады ул чакта. Юк икән, сатып алырбыз, йә, кайсы илнең бөтен нәрсәсе дә җитеш соң, дип... Монда нәтиҗә ничек булды?**

—Тавышка куйгач, өчме, дүртме кеше каршы тавыш бирде.

**—Партком секретаре сөйләдеме?**

—Юк, курыкты. Бер конструктор каршы чыгыш ясады, бер инженер һәм берничә эшче. Аларның кем тарафыннан әзерләнгәнлеге күренеп тора иде.

**—Бу конференцияне өзәргә теләүчеләр булмадымы соң? Мәскәүдән? Министрлык басым ясамадымы?**

—Ул чакта яңа җитәкче оешма — Россия департаменты барлыкка килгән иде инде. Аннан берөзлексез Татарстанның суверенитетына каршы директивалар җибәреп тордылар, мин исә аларны өстәл тартмасына сала бардым.

**—Шуннан соң ничек дәвам итте бу эш?**

—Июль башында, 3 июльдә булса кирәк, Татарстан Министрлар Кабинеты безнең заводны Татарстан юрисдикциясенә күчерү турында карар кабул итте.

**—Моны үстерергә, җәелдерергә кирәк бит инде. Хөкүмәт ниләр майтарды?**

—Шуннан соң шәп кенә китте инде ул. Бөгелмәдәге батырма насослар заводы директоры, акыллы бер урыс малае Прошечкин белән мин үзем сөйләштем. Күндерә алдым.

**—Ничек шулай тиз ризалашты?**

—Соң, файдасы күренеп тора ич. Аның да эш хакын арттыру мөмкинлеге бар, ә Мәскәү рөхсәт итми... Бөгелмәгә барыр алдыннан Сабиров белән киңәштем мин үзе. Шулай эшләсәм мөмкинме, дип. Бик әйбәт булыр, диде. Аннан соң Казандагы «Вакуummаш» директоры Капустин белән, чуваш егете, сөйләштем. Элек минем берләшмәгә кергән предприятие бу, шуңа күрә Капустинның да, башка егетләренең дә миңа мөнәсәбәтләре әйбәт иде. Тиз күндердем. Без өчәү булгач, эш җиңелрәк китте. «Татнефть»нең генераль директоры Галиев белән сөйләшүне инде Сабировлар алып барды. Аннары берәм-берәм чакырып, Түбән Кама заводлары җитәкчеләрен ризалаттылар.

Горбунов заводы директоры Копылов янына мин бардым. Аның элек бездә булганы бар иде. Мин аның заводына, нарядсыз-нисез генә, соңгы модель, бик әйбәт эшли торган өч компрессор җибәргән идем. Баргач, бергәләп кайбер цехларны карап йөрдек. Аннары мин шул ук мәсьәләне кузгаттым. Әмма Виталий Егорович ризалашмады. Авиация заводы Россиясез яши алмый, безнең бу компрессор заводы түгел, диде.

**—Ахыр чиктә Россия аларга төкерде бит, Татарстан ярдәм иткәләде әле.**

—Монысын күрмәде инде ул. Үзен-үзе атты.

**—Ничек инде — атты?**

—Атылды, әйе, ау мылтыгыннан. Заводларны җимерү-корыту башлангач, ул моны кичерә алмады...

Татарстан юрисдикциясенә күчү 2-3 ел буе әйбәт кенә барып, азакта Татарстанга караган предприятиеләр өлеше 92 процентка җитте. Сабиров белән киңәшкәннән соң, «Радиоприбор» заводының директоры Ямалетдиновны шушы Татарстанга караган предприятиеләр ассоциациясенең президенты иттек. Ямалетдинов вафат булгач, мине куйдылар.

**—Татарстанга күчкәннән соң акча арта дигән вәгъдәгезне үти алдыгызмы соң?**

—Икенче айда ук эшләдек.

**—Кыен яклары булдымы? Көтелмәгән хәлләр?**

—Булды! Безгә түләнә торган акчаны шуннан соң Үзәк банк аша күчерә башладылар. 100 миллион сум чамасы булса, 3 әр, 4 әр, 5 әр ай йөри торган иде.

**—Аңарчы ничек иде?**

—Дүрт көн эчендә килеп җитә иде. Бу хәл бик зур кыенлыклар тудырды. Акчаң юк икән, эшчеләргә дә түли алмыйсың, материаллар өчен дә, электр өчен дә...

**—Галиев безне ялгыш юлдан кертеп җибәргән, дип әйтүчеләр булмадымы соң?**

—Әйтергә теләүчеләр, бәлки, булгандыр да инде... Безгә ул чакта Нәфиев бик ярдәм итте. Казан прокуроры, соңыннан Республика прокуроры. Ярдәм итегез, менә шундый хәл, дип, мин турыдан-туры аңа мөрәҗәгать итә торган идем. Ул, запрослар җибәртеп, гаеплене таба, һәм акча терәлгән җиреннән кузгалып китә торган иде.

**—Мәрхүм Сәйфихан әфәнде безнең референдумны Мәскәү прокурорларыннан саклап калган берничә кешенең берсе дә бит әле... Күрәбез ки, яңа Татарстан тарихындагы олы эшләрнең нәтиҗәсе гел аерым шәхесләргә бәйле. Кәнәфидә тәвәккәл кеше утырамы, куркакмы, булдыклымы, җебегәнме...**

—Ул гына да түгел әле, Татарстан карамагына күчеп ярты ел да үтмәде, бездән бөтен хәрби заказларны да алдылар. Аннулировать иттеләр. Алар исә бөтен эшләп чыгару күләменең 38 процентын тәшкил итә иде. Ракета техникасына, Хәрби-Диңгез флотына һәм авиациягә караган заказлар бу. 1570 кеше эшсез торып калды. Халык шаулый! Мәскәү шул рәвешле безне аяктан егарга уйлагандыр инде. Без нишләдек? Яңа төр техниканы бик тиз эшләү ысулларын таптык. 2-3 ай эчендә бөтен кеше бүтән төр продукциягә күчеп эшли башлады. Акча да ала башладылар. Теге эшсез торган айлары өчен дә уртача эш хакы түләп бардык әле.

**—Димәк, чыннан да, вәгъдәгә хилафлык килмәгән. Мәскәү моның өчен нык тырышкан хәлдә дә.**

—Әйе. Аяк чалырга маташулар тагын да булды ул... Без Татарстанга күчкәч, хәрби вәкилләр без эшләгән хәрби продукцияне кабул итми интектерделәр. Гаеп юк җирдән гаеп тапкан булып. Хәрби булмаган продукция белән дә кыенлыклар чыга ала иде, чөнки Госприемка Россиягә буйсына. Ләкин безнең эшне кабул итеп алучы мишәр егете белән уртак тел таптык без.

**—Мәскәү белән бәйләнешләр бөтенләй өзелдеме?**

—Юк, өзелмәде. Безнең завод «Аконхол» дигән, 80 предприятиене берләштергән яңа концерн составында да калды. «Аконхол» безне төрле детальләр, насослар белән тәэмин итеп тора иде. Шуның өчен табышның бер өлешен аңа күчереп бардык. Завод, Татарстан Министрлар Кабинеты һәм концерн арасында өчьяклы килешү төзелде.

**—Яңадан Мәскәү кулына керү түгелме соң бу?**

—Һич юк. Элек табышның 35 процентын Союз бюджетына күчерә идек. Аның безгә тиене дә әйләнеп кайтмый иде. Татарстан юрисдикциясенә күчкәч, бу 35 процентның 25е Татарстан бюджетына керә башлады. 5 миллион сум чамасы бу. 10 проценты заводның үзендә калды... Теге концернга килгәндә, мин аның җитәкчесенең урынбасары идем. Заводыбызны Татарстан карамагына күчергәч, концерн идарәсен җыйдык. 58 директор алдында чыгыш ясап, моның сәбәпләрен аңлаттым. Сез дә үз республикагызда, Украинамы, Әрмәнстанмы бу, шуны эшли аласыз, дидем. Күпләр соңыннан, безнең тәҗрибәне файдаланып, үз республикалары юрисдикциясенә күчтеләр.

**—Димәк, сез Союз күләмендә дә беренче булып чыккансыз.**

—Әйе.

**—Аннары ничек барды сезнең эшләр?**

—1991-95 еллар минем иң яратып эшләгән чор булды. Бернинди аяк чалулар, чикләүләр, чабудан тартулар тоймыйча. Авыр вакыт иде үзе, Россиядә акча түләүләр начарланды. Без экспортка эшләүгә күчтек. Экспортка элек тә чыгаргалый идек. Тик хәзер инде — турыдан-туры үзебез. Лицензия алдык, заводта экспорт бүлеге булдырдык. Экспорт өлеше 38 процентка җитте, һәм шуннан кергән акча бөтен чыгымнарны да каплап барды.




*Әхмәт Галиев «Казан утлары» журналының юбилей кичәсендә чыгыш ясый. 1992 ел.*

**—Икътисадта эшләр кирегә сүтелү ничек башланды?**

—Гайдар премьер-министр вазифасын үз өстенә алгач башланды ул сүтелүләр. Гайдар хөкүмәте чын-чынлап икътисадны җимерү хөкүмәте иде. Без Сабиров белән аның үзендә дә булдык. 1993 елда бу. Минем баруның максаты заводта янә хәрби продукция җитештерә башлау мәсьәләсен хәл итү иде. Ләкин миңа авыз ачып сүз әйтәсе дә булмады... «Чем скорее разрушится, тем лучше» — хәрби промышленность турында Гайдар әнә шулай диде. Ачыктан-ачык. Аларга тулаем совет промышленность системасын да җимерү кирәк иде — базар икътисадын корыр өчен. Базар икътисады исә табыш алуга гына юнәлдерелә. Ләкин шул ягы да бар: Америка, Англия, Франция кебек илләрдә эшләп чыгарылган продукция бәһасенең 60-70 проценты хезмәт хакы түләүгә китә. Ә бездә аның 30 проценттан артканы юк әле. Кеше үзенең эшләгән җирендә торак сатып алырлык, гаиләсен әйбәт шартларда яшәтерлек хезмәт хакы алмый бездә. Беркадәр социаль якны да кайгыырткан элекке системадан да аерылдык, базар икътисадының да һаман кереп җитә алганы юк әле. Иле әллә нинди ил аның!

**—Һаман шул, шактый гына мөстәкыйльлеккә ия булып та, сукырларча Мәскәүгә ияреп бару нәтиҗәсе инде. Безгә үзгәрәк юлдан китәргә кирәк булгандыр.**

—Нинди юл белән, мәсәлән?

**—Профессор Әгъдәс Борһанов — завод-фабрикалар, төзелеш оешмалары һ. б.га хезмәт коллективларын хуҗа итү тарафдары. Заманында ул моңа Татарстанның олы түрәләрен дә димләп караган иде, колак кына салмаганнар.**

—Җитәкчеләре продукциянең бөтен нечкәлекләрен, технологияне, икътисадны шәп белгән, бирелеп эшләгән хәлдә, предприятиене коллективка бирергә була. Бу очракта инде дәвамчанлык та саклана, яшь кадрлар да үсеп чыга. Һәм — халык милеккә ия була. Хәерче булмый. Фәкыйрь халык белән берни дә эшли алмыйсың.

**—Эшче белән завод директорының эш хакы арасында аерма зур идеме әлек?**

—Зур иде. Мин, беренче категорияле завод булгач, 330 сум ала идем. Эшчеләр 200 сум тирәсе ала иде.

**—Шул аерма зурмы? Ә хәзер директорлар күпме ала?**

—Монысын мин әйтә алмыйм инде. Хәзер хезмәт хакын директорлар үзләре белгелиләр һәм сер итеп саклыйлар. Күп алалар дисәк, ялгышмабыз.

**—Әхмәт абый, ку-у-у-у-у-у-уп алалар дисәк, бигрәк тә ялгышмабыз.**

—Шулайдыр, эшчеләрдән йөзләрчә тапкыр күбрәк алучылары да бардыр дип уйлыйм.

**—Татарстан җитәкчеләренең иң зур хатасы ни булды?**

—Мөстәкыйльлекне якламау. Чигендек. Нык чигендек. Төп гаеп — хөкүмәттә, югарыда утырганнарда. Яуланган бөтен нәрсәне дә диярлек җуйдык. Йә, шунда бер генә депутат булса да мандатын биреп чыгып киттеме? Ник без болай эшлибез дип әйтүчеләр булдымы?

**—Әйтүчеләр булды, Әхмәт абый. Бөтен залдан 2-3 бөртек депутат.**

—Нәрсә булды, кемнәр булды? Бу кешеләрдән эш кетеп утырудан бернинди файда юк. Иң әүвәл, Дәүләт Советындагы депутатлар кем икәнлекләрен аңлап бетермәделәр дип уйлыйм. Хөкүмәт башында утырганнар да, үзләре баеп, күбрәк шул байлыкларын һәм привилегияләрен саклап калу турында уйладылар дип беләм мин... Дудаевның ни өчен ракета белән башына җиттеләр? Чөнки республиканың мөстәкыйльлеген бирмәс өчен күп тырышты. Аның ялгышы, минемчә, фәкать шул булды: чит илдән килгәннәрне үзенә керттә, шулардан үзенең мөстәкыйльлеген җуйды. Әгәр дә үз халкына таянып кына көрәшкән булса, Россия дә бүтәнчәрәк караган булыр иде әле.

**—Сез башлаган теге олы эштән ни калды, Әхмәт абый?**

—Берни дә калмады. Янә бар да Россия кулында хәзер.

**—Алайса, «Казан утлары»нда тарих өчен бер язма булса да калсын әле менә. Бәлки балалар яки оныкларга кирәге дә чыгып куяр.**

—Шулай була күрсен!

*Техник фәннәр докторы Әхмәт Галиев 1996 елны, авырып, эштән китә. Аңардан заводта ни кала? Иң әүвәл, абруйлы исеме, әйбәт хатирәләр кала. Ул җитәкчелек иткән чорда заводның эшләп чыгару куәте 3,5 мәртәбә, хезмәт җитештерүчәнлеге 2,2 мәртәбә арта, биредә эшләнгән суыткыч машиналар алты халыкара премия ала. 3 меңнән артык гаилә квартир белән тәэмин ителә... Аның исеме дөньякүләм елъязмага да теркәлде. АКШның Библиография институты карары белән ул «1995 елның Дөнья Кешесе» дип танылды һәм Алтын Медаль белән бүләкләнде.*

**Рәфикъ ЮНЫС**

# НАХАКТАН АРАЛАУ ЮНӘЛЕШЕНДӘ

(ТӘНКЫЙТЬЧЕ КӨНДӘЛЕГЕННӘН)

Әдәби тәнкыйтьне, исеменә карап, гел әсәрдән кимчелекләр, чатаклыклар эзләүче тармак икән дип аңлыйлар.

Әйе, ана чыннан да, көрәш сыйфаты хас. Ул сүз сәнгатендәге, әдипләр иҗатындагы җитешсезлекләргә, эстетик хаталарга игътибар юнәлдерә, аларның кайсы җәһәттән «килеп җитмәгәнлеген», сәнгатьлелек кануннары белән ярашмавын аңлата, шул рәвешле әдәбиятка кимчелекләрдән арынырга булыша, укучыларны яманлап яхшыны аерырга өйрәтә, аларда сәламәт зәвык тәрбияли.

Ләкин шулай да әдәби тәнкыйтьнең бурычы җитешсезлекләр турында гына сүз йөртү белән чикләнми. Аның аеруча мөһим вазифасы: чын сәнгатьчә иҗатның, югары художестволы әсәрнең әдәби кыйммәтен, гүзәллекнең серен ачып сала белү, табигатен, үзенчәлекләрен дөрес һәм дәлилле аңлату.

Кыскасы, кимчелекләр белән килешмәүчәнлек һәм унайны хуплау—әдәби тәнкыйть эшчәнлегендәге бердәм процесс. Әнә шул бердәмлек кенә әдәбиятның сәламәт үсешенә файдалы, бәрәкәтле йогынты ясый.

Шуның белән бергә без яшәп алган тоталитар системада моңа тагын, бик күзгә бәрелеп, кычкырып тормаса да, өченче вазифа өстәлде: талантлы, ләкин мөстәкыйль, кыю фикерле әсәрләрне түбәнсетүдән, кара мөһер сугудан аралау, чын сәнгатьчә кыйммәтләрне саклап калу өчен көрәш. Хәзер үзебез үткән юлга әйләнеп карыйм да, «минем дә моңа беркадәр өлешем керде бит» дип уйлап куям.

Алтмышынчы еллар уртасында Салих Батталның «Сигезенчесе кем?» повесте дөнья күрде. Бу әсәр гыйбрәтле язмышларны яктыртуы белән игътибарны җәлеп итте. Әнә шуларның образлы сурәтләнешен анализлап мин Казан пединститутының гыйльми язмаларында һәм «Казан утлары» журналында (1975, 8-сан) бер хезмәт бастырдым. Ул шактый вакыт әдип күзенә чалынмый торган, ахрысы. Әмма күргәч, укып чыккач, моңарчы гел тиргәү, орышу гына ишетеп килгән С. Баттал аны ошаткан, куанган булса кирәк. Ул, минем туган көнгә туры китереп, үзенә хас шаянлык һәм оригинальлек белән, котлау шигыре җибәрде. Анда мондый юллар бар:

*Уннарча ел ялаларга*
*тап булган идем гәрчә,*
*табылды бит иҗатымны*
*яклаучылар ирләрчә.*

*Әнә, паника куптарып*
*ялачылар сафында,*
*Фәрит Хатипов туа бит*
*һәр яңа ел башында!*

1966 елда Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повесте унае белән мин "Казан утлары» журналында (9-сан) «Ихтыярсыз» геройлар һәм кырыс дөреслек» дигән мәкалә игълан иткән идем.

Аксубай районыннан укытучы Салих Заһретдинов шушы язма унае белән болай дип язды: «Бигрәк тә Фәрит Хатиповның 9 нчы санда «Ихтыярсыз» геройлар һәм кырыс дөреслек» исемле мәкаләсен матур, әйбәт язылган поэма укыгандай укыдым («Казан утлары», 1967, 1-сан). Әлеге «Өч аршын җир» тирәсендәге хезмәттән соң кайнар бәхәсләргә дә нокта куелды.

Әмма повесть авторы Аяз Гыйләҗевның әлеге мәкаләгә мөнәсәбәте бераз катлаулырак булды. «Идел» журналына биргән интервьюсында ул: «Әсәрне татар тәнкыйтьчеләре тетеп салдылар. Дөрес, Фәрит Хатипов—хәзер танылган галим,

профессор—әсәрне анализлап аңа тиешле хак бәяне биргән иде,—дип бәян итте Аяз һәм ахырдан болай дип өстәде: - Соңыннан үз мәкаләсеннән курыкты, җыентыкларына кертергә базмады» (1991, 1-сан).

Чынында исә мин карашларымнан һич тә баш тартмадым. Хикмәт шунда ки, ул чакта әле минем тәнкыйть мәкаләләреннән төзелгән бер китабымны да чыгарганым юк иде. Мәкаләнең кабат китапта күренмәвен әдип минем үз позициямнән чигенү дип аңлаган ахрысы. Минем тәүге җыентык «Мөлкәтебезне барлаганда» исемендә 2003 елда басылды, һәм анда «Өч аршын җир» турындагы хезмәт үзенә тиешле урынны алды, әлбәттә.

Эстетик төгәллеккә, объектив бәягә аеруча Әмирхан Еники иҗаты күп еллар буена мохтаҗлык кичерде. «Совет әдәбияты» журналының 1955 елгы 9-санында аның «Саз чәчәге» повесте басылып чыкты һәм ул кинәт күңелләрне сискәндереп җибәрде. Бер яктан, ул—югары камиллеккә ирешкән чын сәнгать әсәре. Икенче яктан, анда райком секретареның... мещанлык сазлыгына батуы тасвирлана. Ул чорда рәсми тәнкыйть аеруча әнә шундый күренекле, ләкин кыю, мөстәкыйль фикерле әсәрләргә ябырыла, аларның абруен төшерергә тырыша иде.

Шул айларда мин Төмән өлкәсенең Тубыл каласына килеп төштем, пединститутта әдәбият укыта башладым. Озын-озакка сузмыйча, анда Төмән, Омск, Свердлов, Пермь өлкәләреннән, Башкортстаннан килеп укучы студентлар, 15 татар урта мәктәбе һәм педагогика училищесы укучылары һәм укытучылары, татар китапханәсе хезмәткәрләре катнашы белән шушы әсәр буенча укучылар конференциясе үткәрдем. Шунда әйтелгән уртак фикергә нигезләнеп, «Совет Татарстаны» газетасында «Себердән хат» рубрикасы астында «Саз чәчәге» повесте турында» дигән мәкалә бастырдым (1956, 13 март). Дүрт айдан соң, «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы июль санында Ибраһим Нуруллинның шушы әсәр турында «Иллюстрациядән проблемага» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Болардан соң «Саз чәчәге»н ачыктан-ачык ямanlаган рецензияләр күренмәде кебек. Хәтта «Кояшлы язны рәшә капламасын» дигән мәкалә авторы да аңа бәйләнүне кирәксенмәде, киресенчә, аны әдипнең «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге» кебек күренекле әсәрләре рәтеннән санады. Югыйсә, алар стиле, эчке рухы белән бер-берсеннән кискен аерылалар бит. Әдип үзе дә, «Рәхмәт, иптәшләр»не күздә тотып, «Соңгы китап» әсәрендә болай дип язды: «Шулай да повестьның үзенә рәхмәтне әйтергә кирәктер - ул минем авыр хәлне шактый ук җиңеләйтте. Инде уңышны беркетер өчен тагын шундыйрак бер отышлы нәрсә язасы иде дә бит, ләкин мин, тиле, чыгымчы аттай, янадан буразнаны боза башладым. «Саз чәчәге» исеме белән бер райком секретареның обывательгә әйләнүе турында повесть яздым». (483 б.)

Хәзер уйлап куям: «Саз чәчәге»нә уңай мөнәсәбәтне, аның язмышын билгеләүдә әлеге Себердән җибәрелгән язманың һәм И. Нуруллин мәкаләсенең, аларда урын алган профессиональ анализның роле дә булмады микән?

1958 елда А. Хисмәтуллин дигән автор Ә. Еникинең «Йөрәк сере» буенча «Повестька карата бер-ике сүз» дигән рецензия язып чыкты. («Совет Татарстаны», 1958, 12 октябрь). Ул анда әсәрнең баш герое Зөһрәнең үзе яратмаган кешегә тормышка чыкмавын, бу мәсьәләдә, тәнкыйтьче язуынча, «тәрбияле ике гаиләнең тырышлыклары» да бушка китүен ошатып бетерми. Аныңча, Зөһрә әхлак нормаларын боза, ул типик образ түгел.

Күрәсез, бу сүзләр аркылы әсәрнең бөтен сәнгатьчә нигезе кире кагыла, аңа ялгыш бәя бирелә. Моның белән килешү мөмкин түгел иде. «Совет әдәбияты» журналында басылган мәкаләдә (1960, 5-сан) мин әсәрдә чын мәхәббәткә нигезләнгән гаилә сурәтләнүен, повестьның эстетик куәте, гүзәллеге дә нәкъ менә шунда булуын дәлилләргә тырыштым. Ул чакта инде дәүләт университетында эшли башлаган идем. Шундагы студентлар белән очрашу вакытында Ә. Еники бу мәкаләне аерым искә алды, әсәрнең сәнгатьчә асылын әнә шулай дөрес аңлатырга кирәклегенә тукталды.

Шулай итеп, Әмирхан Еники иҗатына кереп китүем аның әсәрләренә карата бирелгән яки бирелү ихтималы төсмерләнгән хата бәяләр белән килешмәү җирлегендә булды.

Ул елларда бик гади, гадәти сюжетлар да рәсми тәнкыйтьтә ризасызлык тудыра иде. Күренекле әдип Мирсәй Әмир язучылар җыелышындагы бер чыгышында болай дип сөйләде: «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә автор бүгенге тормышыбызда әйдәүче урын тоткан буынны инде картлыкка чыккан буынга каршы куя... Тагын да ачыграк: картлар ягына, әсәрдә сурәтләнгәнчә, инде бетүгә хөкем ителгән, төзәлмәс чиргә мөбтәля булган, хәтта инде үлеп үк киткән Акъәбиләр, яки өрәге бу дөньяда булса да, үзе кеше буларак инде күптән сафтан чыккан Миңлебай картлар ягына кушыла (М. Әмир.Үзебез турында. -Казан: Тат. кит. нәшр., 1971, 70 -71 б.).

Әмма тирән белемле, житди тәнкыйтьче Гали Халит ошбу әсәрнең бик алай беркатлы булмаганлыгын төшендерде, аның мөһим фәлсәфи мәгънәсен, сәнгатьчә әһәмиятен ачып күрсәтте, Ә.Еникинең әтрафлы иҗат портретын язды (Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1975, 116-1486.)

Шулай итеп, иҗади тәнкыйть әдәби җәүһәрләрне саклап калу, сәнгать казанышларын үстерү, ныгыту өчен көрәшә килде, дип әйтә алабыз.Бу эштә төп кыйбла идеология күрсәтмәләре түгел, әсәрләрнең сәнгатьчә камиллеге булды.

Берара миңа Әмирхан ага белән якыннан аралашырга мөмкинлек туды. Ике ел Переделкинодагы иҗат йортына бергә барып, бергә кайттык. Анда чакта гадәттә төшке аштан соң бераз шул тирәдә йөреп керә идек. Мин аның иҗатына кагылышлы берәр сорау биреп куям.Ул аны бик табигый кабул итә, үз әсәрләре, геройларның прототиплары, баштан кичкәннәре хакында иренмичә, җай гына сөйли.Ул бик төзек җөмләләр белән, эзлекле итеп, тигез-салмак баян итә. Кайбер көнне үзе үк сорап та куя:

—Йә, тагы ниләр кызыксындыра?

Мин игътибар белән тыңлап барам. Бүлмәгә кергәч, ишеткәннәрне шунда ук теркәп куям.

Әдипнең туксан еллыгына без Рифат Сверигин белән берлектә «Рәшәле дөнья» дигән өч басма табак күләмендә мәкалә яздык. «Мирас» журналы аны, бер кәлимәсен дә төшереп калдырмыйча, ике санда бастырып чыгарды. Әмирхан ага аннан канәгать калган булса кирәк. Ул шылтыратып болай диде:

—Мәкаләне бик тәмләп укыдым. Анда минем иҗат бик тулы һәм дөрес яктыртылган.

Ләкин әле һаман да минем алда бу талантлы, үзенчәлекле иҗатның яңадан-яңа яклары ачыла тора. Нәтиҗәдә шуларның кайберләре «Кызыл артында—каралык», «Сәнгатьлелек кимәлендәге контрастлар» дигән мәкаләләрдә үзенең чагылышын тапты.

Ә. Еникинең һәр әсәре - тиргәлгәне дә, макталганы да - безнең әдәбиятта вакыйга буларак кабул ителде. Табигый, аның иҗаты турында күп авторлар үзләренең фикерләрен әйттеләр. Мин дә бер китап төзеп нәшриятка тапшырдым. Ул әдип эшчәнлегенә мөнәсәбәтне, җәмәгатьчелек фикерен, иҗатының күп якларын шактый тулы иңли. Әмма әле ул да боларның бөтен нечкәлекләрен ачып бетерми, дип уйлыйм. Чөнки зур талант иҗатына күп серләр яшерелгән була.

Әмирхан Еники үзенең әсәрләрен дөнья классикасы дәрәҗәсендә язды. Хәзер инде ул иҗат яклауга мохтаҗ түгел. Ләкин, менә карап, тәнкыйтьнең бурычы җиңеләйде, дип әйтеп булмый. Киресенчә, ул тагын да катлауланды, җаваплылык бермә-бер артты. Тәнкыйть аның гениальлеген, талант серләрен, сәнгать ачышларын укучыларга калку итеп күрсәтергә бурычлы.

Һәм бүтән әдипләребезнекен дә!

**Фәрит ХАТИПОВ**

# ТАМЫРЛАРЫ ҮЗЕБЕЗДӘ

Зур күләмле әдәби әсәрнең дөньяга чыгуы авторга сөенеч, шатлык китерү белән бергә, әдәбиятны укып, күзәтеп баручы укучылар даирәсе, тәнкыйтьчеләр, галимнәр өчен дә еш кына мәдәни вакыйгага әйләнә. Әсәр турында фикер йөртәләр, аны әтрафлы бәялиләр, киләчәк язмышы, әдәбияттагы урынына кагылышлы юраулар ясыйлар. Күпме уй, фикер әйтелсә, караш, бәяләр төрлеләнсә, шулкадәр яхшырак. Ә инде иҗат җимешенә карата матбугатта йола өчен генә чыгыш ясалса, берьяклы гына рецензия басылса, бу, мөгаен, күпләрдә начар иләнгән тире тәэсире уятадыр. Каты, кулга илекмәс мех кисүченең, тегүче һәм итекченең кәефен кырган сыман, тәнкыйть тарафыннан тиешенчә эшкәртелмәгән әсәр дә әдәбиятчыларның, иҗатчыларның күңелләрендә бик күп сораулар калдыра: кайсы китап киштәсенә куябыз аны, тормышка мөнәсәбәттә, яңалык ягыннан нинди әсәр бу һәм, ниһаять, шедеврмы яисә урта кул үрнәкме бу?

Галимҗан Гыйльмановның 2003 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Албастылар» романы да, минем карашка, әлегә начар «иләнгән» әсәрләр рәтендә. Дөрес, журналда басылып чыгуга ук Дания Заһидуллина аңа багышлап «Албастылар яки татар прозасында яңа сыйфатлар» (Казан утлары, 2001, №11) исемле күләмле рецензия язды. Ләкин әлеге әсәр тудырган фикерләрне бер рецензиягә генә сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә «Албастылар» турында сөйләшүне бередә дәвам итәсе килә.

Д. Заһидуллина үзен дулкынландырган гыйльми идея белән рухланып, Г. Гыйльмановның әлеге әсәрен «татар постмодернизм әдәбиятындагы беренче дулкынның югары ноктасы» итеп карый. Сүз юк, милли иҗат үрнәген гареп әдәбиятларындагы катлаулы процесслар, юнәлешләр яктылыгында карап бәя бирү, анда теоретик казанышлар чагылышын табу, күрү—бүгенге татар тәнкыйтенең фәнни югарылыгы, маһирлыгы ул. Ләкин өлкән әдәбиятчыбыз Рифат Сверигинның мондый репликасын да искә алмый мөмкин түгел: «Могтәбәр әдәбият белгечләренең авангардизм әсәрләрен әдәбиятның гел гүзәл казанышлары рәвешендә тәкъдим итүләре, ким дигәндә, гаҗәпләнү һәм сәерсенү уята». Чынлап та, Р. Сверигин әйткәнчә, без модернистик асыллы импрессионизм, экспрессионизм, экзистенциализм, сюрреализм, неореализм әдәбиятларындагы «саташу, сызлану, эшсезлектән һәм үз-үзенне кая куярга белмичә гел илаһи серлелеккә омтылып тормышның үз хакыйкатеннән һәм реальлегеннән ваз кичкән геройлар»ны иҗат казанышы дип бәяләсәк, милли әдәбиятыбызның иртәгәсен нәрсә көтә?

Димәк, «Албастылар» романына Д. Заһидуллина биргән бәя белән беррәттән, татар әдәбиятының үзенең меңъеллык традицияләре, казанышлары яктылыгыннан һәм милли әдәби-эстетик зәвык таләпләреннән чыгып та сүз әйтү сорала.

Әсәргә карата төрле, плюралистик фикерләүләр кирәклеген, боларның соралып торуын мин янә бер таләптән чыгып тоям. Әдәбиятны тормыш белән бәйләү таләбе бу. Д. Заһидуллина постмодернистик әдәбиятның бер сыйфаты итеп түбәндәгене күрсәтә: «Бу әдәбият чынбарлыкны кабат тергезү максаты белән түгел, бәлки яңа чынбарлык төзү, модельләштерү өчен языла», һәм тәнкыйтьче Г. Гыйльманов романындагы хыялый-виртуаль дөнья, андагы герой-персонажларны бәяләүтикшерүгә зур урын бүлә. Әйтергә кирәк, әдәбият белгеченең бу яссылыктагы күзәтү һәм ачышларына һич тә тел-теш тидерерлек түгел. Ләкин бередә нечкә әдәби-эстетик фикерләүләр янәшәсендә модернистик агымнар шаукымына бирелгән язучыларга һәм аларны бәяләүче затларга хас чикләнү, атап әйткәндә, яманатлы «сәнгать—сәнгать өчен» принцибына бирелү дә ачык тоела. Югыйсә, тикшерену мантыйгы үзе үк сорап тора бит. Яхшы, татар язучысы постмодернизм таләбе кушканча үзе күрергә теләгән дөньяны тасвирлаган, ди. Ләкин бу постмодернизм сәнгатенең таләбе генә микәнни соң? Ә соң язучының фикерләү һәм хисләнү хасиятләренә туктаусыз тәэсир итеп торучы социаль тормыш, андагы хәл-әхвәлләр үзләре кайда?

Бүгенге чынбарлык кайсы сәбәпләре белән «Албастылар» авторын виртуаль

дөнья сурәтләүгә этәрә? Романдагы геройлар үзләренең нинди әхлакый-этик сыйфатлары белән безнең бүгенге хәяткә аваздашлык табалар? Ахыр чиктә язучы үзе күтәргән проблематика аша бүгенге укучыга нинди мәгънә, нинди сүзләр ирештерергә тели соң? Менә болар барысы да тәнкыйть тарафыннан куелырга һәм ачыкланырга тиешле мәсьәләләр бит. Матур әдәбиятны ничаклы гына мөстәкыйль, үзаллы, хәтта серле бер дөнья димик, ул анык тормыш шартлары, фәлсәфи, әхлаки-эстетик фикерләүләр белән тыгыз тоташкан. «Постмодернизм үрнәге» дип тәкъдир ителүгә карамастан, Гыйльманов романында чынбарлыкның гәүдәләнеше анык күрсәтелергә тиеш иде.

Милли каләм осталары тарафыннан дөньяга чыгарылган теге яки бу үзенчәлекле әсәрне Көнбатыш әдәбият белеменнән килгән модалы теорияләргә иллюстрация ясап, «изм»нар белән бәйләгәнче, иң элек әдәбиятыбызның тәҗрибәсенә, традицияләренә таянып карарга кирәк. Бәлки «яна теоретик концепция, авангардизм, модернизм» дигәннәребез борынгы сүз сәнгатенең кабатланышы, дәвам итүедер? Бигрәк тә безнең әдәбият кебек меңьеллык тәҗрибәсе, әлләникадәр сокландыргыч, сәнгатьчә камил үрнәкләре һәм образлар тудыру алымнары булган иҗатта күчемлелек эзләү — өметле шөгыль, һәм, чынлап та, Д. Заһидуллина постмодернизм иҗатының мөһим таләпләре дип күрсәткән һәм Г. Гыйльманов романыннан тапкан әдәби алымнар, герой иҗат итү принциплары борынгы әдәбиятыбызда ук ярылып ята. Мәсәлән, «бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы» — ягъни синкретик иҗат—Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында ук бар. Реаль чынбарлык белән хыялый дөнья кушылмасын без Кол Галинең әлеге әсәреннән тыш, Котбның «Җөмҗөмә Солтан» яисә Сәйядинең «Дастан Бабахан» поэмаларыннан да табабыз. Ә инде постмодернизм әдәбиятына хас дип тәкъдир ителгән «җемелдәүче образ»ларны борынгы әдәбиятыбыз әсәрләрендә дистәләп санарга була: Илаһият, Тәңре, Йосыф, Таһир, Зөһрә, ..., Дәрвиш, Хозыр Ильяс... Борынгы шагыйрьләребез, шулай ук постмодернизм вәкилләре кебек, «чынбарлыкны кабат тергезү максаты белән түгел, бәлки «яңа чынбарлык төзү» өчен дә поэмалар, кыйссалар, дастаннар язганнар... Постмодернизм күренешләре борынгы сүз сәнгатенә каян килсен? дип аптырыйсы түгел, чөнки соңгы дәверләрдәге Европа язучылары аларны кадими шәрык әдәбиятларыннан чумырып алалар. Бу—фәндә яхшы ачыкланган күренеш ләбаса. Кыскасы, үз романында мин Гыйльмановның гареп әдәбиятчылары тәҗрибәсенә иярүдән бигрәк, үз әдипләребезнең борынгы традицияләреннән иҗади файдалануын күрәм. Алай гына түгел, хәтта «Албастылар» белән борынгы ядкарьләребез арасында турыдан-туры бәйләнешләр дә бар. Саниянең бала сагышыннан сукыраюы Кол Галиның «Кыйссаи Йосыф» поэмасындагы Ягъкуб ата язмышына тартым. Ә инде Гыйльманов романындагы Майяның «Сезнең Аллагыз әйбәт, Хәлим, ул кешенең рухын сындырмый, аның күңелен богаулап, зиһенен томалап куймый» сүзләрен укыгач, шул ук Кол Гали поэмасындагы гүзәл Зөләйханы искә төшерәсең. Чөнки мәҗүсилек мәзһәбендә булып, тәңресен пот, санәм рәвешендә тойган Зөләйха тора-бара хатасын аңлый; Аллага табына һәм Йосыфка Майяныкына охшаган сүзләр дә әйтә. Араларын гасырлар тезмәсе аеруга карамастан, «Албастылар» авторының Алла көч-кодрәтен, тормышка, кешеләргә йогынтысын күрсәтүдә Кол Гали поэмасына таянуы бәхәссез.

Мәсьәләнең болай куелышын — ягъни Г.Гыйльманов әсәрендә нindидер постмодернизм чагылышларын күрүдән бигрәк, татар әдәбиятының үз асылын, традицияләрен эзләү, табу теләген — күпләр хуплар, мөгаен. Ул олы бәхәс уятмас. Әмма фән үсеше, монарчы күрелмәгән техник ачышлар заманында бу авторның борынгы әдәбият алымнарын терелтеп хыялый-виртуаль дөнья коруы, сәер, серле кеше образлары иҗат итүе нинди максаттан чыга—монысы инде шактый катлаулы мәсьәлә.

Ә бәлки романнан тормыш чагылышын эзләү кирәкмидер? Әдәбиятыбыздагы очраклы бер хәл, чынлап та, бер эзләнү, әдәби эксперимент галәмәтедер ул? Юк, «Албастылар»да гамәли чагылыш тапкан романтик-символик, тирән аллегорияле, көчле парадокслы стиль әдәбиятта «ак чәүкә» түгел, ул узган гасырның сиксәненче елларыннан ук үзен сиздерә башлаган, ә Гыйльманов романы исә аның төрле үрнәкләрдәге чагылышларын бергә җыйнап, калкытыбрак бирүе белән күзгә ныграк

ташлана. Мәсәлән, Ф. Бәйрәмованың «Күл балыгы» повестенда балык-кыз җир кешеләренең нәрсә уйлауларын алдан ук тоеп тора иде. «Албастылар»дагы сихерче карчыклар да шул ук хасияткә ия һәм бу роман авторына геройлар мөнәсәбәтләрен катлаулы, интригалы итеп тасвирлау мөмкинлеген бирә. Н. Гыйматдинова «Сихерче» повесте һәм аңа тартым бер төркем эпик әсәрләре белән өшкерү, им-том, ырымлау ритуалын сәнгатьчә югарылыкта күрсәтте. Сихерләү, имләү поэтикасы Г. Гыйльманов романындагы композициядә дә зур урын алып тора, аңа серлелек бирә. А. Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестенда Бамбук исемле яралы атны ерак чакрымнар аша үз ягына җитәкләгән Кәбирнең туган табигать баласына әйләнүен күргән, аның үсемлекләр, кошлар, хайваннар белән аралашу маһирлыгына сокланган идек. «Албастылар»дагы Хәлим дә Табигать-Ананың үз улы, үз баласы рәвешендә оста тасвирлана...

Санап ялыктыру куркынычы булуга карамастан, Г. Гыйльманов романы белән ике тамчы су кебек охшаш булган янә бер әсәрне телгә алмый түзә алмыйм. Бу—башкорт проза остасы Гөлнур Якупованың «Ерткыч каны» (2003) повесте. Татар һәм башкорт язучысының иҗат җимешләрен янәшә куеп чагыштыру үткәрергә мөмкинлек биргән зур нигез—һәр ике әсәрдәге вакыйгаларның «Урман эчендә, адәм аягы басмаган җирдә», утарларда баруы. Робинзон токымындагыларның тормыш итүләре, тән, җан асрау гамьнәре дә һәр ике китапта уртак. Хәтта алардагы төп геройлар—Хәлим, Һәдиянең нәсел-кодлары аюдан килә, урманда туган балалары да кызлар һәм исемнәре дә рифмалашып тора икән—Гөләш, Миләш... Шулай ук серлелек, мистик башлангычны алга сөрү якынайта кардәш халык язучыларын. Гыйльманов романында куркыныч, шомлы албастылар булса, Якупова повестенда бичура бар. Тегендә дә, монда да Ходайга сыгыну. «Хөкемең хак, Раббым! Ярдәмеңнән ташлама!» дип ихластан ялвару. Алла каршында рухыңны саф хәлдә сакларга тырышу төп омтылышлар булып ята.

Телгә алынган әсәрләрдә геройларның югары рухи, эстетик күренешләрен тасвирлаганда бу охшашлык хәтта гаҗәпләнерлек дәрәҗәгә җитә. Әйтик, һәр ике әсәрнең геройлары үзләре корган хуш исле җәйге куышта күптән көтелгән кавышуга ирешәләр. Әлбәттә, «Ерткыч каны» авторы, хатын-кызга хас булганча, моны беркадәр тыйнаклык, тартыну белән тасвир итә: «Һәдия инәдән-тума ялангач ир янында ята! Әйе шул... Булды шул... Үзең теләп, тәнең тартып бирелгәндә, аңлатып та бетмәслек ләззәт икән лә ул...»

Гыйльманов исә эротик хисне тартынусыз бирә: «Хәлим тәненә салкын куллар кагылудан сискәнеп торып утырды. Шунда ук салкын куллар аның күкрәгеннән этеп, кабат ятарга куштылар. Хәлим буйсынды. Шунда гына ул куыш ишегеннән төшкән яктылыкка коенып, балкып басып торган бер сылу гәүдәне күреп алды. Майя бит бу! Үз гомерендә беренче мәртәбә кавышу, кушылу ләззәте кичереп, ярым шашып, ярып үлеп яткан бу ике җан иясе кешелек дөньясының, Галәмнең үзәге, асылы һәм яшәү мәгънәсе кебек иде...»

Әлбәттә, татар һәм башкорт язучысын берләштергән югары охшашлык аларның кешегә булган уртак карашларында ята. Аны үз әсәрендә Якупова болай тәкъдир итә: «Адәм баласы күп нәрсәне булдыра икән. Чыдам икән ул адәм баласы! Түзмәслек газапка түзеп, аткармаслык эшне аткарып яши ала икән табигатьнең бу баласы...»

Менә шундый әсәрләр яктылыгында без Г. Гыйльманов стилен әдәбияттагы очраклык күренеше итеп кенә карый алмыйбыз шул инде. Д. Заһидуллинача «Албастылар»ны чит кош оясындагы күке баласы төсендә колакка ят «постмодернизм әсәре» дип тану урынлымы? Юк, бу — үзебезнең иҗат җимеше, К. Тинчурин әйтмешли, «милли пәрәмәч...» Бәлки үзебезнең әдәби хәяттәге терминнарга җайлашып, аны романтизмның яна дулкыны чагылышы итеп күрсәтергәдер?

* * *

Г. Гыйльманов романы һәм анда безнең чынбарлык гәүдәләнеше мәсьәләсенә кагылганчы бер сорау куйыйк әле:

—Бүгенге язучы нинди темага әсәр багышларга мөмкин?

Хезмәт һәм үз-үзләрен аямый эш күрсәткән фидакарьләр турындамы? Юк, бу темадан совет заманы язучылары да гарык булдылар, аннары хезмәт кешесенең

абруе да бүген ташка үлчим... Ватанны саклау, патриотизм темасынамы? Тик бармы соң безнең ватан? Бәлки элекке кебек зыялылар темасын активлаштырырга, һөнәргә, ижатка, халыкка булган бирелгәнлек, нечкә әхлак проблемаларын күтәрергә кирәктер? Әмма авызын ачса, үпкәсе күренеп торган зәгыйфь, тишек кесәле интеллигент сәләмәләреннән бүген нинди анык гамәл көтәсең? Чынлап та, жимерелгән ил, кыйбласын югалткан хәят заманында язучыны һәр тарафтан рухи көрчек, өметсезлек сагалап тора. Илнең миллионлаган башка кешеләре кебек, аның акыл астында да жан саклау, имин калу теләге мөһим яшәү инстинктына әйләнә.

Гомәр Бәширов көндәлегендәге 1948 ел белән билгеләнгән язма күңелгә уелды: «Ватан сугышы үзенең коточкычлыгы, рәхимсезлеге һәм дәһшәте белән дини хисләрне уятты. Кеше үз көченә генә ышанып тынычлык табалмады...

Кеше бик зәгыйфь нәрсә булып калды. Нинди дә булса чиктән тыш бер бөек көчкә генә сыгынырга, аннан гына ярдәм табарга мөмкин иде. Бу бөек көч борынборыннан ук поэтик югарылыкка күтәрелгән, кешенең балачагында ук күңеленә кереп урнашып калган, жинелмәс, мәңгелек һәм тинсез кодрәт, билгеле, бер Алла гына иде. Сугыш вакытында динсезләр дә Аллага табына башладылар».

Г. Бәширов «Кешенең кайчандыр, бик борынгы вакытларда, үзе үк табып та, соңыннан йөз чөергән Алласына янадан ялварып баш» июен фән, техника заманының яшертен парадоксы итеп саный.

Әлеге парадокс безнең фетнәле заманның да законсыз юлдашы булса кирәк. Ялгызлык, социаль өметсезлек, әхлакый таркалу, ижтимагый идеаллар югалу кебек гамәлләр Аллага сыгыну һәм рухи бушлыкны дини юанулар белән каплау теләген көчәйтте. Дини-мистик тематика әдәбиятыбызның да төп оешу үзәген тәшкил итә булса кирәк, һәм әнә шул яссылыктан карасак, без «Албастылар» романының идея-эстетик асылын да ныграк аңларбыз. Дини пассион мондагы һәм реаль, һәм хыялый катламның һавасын сугаручы жегәр булып тора. «Сания дингә бирелде, иман догаларын янартты, намазга утыра башлады. Шүрлегендә һәрвакыт Коръән тотты, бөтен тишек-тошыкка бөти яздырып тыкты»,—дип сурәтли язучы аны улын югалткач. Хәлим дә, әле яшь кеше булуына карамастан, Коръән сүрәләре ятлый, догалар укый, үзе белән бөти йөртә. Әсәрнең мистик дөнья тасвирында Алла гаделлек патшасы булып тора, гөнаһлы жиргә яшен, күкрәүләр булып инеп, яисә Хозыр Ильяслары белән килеп хаклык, хакыйкать урнаштыра. Кеше Алла—Кодрәт иясе каршында саф булырга тиеш...

Тик, кызганыч, бөек яшәү кануны жирдәге һәр затка барып ирешми. Көнчелек, урлашу, гайбәт, эчкечелек, үтерешләр аша бозыклык, явызлык яшәп килә. «Жир пычрагына буяла барган саен, кеше Аллаһы Тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта», дип раслый автор һәм үз романында кискен актуальләштереп Табигатьне, табигыйлекне саклау проблемасын куя.

Элекке елларда табигатьне саклау «экология мәсьәләсе» дип атала иде. Безнең язучыларыбыз кайнар пафослы, драматик кичерешле әсәрләре аша Жир-ананың табигый матурлыкларын сакларга—болыннарны сөрмәскә, урманнар байлыккүркен аяусыз таламаска, су-һава сафлыгын, жәнлек-киекләр гомерен сакларга—чакырдылар. Ул чакта браконьерларга төбәп, әмма «вак калибрлы мылтыклардан аткаңнар» иде әдипләр. Ә хәзер табигатькә һөжүм чиксез киң һәм әрсез чаралар белән алып барылган чорда, әдәбият, күрәмсең, мондый юл белән генә канәгатьләнә алмый. Язучыларыбыз халык аңына йогынты ясар өчен Табигать язмышы мәсьәләсен шартлылык, аллегория чаралары ярдәмендә кискенләштереп һәм фәлсәфи тирәнәйтеп куярга омтыла, һәрхәлдә бу ниятнең Г. Гыйльманов романында үзәктә торуын күрмәү мөмкин түгел.

Әйтергә кирәк, «Албастылар» авторы безнең тарафларда цивилизация аягы басмаган жир калмаган бер мәлдә әсәрнең сюжет-композициясенә табигать дөньясын шартлы, мистик чаралар кулланып бик оста урнаштыра. Нәтижәдә укучы Хәлимне, хәтере жуелып, урманда албастылар әсирлегенә төшкән кызганыч зат буларак кабул итә. Хәтта шушы тойгы эффектыннан чыгып, Д. Заһидуллина әсәрнең үзәк каршылыгын да билгели: «Хәлим һәм албастылар каршылыгы». Тора-бара Хәлим өчен дә урман албастыларыннан бигрәк шомлырак көч булып Аллаһдан тайпылган кешеләр яисә, авторча әйткәндә, тормыштагы албастылар күтәрелә. Әйе, менә шул әверелешне искә алганда, чыннан да, романның төп, реаль

конфликты Хәлим, Майя белән шул караңгы социаль затлар бәрелешенә корыла дип расларга мөмкин.

Әмма без Д. Заһидуллинаның: «албастылар утарындагы тормыш идеология белән аның томалап, халыкны колга әйләндерү сәясәтен хәтерләтә»,—дигән сүзләре белән килешә алмыйбыз. Бу тәнкыйтьченең Хәлим тозакка төшкән урман хәятендә элекке тоталитар режим шәүләсен күрергә теләве аңлашыла. Ул чагында Д. Заһидуллина гына түгел, безнең демократлар да романны күккә чөеп мактарлар иде. Әмма әсәр рухы һәм язучы концепциясе мондый мөмкинлек бирми шул. Әнә бит романда төп герой тоткынлыгы хакында, аерым ишарәләр ясап, искәртелгән: «Хәлимнең урман эчендәге яшерен утарда үткәргән көннәре бөтенләй үк мәгънәсез булмаган икән. Бу тормышны «тоткынлык» дип әйтеп булмыйдыр. Хәлимне берсе дә тыймады, сакламады. Ул бу тормышны бик табигый дип таба, гомер яшәешен шулай булырга тиешле итеп кабул итә».

Д .Заһидуллина версиясе авторга нинди реаль дивидентлар китергән булыр иде, әйтеп булмый. Әмма без болай да язучы каләменә янә соклану мөмкинлеген табабыз. Космос белән хәбәрләшүле, мобильниклы, тоташ компьютерлы замандагы һәр социаль зат ижтимагый мониторда ялтырап торуга карамастан, үз героен, Жан Жак Руссо термины белән әйткәндә «табигый кеше» кыяфәтенә кертеп, берничә ел урман хозурында яшәтүгә ирешә бит ул. Һәм язучы үз әсәрендә социолог, педагог, философ кебек уйланып та кеше белән Табигать гармониясе моделен кора.

Тик романның төп идеясен Табигатьне саклау дип кенә атамыйча, табигыйлыкны саклау дип тә өстәргә кирәк. Табигать һәм табигыйлек—бер тамырдан ясалган төшенчәләр. Жирдәге бар тереклекнең Ходай кушкан кануннар нигезендә хак, дөрес гомер кичерүен, асылын бозмавын күздә тота бу әнкә-сүз. Табигыйлыкны саклау таләбе нигездә кешеләргә кагыла, чөнки болар акыл, ихтыяр ярдәмендә үз яшәү гадәтләрен һәм ысулларын корганнар, һәм «Албастылар» романында тасвирланган «Кампәрле» авылы кешеләре хәятен безнең халыкның яшәеш моделе рәвешендә күзалларга була. Язучы аны ничек бәяли соң?

Гыйльманов әсәрендә табигать һәм кешеләр яшәешен конрастлы принципларда сурәтләү максаты куелуын Тәзкирә һәм аның игезәкләре Нәфисә, Майя образларында бик ачык тоярга була. Беренчесе ана куенында калып, Кампәрленең каргалган нигезендә үссә, Майяны исә туу белән урман ияләре урлап китә һәм «Жир-Су яна туган имчәк баласын тулысынча үз яклавы астына ала». Шулай итеп, Нәфисә кешеләр мохитендә үсеп, мондагы яшәү гадәтләрен үзенә сеңдерсә, Майя табигать кочагында риясыз тереклек итү гадәтләренә җайлашып балигъ була. Әсәр финалындагы авырлы Нәфисәгә Майяның ярдәм кулын сузуы, шәфкать күрсәтүе, әмма шуна карамастан, явыз игезәк коткысы белән аның үтерелү фактында зур фәлсәфи мәгънә ята. Кешеләр үзләрендәге кемузардан ярышып бер-берсенә золым-зөльмәт салулары, үзара көнчелекләре, аяусыз дошманлыгы һәм төрле ялган ләззәтләргә чумулары аркасында «Аллаһы Тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрне бөтенләй югалтып» үзләрен-үзләре һәлак итәргә дә мөмкиннәр... Әйе, романдагы трагик язмышлы кызның исеме Майя дип аталу юкка түгел бугай. Бик борынгыда юкка чыккан цивилизация да шул исемдә булган түгелме соң? Шиксез, әлеге параллель аша автор кешелек язмышына куркыныч парадокс салынганын искәртә.

Әмма Гыйльманов парадокслар кору шаукымыннан арына алмаган шул. «Албастылар»дагы мондый чишелеш парадоксы, гарептәге постмодернизм ижаты өчен никадәр ятышлыдыр, әйтә алмыйм, әмма заманчалык хисеннән халкыбыз мәнфәгатьләреннән аерылмаган бүгенге татар әдәбияты — виртуаль-хыялый, мистик дөнья уйлап чыгару белән ничек кенә мавыкмасын, бу финал, билләһи, аның өчен чит, ят. Чын әдәбиятның бервакытта да хаин качкын, ирекле әсир яки чырайсыз өрәкне пьедесталга күтәреп герой ясамаганы шикелле, кешедән-кеше читләшүне, бер-берсеннән курку, шүрләү һәм дошманлык тойгылары чәчүне дә гуманистик ижат түр фәлсәфәсе итә алмый. Әдәбиятта замана үзгәрешләре белән бәйле нинди генә әверелешләр бармасын, югары эстетик таләпләрне күздә тотып ижат итү юлыннан тайпылмаска иде язучыларыбызга!

**Сәгыйдулла ХАФИЗОВ,**
*Уфа.*

# САГЫШ ҺӘМ МОҢ ТУЛЫ

«Рухият» нәшрияты исәннәрнең генә түгел, мәрхүмнәрнең дә кадерен белү, аларның иҗатын укучыга җиткерү буенча аеруча тырышып эшли. Билгеле, авторның үзеннән соң, аннан башка әдип китабын чыгару наширләр иненә тагын да зуррак җаваплылык сала. Узган елда драматург Юныс Әминевның, Сара Садыйкованың китаплары нәшер һәм тәкъдир ителде. Күптән түгел исә бик тә вакытсыз арабыздан киткән талантлы шагыйрь, күпләргә зур шигърият юлына чыгарга ярдәм иткән үтә зәвыклы, нечкә тоемлы мөхәррир Наис Гамбәрнең «Ачык калган тәрәзәм...» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.




«Ачык калган тәрәзәм ...» Наис Гамбәрнең мона кадәр дөнья күргән ике китабында һәм көндәлек матбугатта басылган шигъри бәйләмнәреннән сайлап төзелгән. Китапның мөхәррире Рәдиф Гаташ үзенең баш сүзендә шагыйрь иҗатын югары бәяләп: «Наис Гамбәр фәлсәфи шагыйрьләр мәктәбен үз күрде. Мөгаен, Шәрык шагыйрьләре (Хәйям һ.б.) йогынтысы да булгандыр, әмма иң мөһиме—үз классик шагыйрьләребез, милли классикларыбыз йогынтысы: Тукай, Дәрдмәнд, Туфан мәктәбе...»—дип яза.

*Яшәүдән соң яшәү бармы? Бардыр...*
*Кичтән бата Кояш, иртән—калка.*
*Баш очымда яна алтын алка.*
*Коела орлык... шытып чыга барыбер.*

Менә шулай—каләм иясе шигърияттә үз фәлсәфәсен калдырырга, яшәүнең мәңгелеген табигать кануннары аша исбат итәргә омтыла. Кешене табигать баласы итеп күрү, табигать сурәтләре һәм кеше яшәеше арасындагы янәшәлекләр шигырь тукымасына кереп, афористик яңгыраш ала. «Яшәү белән үлем арасында Яши кеше—үз читлегендә»—ди шагыйрь, лирик шәхеснең илаһи координатларын билгеләп.

*Яшәү—Үлем аша: гөлдән тамган*
*Бу орлыклар язын гөл булыр;*
*...Җаным Сездә кала,*
*Тән үлгән көн*
*Яңа тормыш туган көн булыр,*

—ди тагын шагыйрь, яшәүнең мәңгелеген табигать эволюциясе аша шәрехләп. Әдәбият белгече А. Кимның түбәндәге сүзләре нәкъ менә Наис Гамбәр турында әйткән кебек. «Кеше үзен өзлексез яшәү чылбырында бер боҗра итеп сизсен өчен аңа зирәк зиһен кирәк... Тормышны болай аңлый башлаган кеше—ул гади хезмәткәр генә түгел, ә ул—мәңгелекне тудыручы». *(Ким А. Мы—потомки и патриархи // Сов. Россия, 1987, 1 авг.)*

Әлбәттә, яшәештә мондый нәтиҗәләргә килер өчен шагыйрьнең «Табигать баласы» шигырендәге кебек, Җирдән килгән дулкынны тирәнтен тою һәм кешеләрдә дә табигать ритмын сизәмли белү мөһим.

*Тупылларга тиң син үзең, юкса,*
*Эчләреңдә нинди дулкыннар?!*

Наис Гамбәр. Ачык калган тәрәзәм... – Казан: «Рухият» нәшрияты, 2006 ел.

*Өзелергә җиткән тамчы сыман,*
*Карашларың тора сулкылдап.*

Табигать һәм Кеше. Наис Гамбәр иҗатында алар нииндидер органик бердектә яшиләр. «Өянкеләр-динозаврлар», «мамонт-тупыллар» кебек янәшәлек аша үсемлекләр дөньясына җан өрү яки «Ак бураннар итәгенә сөртәм, Итәгенә бозлы яшемне,»—дип, табигать күренешләрендә кеше образын табу шагыйрьнең лирик шәхес концепциясен үзенчәлекле ача.

*Көзнең күзендә үк шигъри моң бар,*
*Яшерен сабырлык бар җанында.*

Менә мондый юлларда лирик геройның илаһи бер сиземләүгә, гайре табигый күз карашына, үзгә бер гамьгә ия икәнлеге күренә.

Табигатькә табыну шагыйрь иҗатында кошлар, агачлар, стихиясе белән тыгыз бәйләнгән. Берише шигырьләрдә лирик образ көзге монсулыкка чорналып, үзенең күңел халәтен, җан сулкылдавын, сагышның биниһая күп төсмерләрен шигъри юлларга сала:

*Авылда—көз... Дөнья сулып калган,*
*Кошлар китә... Бу бер төш кебек.*
*Ятам кырда—очып барган җирдән*
*Егылып төшкән бала кош кебек.*

«Исә җилләр» шигырендә каләм иясе агач башларында чайкалып торучы кош ояларыннан канат чыгарып җилгә каршы очкан кош балалары язмышын шагыйрь чынбарлыгы белән янәшә куя. Аның «Урман җиле иң беренче булып, Биек агачларга кагыла» дигән шагыйранә кагыйдәсендә үк лирик геройның язмышы чалымлана.

«Син—очар кошым», «Аккош күле», «Кавырсын хат», «Бәбкә саклаучы кызга» кебек шигырьләрдә лирик геройны биләп алган илаһи манзара романтик югарылыкта сурәтләнә. Кош каурые—шушы детальне каләм иясе шигъри символ дәрәҗәсенә үстерә. «Кешенең тынгысыз табигате һәрвакта яңалыкка омтылган кебек, һәр өлкәдә яңа «материклар» ачкан кебек, хәзерге шагыйрьләр дә символиканы яңартырга һәм кешегә якынайтырга омтылалар. Үзләрен камаган предмет-күренешләрнең искесенә дә, яңасына да мөрәҗәгать итеп, аларның эчке мәгънәләрен ачып, көтелмәгән шигъри ассоциацияләр уятып, бүгенге кешенең рухи дөньясына тирәнрәк үтеп керергә, киләчәк буыннарга хәзерге заманның рухын «стенографик формада» теркәп калдырырга тырышалар»,—дип язган иде Нил Юзиев. *(Н. Юзиев Хәзерге татар поэтикасы, 166 б.)*

«Казлар канатына сүзләр язып, Көн дә сезгә сәлам җибәрәм» яки «Су буена төш тә, Кавырсыннар апмен, Истәлеккә гелгә, озакка»—дип каурый-символны мәгънәви яктан тыгызлый шагыйрь. Вакыт—пространство функциясе йөкләнгән символ җанлы бер образ дәрәҗәсенә күтәрелә.

Лирик геройның күңел дөньясын төгәл характерлаган кошлар образы «Кызыма хат» шигырендә үзгә бер сурәтлелек ала:

*Гаҗәпләнмә: бер көн өй каршына*
*Кошлар җиккән арба туктаса,*
*Күңел кошлары ул:*
*Тәкыя үр, Ләйсән,*
*Кошлар биргән гөлдән чук ясап.*

Шигырьләрдәге романтика, хикмәтле символ-сурәтләр лирик геройның бай, әкияти күңел дөньясын гамәли чынбарлык янәшәсендә сурәтләп үзгә бер тирән мәгънә чыгарырга мөмкинлек бирә.

Уй һәм хиснең илаһи көчкә ия булуы, рухи дөнья һәм матди тормыш арасындагы бәйләнеш шигырьләрдә гыйбрәтле ассоциацияләр тудыра:

*Ак болытка язып салган идем,*
*Җитте микән хатым Казанга?*
*Эфир аша килгән хәбәр әйтте*
*Бүген яңгыр яуган Кабанга.*

Шушындый исбатлау нигезендә фәлсәфи сөземтәләр чыгарырга яраткан шагыйрьнең күзәтүләреннән нигезле афоризмнар туа тора:

*Күпме күз текәмә, өметләнмә,—*
*Кояш чыкмый баткан ягыннан.*
яки
*Сөюнең булмый үткәне,*
*Ялганына хәтле... чын.*

Т. Галиуллин сүзләре белән әйтсәк: «Әдәби әсәрдә күңел күзе генә си-

земләгән төсмер, борылыш, буяуга салынган яна бер сызык әллә нинди озынозак сөйләшүләреннән, галәм белән фәлсәфи әңгәмәләреннән кыйммәтрәк бәядә йөрергә мөмкин.» *(Галиуллин Т. Шигърият баскычлары, 179 б.)*

Зур мәгънә сыйдырган шигъри детальләр, үзенчәлекле янәшәлекләр, романтик образлылык, пространстволы күзаллау мәхәббәт шигырьләренә дә үзгә бер яңгыраш бирә. «Төнге учаклар» шигырендә тамчы белән тамчы арасы һәм икәүнең язмышы янәшә куела. Ләкин романтик геройларның төнге яланнарга яланаяк чыгып йөгергән, чирәмнәргә ятып тәгәрәгән, сабый бала кебек тилергән, юләрләнгән, шашкан, таганнарга асылынып атынган вакытта бәллүр тамчы төшеп ватыла. Бу символик образ сөюнең нинди нәфис, нәзберек хис икәнлегенә ишарәли.

«Мин бер аучы, син бер болан кызы» —шагыйрь лирик герой белән аның сөеклесе арасындагы мөнәсәбәтне шушындый антитезада билгели. «Мәхәббәт эволюциясе»ндә дә романтик шәхес каты куллы, сунарчы холыклы булып күз алдына килә:

*Тынды дөнья, күтәрелде кошлар,*
*Мин аларга төзәп ук аттым.*
*Берсе төште егылып алларыма,*
*...Ah, мин шул чакта сине югалттым.*

Г. Халит тә «Җан диалектика»сын антитеза алымыннан башка күз алдына китереп булмый»—дип билгеләгән иде *(Халит Г. Многоликая лирика, 100 б.)* Лирик геройның кичерешләрен эзлекле сурәтләрдә биргән «Мәхәббәт эволюциясе»ндә, шәхес буларак, лирик геройның характер үзенчәлеге калку бирелә. Бу очракта Платонның: «Стиль нинди, характер шундый»,—дигәне искә төшә. *(Федотов О. И. Основы теории лит-ры, 177 б.)*

*Уклы җәя бир дә миңа ат бир,—*
*Ир канаты була җитез ат!*
*(Оч, Дөлдөлем, алга! Укны кулым,*
*Җик Мәргәндәй туры төзәп ат!)*

Менә болары инде—шагыйрь шәхесен, аның холкын, темпераментын тулысынча характерлый торган юллар. «Шигърият шәхестән башлана»,—ди Т. Галиуллин. *(Галиуллин Т. Шигърият баскычлары, 216 б.)* Наис Гамбәр шигырьләрендә дә шагыйрь горурлыгы, лирик шәхеснең үз-үзенә, намусына, үзенең яшәү принципларына тугрылыгы ярылып ята. Ак атка менәр өчен генә «ак»ны «кара» дия һәм дошманына башын ия алмаган лирик шәхес үзенең горурлыгына хилафлык китерми:

*Әмма, Вакыт, калган юлымда да*
*Сикреп меналмасам Ак атка,*
*Гавам күзгесенә төшкән рәсмем*
*Кара килеш калсын, «агартма»!—*

Шәхес концепциясе Наис Гамбәр иҗатында, әлбәттә, шагыйрьнең үз шәхесе, дөньяга карашы, кешеләргә, аларның холык-фигыленә мөнәсәбәте, үзе җан өргән образлар аша үстерелә.

Шагыйрь күңеленең иң газиз, иң җылы почмагында урын алган Әнкәй образы аеруча саклык, нәфислек, баланың анага булган тирән хөрмәте аша яктыртыла. Самавырын көненә әллә ничә тапкыр янартып, күз нурларын түгеп балаларын көтүче, таңда чишмә юлыннан кайтып килүче әнкәй турында: «Әнкәемнең төсе күз алдымда Әйтелмәгән васыять кебек»,—дип шагыйрь психологик киеренкелеккә ирешә. «Әнкәйгә» җырының тәэсир көче, уңышы да шуңа бәйләнгән. Ана белән бала арасындагы иң саф, иң изге хисләр, иң авыр чакларда ана рухына сыену мотивлары «Әнкәй төше», «Килүең дә авыр...» шигырьләрендә дә күренә.

Шәхес—шагыйрь өчен иң беренче чиратта тотрыклы хисләргә, ныклы тормыш принципларына, үз-үзенә һәм башкаларга тугрылыклы зат. Гади генә бер вакыйга яки мисал белән ул шигырьләрендә кешелеклелек үрнәген сурәтләп куя. Мәсәлән, инде күптәннән өендә яшәмәүче күршесенең капка алдын гел чистартып, себереп торучы Гаптери—шундый тип түгелмени? Халыкта: «Күрше хакы—тәңре хакы»,—дигән тәгъбир яши. Авыл кешесенең вакыт та, үзгәреп торган тормыш шартлары да юып ала алмый торган матур сыйфатларны саклап калучы Гаптери—нәкъ менә авторның әхлакый кыйбласын билгели торган шәхес ул.

Кешенең бары тик туган җиренә, туган туфрагына мөнәсәбәттә генә

шәхес буларак сыналуы «Качак» шигырендә гыйбрәтле мисалда сурәтләнә. Туган жиреннән китеп, Кузбасста эшләгән татар агае туган жиренә «качак» сыйфатында кайткан.

*Елады агай маңгаен*
*Өстәлгә бәрә-бәрә.*
*Кайткан ул...*
*Җилкәнсез көймә*
*Ярларга бәргәләнә.*

В. Г. Белинский бик хаклы рәвештә: «Шагыйрь образлар белән фикер йөртә, ул хакыйкатьне исбат итми, ә аны күрсәтә»—дип яза. *(МоисееваТ. В. Работа с поэтическим текстом, с. 7)*

Күңеле белән туган авылга береккән лирик геройның кичерешләре «Кайтсам...» шигырендә дә җете буяулар белән сурәтләнә:

*Мин гел шулай: кайтсам—китмәс өчен*
*Бер-бер хәйлә табам, алдашам;*
*(Йөрәгемдә—утлар, мин су эчәм*
*Атлар белән агач ялгаштан.)*

Шуның өчен дә Наис Гамбәр Шәхесне туган җир, туган телдән аерым күз алдына да китерми:

*Һәрбер халык,*
*Иле булса—Алла,*
*Теле булса гына—пәйгамбәр...*

Мәкальгә, афоризмга әйләнгән ошбу юллар Наис Гамбәрнең шәхес концепциясенең нигезен, этәргеч ноктасын тәшкил итә.

«Шәхесне һәм аның көчен олылау С. Рәмиев поэзиясенең дә нигезендә ята,—дип яза Н. Юзиев.—Әмма анарда шәхесне хис ягыннан ачу беренче урында тора. Хиснең шигырьгә хуҗа булуы аның үзенчәлекле поэтикасын да төзи» *(Юзиев Н. Традицияләр янарганда, 98 б.)* Мондый үзенчәлек романтизм мәктәбен үз күргән Наис Гамбәр иҗатына да характерлы. Поэтик синтаксис, шигырьләрдәге күзгә бәрелеп торган стилистик үзенчәлекләр, строфадагы юлларның үзара ярашуы, авва рәвешендәге рифмалар язучының мантыйгына, дөньяны кабул итү, тану үзенчәлегенә ишарәле кебек. Гетеның мондый сүзләре бар: «Шигырьнең калыбы поэтик хистән ихтыярсыз рәвештә килеп чыга. Әгәр шигырь язганда, калып турында уйлансаң, акылдан язарсың, һәм, әлбәттә, бернинди юньле нәрсә дә яза алмассың.» *(Эккермен И. П. Разговоры о Гете, 446 б.)* Галимнәр билгеләвенчә, нәкъ менә романтик хис шагыйрьгә шушындый иҗат иреге, үзенчәлекле иҗат ызаны ача. Шагыйрь үзенең фикерен ассызыклау, хисси куәтен арттыру максатында шигырьдәге тавыш агымы, ритмның өзелүе, өстәмә пауза кебек чаралардан да файдалана. Образлык, тәэсирлек максатында җөмләләрнең үзенчәлекле корылышы, шигырь юлы яки җөмлә башында кабатланучы сүзләр (анафора), рефрен, рәдиф кебек мөмкинлекләрне эшкә җигә. Шуның өчен дә үзенең озын булмаган иҗат гомерендә Наис Гамбәр милли шигърияттебезнең энҗеләре булып калырлык шигырьләр, халык күңеленә берегерлек гыйбарәләр калдыруга ирешә.

**Ләйсән КӘШФИЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# ТОРМЫШТАН АЛЫНГАНМЫ, ЯЗУЧЫ ХЫЯЛЫНДА ТУГАНМЫ?

Бездә трилогияләр еш язылмый. Галим һәм язучы Тәлгат Галиуллинның укучыга инде яхшы таныш булган «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар» исемле романнарын бергә туплап, аларның үзәк каһарманы исеме белән аталган трилогиясе китап киштәләрендә урын алды: әйе, «Сәет Сакманов» (Татарстан китап нәшрияты 2005). Хәзер бу әсәрләрне бергә җыйнап укырга, иркенләп, уйланып хөкем йөртергә, фикер алышырга мөмкин. Югары дәрәҗәдәге бизәлеш, пөхтәлек, рәсемнәрнең матурлыгы һәм эчтәлеккә ярашып торуы белән китап бик зәвыклы һәм иң таләпчән укучыны да канәгатьләндерерлек булып чыккан. Моның өчен нәшриятыбыз хезмәткәрләренә зур рәхмәт! Авторның бу романнары әле аерым-аерым, бер-бер артлы дөнья күргәндә үк, хәзерге чорыбызны сурәтләүне үзәккә максат итеп куйган булулары белән җәмәгатьчелекне битараф калдырмады. Укылды, югары бәяләнде, авторы исә Язучылар берлегенең мәртәбәле Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек табылды. Бигрәк тә замана «бизәкләрен» үзендә күп туплаган, катлаулы язмышлы Сәет Сакманов образы әле тулысынча туып бетмәс борын ук тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре, укучылар даирәсендә бәхәсләр уятты. Бәяләр төрле-төрле, каршылыклы булды, һәм бу - табигый дә. Аның социалистик реализм концепциясенә җавап бирердәй уңай герой түгеллеге әйтелде (Л. Дәүләтшина), иблис тә, фәрештә дә була алмавы ассызыкланды (А. Хәлим), шул ук вакытта, нинди генә мөһер сугылмасын, аның әдәбияттән (бәлки, тормыштан?!) тиз генә китәргә җыенмаган тип икәнлеге дә искәртелде (С. Хафизов) һ.б. Ләкин, шуның белән бергә, ике гасыр «күрешкән» чорда туган каһарманның ни сәбәпле кызыксыну уятуын, әйтергә яраса, феноменын ачыклап бетерә алмадык. Мин дә соңгы сүзгә дәгъвә итмим.




Коммунистлар фиркасе алып ташланып СССР таркалгач, озын-озак еллар дәвамында «авызлыкка» өйрәтелгән күпләр югалып калды. Әдәп-әхлак кануннары пыран-заран килде, кинәт кабынган уттан качкан тараканнар кебек, халык төрле яшәеш стихиясенә кереп батты. Бераүләр алды, икенчеләр сатты, өченчеләре ил малын таларга кереште... Менә шул чорда, «борылыш» дип аталган болганчык елларның уңай һәм тискәре хасиятләрен үзләренә сеңдергән Сәет Сакманов, Шөреп, Гаяров кебек затлар өскә калыкты. Ягъни тормыш аларны үзе тудырды, тәкъдим итте, укучыга аларны бәялисе, аңлыйсы гына калды. Чөнки, шагыйрь әйтмешли, әгәренки йолдызларны кабызалар икән, димәк, алар кемгәдер кирәк. Әйе, һәр ихтыяҗны иҗтимагый-сәяси яки шәхси мәнфәгатьләр тудыра. Сәет Сакмановны да, аның мохитен, фикердәшләрен һәм дошманнарын да икътисадый-иҗтимагый яшәеш шартлары калыплаган бит. Бу каһарманга мөнәсәбәтебез уңай булып, хуплаган тәкъдирдә дә, Сәетне идеаль герой йөри торган тәртә арасына куып кертеп булмый, ул анда сыймый, андагы таләпләргә җавап бирми.

«Казан утлары» журналында соңгы ике елда уңай герой, олы шәхес турында зурдан кубып бәхәсләшеп, күтәрелеп бәрелсәк тә (ә мондый сөйләшү кирәк иде, өлгергән иде!), проблеманы ахыр-

Тәлгат Галиуллин. Сәет Сакманов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел.

гача чишә, фикерләшүгә барыбызны да канәгатьләндерерлек ноктаны куя, жир шарын әйләндереп куярдай Архимед таяныч ноктасын таба алмыйбыз, һәм ул, гомумән, мөмкин эш тә түгелдер. Һәр чор әдәбияты һәм сәнгате үз геройлары белән килә, шулар белән тарихка уза, ягъни ил-көннең яшәеш вәзгыятенә бәйле рәвештә образлар системасы тудыра һәм алар үзгәреп-яңарып тора. Мәктәп, урта һәм югары уку йортлары программаларына кертелгән, өйрәнелгән XIX гасырның классик саналган образларын, аталары калдырган мал исәбенә типтереп яшәүче Евгений Онегин, Ленский, Печорин, ата жулик Чичиков, ялганчы, буш куык Хлестаков, хыялый, ялкау Обломов, мәхәббәттән башка хис-тойгыны, кайгы-хәсрәтне белмәгән И. С. Тургенев кызларын искә төшерик. Шул чор әдәбияты тәкъдим иткән геройларның берәрсе сука артыннан йөреп, мал абзарын тазартамы, юкә каезлап, чабата үрәме? Лев Толстой каләме тудырган чибәр ханым Анна Каренина колхозның хезмәт «таягы»на тигән барлы-юклы икмәген кире хөкүмәткә илтеп бирер идеме икән?

XX гасырның әдәби-эстетик казанышлары саналган: М. Горькийның «Клим Самгин тормышы», Б. Пастернакның «Доктор Живаго» кебек эпик әсәрләрен алыйк. Икесенең дә романнарга исем биргән үзәк геройлары — тормышта үз кыйблаларын таба, системага жайлаша алмый бәргәләнгән шактый ук урта кул, шул ук вакытта фажигале шәхесләр. Совет әдәбияты чыраена жинүче кыяфәте чыгарган 20 нче еллар, 30 нчы елларда да Илья Ильф белән Евгений Петров каһарманлык бизмәненә шахтер Стахановны, Ардуан батырны, атасын сатып үрнәк пионер даны алган Павлик Морозовны салмыйлар, ә яңа типны - авантюрист, әшәке, алдакчы Остап Сөләйман - Берта - Мария Бендер Задунайскийны утыртып куялар. Холкы, үз-үзен тотышы, эш-гамәлләре, караклыгы белән ничек кенә ачуыбызны китереп, саруыбызны кайнатмасын, Остап Бендер әдәбият тарихына тип булып кереп калды. «Күчеш чоры» тибы дибез, чөнки ул үз вазифаларын «намус» белән үти: көлдерә, нәфрәтләндерә, уйландыра, көендерә... В. Катаевның «Вакыт, алга!», Л. Леоновның «Соть», «Дәрьяга юл», Ф. Панферовның «Бруски» дигән 30 нчы еллар роман-повестьларының үзэгендә вакытны узарга ниятләгән алдынгы эшчеләр, хыялый галимнәр, колхоз тормышы «ләззәтен» татый башлаган крестьяннар торса да, хәтта авторлары талантлырак булса да, берсе дә «Унике урындык», «Алтын бозау» исемле әсәрләр шөһрәтенә күтәрелә алмады, үз чорының сурәтле елъязмалары гына булып калды. Сәбәбе ачык: Сөләйман малае Остаптан рекордлар таләп итмиләр, «фирка уставын бозасың, коммунист исеменә тап төшерәсең», дип дәгъва белдермиләр. Хезмәт процессы никадәр генә матур да, ямьле дә күренмәсен, аны турыдан-туры сурәтләү үзе генә поэтик образ дәрәжәсенә күтәрелә алмый. Аны кеше характеры, эчке дөньясы, кичерешләре ярдәмендә генә шигърият итәргә мөмкин. Көнбатыш әдәбиятының Бальзак, Флобер, Стендаль, Мопассан, америкалы Драйзер кебек бөек реалистлары яшәгән чорда да авыр физик хезмәт булган: шахтер күмер чапкан, игенче жир сөргән, иген үстергән... Мәгәр сүз осталарын күбрәк кешенең рухи дөньясы, мәхәббәте, өйләнүе, балалар үстерүе, башка кешеләр белән аралашуы, күршеләре белән мөнәсәбәте, батырлыклар кылуы, дингә карашы, фани дөнья белән хушлашуы... кызыксындырган. Акны кара дип әйтергә мәжбүр ителгән совет әдәбият белеме бу төр әсәрләрне иске жәмгыятьнең тончыктыргыч шартларын, кара, тискәре якларын ачы тәнкыйтьләп, иске дөньяны фашлауга багышланганнар дип бәяләде. Хәзерге жәмгыять яшәешендәге тискәре күренешләрне, авыр үсеш юлларын күзалларга мөмкинлек биргән Сәет Сакманов та шул типтагы образлар рәтенә сыймыймы?! Язучы хыялында канатланган, яисә тормыш лабиринтларыннан сайлап алынган образны кабул итү укучының зәвыгына, сәнгати шартлылыкны аңлау сәләтенә дә бәйле. Чын шәхес образы катлаулы һәм каршылыклы булса, укучыда ихтирам уята. Андый образны аңларга тырышу, аңлату - әдәби тәнкыйтьченең, сүз сәнгате галименең бурычы һәм намус эше.

Шул рәвешле, А. Гыйләжев үзенең «Балта кем кулында?», Р. Мөхәммәдиев «Кенәри - читлек кошы» әсәрендә баш-

лаган традицияне дәвам итеп, җәмгыять белән идән астыннан идарә итүче кара көчләрнең пәрәвездәй чәбәләнгән катлаулы хәл-әхвәлләрен; алдау, кирәкмәгән кешене юлдан алып ташлау кебек явыз алымнар белән эш итүчеләрне «Сәет Сакманов» трилогиясе үзенчә чыбыркылый.

Автор баш героен төрле яклап сурәтли, уңай сыйфатларын да күрә, кояш яктысына тартып чыгарып, кимчелекләрен дә күрсәтә. Сәет үзен тайгак, пычрак юлга баскан, төзәлергә, чын-чынлап тәүбә итәргә тиешле кеше санамый. Аның үз язмышы өчен көрәшә белүе сокландыра. Сакманов «хәлле яшәешне кешенең акыл сәләтен күрсәтүче билге» дип саный һәм татарның милли байлары булырга тиеш дигән ышаныч белән яши. «Без - тычканнар баскан өйне тазартучы санитар мәчеләр», дип кабатларга ярата ул үзенең яраннарына. Бай белән ярлыга бүленеш табигый, адәм балаларын Ходай тәгалә тигез яратмаган, дип исәпли. Берсенә матурлыкны, таң калырлык чибәрлекне мулдан биргән, икенчесенә дөньяны калтыратып тоту, өченчесенә лидерлык сәләтен тоттырган... Кемнедер горур, эре, тәкәббер итеп яраткан, кайсынадыр байлык туплау, саранлык чирен иңдергән...

Мәхәббәт мажаралары белән бәйле мавыктыргыч борылышлар, укучыны кулда тоту максаты белән уйлап табылган, көтелмәгән хәлләрне сурәтләүгә маһирлык, сюжет канвасының ирекле чигелүе ягыннан Т. Галиуллин әсәрләре Көнбатышта «Декамерон»нан башланып, ничә гасыр дәвамында яшәгән «азгынлык, алдакчылык» романнарын («плутовский роман») искә төшерәләр. Әмма тышкы якынлык эчке яңгырашка, фәлсәфи юнәлешкә кагылмый. «Сәет Сакманов» трилогиясе үзәк персонажда чагылган сәяси-иҗтимагый тәрәккыяткә мөнәсәбәте һәм бәясе; милләт яшәеше, татар теленең язмышы турында уйланулары, тарих тарафыннан рәнҗетелгән, башкалар тарафыннан изелгән кимсетелгән халык баласы багыреннән өзелеп төшкәнлек сизелү белән аерылып тора. Монда халкының киләчәге өчен борчылмаган, җинаятьчеләрне каптыру максаты белән генә мәшгуль алдынгы тикшерүчене яки милиция хезмәткәрен сурәтләгән мажаралы (детектив) романнар белән уртаклык та бар кебек. Ләкин автор тормышка, яшәешебезгә аек карый. Менә, мәсәлән, соңгы елларда шау-шу куптарган, үлем белән беткән бер генә җинаятьнең ачылмаганын да яшерми ул.

Сәет - гади-гадәти образ гына түгел, ул—тип. Кыргый капитализм шартларының типик гәүдәләнеше булган герой, әйтергә яраса, хәтта серле герой. Аның иҗади көчен, җегәрен җәмгыять тиешенчә куллана, файдалы эшкә җигә алмаган. Аерата бер яссылыкта ул үзенә уңай мөнәсәбәт уята. Ул - саф татар баласы. Татар иң болгавыр заманда да югалып калмый, үзен диңгездәге йомычка хәленә төшерми, дигән фикергә алып килә язучы. Т. Галиуллин бу персонажы белән XX гасыр ахыры-XXI йөз башы әдәбиятында яңа тип ачты дисәк тә, зур хата түгел. Әйе, Сакмановларны җәмгыять яшәешеннән сызып ташлап булмый. Әле, бәлкем, шулардай узган гасыр башындагы кебек меценатлар чыгар, алар милләтебезгә зур хезмәтләр күрсәтер. Чөнки Сәетнең атаклы саран Плюшкин кебек үз байлыгына мөкиббән китеп, акча санап ятмыйча олы сәясәткә чыгарга, депутат булырга, әдәбиятны аңларга омтылышы кебек мактауга лаек сыйфатлары да бар. Аны, алда әйтелгәнчә, илдәге вәзгыять ситуация тудырган.

Сәет Сакманов белән якыннан аралашкан кешеләр арасында аның даирәсенә очраклы килеп эләккән, чын мәгънәсендә инсафлы кешеләр дә аз түгел. Андыйлар героебызга мөнәсәбәтле хатын-кыз арасында бигрәк тә күп. Фәнгә тартылган Мисхәт-Миша - шундыйлардан. Яки, әнә, Сталин лагерьларын узган, лаеш шулпасын мулдан чөмергән, нечкә күңелле, юморга бай, мөлаем Әхмәдиша карт һәм аның карчыгы... Бу образлар милли үзенчәлекләрне күзгә бәрелеп тормаган деталь-күренешләр аша тасвирлауга, халыкның ерак тарихи тамырларын эзләүгә, тоталитар режим тегермәненә эләккән аерым шәхес, гаилә язмышы аша тулы бер буынны сурәтләүгә мисал була алалар. Әхмәдиша картның гадәти хәл-әхвәлләрен Сәет һәм аның яраннары белән бәйләп язучы татар халкына хас фикерләү үзенчәлекләрен дә ача. Аңар чылтырап аккан зәмзәм чишмәседәй игелеклек, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек хас. Кеше

үтерүне гадәти бер гамәл санаган бәгырьсезләр дә аның янында, саф әхлакый тәртипләр божрасына эләккәндәй, гөнаһсыз сарык бәрәннәре кебек булып, юашланып кала.

Билгеле инде, әдәби әсәр унай яки тискәре геройны сурәтләүгә генә кайтып калмый. Ул - идән, түшәм, тәрәзә, ишек, ишек тоткасы, баскыч, җылыткыч, яктырту җиһазлары... бердәмлегеннән торган өй шикелле композиция, сюжет, конфликт, характерлар, лирик чигенешләр, тел-стиль, сүз-сурәтләр гонсырыннан төзелгән катлаулы бина. Бу яссылыктан «Сәет Сакманов» трилогиясе житди һәм һәрьяклап сөйләшүгә, фикер алышуга зәмин бирә. Автор төрле яшьтәге, дөньяга һәркайсы үзенчә карашлы йөзләгән персонажлар белән зур оркестр дирижеры кебек оста идарә итә; вакыйгалар жебен чуалтмый. Инде онытыла башлаган каһарманның янадан «кирәге» чыга, ул янадан сүзгә, хәрәкәткә катнашып китә... Күп кыллы, күп тавышлы полифоник әсәрдә кеше җанының бәргәнәлүләрен, «зиһен ташкынын» сурәтләгән урыннар да житәрлек. Катлаулы композициянең «сүтелгән, убылып төшкән урыннары» авторга озак еллар дәвамында татар, рус әдәбиятлары тарихын студентларга өйрәтү, сүз сәнгате әсәрләрен анализлау буенча махсус курслар алып бару да ярдәм иткәндер дип уйлыйм. Әгәр бу әсәрнең ижат методын якынча «кырыс реализм» дип билгеләсәк, трилогиянең теләгән фикерне, хәтта эстетик идеалны ачуда үз бурычы бар. Трилогиянең беренче кисәгендә («Тәүбә» романы) Көнчыгыш әдәбиятлары романтизмына барып тоташкан шигъри мәхәббәт фонында автор безнең көннәрдәге җинаятьчелекнең килеп чыгуының иҗтимагый һәм икъдисадый сәбәпләрен ача. Икенчесендә («Элмәк») хакимият һәм хөкем оешмаларының кайбер вәкилләре «фатихасы» белән җинаятьчелекнең көчкуәт алып бәйдән ычкынуының нәрсәләргә алып килүе шактый ук тирән психологик анализ ярдәмендә тикшерелә. Өченче роман («Төнге юллар») «ахыр чиктә бер түлисе була, берсе генә дә - мәхәббәт ләззәтләре дә, байлык хозурлыклары да - мәңгелек түгел» дигән мәгънәне, кичерешне укучыга житкерү бурычын үти. Гаилә бәхетенә, байлыкка ирешкән Сәет бу рәхәт тормышның озакка бара алмасын «татлы бер сиземләү» белән сиземли. Мәхәббәт — аның өчен үтеп чыгарлык, ләкин житди сынау. Өч романның стиленә дә тормышка жанлы мөнәсәбәтнең ачык чагылышы, сурәтләү чараларының күптөрлелеге, тапкыр һәм көтелмәгән чагыштырулар, юмор хисе, фажигале хәл-әхвәлләр унае белән дә «күз яше аша көлү» хас.

Автор традицион сынландыру алымнарын һәм чараларын урынлы куллану белән беррәттән төрле яссылыкта яткан төшенчәләрне янәшә кую, тәсләр, исләр берлеге һәм каршылыгы, синестезия күренешләренә мөрәҗәгать итү ярдәмендә сурәтне төрләндерә, жанландыра. «Мәҗүси жил», «битараф ай», «шадра йолызлар» кебек табигать сурәтләре янында «төссез, иссез, тәмсез, ләмле, үчле тавыш» кебек эпитетлар психологик халәт тудыруга ярдәм итә. Онытыла барган, яки жирле сөйләшләргә хас сүзләрне кулланудан да автор тартынып тормый һ. б.

Кыскасы, татар әдәбияты бүгенге заманыбызны каршылыклары, табигый матурлыклары белән сурәтләгән романтрилогиягә баеды. Сәнгатьчәлек ягыннан югары дәрәҗәдәге трилогия герое - Сәет Сакманов, бер тәнкыйтьче әйтмешли, китәр өчен килгән, узгынчы каһарман түгел. Шунысы хак. Бу язманың исеменә чыгарылган сорауга да шикләнми җавап бирергә мөмкин: ул - тормыштан алынган, әмма язучының сәнгати хыялы ярдәмендә агымдагы тормыш каршылыкларын, бүгенге адәми зат рухының гаҗәеп бай һәм катлаулы булуын тагын да ачыграк һәм тулырак чагылдыра торган итеп сурәтләнгән.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

**СӨҢГЕ**—Сугыш һәм ау коралы. Борынгы төрки телдә—*сүңгү*. Сөңге сабын нык агачтан (гадәттә каеннан), үткен очын борынгылар таштан, сөяктән ясаганнар, аннары металлдан ясауга күчкәннәр. Атаманың этимологиясенә килгәндә, "сөңге" (борынгы уйгурда *сүңүк*) сүзен "сөяк" сүзе белән янәшә куеп карарга мөмкин. Металл очлы сөңгеләр Идел-Кама төбәгендә яңа эрага кадәр VII гасырда күренә башлаганнар. VIII-XV гасырларда болгар-татарлар өч кырлы, дүрт кырлы һәм җәенке очлы сөңгеләр кулланганнар.

Төркиләргә кыска сөңге-*җыба* (*чыда, чида, җида*—дротик, ыргытмалы ук), җәпле һәм тешле сөңге—*нәйзә*, ике җәпле *аю сөңгесе*, зур, озын сөңге—*салдау* таныш булган. Судан балык чәнчеп ала торган сөңгене дә салдау дип атаганнар. Андый сөңгенең башка исеме—*сөйре* яки *сөйрек*. Сөңге очлыгы (сөңге яфрагы) гарәпчә *вәрак рәмхи* дип тә аталган. Башына бау элмәк ясалган сөңге—*корык* атларны тотар өчен кулланылган. Сөңге байрак сабы булып та хезмәт иткән. Мәс., монголларның "тугыз аяклы" байрагы тугыз сөңгедә күтәрелгән, сөңге саен очына берәр ат койрыгы (чук) асылган. Сөңге очындагы айны *маһичә* дип йөрткәннәр. Гаскәр башлыгының сөңгесенә бәйләнә торган ак ситсы әләм *лива* дип аталган.

**СӨРӘЙЯ** *г.* —**1**.Люстра. **2**."Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге"ндә Сөрәйя "Җидегән йолдыз"—"Созвездие Большой Медведицы" дип күрсәтелгән. Ләкин диңгезчелек буенча күптомлы энциклопедия язган Әхмәд ибн Мәҗид Сөрәйя дип Иләк йолдызны (Өлкәрне) атый. Оптик коралсыз караганда гади күз бу йолдызлар төркемендә шулай ук җиде йолдыз күрә, аларның алтысы бер үзәк йолдыз тирәли урнашканнар. Шуңа күрә гарәпләр аны "Люстра" дип атаганнар да. Ә Зур Җидегән гадәттә *Дөббеләкбәр* һәм *Катафалк* исемен йөрткән. Н.Исәнбәтнең "Татар халык мәкальләре"ндә: Сөрәйя—*Өлкәр*.

**СӨРӘН**—Бу сүз "язгы бәйрәм" (асылда спорт бәйрәме), "Язын явыз рухларны тораклардан "сөрү" мәгънәләренә ия. "Бәйге" сүзен "сөрән" сүзенең синонимы итеп тә карыйлар. Охшаш сүз, төрки телләрдән кала, удмурт, мари телләрендә дә күзәтелә. //*Газиз сөрән*—"мактаулы, бер ел тәүлеге көтеп алынган бәйрәм", сабан туе. *Сөрән көне*—сабан туе алдыннан өй борынча йөреп халыктан бүләкләр җыю көне. *Сөрәнгә чыгу*. Борынгы төрки телдә *сөрән/сүрән*—сугышка өндәп кычкыру.

**СӨҺӘЙЛ ТАБЫ**—Каноп(ус) йолдызы (*Киль* йолдызлыгының альфасы) табы. Мөселманнар Сөһәйл йолдызы Йәмәндә калка дип уйлаганнар. Бу якты йолдыз нуры төшкән тәндә тап кала, ул тап кешене йә яхшы, йә яман итә дип ышанганнар. Гарәбстанда бу йолдызның тире эшкәртүгә тәэсире бар дигән ышану да таралган. //*Барчага тикәр Сөһәйл (табы) нуры, ләкин Бер йирдә булыр затлы күн, бер йирдә—затсыз.* Сәйф Сараи.

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

***СУ*** – "Төркиләр барыннан да элек утны, һаваны һәм суны хөрмәт итәләр..." (Симоката Феофилакт, "История", М., 1957). Борынгы бабаларыбыз суны дөньядагы бөтен нәрсәнең башлангычы һәм чыганагы итеп күзаллаганнар. Җир үзе дә дөнья океаны төбеннән үрдәк кабып чыккан балчыктан барлыкка килгән имеш. Татар телендә "кояш, ай, йолдызлар бата һәм калка", ягъни бу сүзләрдән үк без борынгы ата-бабаларыбызның бөтен дөньяны су әйләндереп алган дип ышанган булуларын күрәбез (кояшка карата "байу / баю сүзе дә кулланыла, монысын Р.Әхмәтьянов төрки телләрдәге "әкренәю", тукталу; көчеп килеп утыру" мәгъэсендәге сүздән дип аңлата). Болгарлар суны пакъләнү чарасы дип белгәннәр, изге чишмә сулары белән дәваланганнар. Татар зиратлары елга яки элекке елга үзәне буенда, гадәттә авылга карата аръякта урнашкан булган, чөнки шулай итмәгәндә үлгән кешеләрнең җаны авылга кайта дип уйлаганнар. Мәчетләр дә, кагыйдә буларак, суга якынрак җирдә, әйтик, берәр күл буенда төзелгән була.

***СУМ*** I – Бу сүзне Р.Әхмәтьянов гомум төрки "сум, тоташ кисәк" сүзеннән, беренчел мәгънәсе "тоташ кисәк алтын" дип аңлата. Мәхмүд Кашгарый сүзлегеннән китерелгән мисал: *сун алтун*-алтын коелмасы ("бармак чаклы алтын"). Бу мисалдагы "сун" кытай телендәге *цунь* сүзеннән (3 см чамасы озынлык үлчәү берәмлеге). "Элегрәк мөһерле акча урынына гади алтын яки көмеш кисәге йөргән, аны ваклау да конкрет мәгънәдә эшләнгән." (Р.Әхмәтьянов.) Чыннан да XI-XIII гасырларда Болгар базарларында сәүдә эшендә шундый көмеш коелмалар кулланылган. Рус кенәзлекләрендә дә әйләнештә йөргән андый көмеш кисәкләрен, гривна сүзе белән беррәттән, *соум* дип тә атаганнар. Рус кенәзләре Алтын Урдага ясакны да соумнар белән түләгәннәр һәм бу көмеш анда акча сугу өчен мөһим чыганак булган.

Тагын кара: ***СОМ.***

***СУФИ, СУФЫЙ*** *г.* – "Суфи" атамасы гадәттә *мистик, мистицизм тарафдары* мәгънәсендә йөри. Бу сүз Коръәндә юк. Кайбер чыганакларда "суфи" сүзенең этимологиясен грек сүзләре "софиа" ("гакыл", "хикмәт") һәм хәтта "софистика" ("акыл сату") белән бәйләргә тырышу очрый, ләкин мондый караш нигезләнеп җитми. Гарәпләр грекча "философия" сүзен фәлсәфә дип алганнар, ә "софизм" сүзе аларда тискәре мәгънәле "сафсата" сүзе белән бирелә башлаган. "Суфи" сүзенең килеп чыгышын гарәпчә "йон" мәгънәсендәге "суф" сүзе белән бәйли торган фараз да бар (суфилар тупас йон тукымадан тегелгән кием киеп йөргәннәр). "Иранда да суфи шагыйрьләр еш кына үзләрен, гарәпләр өлгесе буенча, *пәшминә* ("йонтәс") дип йөртә торган булганнар. Йонтәсләнү – өстеңә баштарак дөя тиресе бөркәнеп йөрү, соңрак иске-москы кием киеп яшәү – суфилар өчен хас һәм типик күренеш." (Әхнәф Харисов.)

Кайчагында суфилар үзләрен *"балда"* ("әл-балда"), ягъни дивана, идиот дип атаганнар. Бу сүз Александр Пушкинның Балдасын искә төшермичә калмый.

Суфиларны Исламга гына нисбәтле дип булмый, мәс., *христиан суфийы* дигән төшенчә дә бар. Ләкин суфиларның тарихи эшчәнлеге башлыча Ислам белән бәйле.

Исламияттә суфи термины барлыкка килгәнче дәрвишләрне *"заһид"* дип йөрткәннәр.

Суфилар иерархиясендә баш изгене *котыб* дип, шигыйларда кайчагында *котыблар котыбы* яки *кояш котыбы* дип атаганнар.

Суфилар арасында бөек теологлар, шагыйрьләр, галимнәр булган. Алар атом теориясен яклаганнар, Чарлз Дарвинга кадәр алты гасыр элек эволюцион тәгълиматны бәян иткәннәр.

Суфилар (кимендә 12 ел белем алучылары), мәхәббәт кушуы буенча, кешеләрне, бигрәк тә рухи авыруларны дәвалау белән шөгыльләнгәннәр. Шунысын әйтик, суфи табиблар дәвалаган өчен бер уч арпадан артык түләү алмаска тиеш булганнар. Авыру кешене тирән гипноз халәтенә кертеп, алар аны үзенең авыруын ачыкларга һәм аңа каршы дәва табарга мәҗбүр иткәннәр.

Суфиларның бүгенге тормышка йогынтысына гадәттә бәя биреп җиткерелми. Әйтик, күбәүләрнең яраткан эчемлеге кофе (каһвә) беренче тапкыр суфилар тарафыннан зиһенне ачу өчен кулланылган. Хәзерге чалбар да нигездә суфилар киемен кабатлый.

Көнбатыш кешесе яратып укый торган күп кенә авторлар (Данте, Д.Дефо – үзенең "Робинзон Крузосы" белән, Чосер һ.б.) асылда суфи булганнар. Көнбатыш психология фәнендә Юнг һәм Фрейд ачышлары суфилар өчен яңалык булмаган инде. Суфи шәехе әл-Газали моннан 900 ел элек җенси мөнәсәбәтләр (секс) турында Фрейд ясаган нәтиҗәләрнең мөселман теологларына мәгълүм булуын раслый (Идрис Шаһ).

XVI гасырда Руми тарафдарлары булган суфилар дога укыган вакытны билгеләү өчен сәгать уйлап тапканнар.

"Кабуснамә"дә (XIII гасыр) суфиларга хас булган сыйфатлар санап чыгыла. Шәехләр фикеренә карaганда, суфилык өч нәрсәдә: мал-мөлкәт булмауда, үзеңне Аллаһыга тапшыруда һәм ныклы Иманда. Дәрвиш тәкъва, тәмле телле булырга, кеше рәнҗетмәскә, күндәм булырга, пакь кием кияргә, аңарда сәфәр өчен һәм туктальшларда кирәкле таяк, хәер өчен касә, юыну өчен комган, намаз уку өчен намазлык, җилпәзә, тарак, энәләр, тырнак кисү өчен пәке кебек кирәк-яраклары булырга тиеш. Ул сәфәрдә йөрүне яратырга, ләкин ялгызы гына сәфәр чыкмаска тиеш һ.б.

Иске тарикатьтәге күпчелек суфилар никахта торганнар. "Сүрия чәчәге" дигән ләкаб алган суфи Ибн әл-Хәвәринең (вафаты 383/995 елда), мәсәлән, дүрт хатыны булганлыгы билгеле. Ләкин инде XI гасырда капма-каршы юнәлеш – никахсызлык, үзеңне Аллаһка гына багышлау, пакь күңелле булырга омтылыш өстенлек ала. Суфилар арасында хәләл җефетенә алтмыш биш ел кагылмыйча гомер итүче дә булган дип сөйлиләр, ә Шираздагы мәшһүр ибн Хәфиф суфи 400 тапкыр никахланган, ләкин шундук, хатынына кагылмастан, талак кылып аерып җибәргән.

Дөреслек хакына шуны да әйтергә кирәк, христиан монахларын сагалап торган "гөнаһ"тан – гомосексуализмнан мөселман суфилары да азат булмаганнар.

Шәрыктә мәгълүм суфилар: *Мәгъруф Кәрхи* (вафаты 815/816), *Шибли* (861-945), *Баязид Бистами* (вафаты 875), *Мансур Хәллаҗ* (857-922), *Җөнәйд* һ.б.

Мөтәсәүвиф (мутассавыф, мөтәссәүф) сүзе дә "суфи" мәгънәсендә.

Ялган суфиларны безнең халык *суган суфи, ак суфи* дип атаган.

*//Суфи бернәрсәгә дә малик булмас, вә беркемгә дә мәмлүк булмас, диде.* Каюм Насыйри.

Тагын кара: ***СУФИЧЫЛЫК.***

***СЫЗГЫРА ТОРГАН УК*** *тар.* – Тимер яки сөяк очлыгы (семәге/сөмәге, укбашагы) белән сабагы арасына эче куыш һәм тишекле мөгез шарчык беркетелгән ук. Археологлар тишекле сөяк очлыклар да табалар. Башка төрле укларда укбашагы агачтан өчкырлы итеп ясалган булган ("Древнетюркский словарь"да бу деталь *соким* дип атала). Очкан вакытта мондый уклар сызгырган тавыш (сызгырык) чыгара. Аларны Үзәк Азия һәм Коньяк Себер күчмә халыклары яңа эрага кадәр I меңенче еллар ахырында, һуннар заманында, сугыш максатларында куллана башлаганнар. Мондый уклар соңгы заманнарга кадәр кытайларда һәм Себер халыкларында сакланган була әле. Сызгырып оча торган укны сунарда, мәсәлән, ботаклар арасына яшеренгән тиенне куркыту һәм ачык җиргә китәргә мәҗбүр итү өчен кулланганнар. Бурятлар һәм монголларда яубашлары үз гаскәрләре өстеннән сыбызгылы уклар атып, сугышчыларга көч-гайрәт биреп торганнар, шул ук вакытта ук аткан юнәлештә һөҗүм итү турында боерыкларын җиткергәннәр.

Гильом Рубрук язмаларында монголларда көмештән ясалган тишекле-тишекле очлык куелган укларның "флейта кебек" сызгырып очканлыгы телгә алына.

"Алтын тобчи" дигән борынгы монгол китабында "гөрелтеле" укбашының бозау мөгезеннән ябыштырп ясалганлыгы әйтелә.

Татар язучысы Нурихан Фәттахның бер тарихи романы "Сызгыра торган уклар" дип атала.

***СЫЗГЫРА ТОРГАН ЯДРӘ*** *тар.* – Иске Казанны казыганда табылган эче куыш балчык ядрә. Мондый ядрәләр, сызгырып очып, куркыту, паника тудыру өчен кулланылган.

***СЫЙНЫФ*** *г.* – Төр, сорт, категория, класс. Хәзерге вакытта мәктәптәге классларны

да яңадан сыйныф дип атауга күчеп баралар. Ләкин класс сүзенең татар телендә дә күпсанлы тармаклары булганга, җитди текстта *класс* тамырлы сүзләр үз урыннарын саклап калыр дип уйларга кирәк (классик, классификация, имезүчеләр классы, беренче класслы шофер һ.б. кебек сүзләр). Дөрес, элегрәк мәктәп дәреслекләрендә *имезүчеләр сыйныфы* термины да йөргән, ләкин, иҗтимагый сыйныфларның дәрәҗәсен "төшермәгәе" дип шикләнүдән ахры, аны "имезүчеләр классы" дигән термин белән алмаштырганнар.

Күплек саны шәкелләре — *әснаф, сонуф*. / / *Әснафе мөмтазә* — өстен сыйныфлар.

***СЫЙФР*** *г.* — Буш, нуль. Цифр сүзе шуңардан килеп чыккан. / / *Бу гаризаларның рус телендә булуы...вә мөселманнарны көчләп чукындыру ... чукынучылар санын сыйфр дәрәҗәсенә төшерде* (нульгә кадәр киметте) ("Милләтебездә Ислам дине" китабыннан). *Ләкин җыен ярлыдан бер бай чыкмаганга, сыйфрларның мәҗмугәсеннән сыйфрлар гына чыкканга, Хәлимгә бу "чәйдәшлек" тән файда чыкмады.* Г.Исхакый (Гаяз Исхакый әсәрләренең 3 нче томында бу урында "цифр" дип язылу аркасында "нуль" мәгънәсе югалып калган). "Нуль" һәм "сыйфр" сүзләренең тәңгәл мәгънә белдерүе Шакир Мөхәммәдевнең "Әлгасрелҗәдит" журналында басылган бер нотыгында (1902) ачык күренә: "...Бездә ни бар? Мәктәп бармы? Җәмгыяте хәйрия, хастаханә, ятимханә бармы? Үз телебездә бер газетабыз бармы? Дәхи болар кеби ничә сөальләрнең каршына җавап уларак төрекчә — сыйфр, русча — нуль куелачак ки, мәгънәсе дә — һич, яхут-юк, димәктер."

Тагын кара: *Цифр.*

***СЫКТАУ*** — Мәет озатканда такмаклап елау йоласы. Сыктау йоласы тәңречелек заманнарына барып тоташа. Сыктау вакытында әйтелгән сүзләрдә вафат булган кешенең сыйфатлары һәм эш-гамәлләре мактала. Җеназа артыннан кычкырып елап баруны тыя торган Ислам кануннары йогынтысында сыктау хушлашу догаларына һәм мөнәҗәтләргә әверелгән. Хәдистә: "Җеназа артыннан кычкырып елау-җаһилият галәмәте" дип әйтелсә дә, тормышта җеназа артыннан елап баручы профессиональ сыктаучылар да булган. Гарәпләр аларны *наихә* дип атаганнар. Борынгы төрки телдә шушы ук мәгънәдә *сыгытчы* — сыктаучы сүзе булган.

***СЫН БИТЛӘҮ*** — Сынын, төсен алыштыру (мәс., соран-хамелеон кебек), кыяфәт төрләндерү. Бу сүз русча "перевоплощение" (реинкарнация) мәгънәсен бирә ала шикелле.

***СЫРА*** — Аз алкогольле эчемлек. Көнбатышта сыраны Фламандиянең әкияти короле Гамбринус уйлап тапкан дигән риваять яши. Ләкин асылда ул төрле илләрдә уйлап чыгарылган. Сыра әчетү өчен колмак кулланыла. Билгеле булганча, татар телендә "өй сырасы" гомумән куасны белдерә. Сыра кайнату, руслардан тыш, чуашларда да мәгълүм (чуашлар аны бездәге кебек "сыра" дип атыйлар). Удмурт телендә дә "сыр" (сыра) сүзе бар. Галимнәр "сыра" сүзен фарси *сәраб* (куе эремә, спирт эремәсе, куе хәмер, шәраб; сироп?), фарси-таҗик *ширә* (сироп, йөзем суы, Кырым татарларында-шыра) сүзләренә бәйләп аңлаталар. Кыскасы, "сыра" дигән эчемлек безгә әүвәле Шәрыктән килгән булырга тиеш. Шулай да "Татарча-урысча сүзлек"кә (1931) "пиво" мәгънәсендәге "*пирәш*" сүзе теркәлгән булуын да әйтеп китик. Ислам диненең таралуы сыра кайнатуны һәм сыра куллануны чикләп, аңа безнең җирлектә тамыр җәяргә ирек бирмәгән булса кирәк. Бия сөтеннән коела торган кымызга килгәндә, ул хәрәм эчемлек дип саналмаган һәм безнең ата-бабаларыбыз күбрәк кымызны белгәннәр. Мәҗүсилектә калган чуашларда сыраны тыю һәм аны эчүдән тыелу булмаган.

Хәзерге вакытта җан башына сыра куллану буенча беренче урында Германия тора (елына 160 литр).

***СЫРГАВЫЛ*** *тар.* — Күзәтү каланчасы, каравыл каланчасы; мачта. Гаскәрнең артка калдырылган күзәтчесен дә сыргавыл дип атаганнар.

***ТАБӘКА*** *г.* — **1**.Катлау; кат; буын. **2**.Дәрәҗә. / / *Табәкаи галия* — *югары катлау.*

*Шушы нәрсәләрнең һич берен заигъ кылмый фиһристләргә кайд кылу вә Хәсән әфәндесенең милләткә булган йәдкәре итеп саклау чараларына керешү беренче мәртәбәдә Акчурин фамилиясе вә икенче мәртәбәдә милләтебезнең зыялы яшь табакасы өстенә төшә торган бурычтыр.* Р.Фәхреддин.

Билгеле бер вакыт арасында (бер заманда) яшәгән кордаш кешеләрнең биографияләрен табәка диләр. Гарәп историографиясендә табәка биография жанрының аерым тармагын тәшкил итә. Баштарак табәкалар хәдис һәм хокук белгечләренә багышланган була, соңга таба исә төрле һөнәр иясе һәм төрле дәрәҗәле кешеләрнең биографияләрен эченә ала.

Күплек саны шәкеле – *табәкат.*

***ТАБӘКАИ ГАЛИЯ*** *г.* – Югары катлау; югары даирә. Ф.Әмирханда – *"өстке тәбакә"*.

***ТӘҢКӘ*** – Сум; вак акча (монета); балык тәңкәсе; капитал. Кайбер тел галимнәре "тәңкә" борынгы *"тәңгерек"* – "түгәрәк" сүзеннән килеп чыккан диләр. Акча мәгънәсендә ул рус теленә үтеп кереп, "деньга" сүзенә әйләнгән (мәс., сәяхәтче сәүдәгәр Афанасий Никитинның XV гасырга караган сәяхәтнамәсендә "тен(ь)ка" формасында очрый). Асылда бу сүзнең чыгышы – фарсы теленнән. Электә йөргән көмеш тәңкә болгар-татарда фарсы сүзе белән *дәник, дәника* дип аталган, ул дирһәмнең чирегенә, динарның сигездән бер өлешенә тигез булган.

Монгол телендә – *тәнкә, теңкә*, Идел буе Болгар иленең икътисади даирәсенә караган халыклардан башкортта – *тәңкә*, чуашта – *тенке*, мари телендә – *танка, танкы*, удмуртларда да-*танка, тәнкы*. Охшаш сүзләр, әлбәттә, башка төрки телләрдә (казакъта, кыргызда, үзбәктә, каракалпакта, уйгурда) да бар, ләкин төрек телендә "акча" – пара/ парә (гомумән "акча" мәгънәсеннән тыш, бу сүз "вак акча" һәм "кисәк", "өлеш" мәгънәсенә дә ия – татар телендә дә актив йөри торган фарсыча "парә" сүзен искә төшерик). "Пара" сүзе болгар теленә дә кергән.

Элек татарлар "один целковыйны (рубль)" *тәңкә, бөтен тәңкә* дип атаганнар (В.М.Беркутов).

Тагын кара: ***АКЧА; ТИЕН; ТИГЕН.***

***ТАБУТ*** *г.* – Хәзерге мәгънәсе – гроб (русча). Электә мәетне салып зиратка илтә торган агачны (*җеназа агачын*) да табут дип атаганнар. Темников (Төмән) сөйләшендә "Тәбүт – **1**.Колаша, мәет юа торган җайланма; гадәттә ул такталардан ясала, баш турысында су агызу өчен тишеге дә була. **2**.Мәетне зиратка күтәреп илтә торган, бер ягы ачылмалы, сай ящиксыман җайланма." ("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969.)

***ТАБЫНДЫК*** *тат.* – Табыну нәрсәсе, пот, санәм. *Табындык* сүзе Һади Атласида очрый.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# САБА ТӨБӘГЕНЕҢ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Кукмара һәм Әгерже районнарында үткәрелгән нәтиҗәле эпиграфик экспедицияләребездән соң, башлаган шушы фәнни юнәлешебезнең дәвамы буларак, Саба районы авылларындагы гарәп язулы кабер ташларын максатчан рәвештә өйрәнеп чыктык. Районның туган якны өйрәнү музее бу эшкә шактый зур кызыксыну белдерде. Әлбәттә, тарихи тикшеренүләргә бәйле гамәлләрнең беренче чиратта Саба районы хакимияте тарафыннан хуплануын, җитәкчеләрнең аңлавы, теләктәшлеге һәм матди ярдәме белән башкарылуын да ассызыклап әйтергә, хәерхаһлы мөнәсәбәтләрен мактау һәм рәхмәт сүзләре белән тәкъдир итәргә кирәк.

Без 2001, 2002 һәм 2004 елларның яз-көз айларында районның 62 татар авылында булып, зиратларын, каберлекләрне тикшердек һәм алардагы эпиграфик истәлекләрне укып, язып алдык, фоторәсемгә төшердек. Барлыгы 218 борынгы кабер ташы табылу һәм теркәп алыну—Саба районы авылларының тарихи ташъязма истәлекләргә шактый бай булуын дәлилли. Аларны барлау, нигездә, төгәлләнде дисәк тә була. Гомуми нәтиҗәләрне туплап журнал укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.



*Эзмә авылы басуындагы каберлектә сакланган XIV йөз кабер ташларының берсе.*

Саба җирлегендәге иң борынгы ташъязма истәлек—Эзмә авылы басуында сакланган XIV йөз кабер ташы. Ул күпләргә мәгълүм, тексты белгечләр тарафыннан укылган, аның турында фәнни әдәбиятта да шактый язылган,—ягъни, районда яшәүчеләргә дә, галим-голәмага да яхшы таныш. Шуңа күрәдер дә, игътибардан читтә калмаган: чардуган белән әйләндереп алынган, калай түбә белән капланган һәм чардуганына гамәлдәге хәрефләр белән "Йосыфҗан бине Хөсәен. 1332" дигән язу да беркетелгән. Ләкин, бу ташның янәшәсендәге, ягъни шул ук чардуган эчендәге һәм шул ук түбә астындагы икенче кабер ташы бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек. Бары тик этнограф һәм тарихчы галим Н.И.Воробьев кына 1929 елда басылып чыккан бер мәкаләсендә *(О болгаро-татарских надгробных камнях Мамадышского кантона ТССР// Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. 3-й вып.—Казань, 1929.—С. 11-13.)* шушы каберлек турында яза, андагы ике болгар ташының һәм 5 кисәккә ватылып җирдә ята торган, күпертмә язулы тагын бер ташның (анысын галим Казан ханлыгы чорына, төгәлрәге, 1534 елга карый дип белдерә; хәзерге вакытта да чардуган эчендә таш кисәкләре аунап ята, ләкин аларда нинди дә булса язу билгеләре, бизәк элементлары бөтенләй күренми) тышкы күренешләрен тасвирлый һәм үлчәмнәрен бирә. Аның язуына караганда да, хәзерге өлкән буын кешеләренең сөйләүләре буенча да, шушы тирәләр—борынгы зират урыны, күп еллар элек андагы кабер ташларының да саны дистәдән артык булган.

Күренекле эпиграфист-галим Һарун Йосыпов та борынгы татар кабер ташларына багышланган хезмәтендә *(Введение в булгаро-татарскую эпиграфику.—*

*М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960.—С. 188-189.—Табл. 11.)* Эзмәдәге бер (беренче) ташны гына тасвирлый, ягъни, фоторәсемен, үлчәмнәрен, гарәп хәрефләре белән текстын һәм шушы текстның рус теленә тәржемәсен бирә, тарихи чорын (датасын) билгели.

Икенче (өйрәнелмәгән) таш өслегендәге беленер-беленмәс гарәп язуы элементларыннан кайбер сүз-гыйбарәләргә ачкыч таба алдык. Беренче өч юлга язылган гарәпчә дини гыйбарәләр укылды ("Лә иләһә иллә Аллаһы...", "Һуәл-хәййе әлләзи лә...", "Рабби лә тәдәрри ли-әмурни вә..."; тәржемәләре—"Аллаһыдан башка иләһи зат юк", "Ул (Аллаһы Тәгалә) үлемсез", "Аллаһының әмереннән качып булмый" мәгънәләренә туры килә), 4—7 юлларда "Йосыф хажи", "жиати жүр" (жиде йөз), "рихләт" дигән сүзләрне танууга ирештек. Таш өслегенең бөтенләй кыршылган уң як яртысы текстның эчтәлеге тагын да тулырак ачыкларга мөмкинлек бирмәде, ләкин укылган кадәресе дә бик әһәмиятле нәтиҗәгә китерә: кабер ташының монысы да XIV йөзгә карый, ул янәшәдәге ташка исеме теркәлгән "Йосыф хажи улы Хөсәен"нең (күренекле эпиграфист галим Һ. Йосыпов укылышында да, безнең укылышта да нәкъ менә шулай, ә чардуганга беркетелгән тактадагыча, "Йосыфжан бине Хөсәен" түгел!) атасына, ягъни шушы Йосыф хажига яисә аның башка бер баласына куелган. Димәк, алга таба фәнни әдәбиятта Саба районының Эзмә авылына бәйләп бер генә түгел, ә ике эпиграфик истәлек—ике борынгы кабер ташы—турында сүз йөртү зарур.

Һарун Йосыпов 1960 елларда язып калдырганча, Саба районының Иске Мичән, Кече Шыңар һәм Эзмә авылларында Казан ханлыгы дәвере ташъязма истәлекләре булган. Эзмәдәге XVI йөз кабер ташының ватылып харап булуы турында югарыда әйтелде инде. Безнең экспедиция вакытында Иске Мичәндәгесе дә табылмады. Кече Шыңарда борынгы кабер ташы барлыгын язса да, Һ.Йосыпов аның текстын бастырмаган, елын һәм андагы кеше исемен дә күрсәтмәгән. Хәзерге көндә мәктәп музеенда бу ташка бәйләнешле кызыклы язма мәгълүмат саклана. Аннан аңлашылганча, авылның элекке мулласы Мөхәммәтҗан хәзрәт биредә җирләнгән кеше турында "Бу кеше көймәле арбага утырып, гаиләсе белән каядыр барышы булган. Безнең авыл янына килгәч, ул каты авырган. Хатыны аңа эчертү өчен сөт эзләп безнең авылга кергән, иренең авыруын һәм сыер сөте эчәсе килгәнен әйткән. Ләкин ул сөт эчеп кенә терелмәгән. Шул туктаган урыннарында арбада үлгән. Авыру булгач, халык аны авылга кертмәгән, шул ук урында күмгәннәр. Әле ул вакытта авыл кечкенә булган, мәрхүм күмелгән җирләр басу булып, авылга шактый ерак булган. Бу кешенең исеме "Ала күз Хафиз", үзе коръәнхафиз (ягъни Коръәнне яттан белүче) һәм мулла булган. Аның каядыр күчеп барышы икән. Моңа якынча 500 еллап чамасы булырга тиеш,"—дип сөйли торган булган һәм үзенең Коръән бите читенә язып та калдырган, имеш.



*Кече Шыңар авылында сакланган Казан ханлыгы дәвере (1524 ел) кабер ташы.*

Хәмит Тимершин ихатасындагы бу ташның язуларын укыгач, шуларны ачыкладык. Таш һиҗри (мөселманча) ел исәбе белән 930 елның рабигыль-әүвәл аенда (гамәлдәге ел исәбе белән 1524 елның гыйнвар аена туры килә) вафат булган кешегә куелган. Текстта Шәех би угылы Алакүз, Хафиз абыз дигән исемнәр бар. Аннан соң "...суга барып шәһид булды" дигән сүзләр язылган. Кызганыч ки, таштагы хәрефләрнең кайберләре җуелганлыктан, текстның төп-төгәл мәгънәсен аңларга читенрәк. Ташның язулы алгы ягы татар эпиграфик истәлекләренә хас традицион кайма бизәк белән әйләндереп алынган. Ян-якларында татарча һәм гарәп телендә "Күрәмен дөньяны вәйран булган хәлдә, берни дә мәңгелек түгел—Аллаһының

моңа карары юк" мәгънәсендәге шигъри юллар уелган, бу да—Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары кабер ташларыннан ук күчкән традицион бер үзенчәлек. Әлеге ташның биеклеге—135 см, ине—47 см, калынлыгы—17 см.

Олы Шыңар авылы басуында да әһәмиятле тарихи истәлек бар. "Совет хакимлеге урнашу дәверендә күрше авылларның берсеннән килеп, мондагы кешеләр белән үзара низагка кергән комсомол егет биредә җирләнгән, тимер чардуган эчендәге таш шуңа куелган, имеш",— дип авыл кешеләре сөйләгән риваять дөреслекне чагылдырмый. Чөнки ташның тышкы билгеләре үк, ягъни калыбы, бизәкләре, язу рәвеше аның күпкә борынгырак булуын күрсәтеп тора. Бу ташның Казан ханлыгы дәверенеке булуы шиксез. Текстның баштагы берничә юлыннан традицион дини-фәлсәфи гыйбарәләр танылa, ә кеше исеме һәм елы теркәлгән аскы юллары сакланмаган. Арткы ягында "Бу ләүхне хәлале Көләчхан бина к[ылды]" дип язылган, ягъни ташны мәрхүмнең хатыны Көләчхан ясатып куюы әйтелгән. Уң һәм сул як кырларында Кече Шыңар ташындагыча ук шигъри юллар уелган. Бу эпиграфик истәлекнең табылуы һәм ачыкланувы—Саба төбәгенең үткәне өчен дә, тарих фәне өчен дә, һичшиксез, мөһим яналык. Аның турында фәнни хезмәтләрдә моңарчы мәгълүмат юк диярлек иде.



*Олы Шыңар авылы басуында сакланган Казан ханлыгы дәвере ташъязма истәлеге.*

Олы Нырты авылының иске зиратында XVII йөз (1671-1672 нчы еллар) татар кабер ташы сакланган. Түгәрәкләп эшкәртелгән өске өлешенә чәчәк-яфрак үрелмәләре рәвешендә гаҗәеп матур нәкышь-бизәк төшерелгән 94 х 48 х 20 сантиметр үлчәмнәрендәге бу ташның алгы һәм уң як өслегеннән түбәндәге текстны укыдык һәм күчереп алдык (язу юллары номерлап бирелә):

**Алгы ягында:**

1) Һуәл-хәййе әлләзи лә йәмүт вә күлли хәйи сәйәмүт калән-нәби галәйһис-сәлам

2) әд-дөнья сагать фәәҗгальһа тагать садака калән-нәби галәйһис-сәлам

3) әд-дөнья җәйфат вә талябиһа киляб тарих мең дә моксән икедә

4) дирләр ирде Чирүче угылы Килмөхәммәд үз вахтында [торырды] мөселманлардин

5) дога өмид өчен күрәрмен дөньяны вәйран бары бакый ирмәс һәмишә юк карары

**Алгы якның уң кырында вертикаль рәвештә:**

1) кәтәбәһе Килмөхәммәд ибне Ишмән

Гарәпчә гыйбарәләрне һәм башка аңлашылмый торган сүзләрне тәрҗемә иткәндә, текстның татарчасы мондый рәвештә:

**Алгы ягында:**

1) Ул [Аллаһы Тәгалә] үлемсез, ә башка һәрбер тереклек иясе үләчәк. Пәйгамбәребез [Мөхәммәд], аңа Аллаһы Тәгаләнең сәламе булсын, әйтте:

2) Дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр. Садака. Пәйгамбәребез [Мөхәммәд], аңа Аллаһы Тәгаләнең сәламе булсын, әйтте:

3) Бу дөнья үләксәдер, аны этләр эзләп йөрер. Тарих мең дә моксән икедә

4) иде. Чирүче улы Килмөхәммәт үз вакытында [шушында җирләнде, шушында ята] мөселманнардан

5) дога өмет итеп. Күрәмен дөньяны вәйран булган хәлдә, берни дә мәңгелек түгел—Аллаһының мона карары юк.

**Алгы якның уң кырында вертикаль рәвештә:**

1) моны язучы Килмөхәммәт Ишмән улы

Килмөхәммәт Ишмән улы—XVII гасырның күренекле татар хаттаты (каллиграф, матур язучы) һәм ташъязмалар уючы. Аның тарафыннан язылган, калыпкыяфәтләре, үлчәмнәре, чәчәк-үсемлекләр төшереп ясалган үзенчәлекле бизәкләре, текстларының эчтәлеге һәм урнашу тәртибе, ниһаять, безнең көннәргә кадәр чагыштырмача әйбәт сакланышлары белән дә бер-берсенә охшаш булган кабер ташларының Татарстан, Башкортстан һәм Чуашстандагы татар авылларында булуы билгеле. Шундыйларның бишесен Кукмара районында, сигезен Әгерҗе районында, берсен Балтач районында үзебез күреп, язмаларын укып өйрәндек. Ләкин Килмөхәммәт Ишмән улы үз исемен барысында да күрсәтмәгән. Шуна карамастан, тышкы сыйфатлары һәм текстлары аларның бер үк кул белән башкарылганын ачык раслый.

Алгы яктагы текстның 1-3 нче юлларында җирдәге дөньяның вакытлыча (фани) һәм авыр, начар булуын, ә бакый дөньяның җинеллеген, рәхәтлеген тасвирлаган Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре китерелә. 3-4 нче юллар вафат булу вакытын һиҗри ел исәбе белән (милади белән ул 1671-1672 нчы елларга туры килә) күрсәтә, мәрхүмнең исемен һәм атасының исемен белдерә. 5 нче юлдагы борынгы төркичә шигырь—элеккерәк чор кабер ташларыннан килгән традицион дәвамчанлык мисалы.

Истәлектәге Чирүче дигән кеше исеме (бу очракта гүр иясенең атасының исеме) борынгы төрки телдә "гаскәри, сугышчы" мәгънәсен белдергән. Бу кеше исемен Олы Нырты янындагы Чәбия-Чүрчи авылы атамасы (халык телендә Чирчи-авыл дигән әйтелеш варианты да бар) белән дә бәйләп карарга мөмкиндер. Әмма бу мәсьәлә махсус тирәнтен тикшеренүләр аша ачыклауны таләп итә.

Тимершык авылы янындагы тау битенә күмелгән Изге Тимершәех бабаның кабере дә—борынгыларның берсе. Әмма аның үз заманында куелган ташы юк, ул бәлки бөтенләй куелмаган да булгандыр. Якынча XIX йөз ахырында—XX йөз башында куелган гарәп язулы ташы исә өч кисәккә ватылган, анда бернинди дә дата күрсәтелмәгән.

Кукмара, Әгерҗе, Балтач, Саба районнарында үткәргән фәнни-тикшерену эшчәнлегебез нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Татарстанның әлеге төбәкләрендә XVIII йөзгә караган ташъязма истәлекләр бик сирәк очрый. Саба районының бер генә авылында—Түбән Симеттә—бары тик бер генә шундый таш табылды. Ул—түбәннән югарыга таба тарайтылган калыплы, бизәксез гади комташ, чагыштырмача тәбәнәк (42 см), тар (17—13 см) һәм юка (10 см), язу рәвеше дә камил түгел, текстында мәгълүмат бик саран бирелгән. Өстәвенә, кабергә иңдерелгән затның исеме язылган аскы өлеше ашалып, хәрефләре җуелган. Әмма текстта мәрхүм(ә)нең вафат булу вакыты күрсәтелгән һәм бу дата, башка ташъязмалардан аермалы буларак, сүзләр белән милади ел исәбендә язылган. Биредә текстны тулаем китерәбез: "Лә иләһә иллә Аллаһы, Мөхәммәд рәсүлуллаһе. Тарих мең дә йете йөз дә йетмеш тукызынчы елда вафат булды ошбу кабер иясе..."

Тарих өчен аеруча әһәмиятле кабер ташларының XIX йөздә һәм XX йөз башында куелганнарына да киңрәк тукталыйк.

Казанчы Бигәнәй авылындагы "Ишан каберлеге" ташлары, гомумән, эшләнешләре, бизәлешләре, текстларының мәгълүматлылыгы җәһәтеннән аерым әһәмияткә ия. 1994 елда Казанчы Бигәнәй авылының "Ишан зираты"нда булып, гарәп язулы дистәләп ташны укыдык һәм текстларын хәзерге язуга күчердек.

Каберлек үзе 12 метрга 16 метр чамасы зурлыктагы мәйданны били, табигый известьташтан өелгән койма белән уратып алынган. Каберлек эченә керү өчен тимердән ясалган капкасы да бар. Зурлыгы һәм үзенчәлекле формасы белән башкаларыннан аерылып торган бер кабер ташы, җирле халыкның раславы буенча, Казанчы Бигәнәйдә яшәгән, халыкны дәвалау белән дә шөгыльләнгән дин

эшлеклесе Вәлиәхмәт ишан Мөхәммәтгалим угылы каберенә куелган. Эшләнеше ягыннан традицион булмаган әлеге ташның гомуми биеклеге 1 метр 70 сантиметр чамасында һәм ул өч ярус-баскычтан гыйбарәт. Иң очында комлы-цементлы измәдән "чалма" эшләп куелган. Икенче яруска 2 сантиметр калынлыгындагы язулы мәрмәр плитә беркетелгән булган, кызганыч, ул бөтенләй диярлек сакланмаган, кабер өстендә яткан берничә кыйпылчыгын гына күрә алдык. Очлаеп менгән өске яруста ай һәм йолдыз сурәте, "Лә иләһә иллә Аллаһы" гыйбарәсе уелган. Түбәнге яруста ташка язулар уючы оста Фәтхелкадыйр Кәлмитевнең исеме теркәлгән.



*Казанчы Бигәнәй авылындагы "Ишан зираты"ның гомуми күренеше.*

"Ишан зираты"ндагы башка ташларның күбесе гадәти формада, бер-берсенә бик охшаш. Текстларының язу өслүбе аларның, нигездә, бер кул белән башкарылганын күрсәтә. Кайберләрендә Мөхәммәтзакир исемле бу останың исеме дә уелган. Аның хәзерге Алабуга районына керә торган Морт авылыныкы икәнлеген ачыкладык. Ул язган ташлар Алабуга, Менделеев һәм Әгерже районы авылларындагы зиратларда да сакланган. Бигәнәйдәге "Ишан зираты" ташъязмалары, гомумән, әлеге төбәкнең Алабуга ягы белән тыгыз элемтәләре булганлыгын дәлилли. 1918 елда 85 яшендә үлгән Әсфәндияр Гаделшаһ угылы Мозаффаров каберенә куелган затлы ташта да моны раслаучы мәгълүмат бар: "Сатышта укыгач, Бохарада 8 ел белем алганнан соң, Алабуга өязенең Дөмдөм авылында 45 ел имам булып, кияве ишан хәзрәткә кунакка килгән вакытында Бигәнәйдә вафат булды."

Байлар Сабасы элек-электән үк тирә-яктагы зур авылларның берсе булган, авыл эчендәге иске зиратының мәйданы да кечкенә түгел. Үсеп утыра торган агачларына караганда, зират шактый ук борынгы да булырга тиеш, әмма, ни кызганыч, моны раслардык нигезле дәлилләр—бик әүвәлге кабер ташлары гына сакланмаган. Зираттагы ташларның иң әүвәлгесе—1810 елгы, шулай ук 1834, 1839, 1878 елларда вафат булган кешеләргә куелганнары бар, ә күпчелеге,ягъни 14 ташның сигезе 1920-1930 нчы елларга нисбәтле. Арада затлылыгы, купшылыгы, күренекле, абруйлы затка куелуы белән аерылып торган кабер ташы юк. Борынгы кабер ташларын өйрәнүче галим Марсель Әхмәтжановның бер мәкаләсендә *(Татар дөрбәләре тарихына// Татарская археология.—2002-2003.—№1-2.—Б. 149.)* әлеге зират турында мондый юллар бар: "Яндырылган кызыл кирпечтән эшләнгән өй сыман (түбәсез) дөрбә Байлар Сабасы зиратында булып, аның тик нигезе генә калган. Дөрбә Абалаковлар дигән сәүдәгәрләрнеке булып, 1940-50 нче елларда кирпеч хаҗәте өчен сүтеп бетерелгән". Районның Сатыш, Түбән Шытсу авыллары зиратларында заманында төрбә итеп тезелгән ташларның берничә рәте, Иске Икшермә, Татар Икшермәсе зиратларында исә табигый ташлардан өелгән зур гына төрбәләр әле дә саклана.

Районның Сатыш авылы—йөзәрләгән татар яшьләренә гыйлем өйрәткән, милләтебезгә күренекле шәхесләр биргән мәдрәсәсе белән XIX йөз—XX йөз башында тирә-якта мәшһүр булган мәгърифәт үзәкләренең берсе. Әнә шул укымышлылык, мәдәнилек рухы зиратта бүгенгәчә сакланган, ул каберташ истәлекләрендә сизелә. Алар бирелә затлы, бизәкле, биек һәм нык итеп эшләнгән, текстлары да матур, гарәп хәрефләре белән камил язылган. Авыл имамнары һәм мәдрәсә мөгаллимнәре вазыйфаларын үтәгән мулла Жарулла бине мулла Бикмөхәммәт, дамелла Мөхәммәт бине дамелла Мөхәммәтгали, дамелла Габдеррахман ибне дамелла Мөхәммәт зиратта соңгы сыену урыннарын тапканнар. Шушы бер зиратта гына да гарәби язулы һәм фәнни җәһәттән әһәмиятле 13 истәлек теркәп алынды. Чагыштыру өчен:

Байлар Сабасының үзендәге иске зиратта теркәлгән ташларның саны—14, Казанчы Бигәнәй авылының гомуми зиратында һәм "Ишан зираты"нда җәмгысе—16, Яна Мичән һәм Пүкәл зиратларында—унар, Түбән Утарда—9, Олыязда—8; калганнарында бу саннар кимрәк.

Сабай авылы зиратына шушы төбәкнең абруйлы дин эшлеклесе, мулла Гыйльман Яхин җирләнгән. Кабере өстенә куелган таш сынып-ватылып берничә кисәккә аерылган, шул сәбәпле, төгәл вафат елын укып булмый, бары тик 1850 нче елларда икәнлеген чамаларга мөмкин. Гыйльман Яхин—күренекле татар мәгърифәтчесе Таиб Яхинның (1844–1910) атасы. Аның туган-үлгән елларын (1801–1853) архив документлары буенча ачыкладык. Гыйльман хәзрәтнең улы Габделгалләмгә куелган таш та шушы ук зиратта. Ул 1910 елда 78 яшендә дөнья куйган. Шул тирәдә үк Габделгалләмнең хатыны Гөлбашира Габделмән кызы (1834–1890) һәм аларның уллары Габдулла (1862–1918) да җирләнгән, каберләре өстендә ташлар бар.



*Сабай авылы зиратында Гыйльман хәзрәт Яхин (1801–1853) кабере өстенә куелган таш.*

Шиһабетдин Мәрҗанинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" һәм Ризаэтдин Фәхретдиннең "Асар" китапларында исеме телгә алынган Фәхретдин хәзрәт Бикмөхәммәт мулла улы (1865 елда вафат) һәм аның хатыны Бибимәфтуха Ягъкуб кызы (1886 елда вафат) Урта Саба авылы зиратында янәшә күмелгәннәр, агачтан бик нык һәм күркәм итеп ясалган чардуганнары эчендә тагын да күркәмрәк һәм затлы итеп эшләнгән кабер ташлары тора.

Татар Икшермәсе авылы зиратында шушы төбәкнең тагын бер танылган затларыннан имам, мөдәррис һәм мөхтәсиб Тажетдин Сәйфетдин мулла улына (1799–1866) куелган кабер ташы игътибарга лаек. Шушы ук ташның уң ягында янәшә җирләнгән хатыны Бибихәнифә (Түбән Тегермәнлек авылы имам-мөдәррисе Габделмәҗит хәзрәт кызы, 1870 елда вафат), ә сул ягында шулай ук янәшә җирләнгән атасы Сәйфетдин мулла Габбас улы Кышкарый исемнәре уелган.

Оет авылында 49 ел имам булып торган Шаһиәхмәт Бәхтияр улының (1893 елда вафат) кабер ташы тулаем диярлек гарәп телендә язылган булуы белән үзенчәлекле.

Аккүл Бигәнәй авылы зиратында ирле-хатынлы мулла Җәлалетдин Сәгыйт улы Колаев (1819–1908) һәм Бибикамәр остазбикә Бикмөхәммәт хәзрәт кызы (1833–1895) җирләнгән. Аларның ташларыннан бераз читтәрәк Җәлалетдин Колаевның уллары Әхмәтшаһка (1842–1866), Мөхәммәтсафага (1871–1898), Йосыф муллага (1862–1924) куелган нәфис һәм бик матур язулы кабер ташлары да бар. Бер зиратта бер үк гаиләдән булган биш кешенең язулы ташлары сакланып калу—игътибарга лаеклы күренеш.

Кече Шынар авылы зиратындагы ташларның берсе мәгълүматлылык ягыннан әһәмиятле. Анда мондый юллар бар: "Бу кабердә галимә Маһруй дамелла Әхмәткәрим кызы, имам Мөхәммәтҗан хәзрәт зәүҗәсе (хатыны). 1924 ел 24 декабрь 67 яшендә вафат. Маһруй абыстай 49 ел Кече Шынарда балалар укытып гомер итте. Алты угылын имамлык ләвазименә (вазыйфасына) калдырып китте."

Шактый ук тулы текстлы эпиграфик истәлекләр тагын берничә авылда бар. Менә шундыйларның берсен Кызыл Мишә авылы зиратында очраттык: Һиҗри 1328 сәнәдә *(мөселманча ел исәбе белән 1328 елда)* маһе рәҗәбнең *(рәҗәп аеның)* 2 нче йаумендә *(көнендә)* карьяи Пүскән *(Пүскән авылының)* имам Габделәхәт

әһлиясе *(хатыны)* Гайшәбикә бинте мулла Әхмәтхафиз *(Әхмәтхафиз мулланың кызы)* 1910 нчы миладидә *(христианча ел исәбе белән 1910 елда)* июнь 28-ендә 26 яшендә йауме җомга *(җомга көнне)* даре бәкага рихләт кыйлды *(мәңгелек дөньяга күчте)*. Өстәвенә истәлекнең икенче ягына "Бисмилла...", Коръән гыйбарәсе һәм гарәпчә шигырь юллары да язылган. Мәртен авылы зиратында куелган тагын бер таш текстын да мисал итеп китерик. Аның алгы өслегендә "...Сәнәи 1881 *(1881 ел)* февраль 2 нче йаумендә *(көнендә)* мулла Шәмсетдин мулла Садыйк угылы 66 яшендә Мәртен авылында мәдфүн *(җирләнде)* 35 сәнә *(ел)* имам булып гомер кичерде. Рәхимәһе Аллаһы Тәгалә рәхмәтән васигатән *(Ана Аллаһы Тәгаләнең кин рәхмәте булсын)*. Амин". Ташның уң һәм сул ян якларында исә "Бу көн бәңа *(мина)* икән— йарин сәңадыр *(иртәгә синадыр)*, галәмәтдин морадым *(язулы таш куйдыруның максаты)*—бер догадыр" дигән юллар уелган.

Төбәк авылы зиратында, традицион эшләнештәге һәм текстлары гадәтирәк эчтәлектәге кабер ташлары белән беррәттән, шулай ук бер үзенчәлеклесе бар. 1936 елда 63 яшендә вафат булган Сәхибкамалга куелган ташъязмада аның 4 буын ата-бабасы язылган, ягъни кечерәк кенә бер шәҗәрә теркәлгән. Схематик рәвештә аны болай күрсәтик: Сәхибкамал—Нурмөхәммәт—Бикмөхәммәт—Бикчәнтәй—Рәим. Кабер ташына шәҗәрә язу—бик кызыклы һәм тарихи яктан да әһәмиятле күренеш.

Саба төбәге эпиграфик истәлекләренең кайбер гомумирәк сыйфатларына тукталыйк. Мөгаен, беренче чиратта, бу як халкында әүвәлге традицияләргә карата хөрмәтнең зурлыгы һәм аларны сакларга омтылу сәбәбеннәндер, авыл зиратларында 1940–1950 нче елларда, хәтта 1960–1970 нче елларда куелган, калып-кыяфәтләре, текстларының төзелү тәртипләре белән XIX йөз ахыры—XX йөз башы истәлекләренә охшаш гарәп язулы кабер ташлары чагыштырмача күп очрый. Традицияләр дәвамчанлыгын күрсәтә торган факт буларак, бу күренеш, һичшиксез, игътибарга лаек.

Кабер ташлары ясап кую өчен Саба төбәгендә күбрәк җирле табигый материал—нигездә, комташ кулланылуын, аның бик гади калыпта, кайбер очракта хәтта примитив дәрәҗәдә генә эшкәртелүен, шомартылуын һәм бизәлүен дә билгеләп үтәргә кирәк. (Әлбәттә, уалучан һәм көпшәк булганга, комташны яхшылап эшкәртү мөмкинлекләре, теләгән очракта да, чикле икәнлеген онытмыйк.) Бу үзенчәлекнең эпиграфика фәне өчен аянычлы икенче бер ягы бар—мондый кабер ташлары озак сакланмый, мүкләнә, ашала, сына-ватыла, язулары да тиз уала. Зиратларда билгеистәлек сыйфатында очлырак бер башын өскә каратып, аскы өлешен бераз җиргә батырып, язусыз һәм шәкелсез яссы известьташ кисәкләре бастырып кую гадәте дә киң таралган булган. Бу соңгы үзенчәлекләр монда яшәгән гади халыкның матди хәленә, көнкүреш дәрәҗәсенә дә бәйле булган, әлбәттә.

Калын тактаны кабер ташы калыбынча эшкәртү һәм өслегенә гарәби язулар уеп яисә нәсел тамгасы сугып мәрхүмнәрнең каберләре өстенә утырту очраклары Саба районында, башка төбәкләр белән чагыштырганда, ешрак күзәтелә. Агач—әлбәттә, арзанлы, кул астында гына булган һәм эшкәртергә дә унайлы материал, аны кабер ташларына хас формага китерү кыен түгел. Әмма Саба районында табылган шундый өч эпиграфик истәлекнең икесендә текстларны гаҗәеп дәрәҗәдә нәфис гарәби хәрефләр белән агачка уеп төшерү өчен бик зур осталык кирәк булганлыгы ачык күренеп тора. Агачның да ныгын, чыдамлысын сайлый белгәннәр безнең бабайлар—череп-таркалып бетмичә, язулары бозылмыйча хәзерге көннәргә кадәр сакланып калулары да бер гаҗәеп хәл бит боларның! Такта-билгеләрнең берсе Тимершык авылы зиратында, ул тумышы белән Бөкәш *(Котлы Бөкәш?—авт.)* авылыннан булган, Тимершыкта имамлык иткән һәм илле ел буе мәдрәсәдә гыйлем биргән, 92 яшькә җитеп 1867 елда бакый дөньяга күчкән мулла Хәмит Галикәй угылына куелган. Икенче тактаны Сатыш авылы зиратында күреп, язуларын укыдык, ул—1906 нчы елда вафат булган Гыйрфан угылы Гатиятулланыкы. Өченчесе, 1939 елда бу дөньядан киткән Мөбарәкша Тимербай угылының исеме язылып, Юлбат авылы зиратында куелган. Югары Симет, Оет, Өчнарат авыллары зиратларында да шундый такта-билгеләр теркәдек, язуларын укыдык, фоторәсемгә төшердек.

Татар кабер ташларының текстлары, гадәттә, татар һәм гарәп телләрендә катнаш язылган һәм, чорына карап, билгеле бер тәртип, кагыйдә белән төзелгән. Совет заманында бик зур үзгәртүләргә дучар булсалар да, әлеге традицион тәртипләр элек аеруча катгый үтәлгән. Мәсәлән, XIX йөзгә—XX йөз башына караган күпчелек эпиграфик истәлекләрнең текстларына хас гомумиләштерелгән схема: 1) кабер ташының алгы ягына, ин өске өлешенә башта бизәк (затлырак ташларда—чәчәк-яфрак үрелмәләре, гадирәкләрендә—ярымай, биш-алты-сигез почмаклы йолдыз-чәчәк) төшерелгән, тугърасыман челтәрләнгән яисә гадәти рәвештәге дини гыйбарә, Аллаһыны данлаган, үлемнең котылгысызлыгын искәрткән сүзләр (*"Ләиләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд рәсүлуллаһе", "Лилләһил-фатиха", "Һуәл-бакый", "Әл-кабер гыйбрәт", "Күлли нәфсин заикател-мәүт" һ.б.)* язылган; 2) Алга таба мәрхүмнең яки мәрхүмәнең исеме, атасының исеме, нинди һөнәр иясе булганлыгы, хатын-кызның кем җәмәгате икәнлеге, читтән килгән кешенең төп ватаны күрсәтелгән; 3) Мәрхүмнең (мәрхүмәнең) вафат булу датасын белдерүдә берничә төрле вариант кулланылган: яки ул һиҗри (мөселманча) ел исәбе белән генә, яки милади (христианча) ел исәбе белән генә, яки икесендә дә бирелгән. Төгәллек шулай ук төрлечә: бер ташъязмада елны гына күрсәтү белән чикләнсәләр, икенчесендә, киресенчә, елын, аен, көн санын, атна көнен дә атаганнар; 4) вафат булу датасының алдында яки аннан соң мәрхүмнең (мәрхүмәнең) ничә яшьтә булганлыгы әйтелгән; 5) Алга таба күптөрле вариантларның берсе белән "үлде, вафат булды" төшенчәсе белдерелгән: *мәрхүм булды, дөньяны ташлады, рихләт әйләде, мәдфүн, бу каберroutedгә дахил, даре бәкага күчте, дарел-фаналин дарел-бәкайа рихләт кыйлды һ.б.;* 6) Текст, гадәттә, мәрхүм (мәрхүмә) булган затка карата изге теләкләр, аның гөнаһларын кичерүне сораган сүзләр, бу дөньяда калганнарга мөрәҗәгать итү белән тәмамлана: *Аллаһы рәхмәт кыйлсын, Аллаһы шәфәгатьче булсын, Аллаһы Тәгалә каберен нурлы кыйлсын, Аллаһы Тәгалә каберен оҗмах бакчаларыннан бер бакча итсен, рәхмәтуллаһи Тәгалә рәхмәтән васигатән, гафәрә Аллаһы зөнүбиһа, нәүвара Аллаһы мәркадиһа, бу дөньяга алданма—гамәл хәзерлә, бу көн бәна икән—йарин сәнадыр һ.б.* Югарыда мисал өчен китерелгән өземтәләрнең барысы да Саба районы кабер ташларындагы текстлардан алынды.

Ин якын кешене, ата-ананы, газиз туганны югалту сагышы, әлбәттә, күңелләге нечкә хисләрне кузгаткан, бер үк вакытта кайгылы да, юатулы да шигъри юллар тууга сәбәпче булган. Мондый шигырьләрне еш кына кабер ташларына да язып куйганнар. Саба төбәге эпиграфик истәлекләреннән язып алынган шигъри үрнәкләрнең кайберләренә игътибар итик:

*Кәрәм әйләп (киң күңеллелек күрсәтеп), догада итегез йад,*
*Тәсаддыкъ(ъ)лә (садака биреп) кыйлыгыз рухымны шат.*
*Бу кабер хәлләрен сагышлайасыз,*
*Безгә Коръән укып багышлайасыз.*
*Безем (безнең) Коръән укырга хәлемез юк,*
*Хәер-ихсан кыйлырга (садака белән ярдәм итәргә) малымыз юк.*

*Мәркадеңдә (гүреңдә) ят син, әнкәм,*
*Кайгы-гамьләр чикмичә.*
*Юк күрешмәк инде безгә,*
*Йауме мәхшәр (мәхшәр көне) җитмичә.*

*Әй мөселман, Аллаһының киң рәхмәте булсын сиңа,*
*Бу кабергә утырып кыйлсаң әгәр изге дога.*

*Йа, вакыйфән би кабри*
*мөтәфәккирән би әмри.*
*Бил-әмси күнту мисликә*
*гадән тәсайир мисли.*

*(Татарча мәгънәсе: Әй, каберем янына килеп басучы, минем хәлне фикерлә. Бүген шушы хәлеңдә булсаң, иртәгә минем кебек булырсың.)*

Кабер ташларындагы язуларны уючы оста (әгәр ул чынлап та үз эшенең остасы һәм тирә-якта шуның белән мәшһүр дә булса), текст ахырындарак үзенең исемен теркәп калдыруны да мәгъкуль күргән. Мондый очраклар Саба районы эпиграфик истәлекләрендә дә күзәтелде. Ташъязма уючылардан Килмөхәммәт ибне Ишмән (Олы Ныргы авылындагы XVII йөз кабер ташы), мулла Мөхәммәткәмал бине мулла Мөхәммәтҗан Түбән Мишәбашыви (Явлаштау авылы зираты), Бикчәнтәй бине Салих бине Исмәгыйль бине Хәсән (Байлар Сабасы авылындагы 1810 елгы таш), Мөбарәкша бине Гайсә мулла әл-Казакларый (Сатыш авылы зираты) исемнәре берәр тапкыр очрады. Осталарның күбесе, ташка исемнәрен теркәп калдыру белән генә чикләнмичә, үзләренең асыл ватаннарын, ягъни кайсы төбәктән яки авылдан булуларын да күрсәткәннәр. Игътибар итегез: Мулла иленең (хәзер Яшел Үзән районына керә торган авыл) Хуҗа мулла язган таш Кече Шынар авылы зиратында, Пурхавайдан (Казандагы Пороховой бистәсе) мөәзин Иргали язганы Сабай авылы зиратында, талибел-гыйлем (мәдрәсә шәкерте) Мөбарәкша Казакларый (Казаклар авылыныкы дигәнне белдерә) язганы Чәбки-Саба авылы зиратында, мулла Шиһабетдин әл-Мамалайи уйган ташлар Мамалай һәм Ике басу Арташ авыллары зиратларында, Фәллахетдин бине мулла Шәмсетдин әл-Кенәбаши (хәзерге Кукмара районына керә торган Кенәбаш авылы кешесе, муллалар нәселеннән, үзе дә мулла) тарафыннан язылган берәр таш Мичәнбаш һәм Төбәк авыллары зиратларында, Казанның Фәтхелкадыйр Кәлмитев язган бер таш, Мортның (хәзер Алабуга районына керә торган авыл) Мөхәммәтзакир мөәзин язган өч таш Казанчы Бигәнәй авылы зиратында, мулла Габделхак язулар уйган бер таш Ике басу Арташ авылы зиратында сакланган.

Кабер ташларының уң, сул кырларына яисә арткы якларына уелган "Яздырып алып кайтты угылы Җәлалетдин Каргалыдан" (Сабабаш), "Иске Мәкчем авылы Мөхетдин Мохтар угылының зәүҗәсенең (хатынының) кабере өстенә куйды Бигәнәй хәзрәт" (Казанчы Бигәнәй), "Бу ташны яздырып куйды хаҗел-хәрәмәйн әш-шәрифәйн *(изге Мәккә белән Мәдинәгә хаҗ кылган)* мелла Мирсәет әткәсенең кабере шәрифенә" (Казанчы Бигәнәй), "Яздыргучы Өчнарат иленең Мөхәммәткәрим Габделхаликъ угылы" (Иске Икшермә), "Йәмәгате Нәгыймә тарафыннан йәдкәр" (Олы Арташ), "Гыйльфан Гыйльман угылы хиражәте илә (акчасына)" (Яңа Мичән) кебек җөмләләр—өстәмә тарихи мәгълүмат чыганаклары.

Мәкаләдә эпиграфик истәлекләргә кагылышлы мөһим бер проблеманы да кузгатмый мөмкин түгел. Бу—аларның сакланышы мәсьәләсе. Ул татар эпиграфик истәлекләренең зур күпчелегенә хас. Фәнни яктан караганда да, бәһасез мәгълүматлар тупланган бу төр тарихи чыганакларның һаман да игътибардан читтәрәк булуы бик кызганыч. Саба районындагы әүвәлге кабер ташларының да сакланышы мактанырлык түгел. Бигрәк тә, Кече һәм Олы Шынар авылларындагы Казан ханлыгы дәвере ташларының, Казанчы Бигәнәйдәге "Ишан каберлеге"нең бүгенге торыш-халәте, Сабай зиратында Гыйльман Яхин ташының бернничә кисәккә ватылып ятуы күңелләрдә борчу тудырды. Зиратларны, каберләрне чистартып, койма-чардуганнарын төзәтеп, аеруча кадерле ташъязмаларның өсләренә түбәләр ясап, сынган-аерылган кисәкләрен үзара беркетеп, ауган-кыйшайганнарын турайтып яки башка юллар белән бер, ике гасыр, хәтта биш йөз елга якын торган истәлекләрнең гомерен тагын күп елларга озайтыйк!

**Ирек ҺАДИЕВ, Раиф МӘРДАНОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Каракитә

Каракитә авыллары искә төшкәндә, иң беренче күз алдыма килгән әйбер — тәрәзә төпләрендә үскән гөлләр. Әллә соң Каракитә хатын-кызлары үзара ярыша-ярыша гөлләрнең иң матурларын үстерәләр микән?

Югары Каракитә авылы район үзәге Чүпрәледән 20, Түбән Каракитә 21 чакрым ераклыкта урнашкан.

Каракитә авыллары Чуваш республикасы белән янәшәрәк тора. Аны чувашлар Карахата дип йөртәләр.

Авыл атамасы Казан ханлыгы чорына нисбәтле чыганакларда һәм башка тарихи хезмәтләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә искә алына. 1859 ел мәгълүматларына караганда, Түбән Каракитә һәм Югары Каракитәдә дә лашманчылар яшәгән. Түбән Каракитәнең 66 йортында 370 ир-ат һәм 354 хатын-кыз көн иткән. Бер мәчет эшләгән. Югары Каракитәнең 101 йортында 544 ир-ат һәм 477 хатын-кыз яшәгән. Мәчет берәү булган.

Кечкенә генә булса да, һәр авылның зур тарихы була. Каракитә авылының да тарихы борынгы чорларга барып тоташа. Авылда яши торган өлкән буын вәкилләре сөйләвенә караганда, Югары һәм Түбән Каракитә авыллары оешканда, бу төбәк кара урманнар белән капланган булган, анда аю-бүреләр һәм башка кыргый җанварлар да күп булган. Авыл халкы хәзерге иген басуларын карурманны төпләп яисә яндырып ясаган. Моны тирә-юньдәге топонимнар да раслый: Карурман кыры, Лашман күпере h. б. Бу урманнарда, димәк, лашманчылар да эшләгәннәр, дәүләт өчен урман кисканнәр.

Авыллар нигезләнүгә һәм Каракитә дигән исем килеп чыгуга карата халык хәтерендә күп төрле гоман-фаразлар яши.

Авыл оешканчы ук монда халык яшәгән инде. Урта мәктәпне салганда урынын Кара елга буеннан сайлаганнар. Җир казу эшләре башлангач, биредә кеше сөякләре һәм археологик ядкарьләр табылган. Бу елгадан өске яктарак урнашкан басу киртә белән тотып алынган булган. Соңрак киртәне кара киртә дип йөртә башлаганнар. Шуңа бәйле рәвештә авылны да Каракитә дип кушканнар. Халык этимологиясенә нигезләнгән фараз әнә шундый.

Каракитә атамасы нәрсә аңлата соң? Бу турыда төрле фикерләр бар. Профессор Гомәр Саттаров чуваш галиме В. К. Магницкийның «Список селений (мишарей) в Буинском уезде Симбирский губернии» хезмәтендә Каракитә авылы атамасының килеп чыгышын Кара Катта (чувашча Хура Ката, «кара куаклык») дип, чуваш теле нигезендә аңлатуын кабул итә. Безнең уебызча, авыл исеме борынгы төрки кабиләләрнең бер төре — кара киданнарга нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Авылның урысча атамасы Каракитан рәвешле бирелгән. Ул — борынгы төрки этноним язылышына һәм әйтелешенә тагын да якын.

Тарихчы һәм этнограф h. В. Йосыпов үзенең «Булгар-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар» мәкаләсендә Татарстандагы байтак кына топонимнарның килеп чыгышын, тел һәм ономастика закончалыкларын нечкәләп исәпкә алып, борынгы төрки һәм башка халыкларның этнонимнары белән бәйли. Автор, топонимика һәм гидронимика мәгълүматларыннан чыгып, татарларның бабаларында, башка төрки халыкларда да очрый торган түбәндәге этнонимик атамалар (ыру-кабилә исемнәре) кулланылышта йөргән дип саный: Тазлар,

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 6 санында.*

Тоба, Телес, Тәтеш, Мөндеш, Дусем, Төркәш, Карлык, Кыят, Аты, Пәрәү, Сарай, Алат, Сарман, Кыркүл, Күл, Сөн, Үләмә (Ыглама), Күкчә, Бия, Ачы, Кәче, Чал һ. б. Бу топонимнарның һәм гидронимнарның нигезендә борынгы төрки кабилә исемнәре (этнонимнар) ята дип яза ул.

Тарихтан билгеле булганча, борынгы төрки кабилә-кавемнәрнең кайберләре утрак тормышка күчеп, төрле урыннарга нигезләнеп калганнар. Халык хәтерендә Түбән һәм Югары Каракитә авыллары оешкан чор булып 1440 ел сакланып калган. Бу авылларны Алатырь ягындагы Каракитә авылыннан күчеп килүчеләр нигезләгән. Югары Каракитәне Акмай, Түбән Каракитәне Тукмай исемле кешеләр башлап җибәргән. Ике гаилә Касыйм якларыннан да килеп урнашкан. Тора-бара бу урыннарга башка кешеләр дә килеп утыра башлый һәм авыллар зурайганнан-зурая бара.

Хәзер ике авыл арасыннан олы юл үтә. Революциягә кадәр Югары Каракитә белән Түбән Каракитә авыллары халкы арасында низаг та чыгып алган. Түбән авыллар Югары авылдан 5 елга арендага җир алып торганнар. Вакыты үткәч, Түбән авылларның җирне кире кайтарып бирәселәре килмәгән. Шуның нәтиҗәсендә авыллар арасында җир өчен сугыш чыккан. Бу мәгълүматлар белән авылның тарих музеенда танышырга мөмкин.

Авыл музее мәдәният йортының өске катына урнашкан. Анда авыл тарихы, халык хуҗалыгының элекке көнкүреш әйберләре, авылның күренекле кешеләре турында мәгълүматлар һәм аларның фоторәсемнәре кадерләп саклана.

Югары Каракитә авылында яшәгән Габделсаттар бабайларга Габделҗаббар Кандалый да килеп йөргән. Шулай ук ул Сембер өязендәге Каракитәгә дә барып чыга торган булган.

1985 елда мин Буа һәм Чүпрәле районнары авылларында экспедицияләрдә йөрдем. Халык күңелендә үзебезнең йола-кануннарга карата сакланган көчле ихтирамны күреп исләрем китә иде. Бу якларда һәр авылда чират белән мәүлет укыталар, рамазан аенда авыз ачтыру (ифтар) мәҗлесләре ясыйлар. Чират белән үткәрүнең сәбәбе бик гади, әгәр чиратны мулла дәфтәренә язып алып бармаса, авылда бер көнне ун-унбиш урында дини мәҗлес җыелачак һәм халык кайсына барырга икән дип аптырап калачак. Дин тоту, исламга мәхәббәт һәм хөрмәт бу якларда бик нык сакланган. Кайбер аймакларда яши торган милләттәшләремә мин бу яклардагы кардәшләреннән үрнәк алырга киңәш итәр идем. Югыйсә, шагыйрь Харрас Әюпнең «Мәүлет кичендә» дигән шигыре юк җирдә тумаган, ә чынбарлыкны чагылдыра. Менә ул юллар:

*Гүр иясе күрше карчыклары!*
*Кичерегез барсы өчен дә—*
*Кайтарасым килде бүген сезне*
*Бик күптәнге мәүлет кичәнә.*

*Күбегез тол.*
*Яшьләр кипкән инде*
*Чаба-чаба колхоз эшенә.*
*Җанын сыйпап бер юатыр өчен*
*Мөнәҗәт тә җитә кешегә...*

*Сезнең якты әле дә төшә безгә...*
*Бүгенгеләр нәрсә калдырсын—*
*Уң белән сул тәмам буталган чак,*
*Кая барыйк, кыйбла бармы соң?*

*Юл тапкансыз,*
*Юкса лампагыз да*
*Җиделе генә иде ул чакта.*
*Ә без менә юлдан язып беттек,*
*Ильич яктысында булсак та.*

Каракитә җирләре гүзәл. Аның тирә-ягында географик берәмлекләр, аерым алганда елга-инешләр, чишмә-кизләүләр, урман-аланнар, күлләр, юл, урам, тау, чалу һәм авылга ямь биреп торучы болын-басулар күп. Исемнәре халыкның күңел түреннән чыкканга, җанга һәм йөрәккә якын. Аларның иң әһәмиятле ягы шунда, бу исемнәр халыкның тел үзенчәлекләрен, тарихи үсеш баскычларын, үсешнең бормалы юлларын чагылдыралар.

Авыл яныннан ага торган суны Түбән елга дип йөртәләр. Авыл уртасыннан Кара елга ага. Хәзер бу елганың суы бик саеккан. Кыркеләү суы Түбән елгага кушыла. Аның суы келәүле дип исәпләнә. Авыл халкы сөйләвенә караганда, бу елгадан су эчкәннән соң бер хатын-кызның авызы кыйшайган. Елга суының шулай тота торган гадәте бар икәнлеген бик әйбәт белгәннәр һәм аның янында итәк-җиңне җыеп йөргәннәр. Түбән елга суы Бизнәгә кушыла. Бизнә исә Сор (Сура) суына тоташа. Моннан башка тагын Кара, Саз, Челем, Кукавыш, Ыҗы, Ярана, Усия һәм Урта елга исеме алган инеш-сулар бар. Чишмәләрдән Кыркеләү кизләве, Тяпый, Купка, Җиде кизләү атамаларын әйтергә мөмкин. Мукай бабай кизләвенең суын Югары Каракитә халкы элек-электән яратып эчкән. Ташкизләү чишмәсе суын Бизнәгә коя. Шушы таш арасыннан тибеп чыга торган чишмәләрнең җанлы агышы газиз җир-ананың йөрәк тибеше булып хәтердә кала.

Урын исемнәреннән Аю кыры, Стрелка, Туктык, Җиде кизләү өсте, Вәлит чирәме, Аюлар җирләре һ. б.; кыр исемнәреннән Эсте чалган, Атламыш, Торна аланы, Карурман, Төбәк кыры һ. б., аннары Зур күл, Урта кырдагы күл, Бизнә тавы, Кыркабак юлы, Саз күпере, Ыстан күпер, Мунчала күпере, Лашман күпере һ. б. кебек атамаларны искә төшереп китү урынлы булыр.

Авылдан якын гына урман бар. Ул Кара урман дип йөртелә. Аннан узгач, Челем авылының печәнлек җирләре китә. Күрше чуваш авылы белән ике арада таулык. Авылдан күрше авылга барганда, Ыстан күперен чыгарга кирәк. Авылның түбән як кырыенда куаклык үсә, аның янында саулык. Ул җирне Тупик дип атыйлар. Элек анда сазлыкны киптереп яшелчә утыртканнар, печән җире ясаганнар. Сазлыкның бер урыны әле дә булса кыргый халәтен саклаган.

Авылда өч зират бар. Аларның берсе Югары авылда, икенчесе Түбән авылда, өченчесе урталыкта, ул элекке зират. Өченче зират җир белән тигезләнгән, тирә-юне тотып алынмаган. Беренчесе һәм икенчесе тотып алынган, авыллар халкы аларны тәртиптә тота. Җәен халык андагы печәнне чаба, язын, коелып кыш чыккан яфракларны себерә, зиратны чистарта.

Авыл уртасында ак кирпечтән салынган ике катлы мәдәният йорты балкып тора. Алда әйтеп кителгәнчә, аның икенче катында авылның тарих музее һәм китапханә урнашкан. «Йолдызкай» дип исемләнгән балалар бакчасы Югары авылда. Анда сабыйлар уйнарга, җырларга, сәнгатьле итеп шигырь сөйләргә һәм әхлак кагыйдәләренә өйрәнәләр.

Авыл халкы бер-берсенә карата миһербанлы һәм шәфкатьле. Авылда олы яшьтәге карт-карчыклар күп, караучылары булмаган картлар да бар. Андыйларга бу әби-бабайларның күршеләре ярдәм итә. Игелекле җирдә игелекле кешеләр яши.

1994 елның җәй аенда авылда мәчет ачылган. Элек исә авылда мәчетләр өчәү булган.

Хәзер авылда 500 дән артык хуҗалык бар. Киләчәктә авыл тагын да үсәчәк әле, чөнки кайчандыр Воркутага һ. б. урыннарга эшкә китеп урнашкан кешеләр яңадан авылга кайтып яши башлаганнар. Хәзер авылда бер генә буш йорт яки йорт урыны да юк. Кыскасы, авылның киләчәге өметле. Халык үзәкләштерелгән газ яга.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Равил
Фәйзуллин

# ТЕЛ САГЫНДА ТОРА СОЛДАТ

Тел гыйлеме хезмәтләре кемнәргәдер мавыктыргыч һәм кызыклы тоелмаска да мөмкин. Кеше үзе сөйләшкән телне әйбәт беләм дип исәпли. Өстәвенә тел гыйлеме шактый катлаулы һәм четерекле фән. Һәр телнең үз фонетик закончалыклары, морфологик үзенчәлекләре, җөмлә төзелеше ысуллары, стиль күренешләре... Шуңа күрәдер яшьрәк чакта бу фән ялыктыргыч булып тоела. Аның никадәр кызык һәм әһәмиятле икәнен еллар үткәч төшенәсең икән! Төптәнрәк уйлап карасаң, тел—һәр халыкта өйрәтелә торган төп фәннәрнең берсе бит. Тел аша халыкның тарихын, фикерләү рәвешен, психологиясен, әхлагын, эстетик тоемын, икенче төрле әйткәндә, аның жанлы рухи портретын белергә була. Тикмәгә генә тел—милләтне билгеләүче төп компонентларның берсе, дип исәпләнми шул. Шундый четерекле фәннең лаек рәвештә үсүе өчен, әлбәттә, бу эшкә фидакарьләрчә бирелгән кешеләр—галимнәр булу кирәк. Бу язмамда төп сүз шундый шәхесләрнең берсе—профессор Вахит Хөҗҗәт улы Хаков турында. Ул хәзер тюркологиядә исеме киң танылган галимнәребезнең берсе.



Мәгълүм хакыйкать: һәрнәрсәнең, шул исәптән һәр игелекле зур эшнең яралгысы өчен төп нигез-сәбәп кирәк. Аннан соң әле шул яхшы яралгының үрләп китүе өчен этәргеч көч кирәк. Кечкенә Вахитның зур профессор булып житешүенә башлангыч шартлар әйбәт булган: Зөя буйларының кабатланмас матурлыгы, хезмәт сөючән тату гаиләдә тәрбияләнү һәм укытучы әтисенең төпле киңәшләре, күңелнең сафлыгы, максат ачыклыгы...

Китапка-белемгә омтылыш Вахитта бик яшьли башлана. Мона өйдәге бай китапханә дә зур этәргеч ясый. Анда XIX гасырда һәм XX гасыр башында гарәп әлифбасында чыккан К.Насыйри, Ш.Мәржани, Г.Тукай, Р.Фәхретдин, Ф.Әмирхан һ.б. әдип һәм галимнәрнең әсәрләре белән беррәттән, «Казан мөхбире», «Әл-ислах», «Кояш», «Карчыга», «Шура», «Яшен», «Уклар» кебек газета-журналлар да була. Борынгы классик татар әдәбияты үрнәкләрен—«Кыйссаи Йосыф», «Таһир вә Зөһрә», «Ләйлә вә Мәҗнүн»нәрне кышкы кичләрдә гаиләдә жыелып уку да зур тәрбияви роль уйнаган.

Вахит Хаков 1926 елда Татарстан республикасы Буа районы Кузби авылында туа. Үз авылында башлангыч белемне алгач, Килдураз урта мәктәбендә укый. Мәктәп елларында укыганда, язу-сызу, ижат эше белән кызыксына, жырлар, бәетләр, мәзәкләр жыя, газета-журналларга хәбәрләр, әдәби парчалар яза. «Пионер каләме», «Яшь ленинчы»—аның иң яраткан газета-журналларына әверелә. Балалар язучысы Абдулла Алиштан файдалы киңәшләр ала, кадерле хатирә буларак, аның хатлары бүген дә саклана. Язучы Абдулла Әхмәт тарафыннан төзелеп, 1942 елда басылып чыккан «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» дигән китапта аның да халыктан жыйган мәзәкләре кергән. Ул 8 сыйныфны гына бетереп кала, бөтен хыял һәм изге теләкләрне чәлпәрәмә китереп, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлана. Ихтимал, Вахит ага биографиясенең иң ялкынлы сәхифәсе—ул аның яшьли Ватан сугышында чыныгуыдыр. 17 яшь тулар-тулмас вакытта, ул шактый озакка сузылган гаскәри хезмәткә китә. Ике ел Монголиядә, аннары Кытайда була, аңа японнарга каршы сугышларда катнашырга туры килә. Ул хезмәт иткән дивизия кыска гына вакыт эчендә җәяүләп мең чакрымлык авыр хәрби юлны үтә, Гоби чүлен, Хинган тавын кичә. Монголиянең Баян-Төмән (соңыннан—Чойболсан) шәһәреннән башланган хәрби поход Кытайның Сары дингез

буенда гына тәгәлләнә. Көнчыгыш экзотикасы, борынгы төрки бабаларыбызның яшәгән җирләре анарда зур кызыксыну уята. Төрки рун язмаларын да ул беренче мәртәбә шунда күрә, алар белән шунда таныша. Табигый ки, аның дөньяга карашы, профессиясе формалашуда болар берсе дә эзсез калмый.

Сугыш беткәннән соң да ул озак кына армия сафларында хезмәт итә. «Без авырның өстеннән, шинелнең астыннан чыгарга исәп тотмадык,—ди ул фронтовикларның ул чактагы бердәм халәтен белдереп.—Тыныч хезмәткә сусап кайттык». Шуңа күрә, анысы-монысы житешмәүгә игътибар итмичә, солдат Хаковның фәнгә килүе шактый урау юллар аша була. Ул аңа мәктәптән—практик лабораториядән килә. Башлангыч мәктәптә укыта, урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, уку-укыту бүлеге мөдире була. В.Хаковның кайбер хәбәр-язмалары матбугатта сугышка кадәр үк күренгәләсә дә, тел һәм әдәбиятка караган җитдирәк мәкаләләре 50 нче еллар башына туры килә. Ул инде мәктәптә укытканда ук күңеленең фәнгә тартылуын ачык төшенә, һәм, мөмкинлек чыгуга, язмышын татар филологиясе белән бәйли.

1949 елда армиядән кайту белән, сугыштан соңгы авыр елларга булуга карамастан, ул укуын дәвам итәргә керешә. Тәтеш педагогия училищесын тәмамлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә, аны кызыл дипломга тәмамлап чыга. Шул елны ук СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурага имтиханнар тота һәм конкурстан үтә. Профессор Л.Җәләй җитәкчелегендә аспирантураны уңышлы тәмамлагач, аны 1960 елда Казан университетының үзе укыган татар филологиясе бүлегенә укытучы-ассистент итеп күчерәләр. Вахит Хаковның моннан соңгы эшчәнлеге тулысы белән диярлек университет белән бәйләнгән. Аңа 1965 елда—доцент, 1974 елда профессор дәрәҗәсе бирелә. Ул XIX йөздә һәм XX йөз башында татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган кандидатлык диссертациясен 1961 елда, ә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсешенә багышланган, филология фәннәре докторы исемен алу өчен язылган докторлык диссертациясен, 10 ел үткәч, 1971 елда яклый.

...Кайчан гына ул, кандидатлык диссертациясе яклап, мәш килеп йөргән иде, инде баксаң, докторлыгын яклаганга да күп вакыт узган. Университетта студентларга лекцияләр уку, диплом, курс эшләре җитәкчесе булу, аспирантурада программалар, методик кулланмалар төзү, монографияләр язу... Республикада, үзәк һәм тугандаш халыклар матбугатында чыккан фәнни хезмәтләре генә дә берничә йөзгә якын. Шуларның 15 кә якыны аерым басма булып, китап итеп чыгарылган. Безгә аның күптән түгел зур күләмле «Татар әдәби теле тарихы» дигән хезмәтенең тәгәлләнүе билгеле. (Бу хезмәт 1993 елда Казан университеты нәшриятында басылып чыкты. Күләме—326 бит.) Чыкканнарының берничәсен генә искә төшереп үтик: «Тел һәм стиль мәсьәләләре», «Татар теле стилистикасына кереш», «Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар», «Мәктәптә стилистиканы өйрәнү», «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше», «Мәктәптә язучылар телен өйрәнү», «Стилистика һәм сүз сәнгате», «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20—30 нчы еллар)» һәм башкалар.

Тел мәсьәләсе җәмгыятьтә һәрвакыт зур иҗтимагый проблемаларның берсе булып санала. Өлкәнрәкләрнең хәтерендәдер, сугыштан соңгы елларда тел турында, аларның килеп чыгуы һәм үсеш юллары турында кискен-кискен бәхәсләр булган иде. Ул вакытта дәүләт башлыкларының һәм телчеләрнең хезмәтләрен һәрбер вузда өйрәнәләр иде. Тел мәсьәләсе хәзер дә актуаль булып кала бирә. Мәгълүм булганча, татар халкы сан ягыннан Русиядә икенче урында тора. Шунысын да әйтеп үтик: безнең телебез чагыштырмача әйбәт өйрәнелгән. Бу җәһәттән аның күркәм тарихы бар: элекке дәвердән—Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннар, К.Насыйри, ә бу гасырның беренче яртысында—Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Шәрәф, Г.Алпаров, М.Корбангалиев, Ш.Рамазанов, Л.Җәләй, В. Хангилдин хезмәтләре. Бүгенге көндә исән-сау һәм нәтиҗәле эшләп килүче галимнәребездән М.Зәкиев, Д.Тумашева, Х.Курбатов, Р.Юсупов, Г.Саттаров, Ф.Сафиуллина һәм башка галимнәребезнең тырышлыгы аркасында тел белеме фәнен өйрәнү һаман күтәрелә бара. Тел гыйлемендә, тырышлык һәм сәләт белән бергә, гражданлык һәм патриотизм хисләренең югары булуы да, фидакарьлек тә сорала. Тел бакчасы зур, андагы хәзинә бәһа җитмәс кыйммәтле булгач, билгеле, бакчачылар, аның сагында торучылар үзләре дә галел, көчле, зирәк булырга тиештер. Әгәр Ватан сугышы утларын кичеп, көче-җегәре ташып торган мәһабәт гәүдәле ир кеше татар теле фәненә алынган



*Вахит Хаков университет студентлары белән. 1972.*

икән, моны бик табигый сайланыш дип уйларга кирәк.

Профессор Вахит Хаковны тел гыйлеменең төрле яклары, әйтик, лексикология, терминология, фразеология, орфография, этимология проблемалары, сөйләм культурасы, мәктәпләрдә тел укыту методикасы да кызыксындыра, ләкин шулай да аның төп хезмәте—татар әдәби теленең тарихы, төрки-татар язма ядкярләрен тикшерү һәм бүгенге телдәге стилистика мәсьәләләре. Мәгълүм булганча, төрки һәм татар әдәби телләренең ерак гасырларга сузылган үсеш юллары бар. В.Хаковка моңа кадәр билгеле булган элекке төрки язма һәм басма әсәрләрнең барысы белән дә танышып чыгарга туры килә. Телнең хәзерге үсешен шул нигездә генә ачык күз алдына китерергә мөмкин. Аның 1971 елда Алма-Атада яклаган докторлык диссертациясенең исеме дә «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм аның стильләре үсеше» дип атала. Минем аңлавымча, бу—әдәби телнең эволюциясен чагылдырган хезмәт. Билгеле, болай колачлау өчен тикшеренүчеләрдән телне һәр яктан: лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик яктан тирән белү сорала. Бу хезмәттә темага комплекслы килү саклана да, барыбер аның үзәк өлеше әдәби тел тарихына һәм аның стильләренең дифференциация мәсьәләләренә багышланган. Автор, һичшиксез, бу өлкәнең зур белгече. Профессор В.Хаков инициативасы белән, аның хезмәтләре нигезендә югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләрендә «Татар әдәби теле тарихы» һәм «Стилистика» буенча махсус курслар барлыкка килде. Алар, хәзер фән буларак, Казан һәм Уфа университетларында һәм педагогия институтларында студентлар тарафыннан махсус өйрәнелә.

Кемдер әйткән канатлы тәгъбир бар: стиль—кешенең үзе бит ул! Бераз кискенрәк һәм көтелмәгәнчә әйтелсә дә, гаҗәеп мәгънә бар бу сүзләрдә. Чыннан да, стиль ул бик киң төшенчә. Стиль—рухи эшчәнлекне белдерүче бер билге ул. Ә инде кешенең уйлау рәвеше һәм аның чагылышы булган сөйләмендә һәм язуында стиль бигрәк тә ачык күренә. Профессияләре язу эшенә бәйле кешеләр өчен стиль төрләрен белү, шул стильләрне тәшкил итүче чараларны ачыклау аеруча зарур. Лингвистиканың кайбер өлкәләре фәннең эчке үсеше өчен күбрәк кирәк булса, минемчә, стилистика—тел фәненең практик гамәлгә якынрак торган өлеше. Әдәбият белән тел гыйлеме бергә йөргән кебек, матур әдәбият тудыручы язучыларның әсәрләре тел галимнәренең житди хезмәтләре белән аерылгысыз итеп каралырга тиеш. Безнең шартлар өчен бу нәрсә аеруча мөһим. Әгәр әдәбиятчылар үзбаш, тел галимнәре үзбаш тормыш белән яшәсәләр, тел үзе дә, әдәбият та әллә ни алга китмәс, халыкның милли рухы да үсмәс иде. Шушы позициядән караганда, матур әдәбият телен фәнни нигезгә салып өйрәнүдә дә В.Хаковның хезмәте зур. Язучыларыбызның әсәрләрен телчеләребез укып, өйрәнеп барган кебек, язучыларыбыз тел гыйлемендәге яңалыклар белән тиеш

дәрәҗәдә танышалар микән? Әйтик, каләмдәшләр тел галимнәреннән Х.Курбатов яки Ф.Сафиуллиналарның язучыларга кагылышлы яна хезмәтләрен дикъкать белән укып бәһаләделәрме? Мина, мәсәлән, В.Хаковның үткән ел Казан университеты нәшриятында чыккан «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше» дигән китабы аеруча ошады. Анда татар теленең революциядән соң гомуми үсеш тенденцияләре яктыртыла, конкрет мисалларда тел үзгәрешләренә анализ ясала. Әдәби телнең эшләнеше, 20—30 нчы елларда татар телен гамәлгә кую мәсьәләләренә багышланган бүлекләр аеруча гыйбрәтле.

Һәр фәннең бүгенге тормышта заман куйган проблемаларны хәл итә-итә үсүе хәерле. Без ана телебезнең үсешенә, реаль тормыштагы функциясенә, киләчәктәге язмышына битараф була алмыйбыз. Галим В.Хаков та үз хезмәте белән халкыбызның рухи пропагандисты. Ул әле укытучылар, әле журналистлар алдында тел һәм сөйләм культурасы турында лекцияләр, докладлар белән чыгыш ясый.

Телне «халыкның күмәк хезмәтен, күмәк акылын чагылдырган могҗиза» дип атыйлар. Профессор Вахит Хаков кырык елдан артык инде шул могҗиза сагында тора. Аның йөзләгән шәкертләренең берсе буларак, күнелдә шигырь юллары калка:

*Яшәсен,*
*эш сөйгәннең—хезмәтеннән*
*зур шатлык ала алганы.*
*Егетләрнең бик түбәннән*
*күтәрелеп дан алганы!*

*1986*

* * *

*Бу язма моннан егерме ел элек язылган. Нindiрәк еллар иде соң ул еллар? дип сорасалар, торгынлык дәверенең апогея еллары иде ул еллар диярбез. Шул заман рухы бу язмада да беркадәр сизелә шикелле: фактик материалны констатацияләү, проблемалар куеп изаланмау, юбилярга мәдхия белдерү (В. Хаковка ул чак 60 яшь булган), салмак кына хикәяләү (хәер, галим үзе дә салмак, ипле кеше)... Нишлисең, без дә замана баласы... Әмма һич үкенү юк, язылган кадәресе, күңелгә хыянәт итмичә, ихлас язылган.*

*Әйе, соңгы бу егерме ел эчендә, социаль-иҗтимагый мәгънәдә, дөньяның асты өскә килде. Алга дип күз төбәп барган маяклар ауды, яңалары пәйда булмады... Җәмгыятьнең яшь, көчле, әрсез һәм оятсыз өлеше бөтенхалык көче белән барлыкка килгән байлык-мөлкәтне йолку-булу, көрәш-төртеш чорында, рух дөньясы, шартлыча аны Муза дип атыйк, кырыйда, нарасый ятимдәй өлешсез, нәүмиз булып калды... Фән-гыйлем өлкәсенә дә кагыла бу өлешсезлек. Туган телебез язмышына да. Соңгы дистә елларда тел турында, моңа кадәр булмаганча кайгыртып сөйләсәк тә, канун-законнар игълан итсәк тә, гомумтатар күзлегеннән караганда, бу өлкәдә алгарыш юк. Моннан кырык-илле ел элек тел үсешенә рәсми игътибар булмаса да, тамырлар әле нык булган, хәзер—киресенчә, тамырлар кипшергән, өстән күпме генә су сипсәң дә, нәтиҗә аз...*

*Читкәрәк кителде шикелле. Сүзебез бит галим Вахит ага Хаков турында. Тел галиме турында булгач, туган тел язмышы турында уйланмый мөмкин түгел шул.*

*Соңгы дистә еллар эчендә фикерләү рәвешенә бәйле рәвештә язу өслүбем беркадәр үзгәрсә дә, бу өстәмә, язмамны элгәрге язган рухта, шул стильдә дәвам итеп тәмамламакчы булам.*

Әйе, соңгы дистә еллар эчендә катаклизмга якын үзгәрешләр булса да, әйтергә кирәк, тел тарихын халык тарихы белән бәйләп объектив тикшерү өчен киңрәк мөмкинлекләр ачылды.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков, татар тел гыйлемендә «Әдәби тел тарихы» фәненә нигез салучы, «Стилистика»ны фәнни әйләнешкә кертүче галим буларак, бүген дә шул тармакларның катлаулы проблемаларын киң күләмдә фәнни яктан тикшерүне дәвам иттерә. Ул—шушы өлкәләргә караган юнәлешнең фәнни җитәкчесе. В. Хаков яшь фәнни кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Аның фәнни җитәкчелегендә 20 гә якын кандидатлык һәм берничә докторлык диссертацияләре якланды. В. Хаков

Халыкара Тюркологик форумнарда, конференцияләрдә докладлар белән чыга, үзенең фәнни ачышлары белән уртаклаша: Казанда үткәрелгән Халыкара Тюркологик конференциядә (1992), Әнкарада (Төркия) оештырылган III Халыкара Төрки Телләр Корылтаенда (1996), Америка татарлары җәмгыяте җыелышында (АКШ, 2000), Уфада җыелган Халыкара тюркологик конгресста (1997), Казанда Г. Ибраһимовка (1997), Г. Исхакыйга (1998) багышланган Халыкара конференцияләрдә һ. б. 1993 елда аның университет нәшриятында «Татар әдәби теле тарихы», Татарстан китап нәшриятында «Татар әдәби теле («Стилистика нигезләре)» (1999), «Тел-тарих көзгесе» (2003) дигән зур күләмле монографияләре басылып чыкты.

В. Хаков—500 дән артык фәнни-теоретик һәм методик-практик мәкаләләрнең, 30 дан артык китап, монографияләр, дәреслекләр, уку-укыту кулланмалары авторы. Ул үзенең фәнни һәм педагогик эшчәнлеген соңгы елларда җөмһүриятебездә барлыкка килгән үзгәрешләр, татар телен гамәлгә кую, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә алып бара. 1989 елның февралендә Татар Иҗтимагый Үзәген оештыру Корылтаенда, Тел коммиссиясе рәисе сыйфатында, ул «Татар телен яклау һәм аңа дәүләт статусы бирү турында» дигән докладында, беренчеләрдән булып, татар телен рәсми рәвештә дәүләт теле итеп игълан итү мәсьәләсен күтәреп чыкты, моны фәнни һәм тарихи яктан дәлилләде.

Ул Татарстан Республикасы Югары Советы Президенты карары белән «Телләр турында Закон» проектын әзерләү комиссиясенең әгъзасы буларак та зур эш башкарды. В. Хаков хәзер дә Тел комиссияләренең эшендә актив катнаша, татар теленең кулланылышын киңәйтү юнәлешендә, туган телгә карата яңача фикер тәрбияләүдә күп эшли. Соңгы дәвердә, беләсез, төрки халыкларда латин язуына күчү буенча зур хәрәкәт башланып китте. В. Хаков татар язуын латинга күчерү юнәлешендә киң эш алып бара, аның кирәклеген раслап мәкаләләр, уку-укыту кулланмаларын бастырып чыгарды. 30 елдан артык Татарстан радиосыннан тапшырыла торган «Тел күрке—сүз»не оештыру һәм хәзерләү аның иҗади катнашлыгында бара. Бу хакта филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллин матбугатта: «Тел күрке—сүз» фәнни яктан этрафлы, формасы ягыннан мавыктыргыч итеп алып барыла. Монда тапшыруларның фәнни консультанты В. Хаковның өлеше зур»,—дип язып чыккан иде. Әйткәнемчә, профессор Вахит Хөҗҗәт улы Хаков—тюркология даирәсендә, гомумән, тел белеме дөньясында исеме киң мәгълүм галимнәребезнең берсе. Ул—Мәскәү, Алматы, Ташкент, Баку, Ашхабад, Бишкек, Уфа, Махачкала һ. б. шәһәрләрнең галимнәре белән тыгыз элемтәдә яшәп, иҗат итә. Бөтенсоюз, вузара, региональ фәнни-теоретик конференцияләрдә дә аның чыгышлары еш яңгырый. В. Хаков зур һәм тырыш хезмәтләре өчен «Бөек Ватан сугышы ордены», күп медальләр, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгы тарафыннан «Эштә иң яхшы уңышлары өчен» билгесе һәм Мактау грамоталары белән бүләкләнде, күп рәхмәтләр алды. Ә 1987 елда Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Татар теленең тарихи үсешенә багышланган хезмәтләре өчен ул Университет премиясенә һәм лауреат исеменә лаек булды. Галимне тану һәм олылау буенча мәгълүмат күрсәткечләрне тагын да санарга мөмкин. Эш анда гына түгел. Төп хикмәт—халык ихтирам итүдә.

Әле күптән түгел генә Вахит Хаковның Телләр тарихына багышланган «Татар әдәби теле диахроник һәм синхроник аспектта (татар теленең барлыкка килүе һәм үсеше)» дигән исем белән бер цикл рәвешендә биш монографиядән торган фәнни хезмәтләре (барысы—82 басма табак күләмендә) В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты тарафыннан Татарстан Республикасының 2006 елда Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Күп еллар дәвамында эшләгән галимнең әдәби тел тарихына караган хезмәтләре белән таныш булганга күрә, без бу тикшеренүләргә зур бәя бирәбез, моның татар тел белеме өлкәсендә генә түгел, татар әдәбияты, мәдәнияте һәм тарихына кертеән зур өлеш булганлыгын билгеләп үтәбез һәм аның авторы—Вахит Хаковны, һичшиксез, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясенә лаек дип саныйбыз.

Үз нәүбәтебездә, Вахит Хөҗҗәт улы Хаковны олуг юбилее белән котлыйбыз, аңа сәламәтлек, фәнни-педагогик эшчәнлегендә уңышлар телибез. Безгә—күп санлы шәкертләренә куаныч түгел мени!—солдат, галим, гражданин һаман алгы сафта.

Səngət
Сәнгать

*Латыйф Хәмидинең тууына 100 ел*

# ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗ ЯКТЫСЫ

*Сибелә чәчәк җилләр искәндә,*
*Өзелә үзәк искә төшкәндә...*
Халык җырыннан

Бауман урамындагы ул чактагы Язучылар йортының бер бүлмәсендә ничектер җиде-сигез кеше җыйналып утырган чак иде бу. Кинәт радиодан сискәндереп, саркытып кына «Сибелә чәчәк» көе агыла башлады. Хәтерем ялгышмаса, Фәридә апа Кудашева җырлады бугай аны...

Фронт юлларын кичкән олпат шагыйребез Сибгат ага Хәким, җырны тыңлап бетергәннән соң, моңая һәм сагая төшеп, нибары өч кенә сүз әйтте:

—Сибелдек шул, сибелдек...

Без, милли мәсьәләдә борынына азмы-күпме «ис керә» башлаган студентлар, ничектер тын калдык. Ә менә арадан өлкәнрәк бер язучы фикерен турыдан-туры ярып салды:



—Ни бит, Сибгат агай, безнең татар кайда да югалып калмый ул!

—Әйе, югалмый анысы... Тик менә бүтән нәрсәләрне югалтуыбыз бар. Әйтик 40-50 елдан соң безнең язганнарны укучы табылырмы, музыкабызны тыңлаучы булырмы?

Заманы өчен, ай-һай, каты сорау иде бу: башларыбызга күсәк белән органдай тәэсир итте бу сүзләр.

Тора-бара, кайта-кайта аңладым: Сибгат ага әнә шул чакта ук мәсьәләнең иң кискен ягына карап, татар мәктәпләре һәм туган телебезнең урыс-совет мохитендә бетә-йомыла баруы өчен борчылып яшәгән икән...

Чү, укучы мине гафу итсен, — сүзебез бит Латыйф Хәмиди турында барачак иде! Кем ул, кайдан, ниләр кылган, ниләр майтарган? Безнең күпләребез, әлбәттә, аның үзен яисә иҗатын, шәхесен, Казагыстандагы эшчәнлеген начар яисә чамалы гына беләбез. Менә шуңа күрә «көй»не нәрсәдән башлыйбыз ки?

Минемчә, аның туып-үскән җиреннән башлап китү дөресрәк булыр. Шулай да, иң әүвәле, «Татар энциклопедия сүзлеге»ннән аның хакындагы кыскача мәгълүматны күздән кичерик әле:

«Латыйф Габделхәй улгы Хәмиди (1906—1983), композитор, педагог, Казагыстанның халык артисты (1966). Казах провессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе. Төп әсәрләреннән «Абай» (1944), «Түләгән Туктаров» опералары (1949), икесе дә Әхмәт Җобанов белән берлектә язылган. Казагыстан дәүләт Гимны авторы (1995, М. Тулибаев, Е. Брусиловский белән берлектә), Казагыстан дәүләт премиясе лауреаты (1978)».

Менә бит ничекләр үскән, күпме дан алган татар егете! Ә инде «сибелгән»гә килсәк, болайрак... Булачак композитор Л. Хәмиди 1906 елның 17 июлендә Татарстанның Апас районы, Бүәле авылында крәстиян гаиләсендә дөньяга килә. Французның атаклы язучысы Сент-Экзюпери нәрсә ди әнә: «Без барыбыз да — балачак иленнән...» Чынлап та шулайдыр ул. Туган авылы Бүәледәге сабыйчак

тормышы, андагы чәчәкле елга-болыннар, урманнар, чикерткәләр хоры, адым саен табаныңны кытыклап торган тере үләннәр, тау артында көн саен кояш баешлары — болар берсе дә эзсез калмагандыр, билгеле.

Сибелгән шул татар, сибелгән...

Чирәмлектә аунап үскән купме татар баласы ул чактагы СССР киңлекләренә таралып, әллә кемнәрнең әллә кем буласын әле берәү дә белеп бетермәгәндер. (Бу хакта азакта янә «чүт кенә» сүзебез булыр әле.)

Заманалар авыр, еллар ябык чаклар бу. Гаиләне туйдырырлык юньлерәк эш, акча эзләп, Габделхәй абзый да Донбасска килә, шахтер булып эшли. Үзбәкстанга барып чыккач, ул инде — тимерче, балта остасы. Кыскасы, ипи ашарлык, балаларны кеше итәрдәй уңышка ирешә.

1913 елда хәзерге Үзбәкстанның Кәттә Курган шәһәренә килеп төпләнүе исә бик тә уңышлы булып чыга. (Җәяләр эчендә булса да әйтеп китик: кәттә — зур дигәнне, курган — тау өеме дигәнне аңлата. Төркилекнең мәңгелек тамырлары түгелмени бу?)

Җиде-сигез яшьлек Латыйф нинди яңа мохиткә килеп эләгә соң? Заманының да шундыйрак чагы, ләкин барыбер шаккатырлык хәл: ул баштарак агасы Кәримулладан укырга-язарга өйрәнә. Аннары җыр, мандолина дәресе гамәлгә кертелгән җәдит мәктәбендә укый. Үзешчән түгәрәктә хор белән «Тәфтиләү», «Кара урман», «Зиләйлүк»ләрне җырлыйлар. Яшь кеше өчен болар — эзсез кала торган нәрсәләр түгел. Дини, кадими шәһәрдә бу бит инде үзе бер гаҗәп хәл! Инкыйлап, яңарыш, үзгәрешләр заманы икәнен искә алганда моны аңлау кыен да түгел.

Яшүсмер этисенә охшаган, бөтенесен булдыра: әле рәсемнәр ясый, әле ансамбльдә уйный, әле шигырьләр язып карый, хәтта поэма иҗат итә... Ә инде шигырьләр белән җенләнеп алуның хикмәте шунда: мөгаллимә, шагыйрәбез Заһидә Бурнашева (тәхәллусе — Гыйффәт туташ) аны әдәбият түгәрәгенә тарта. Монысын да булдыра бу татар малае: аның Сәмәркандта чыга торган балалар журналында шигъри бәйләме басылып чыга.

Егерменче елларда Ташкентта Татар мәгариф институты ачыла. Татарның татар җанлы бер баласы буларак, Латыйф Хәмиди гел шушы казанда кайный, әлбәттә, кешеләр белән аралаша, ныклы чыныгу ала. Гастрольгә килгән вакытларының берсендә Солтан Габәши аны Казанга (ягъни зуррак казанда кайнарга) чакыра. Тукайча әйтелгән «Нурлы Казан»га ничек инде ашкынмыйсың, ди?!.

Казанның да үз хәле хәл икән: Хәзергә музыка училищесында композиторлык бүлеге ачылмаган! Латыйф Хәмиди югалып калмый, татарның беренче музыканты Заһидулла Яруллин белән бергәләп музыкаль салоннарда пианиноның аклы-каралы телләрен биетә, яшәрлек акча эшли.

Белем алырга кирәк — шунсыз композиторның киләчәге була алмый. Латыйф Хәмиди 1936 елны Мәскәү консерваториясенең Татар опера студиясенә укырга керә, теория һәм композиция буенча профессор Генрих Литинский дәресләренә йөри башлый. Ә монда «татарның каймагы» яисә булачак йолдызлар дисәк, кемнәр генә юк: Салих Сәйдәшев, Нәҗиб Җиһанов, Фәрит Яруллин, Мансур Мозаффаров... Ул чакларны Латыйф Хәмиди үзенең истәлекләрендә менә болай искә ала: «Татар музыка эшлекләләренең, шул исәптән композиторларның, бик аз вакыт эчендә үсү һәм иҗади өлгерүләрендә утызынчы елларда Мәскәү консерваториясе каршында ачылган татар дәүләт опера студиясе мөһим роль уйнады. Мин татар халкының күренекле композиторы булган Фәрит Яруллин белән шул студиядә бергә укыдым».

Муса Җәлил белән дуслыгы, иҗатташлыгы хакында да беркадәр әйтеп китү урынлы булыр. 1927 ел, Мәскәү музыка техникумы. Муса Җәлилнең Мәскәүдә укып, «Октябрь баласы» журналын җитәкләгән чагы. Совет балалары өчен яңа, дәртләндергеч җырлар кирәк! Муса сүзләрен яза, Латыйф үзенең көйләрен нотага сала... Әнә шулай итеп, алар утызга якын җыр иҗат итәләр, шуларның һәммәсе диярлек «Октябрь баласы» (хәзерге «Ялкын» дип күз алдына китерик) журналында басылып та чыга.

Композитор Л. Хәмидинең төп иҗаты, ни генә дисәң дә, Казагыстанга бәйле,

чөнки бу республика аның икенче Ватанына әверелә. Инде утызынчы еллар башында ук аны казах драма театры яшь композиторны эшкә чакыра. Озак та үтми, Алма-Ата драма театрының музыка буенча җитәкче итеп куела. С. Сәйдәшев белән икесенең язмышындагы нинди уртаклыклар барлыгын чамалау кыен түгел. 1935 елдан ул Семипалат драма театрында эшли, шәһәр һәм авылларга гастрольләргә йөрү аңа казакъ халкының тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен тагын да тирәнрәк аңларга-өйрәнергә мөмкинлек тудыра.

Бу шәхеснең актив, иҗади эшчәнлегенә таң калырлык. 1943 елда Латыйф Хәмиди (Әхмәт Җобанов белән берлектә) «Абай» опера язарга керешә, бер ел эчендә әлеге күләмле әсәр тәмамланып, зур сәхнәдә янарыш ала. 1944 елда Алма-Атада консерватория ачылгач, укытучы-педагог итеп эшкә чакырыла. Казах уен кораллары кафедрасын җитәкли. Аның укучыларыннан (шәкертләреннән) безгә бик тә таныш булган, Казахстанның, Татарстанның, Россиянең артисты, дирижер Фуат Мансуровны атап китү дә күп нәрсәне аңлата.

«Түләгән Туктаров» һәм «Җамбул» опералары да композиторның колачлы, киң карашлы шәхес икәнлеге хакында сөйли. Л. Хәмидинең иҗади-музыкаль эшчәнлеген югары бәяләнә: ул — җитмеш яшен тутырганда өченче Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә, Абай исемендәге Казагыстан дәүләт премиясе лауреаты исеменә лаек була.

Язучы Тәүфыйкъ Әйди үзенең «Кайда да кадерле» дигән мәкаләсендә бик дөрес әйткән: «Зур исем һәм бүләкләргә лаек булган бу композитор белән җентеклəбрәк танышырга теләүчеләр А. Юсфинның Мәскәүдә (1964) һәм Б. Гыйззәтевнең Алма-Атада (1966) чыккан «Латыйф Хәмиди» дигән шактый күләмле китапларыннан да тулы мәгълүмат ала алмас». Чөнки аларда композитор эшчәнлегенең соңгы егерме еллык иҗаты бөтенләй керми калган, фәлән елларда чыккан китапларның искерүе дә бик табигый.

Ул чакларда Татарстан композиторлар союзының җаваплы секретаре булып эшләгән Мирсәет Яруллин сөйли: 1976 елда ул үзенең 70 яшьлек иҗат бәйрәмен Казанда да үткәрергә теләге барлыгын белдереп хат язган булган. Ләкин ул хат партия коридорларында ничектер күз игътибарыннан «төшеп» калган икән... Ә бәлки теләүче, ашкынып торучы да табылмагандыр. Кызганыч ки, бездә исән чакта кеше кадерен белеп бетермәү мисаллары җитәрлек.

Композитор, педагог, редактор, күпкырлы җәмәгать эшлеклесе — Казагыстанда аны әнә шундый шәхес буларак яхшы беләләр. Кайбер саннарга гына тукталыйк: 50 дән артык җырлар, романс, хор хезмәтләре; 20 ләп инструменталь әсәрләр, 12 сәхнә әсәренә һәм 5 кинофильмга музыка, дистәгә якын кулланма дәреслекләр һ. б. Кеше чын-чынлап иҗат дөньясында яшәгән! «Казагыстан татарларының халык музыкасы» дигән күләмле мәкалә язарга да вакыт тапкан.

«Сибелә чәчәк» көн саен искә төшә... Чынлап та, җир шарының кайсы гына төбәкләренә сибелгәнбез, таралганбыз. Бервакыт дөньяда дан тоткан теннис остасы Марат Сафин турында үзәк газеталарының берсендә «русская ракетка» дип язып шаккаттырганнар иде. Ярый әле атаклы биючебез Рудольф Нуриевны аралап калдык, Казанда аның исемендәге балет фестивален гамәлгә кертеп җибәрдек.

Композитор Латыйф Хәмиди, Казагыстан сәнгатенә хезмәт итсә дә, ерактагы йолдыз яктысыдай, ул Татарстанга да үзенең нурын сибеп тора.

**Рашат НИЗАМИ**

# Б

**БУЛИЧ** Николай Никитич (3 яки 5.2.1824, Курган ш. – 24.5.1895, Спас өязе Урыс Йорткүл а.), әдәбият галиме, Петербург ФАнең мөхбир-әгъзасы (1883). Казан ун-тын тәмамлый (1845). 1850 елдан Казан ун-тында, 1854 тән проф., 1862-64, 1875-78 һәм 1881-82 дә тарих-филология ф.-ты деканы, 1864-71 дә проректор, 1882-84 тә ректор. 1865 тән шәһәр һәм җәмәгать китапханәләре б-н идарә итү к-ты мактаулы күзәтчесе, соңыннан әгъзасы. 1880-90 да земство эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, өяз һәм губерна земстволары гласные, земство мәктәбе идарәчеләре советы рәисе. 1863-95 елларда «Казанские губернские ведомости», 1872-73 тә «Камско-Волжская газета», 1884-95 елларда «Волжский вестник» г-таларында әдәби тәнкыйтьче буларак язмалар бастыра. 1865-68 һәм 1881-85тә «Учёные записки Казанского университета» ж-лы мөхәррире. А.П.Сумароков турындагы монография, Г.Р.Державин, М.В.Ломоносов, Н.М.Карамзин, В.А.Жуковский, А.С.Пушкин, Ф.М.Достоевский турындагы мәкаләләр һәм чыгышлар, Казан ун-ты тарихы буенча (1887-91) беренче фәнни хезмәт авторы. 1894 тә аның 3000 китапны туплаган (7000 тт.) китапханәсен Казан ун-тына бүләк итә.

Әсәр.: Из первых лет Казанского университета (1805-19). В 2 т., 1889-91; Очерки по истории русской литературы и просвещения с начала XIX века: В 2 т. СПб., 1902-05.

Әд.: Фирсов Н.А. Студенческие истории в Казанском университете. 1855-63 гг. // Русская старина. 1889. N4; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804-1904). К., 1904. Ч. 1; Азбукин В.Н., Макурин В.П. К оценке литературоведческого наследия Булича // Романтизм в русской и зарубежной литературе. К., 1974.

*М.М.Сидорова.*

**БУРНАШ** Фәтхи (Фәтхелислам) Закир улы (13.1.1898, хәзерге Чуаш Республикасы, Батыр р-ны Бикшик а. – 1.8.1942), шагыйрь, драматург, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Мулла гаиләсендә туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1907-16). 1916 елда үзлегеннән әзерләнеп Казан татар укытучылар мәктәбе программасы нигезендә имтиханнар тапшыра. Укытучы булып эшли, бер үк вакытта «Таң» (1918-20), «Кызыл Армия» (1921), «Татарстан» (1921-24), «Безнең байрак» (1922-24) г-таларында мөхәррир вазифаларын башкара. Б. – «Чаян» ж-лын оештыручыларның берсе һәм аның беренче мөхәррире (1923-24). 1924-28 дә партия оешмаларында эшли, 1927-28 дә Татар академ. театры директоры була, 1930 елларда Татарстан Дәүләт нәшриятында һәм Татар опера һәм балет театры каршындагы опера студиясендә эшли.

Әдәби эшчәнлеге 1910 еллар уртасында башлана. «Сәйяр» труппасы өчен С.Найдёновның «Дети Ванюшина» («Ванюшин балалары», 1914) пьесасын тәрҗемә итә, үзенең беренче «Язмыш» (1914, куела 1917), «Сукбай» (1915, куела 1917), «Саташкан кыз» (1916, куела 1917) пьесаларын яза. «Аң», «Ак юл» ж-лларында беренче шигырь һәм поэмаларын, яшь авторга киң танылу китергән «Таһир-Зөһрә» (1917, куела 1918) трагедиясен, «Яшь йөрәкләр» (1917, куела 1918) комедиясен бастыра. Гражданнар сугышы елларында иске тормышны инкарь итү, социаль гаделлек өчен көрәш, җәмгыятьне революцион үзгәртү мотивлары б-н сугарылган 15 тән артык поэма, шигырь, хикәяләр, памфлетлар яза. Киләчәктә ул мотивлар «Камали карт» (1925) комедиясендә, «Адашкан кыз» (1920-26, куела 1927) драмасында, «Хөсәен мирза» (1919-26, куела 1927) трагедиясендә, «Илһам» (1928) сатирик комедиясендә үсеш ала. Бу пьесаларның геройлары гомерләрен халыкны социаль яктан азат итүгә багышлыйлар, яңа моральне яклап чыгалар. Романтик «Лачыннар» (1931, куела 1933) драмасында, тарихи-революцион «Таң» (1932) драмасында Гражданнар сугышы вакыйгалары тасвирлана; «Олы юл белән» (1929-30) драмасында, «Ялгыз Ярулла» (1940) комедиясендә крәстияннең колхоз тормышында үз урынын табуга омтылы-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

шы күрсәтелә; «Тукучы Әсма» (1931, куела 1932) драмасында производство темасы чагылдырыла; «Мин калдырдым пар казанын» (1930) поэмасында шәхси милекчелек хисенең яңа туып килгән социалистик коллективизм принциплары б-н каршылыгы күрсәтелә: Б. «Колхозчылар маршы»на текст (1933), хатирәләр («Мәҗит ага хатирәсе», 1934; «Горький истәлеге», 1936) һ.б. яза. Татар теленә А.С. Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романын (1939), Л.Н.Толстойның «Хаджи Мурат» («Хаҗи Морат», 1935) повестен, И.С.Тургеневның «Отцы и дети» («Аталар һәм балалар», 1932), М.Горькийның «Мать» («Ана», 1933), Н.Островскийның «Как закалялась сталь» («Корыч ничек чыныкты», 1936-37; А.Шамов һәм Г.Хәбиб б-н берлектә) романнарын тәрҗемә итә. Б.- татар совет әдәбиятының һәм театр сәнгатенең идея-эстетик принциплары формалашуда билгеле бер роль уйнаган биш опера либреттосы (ш. и. «Таһир-Зөһрә», «Шатлык», «Яшь йөрәкләр»), хикәяләр, күпсанлы публицистик мәкаләләр, рецензияләр авторы. 1922 дә ТАССР ҮБК әгъзасы булып сайлана. Милләтчелектә гаепләнеп 10 елга лагерьга сөрелә. 1942 дә атылуга хөкем ителә. Үлеменнән соң аклана.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1959; Яшь йөрәкләр: Пьесалар, шигырьләр, поэмалар. К., 1969; Әдәбият һәм сәнгать турында: Мәкаләләр, рецензияләр. К., 1978; Яшь йөрәкләр. Пьесалар, хатлар. К., 1988.

Әд.: История татарской советской литературы.М., 1965; Драматург, оставшийся поэтом. // Ахмадуллин А. Горизонты татарской драмы. К., 1983; Татар пьесалары. Антология; 1 нче китап. К., 1987.

*А.Г.Ахмадуллин.*

**БУШКАНЕЦ** Ефим Григорьевич (12.11.1922, Пермь ш. – 16.11.1988, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1966), проф. (1967). Казан ун-тын тәмамлый (1948). 1946-63 елларда ТАССР Дәүләт музееның фән буенча директор урынбасары. Аның җитәкчелегендә музейның фәнни-тикшеренү, экспозицияләр оештыру һәм нәшрият эшчәнлеге алып барыла; «Болгар дәүләте» (1960-62), «Татарстан 1917-27 елларда» (1960) экспозицияләре оештырыла; совет чорына караган экспозицияләр үзгәртеп төзелә: беренче мәртәбә «Торгызу чорында мәдәният үсеше», «Бишьеллыклар дәверендә Татарстанда мәдәни революция казанышлары» темалары эшләнә. 1963 тән Казан пед. ин-тында, рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасын җитәкли, бер үк вакытта 1967-70 һәм 1973-76 да тарих-филология фак-ты деканы була. Төп фәнни тикшеренүләре 19 йөзнең 30-40 нчы һәм 60-80 нче елларындагы рус әдәбияты һәм җәмәгатьчелек хәрәкәте тарихына; рус әдәбиятының тарихи чыганакларын һәм җирле әдәбиятны өйрәнүгә; мемуар һәм эпистоляр әдәбиятның теоретик проблемаларына багышлана. Б. тарафыннан В.Г.Короленко, А.Н. Толстой, Н.А.Добролюбовның моңарчы мәгълүм булмаган кайбер әсәрләре ачыклана. Казан б-н бәйле булган язучылар иҗатына караган хезмәтләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Путеводитель по Казани. К., 1961; Мемуарные источники. К., 1975.

Әд.: Ахметзянов М.Г. Памяти Е.Г. Бушканца // Вопросы источниковедения русской литературы. К., 1989.

*М.Г.Әхмәтҗанов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*



***—Татарстан милли китапханәсендә тупланган рухи хәзинәне, байлыкны санап бетерерлек түгел: киштәләрегез сыгылып тора. Бу хәзинәдән кемнәр, ничек файдалана? Туган телебезне саклау, китап язмышы өчен көрәш Россия шартларында шактый авырдан бара. Менә шушы вәзгыятьтә республикабызның иң төп китапханәсенең хәле ничегрәк, авырлыклар сизеләме?***

**Наил Әкрам улы КАМБЕЕВ,** *Татарстан милли китапханәсе директоры:*

—Кыскача әйткәндә, безнең төп укучылар контингенты—студентлар, фән кешеләре, төрле һөнәр ияләре, әдәбият сөючеләр. Ләкин китапханәбезнең ишеге һәркем өчен ачык. Син Мәскәүдән яки Балтыйк буе илләреннән икәнсең дип, берәүне дә борып чыгарганыбыз юк. Чөнки мәдәни, рухи омтылышка киртә куярга ярамый.

Чынлап та киштәләребез сыгылып тора: хәзерге көндә Милли китапханә фондларында 3 миллион нөсхәдән артык басма бар. Татар телендәгеләре—100 мең чамасы, чит телләрдәгесе 78 мең исәпләнә. Китапханә 1000 нән артык исемдә гәҗит һәм журналлар алдыра.

Китап укуны телевидение алмаштыра бара, диючеләр бар. Килешеп бетмәс идем. Татарстан милли китапханәсе заманга хас мондый кыенлыкларны сизми диярлек. Чөнки бездә кешелек уйлап тапкан иң затлы ачышларның берсе саналган китапны пропагандалау, халыкны китап укуга тарту буенча зур эш алып барыла. Мәдәниятле, олы тарихлы халкыбыз китаптан аерылырга тиеш түгел. Мактану булып янгырамасын, ләкин безнең китапханә—мәдәният үзәге, мәгълүмат дөньясы булып саналырга хаклы. Һәрчакны «Ел китабы» дигән бәйге оештырабыз, популяр әдипләрне билгелибез. Яңа чыккан китапларга укучыларның бәясе, мөнәсәбәте китап иҗатучыларның күплеге турында сөйли.

Юкса 90 нчы еллар башында мәдәниятkә, китапханәләргә бюджеттан акча бирүләр бик нык какшаган иде. Яңа китаплар сатып алу да кыенлашты, халык газета-журналлар укудан читләште. БДБ илләре мөстәкыйльлек алганнан соң, алар биләмәсендәге бик күп китапханәләр ябылды h. б. Ә безне, шөкер, кин катлам җәмәгатьчелек үги итмәде. Хөкүмәтебез тарафыннан да һәрвакыт, диярлек яклау таптык. Китап сатып алу һәм районнарга тарату өчен, әйтик, быелтыр бер млн. сум акча бүлеп бирелгән иде. Бу җәһәттән район житәкчеләреннән дә зур активлык, ярдәм, аңлашу сорала, билгеле.

Базар мөнәсәбәтләре безне дә читләп узмады. Әмма түләүле хезмәт күрсәтү китаптан файдаланучылар өчен отышлы дип әйтәсе килә. Чөнки алар үзләре теләгән теләсә кайсы китапның битләрен бездә ксерокстан чыгарып алу хокукына ия. Шулай ук ял һәм бәйрәм көннәренә китапларны өйгә алып кайтырга мөмкин. Интернетка чыгасың килә икән, рәхим ит, ләкин күпмедер түләргә кирәк...

Чит илләр, читтәге татарлар белән дә бәйләнешләребез арта бара. Ульян, Пенза, Мәскәү, Пермь һәм башка төбәкләр белән тыгыз бәйләнештә торабыз. Компьютерларыбыз һәрчак һәм һәркем өчен уяу. Интернет-сайт аша көн саен 300 ләп кеше төрлечә элемтәләргә керә, эзләгәнен таба. Шул исәптән, чит илләр белән дә...

Туган тел исән булганда милли китапханә калачак, гасырларны ерып барачак! Киләчәгебезне өчен кайгыртучы милли зыялыларыбыз, Татарстан фәннәр академиясе, ахыр чиктә милләтебез менталитетын саклап килүче татар авыллары бар. Шуңа күрә мин оптимист: китап йортыбызның, татар китабының киләчәгенә ышанам.

## Ринат Мәннан



Ринат Мәннан (Архипов Ринат Николаевич) 1946 елның 6 февралендә Татарстанның Чистай шәһәрендә укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы Шөгер (хәзер Лениногорск) районында уза. 1964 елда Казан медицина училищесын тәмамлагач, Самара өлкәсенең Клявлино районында фельдшер булып эшли, аннары Совет армиясендә хезмәт итә. 1968—1974 елларда Казан дәүләт медицина институтында укый. Институтны тәмамлагач, башта Мордовия республикасында, ә аннан соң туган якларына кайтып Чистай шәһәрендә табиб булып эшли. 1978 елдан бирле Казанда яши.

Ринат Мәннан шигъри иҗат белән мәктәп елларыннан бирле шөгыльләнсә дә, беренче китабы «Умырзая» бары тик 1998 елда гына дөнья күрә.

Ринатның йөзләрчә шигырьләре Татарстан вакытлы матбугат битләрендә басылып чыкты: «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә», «Салават күпере», «Ялкын», «Школа» журналларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Татар иле», «Мәгърифәт», «Сабантуй», «Казанские ведомости» газеталарында.

Аны аерата пародияләр, сатирик-юмористик шигырьләр язу кызыктыра. «Чаян» журналы белән һәрвакыт багланышта булды. Хәзер дә үзенең иҗади җимешләрен журналга тәкъдим итеп тора.

Ринат Мәннан балалар өчен дә актив иҗат итә. Аның нәниләр өчен: «Табиб әлифбасы» китабының ике басмасы да 50 000 тираж белән «Раннур» нәшриятында басылып, 2001, 2003 елларда тиз таралып бетте. Аның төрле елларда «Дуслар» (1999), «Каян килә тундырма?», «Анатомик театр» (2003), «Микроб», «Ялкау өстәл» (2005) дигән китаплары чыкты. Ринат Мәннан рус телендә дә яза. Аның тәрҗемәсендә Ш. Галиевнең кайбер шигырьләре «Идель» журналында басылды. Ул 1993 елда «Молодежь Татарстана» газетасы оештырган фантастик хикәяләр конкурсында җиңеп чыкты һәм «Озеро» исемле хикәясе белән беренче урынны алып, күренекле фантаст Кир Булычев бүләгенә лаек булды.

Ринат Мәннан шушы елның 22 июнендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.



*Татарстан иҗат оешмаларының пленумы президиумы.*
*Сулдан уңга—Юрий Суровцев, Ибраһим Гази, Гариф Ахунов, Әдип Миндубаев.*
*Үткән гасырның 70 нче еллары.*



*Легендар генерал Якуб Чанышев*
*һәм Мәрьям Чанышева.*
*Үткән гасырның 20 нче еллары.*



*Татарстанда казакъ әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Тугандаш халык язучылары Казан заводларының берсендә. Уртада, ак күлмәктән—Олжас Сөләйманов. 1963 ел.*



*Татар композиторларыннан бер төркем. Сулдан уңга—Фасил Әхмәтов, Заһидулла Яруллин, Аллахияр Вәлиуллин, Сергей Ключарев, Мирсәет Яруллин. 1961 ел.*



*Мәшһүр галим һәм әдип Нәкый Исәнбәт. 1979 ел.*



*Каләмдәшләр очрашуы. Сулдан уңга—А. Гыйләҗев, Шамил Анак, Х. Туфан, А. Айвазов, М. Кәрим, Г. Ахунов, Г. Госман. 1970 ел.*

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САБАНТУЙЛЫ, ТУКАЙЛЫ ҖӘЙ

### Төркия

Төркиядә Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулу һәм татар халкының милли бәйрәме—Сабантуе зурлап бәйрәм ителде. Анда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Рәсми делегация составында Бөтендөнья Татар Конгрессы башлыгы Ринат Закиров, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, композитор Алмаз Монасыйпов, шагыйрь Рамис Аймәт, галимә Асия Рәхимова бар иде. Иҗат төркемендә—күренекле җырчылар, җыр һәм бию ансамбле артистлары, үзешчән сәнгать коллективы вәкилләре... Җәмгысе—120 ләп кеше.

Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган тантаналы кичә «Кемал Решит Рой» залында узды. Чара кысаларында «Рәсем сәнгатендә Тукай» дигән күргәзмә дә ачылды. Анда бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗатын тасвирлаучы экспонатлар, шулай ук Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган китаплар урын алды.

Ә Истанбулның Мәхмет Акиф исемендәге паркында Сабантуе бәйрәме узды. Зилә Вәлиева бирелгән чыгышында Президент Минтимер Шәймиевнең котлавын укыды. Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән, аның башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров чыгыш ясады. Ул танылган галим, тарихчы Надир Дәүләткә «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медален тапшырды.

Делегация әгъзалары шулай ук Бөтендөнья Ислам Конференциясе оешмасы каршында эшләүче Ислам тарихын, мәдәният һәм сәнгатен халыкара өйрәнү үзәгендә, «Топкапы» музей сараенда, Язучылар оешмасында узган очрашуларда катнаштылар, мәшһүр милләттәшләребез Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура каберләренә чәчәкләр салдылар.

Тукайга багышланган тантана һәм Сабантуй (сабантуй ике урында — Истанбулда һәм Әфәнде күпере дигән татар авылында булды) бәйрәмнәре рәсми яктан югары дәрәҗәдә узды. Аларда Төркиянең мәдәният һәм туризм министры Атилла Коч, Россиянең Төркиядәге Вәкаләтле илчесе Петр Стогний һәм башка рәсми кешеләр катнашты.

### Россия

25 июньдә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе башта Санкт-Петербургның Зверинская урамында мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукайга һәйкәл ачылу (сынчылары — Ә. Зыякаев, Ян Нейман) һәм анда төзеләчәк яна мәчеткә беренче таш салу тантаналарында катнашты. Бу чараларда санкт-петербурглылар ягыннан губернатор аппараты җитәкчесе Виктор Лапка, вице-губернатор Александр Вакмистров, Петербург районы хакимияте башлыгы Алексей Делюкин, С.-Петербург мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россиянең Төньяк-Көнбатыш өлеше мөфтие Җәфәр Пончаев бар иде.

Аннары Татарстаннан килгән олуг кунаклар Ленинград өлкәсенең Сярьги авылы янында узган С.-Петербург Сабантуен тамаша кылды. Бәйрәм чараларында Санкт-Петербург губернаторы Валентина Матвиенко катнашып, кунакларны: «Кадерле дуслар, исәнмесез!»—дип татар телендә сәламләде. Ф. Мөхәммәтшин үз чыгышында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең сәламләү хатын укыды, үзләрен җылы һәм дустанә каршылаганнары өчен олуг рәхмәтен әйтте. Санкт-Петербурглылар исә, үз чиратында, Сабантуйны үткәрүдә булышкан Татарстан вәкилләренә, шул исәптән Нурлат муниципаль районы җитәкчелегенә рәхмәт белдерделәр.

### Казакъстан

* * *

Алма-Ата шәһәрендәге Республика милли китапханәсенең утырышлар залында Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган зур әдәби-музыкаль кичә узды. Татарстанның Казакъстандагы вәкиллеге һәм Алма-Ата татар-башкорт җәмгыяте оештырган бу чарада Казаннан ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, Тукай җәмгыяте рәисе, Казан дәүләт университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов, артистлардан Резедә Галимова һәм Кирам Сатиев чыгыш ясады. Камил Муллашев, Гриф Хәйруллин һәм башка күренекле милләттәшләребез катнаш-

кан әлеге чарада Тукай иҗатына багышланган бай күргәзмә эшләде. Бу истәлекле вакыйга Казакъстан матбугатында һәм радиотелевидениесендә дә кин яктыртылды.

* * *

Уральски шәһәрендә Г. Тукайның тууына 120 ел тулу уңаеннан бәйрәм чаралары узды. Анда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты доценты, җырчы Мингол Галиев, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, язучы Җәүдәт Дәрзаман, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече Альбина Нуретдинова, шулай ук Казан университеты һәм Татар дәүләт гуманитар-педогогика университетының сәләтле студентлары катнаштылар.

Очрашулар шәһәрнең Халыклар дуслыгы йортында узды. Бу тантаналарда Казакъстан халыклары кече ассамблеясы рәисе Куанышбай Толебаев, Татарстанның Казакъстандагы даими вәкиле Илдус Тарханов, Россия консуллыгының Уральски шәһәрендәге атташесы Сергей Шимко, Уральски шәһәре «Татар мәдәни үзәге» татар иҗтимагый берлеге рәисе Ришат Хәйруллин катнашты.

## ЯШЬЛӘР ҖЫЕНЫ

Июнь ахырында Татарстанда II Бөтендөнья татар яшьләре форумы узды. Форумда 600 татар егете һәм кызы катнашты. Аларның 180е — ерак һәм якын чит илләрдән, 350се — Россиядән, 100 делегат — Татарстан Республикасыннан. Воронеж, Смоленск, Архангельск, Кабардин-Балкар, Приморье крае, Ингушетия төбәкләре форумда быел беренче мәртәбә генә катнашты. Таҗикстан, Грузия, Молдова, АКШ, Алмания, Кытай, Испания яшьләренең дә бирегә беренче генә килүләре.

Форум «Ак Барс» мәдәният-яшьләр үзәгендә ачылды һәм секцияләргә бүленеп дәвам итте. Әлбәттә, Казанның тарихи урыннарында булырга да, Кол Шәриф мәчетен карарга да, Болгарга барырга да, Сабантуйда бәйрәм итәргә дә вакыт табылды.

Менә форумда яңгыраган кайбер фикерләр: «Сезне мин милләт язмышын кайгыртып яшәүче кешеләр дип беләм. Битараф кешеләр бу форумга килә алмый. Татарларның үз миссиясе — берләштерү миссиясе бар. Сез шул миссияне үтәрсез, дип ышанам», — диде ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова. «Бүген уза торган форумда күп фикерләр әйтелер, идеяләр тәкъдим ителер. Аларны гамәлгә ашыру өчен мин Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, форум бюросы, министрлык белән берлектә Координацион шура оештырырга кирәк дип саныйм», —диде ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Марат Бариев. Татар яшьләре форумы бюросы рәисе урынбасары Руслан Сабиров: «Яшьләрне Ислам дине юлында килеп чыккан низаглар борчый. Туган теленнән, гореф-гадәтләреннән читләшкән яшьләрне үз асылына кайтарырга, ягъни, «этнореабилитацияләргә кирәк», — дип белдерде.

Конгрессның Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров татар гаиләсен саклап калу мәсьәләсенә басым ясады. Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова татар яшьләрен бәйсезлек өчен көрәшергә чакырды. 600 егет һәм кыз бер атна дәвамында әнә шундый җитди эш белән шөгыльләнде.

## ЖУРНАЛИСТЛАР ДЕСАНТЫ КАЗАНДА

«Казан» милли мәдәният үзәгендә төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чараларының II конгрессы булып узды. Аны Россия Дәүләт Думасы, Татарстан Хөкүмәте, Россия һәм Татарстан Журналистлар берлекләре, «Татмедиа» агентлыгы үткәрде.

Конгрессның максаты Россиядә, БДБ илләрендә төбәк һәм милли мәгълүмат чараларының бүгенге хәлен һәм үсеш перспективаларын тикшерү, тәҗрибә алмашу иде. I конгресс 2005 елда үткәрелгән иде. Ул чагында аның эшендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В. Лукин, Россия төбәкләре һәм БДБ илләре гаммәви мәгълүмат чараларының 250дән артык журналисты катнашты. Әлеге чара кысаларында Татарстан телерадиокомпанияләре «Көч куллануга һәм рәхимсезлеккә каршы» дигән хартиягә кул куйды. Конгресс йомгаклары буенча РФ Дәүләт Думасы депутатлары исеменә мөрәҗәгать әзерләнде.

Конгресста катнашучылар алдында Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин чыгыш ясады.

Төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чараларының II конгрессы делегатлары 2007 елда үзенең 1000 еллыгын билгеләп үтәргә тиешле Алабуга шәһәрендә дә булдылар. Конгресс кысаларында журналистлар арасында туган якның милли-мәдәни традицияләре буенча иң яхшы язмага Бөтенроссия бәйгесе игълан ителгән иде. Конгресс барышында бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү дә булды. Конгресс делегатлары Алабуга шәһәренең тарихи урыннарын карады, Сабан туе бәйрәмендә катнашты.

## ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕ ХӘРӘКӘТТӘ

Германия башкаласы Берлинда язучыларның 72 нче Бөтендөнья конгрессы үткәрелде. Конгресс «Язучылар — хәвефле дөньяда» девизы астында үтте. Анда 99 илдән 473 кеше, шул исәптән Татарстаннан 5 язучы катнашты. Алар — Татар ПЕН-үзәге президенты, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин; Татар ПЕН-үзәге вице-президенты, шагыйрь Разил Вәлиев; ПЕН-үзәкнең башкаручы директоры, язучы Әхәт Мушин-

ский; шагыйрьләр Харрас Әюп һәм Зиннур Мансуров.

«Татар ПЕН-үзәге моннан 10 ел элек оештырылган иде. Һәм Мексикада үткәрелгән Бөтендөнья конгрессында (1996 ел) бертавыштан Халыкара ПЕН-клубка кабул ителде. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: бүгенге көндә Россия Федерациясендә мондый ике генә оешма—Рус һәм Татар ПЕН-үзәкләре генә бар. Татар ПЕН-үзәге Бөтендөнья ПЕН-клубының күпкырлы эшчәнлегенә үз өлешен кертергә омтыла. Халыкара берләшмәдә «Лингвистика», «Экология», «Әдәби тәржемә», «Хатын-кыз язучылар», «Төрмәдә утыручы язучылар» һ. б. комитетлар эшләп килә. Ә каләм әһелләре игътибарын таләп иткән көнүзәк проблемалар бербер артлы туып кына тора. Безнең пенчылар Мексика, Шотландия, Финляндия, Македония, Словения, Норвегия һ.б. илләрдә үткәрелгән еллык конгрессларда да, язучыларның аерым төбәкләрдә уздырылган төрледән-төрле форумнарында да катнашып килә. Татар ПЕН-үзәге дистәләрчә илләрнең әдипләре белән якын элемтәдә тора, халыкара хокук яклау акцияләрендә үзенең саллы сүзен белдереп килә. Татар әдәбияты һәм халык иҗаты казанышларын дөньяга таныту аның эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе булып санала.

Язучыларның 72 нче Бөтендөнья конгрессын кереш сүз белән форумны кабул иткән ил вәкиле—Немец ПЕН-үзәге президенты Йохано Страссер ачып җибәрде. Аннары конгресста катнашучыларны Германия Президенты Хорст Келер сәламләде. Тантанада шулай ук Халыкара ПЕН-клуб президенты Иржи Груша, күренекле немец язучысы, Нобель бүләге иясе Понтер Грасс чыгыш ясады. Соңгысының нотыгы—бүгенге болгавыр заманда әдипләргә йөкләнгән үтә җаваплы миссия турында борчылу катыш белдерелгән уй-фикерләре аеруча зур игътибар белән тыңланды.

Конгресста катнашучыларны үзләренең резиденцияләрендә Германиянең Федераль Канцлеры Ангела Меркель, Берлинның идарәче бургомистры Клаус Воверайт кабул итте. Алар бөтен дөньядан җыелган каләм әһелләре белән очрашулары өчен бик тә шат булуларын белдерделәр, бүгенге кешелек җәмгыятендә демократия һәм гуманизмны ныгыту эшенә язучыларның гаять кыйммәтле өлеш кертүен билгеләп үттеләр. Татарстаннан килгән делегация, аерым рәвештә, Берлин парламентында да булды. Мондый югары дәрәҗәдәге рәсми очрашулар Халыкара ПЕН-клубның зур абруйга ия булуын раслый.

Татар ПЕН-үзәге инициативасы белән конгресс делегатлары ассамблеясында патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуы, Берлинда унбер җәлилченең гомерләре фаҗигале төстә өзелүе турында инглиз телендә махсус белдерү ясалды. Аннары Халыкара ПЕН-клуб исеменнән Татарстан делегациясе, шулай ук Рус ПЕН-үзәге, Берлинның татар һәм немец җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашында Плетцензее төрмәсенең җәлилчеләр җәзалап үтерелгән урынына чәчәкләр куелды...

## БЕЗНЕҢ ЭРМИТАЖНЫҢ ДАНЫ АРТА

«Казан-Эрмитаж» үзәгендә «XVI гасырдан алып XX йөз башларына кадәр Көнбатыш Европа чигеше. Интерьер һәм костюм» дип аталган күргәзмә ачылды.

Күргәзмәгә 170тән артык экспонат куелган. Декоратив паннолар, ашъяулыклар, чигелгән картиналар, хатын-кыз эшләпәләре, ир-ат костюмнары—бөтенесе дә зәвык белән, югары сәнгати дәрәҗәдә эшләнгән.

Күргәзмәне ачканда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева Россия Дәүләт Эрмитажы хезмәткәрләренә зур рәхмәт белдерде һәм август аенда Казанда дөньяның иң зур музейлары директорларының очрашуы булачагы турында да әйтте.

Россия Дәүләт Эрмитажы директоры, Россия Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы Михаил Пиотровский республика хөкүмәтенә Казанда Эрмитаж үзәген оештырулары өчен рәхмәт белдерде. «Бу күргәзмәнең кайбер экспонатлары монархы халык хозурына чыгарылмаган иде. Аның уникальлеге әнә шунда»,—диде ул.

М. Пиатровский шулай ук Татарстан Президенты М. Шәймиев белән очрашты. Әңгәмә барышында ел саен Санкт-Петербург Эрмитажында очрашып торучы Халыкара консультатив совет җыелышын Казанда үткәрү турында килешенде.

## ИМАН НЫГЫТУ КӨНЕ

11 июньдә—бабаларыбыз Ислам динен рәсми кабул иткән көнне Изге Болгар җыены узды. Аны быел Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Татарстан Диния нәзарәте, Үзәк Диния нәзарәте һәм Россия Мөфтиләр шурасы бергәләп үткәрде.

«Болгар» музей-тыюлыгының яшел далаболыннарында чатырлар тезелгән. Кайлардан гына килмәгәннәр бирегә: Уфадан, Самара, Әстерхан, Йошкар-Ола, Ижевск, Ульяновск, Пенза, Мәскәү, Ростовтан... Һәр төбәкнең мосафирлары, бер көн алдан килеп, чатырлары янында корбан чалып, бәйрәм табыны әзерләү белән мәшгуль иде.

Ә Зур Манара янындагы сәхнәдә төп җыен булды, анда мөфтиләребез, зыялыларыбыз чыгыш ясады. Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев Изге Болгар җыенына килгән кунакларны бәйрәм белән котлап: «Бу көнне милләтне берләштерү көне дип карасак та ярыйдыр. Елдан-ел безгә кунаклар ешрак килсен. Телне онытмыйк,

динне онытмыйк»,—дип мөрәҗәгать итте. Аннары Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров сүз алды: «Динчеләребез өчен генә түгел, барлык язучыларыбыз, зыялыларыбыз өчен дә бу җир изге, милләтебезнең рухын саклый торган урын. Һәр елны бирегә килик, хәтеребезне яңартыйк, яшьләребез монда күбрәк килеп, тарихыбызны аңласа, милләтебезнең бердәмлеге өчен зур көч булачак»,—диде ул.

Мөфти Тәлгат хәзрәт Таҗетдин үз чыгышында өммәттәшләребезне бердәмлеккә өндәде: «Безнең җаннарыбыз Аллаһның рәхмәтенә омтыла. Әмма ана ирешү өчен бөтенебез бердәм булып, килешеп яшәү мәслихәт»,—диде Тәлгат хәзрәт.

«Адәм баласына һәрвакыт таяну ноктасы кирәк. Без бирегә менә шул таяну ноктасын эзләп килгән халык. Без җаннарыбызны, кыйблаларыбызны турылар өчен киләк». Әлеге сүзләрне күренекле әдип, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Туфан Миңнуллин әйтте.

Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Разил Вәлиевнең чыгышы да гаять гыйбрәтле иде: «Россия Дәүләт Думасы дин һәм дини оешмалар турында закон кабул итте,—диде ул.—Кызганыч, анда барлык диннәр дә, тигез, дигән тәгълимат үз көченда түгел, кайбер диннәргә генә өстенлек бирелә.»

Мөфти Госман хәзрәт Исхакый исә ике ай элгәре Президент Минтимер Шәймиев белән бергәләп Сүриягә, Согыд Гарәбстанына, Кувәйткә барып кайтулары, анда кече хаҗ— гомрә хаҗы кылулары турында сөйләде.

Җыенда шулай ук Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин һәм Роберт Миңнуллин чыгыш ясады. Алар Болгарга багышланган шигырьләрен укыдылар.

Болгар җирендә мондый җыен инде унсигезенче мәртәбә уздырылды.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Июнь ахырында Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Ике идарә утырышы арасында башкарылган эшләр буенча И. Ибраһимов, В. Имамов, Д. Салихов хисаплары тыңланды. Утырышта ТР Язучылар берлеге һәм Лаеш муниципаль районы хакимияте тарафыннан бирелә торган Г. Державин исемендәге әдәби премия лауреатларын билгеләү мәсьәләсе каралды. Фикер алышулардан соң 2006 ел өчен Державин исемендәге әдәби бүләкне «Сквозняк тишины» (2005) китабы өчен Салават Юзеевка һәм «Слеза на лице» (2004) китабы өчен Владимир Лавришкога бирергә дигән карар кабул ителде.

Идарә утырышында «Татнефть» акционерлар җәмгыяте тарафыннан гамәлгә куелган С. Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнүче студентлар өчен стипендияләр бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу нәтиҗәсендә кандидатлар күрсәтелде.

Кабул итү Коллегиясе тәкъдиме буенча Наилә Миңнеханова (Туймазы), Илдар Хәйруллин (Түбән Кама), Ринат Архипов (Ринат Мәннан) Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

## КАЛӘМДӘШЕБЕЗ УҢЫШЫ

Язучы Әхәт Мушинскийның татар һәм рус телләрендә басылган «Әнәс-ананас һәм башкалар» («Мәгариф» нәшрияты) дигән китабы хикәя-повесть жанрында 2005-2006 елгы сезонда, конкурста җиңеп, Россиянең «Күңел түрендәге хыял» Милли балалар әдәби бүләгенә лаек булды.

Конкурста Россия, Бөекбритания, Дания, Нидерланд, Израиль, Италия, АКШ, Канада һәм башка илләрдән 3600 язучы катнашты. Татарстаннан бу әдәби конкурска 24 автор үзенең әсәрләрен юллаган иде.

Җиңүчеләрне Милли әдәби конкурсның жюри рәисе, танылган балалар язучысы Эдуард Успенский бүләкләде. Әхәт Мушинский Мәскәүдән малахит нигезгә куелган китап—канатлы күбәләк сыны (авторы—танылган скульптор В. Руковишников), лауреат танылыгы һәм конкурс финалына чыгучыларның әсәрләре тупланган махсус альманахның үзенә аталган нөсхәсен алып кайтты. Лауреатка шулай ук акчалата бүләк тә тапшырылды.

## ОЛУГ ШӘХЕСНЕ ЯДЬ ИТҮ

16 июнь көнне Казанның Кави Нәҗми урамындагы 24/20 нче йорт янында татар зыялылары, әдип, шагыйрь, журналистлар, сәхнә осталары, киң җәмәгатьчелек вәкилләре җыйналды. Бу йортта 1931-37 елларда милләтпәрвәр шәхес—язучы, тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе Гомәр Гали яшәгән. Нахакка гаепләнеп, кулга алына һәм Сталин лагерьларында 54 яшендә гаип була. Һәм менә, ниһаять, ничәмә-ничә дистә ел үткәч, әдип торган йорт диварына истәлек тактасы куелды. Бронзадан коелган затлы ядкәрне сынчы һәм рәссам Мәхмүт Гасыймов иҗат иткән.

Гомәр Билал улы Галиев (Гомәр Гали) Буа районының Иске Тинчәле авылында туып-үскән. Ул – 1932-34 елларда Татарстан Язучылар берлеген оештыруда башлап йөргән зат буларак та тарихка кереп калган шәхес. Аның исеме шулай ук «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш мөхәррире, «Яңалиф», «Атака» һәм «Совет әдәбияты» журналларының редколлегия әгъзасы, Татарстан китап нәшриятынең баш мөхәррире буларак та яхшы таныш. Гомәр Гали, тәнкыйтьче буларак, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Х. Туфан,

Ф. Кәрим һ. б. әдипләр иҗаты турында иң беренчеләрдән булып матбугатта җитди сүз әйткән, аның җәмгысе 15 китабы, йөзләрчә мәкаләсе дөнья күргән.

Урау юллар узып, якты иселе илгә кайткан әдипкә истәлек тактасы ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, язучы Рабит Батулла, Гомәр Галиненең кызлары Гүзәл һәм Алсу ханым, туганнары Марс Алиев, Мөбарәк Мусин һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

### ГАЛИЯ КАЙБИЦКАЯ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Кайбыч районы тарихында истә калырлык рухи бер бәйрәм булып узды—Татарстанның беренче халык артисты, күренекле җырчы Галия Кайбицкаяның 100 еллыгы республика күләмендәге чара буларак билгеләп үтелде.

Бу тантанада Премьер министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева Кайбыч халкын һәм кунакларны шушы зур вакыйга уңаеннан тәбрикләде.

Бәйрәмдә Кайбыч муниципаль районы башлыгы Ж. Гаффаров, Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев һәм Р. Миңнуллин, шагыйрьләр Ш. Җиһангирова, Р. Зәйдулла һәм Ф. Яхин, күренекле җырчыбыз, Г. Тукай бүләге иясе Ф. Кудашева, Татарстанның халык артистлары З. Сәхабиева һәм Л. Әхмәтова, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары, театрның директоры Ш. Закиров, «Кайбыч» якташлык җәмгыяте рәисе, профессор Р. Гарәфетдинов, Татар дәүләт гуманитар-педогогика университеты профессоры Ф. Галимуллин һ. б. катнашты.

Кайбычта узган тантанага Галия Кайбицкаяның балалары—уллары Сәяр Айдаров һәм Ирек Әүхәдиев, кызы Рушания Ожегова, оныгы Ильяс Айдаров та кайткан иде.

Мәшһүр композитор С. Садыйкованың иҗтимагый фонды рәисе Ә. Хөсәенов Г. Кайбицкаяның Кайбычтагы музее директоры Ә. Закировага Камил Мотыйгыйның озак еллар архивта сакланган тавышын—җыр язмасын тапшырды. Татарның беренче газета-журналларын чыгарган, Г. Тукай белән якыннан аралашкан Камил Мотыйгыйның тавышы, димәк, аның сеңлесе Г. Кайбицкая музеенда да сакланачак.

### ШАГЫЙРЬЛӘР—КОМПЬЮТЕРДА

Тукай, Җәлил һәм башка күренекле әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юллары белән компьютерны белгән һәркем таныша ала хәзер. Татарстан Милли китапханәсенең электрон китапханәсе күренекле шагыйрьләрнең библиографик белешмәләре белән тулыланды. Анда шагыйрьләрнең биографияләре, рус, татар һәм инглиз телләрендә аеруча танылган әсәрләре, аларның тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәкаләләре, 1995-2005 нче елларда дөнья күргән китаплары турында белешмәләр урын алган.

### РӘССАМ ИҖАТЫ—ЯКТАШЛАРЫ ХОЗУРЫНА

Шәмәрдәндә туып-үскән, хәзер Лениногорск каласында яшәүче Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мөдәррис Минһаҗевнның Байлар Сабасының мәдәният йортында шәхси күргәзмәсе булды. Күргәзмәгә рәссамның 100дән артык әсәре куелган иде. Сабада тәүге тапкыр оештырылган күргәзмәне Сабада яшәп иҗат итүче язучы-публицист Тәлгат Нәҗмиев ачты һәм алып барды. Мөдәррис Минһаҗевнның татар рухы белән сугарылган иҗатына рәссамнар Зөфәр Гыймаев, Эрот Зарипов, әдипләр Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Резеда Вәлиева, Җәүдәт Дәрзаман, профессорлар Азат Әхмәдуллин, Николай Нарышкин һәм башкалар олы бәя бирде.

Саба муниципаль районы башлыгы Рәис Миңнеханов мөхтәрәм якташыбызга күптән түгел рәсмиләштерелгән һәм алтыннан коелган районыбыз гербын—күкрәк билгесен бүләк итте.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы халкына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә керткән лаеклы өлеше өчен «Татарстан» журналының бүлек мөдире **Мостафин Рафаэль Әхмәт улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

* * *

2006 елның 16 июнендә язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Гарипов Рәшит Гариф улы** вафат булды.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан. Кремль панорамасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Нурулла Гариф**.

# Яңа китаплар



**Матбугат йорты—гомер китабы: Истәлек-хатирәләр.**—Казан: Мәгариф, 2006.—271 б. Тиражы—1000 данә.

Матбугат йорты—татар мәдәниятенә һәм әдәбиятына хезмәт иткән берничә буынның язмышы белән бәйле Олуг Йорт ул. Данлы-шанлы вакыйгаларны, фаҗигале-аянычлы хәлләрне күп кичергән бина. Физик яктан искергән, тузган булса да, күңелләрдә мәңге яшь иҗат учагы булып калган бинаның бай тарихын «ташка басып калдыру максатында әзерләнгән бу китапка байтак журналист-язучыларның, нәшрият матбугат хезмәткәрләренең язмалары, истәлекле фоторәсемнәре тупланган.

Китапның проект авторы—Мөдәррис Вәлиев, редактор-координаторы Люция Гыйззәтуллина.

Татар әдәбиятын, мәдәниятен хөрмәт иткән һәр кеше өчен кыйммәтле басма булган бу китапны әзерләүдә, шулай ук, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының татар филологиясе факультетында «Нәшрият эше» белгечлеген үзләштергән чыгарылыш курс студентлары да катнашкан.




Рафаэль Мустафин. **Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана.** —Казан: Тат. кит. нәшр., 2006. —351 б. Тиражы—2000 данә.

Күренекле язучы-публицист, тәнкыйтьче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Рафаэль Мостафинның яңа китабының аннотациясендә мондый юллар бар: «Бу китапта Колгалидән башлап Равил Фәйзуллинга кадәрге чорда иҗат иткән күренекле татар язучыларының әдәби портретлары бирелгән». Чыннан да, берничә дистә шәхесләр арасында Мөхәммәдьяр, Каюм Насыйри, Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Шамил Госманов, Хәсән Туфан, Салих Баттал, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Илдар Юзеев кебек исемнәрне очратырга була.

Соңгы дәвердә татар әдәбияты, аның тарихы белән рус телендә язылган чыганаклар аша кызыксынучы даирә киңәя төште. Татар әдәбиятын пропагандалауда кызыклы һәм кирәкле басма саналырга лаек бу китап.

Китапның редакторы—А. Алишева, рәссамы—И. Шәмсетдинов.



Нурулла Гариф

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)